
ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2008





**Галиәсгар Камал**
**(1879–1933)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2008

12
(1034)

***ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:***
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

***НАШИРЕ:***
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гәрәй РӘХИМ. Сәгать тавышы—гомер агышы. *Шигырьләр* ..... 5
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Кош булып очар идем... *Роман* ..... 10
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Агымсуга башын игән тал мин. *Робагыйлар* ..... 60
Әхәт ГАФФАР. Кәфенгә кесә текмиләр. *Хикәя* ..... 65
Рушания АРСЛАНОВА. Моңнар бүләк итәм... *Шигырьләр* ..... 78
Илсөяр ИКСАНОВА. Җиткән кыз. *Хикәя* ..... 81
Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ. Күңел кыллары чыңлый... *Шигырьләр* ..... 87

**ХӘТЕР**

Нурихан ФӘТТАХ. Беренче шигырь күк балачак... *Истәлекләр* ..... 89
Роберт МИҢНУЛЛИН. Шагыйрь булулары җиңел түгел. *Бер хатирә.* ..... 103
Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре ..... 141
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр* ..... 168

**ТАРИХ**

Булат СОЛТАНБӘКОВ. Татарлар һәм Игнатьев ..... 121

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Тәфкил ВАФИН. Мәкруһлар ..... 113
Рәфикъ ЮНЫС. Карабыбыз батып барганда ..... 133

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Ак күңел һәммәбезгә кирәк ..... 150

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Габделмәннан Рахманколый (тууына—150, үлеменә—100 ел) ..... 157
Камил КӘРИМОВ. Комиссар әдип урамы. (Ш. Усмановның тууына 110 ел)... 158

Гүзәл ГАБДУЛЛИНА. Сәхнәгә җан кертте (Драматург Х. Вахитнең тууына 80 ел) ..... 160

**ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН**

Дифгат СИРАЙ. Ватан төсе. *Шигырьләр* ..... 163

**УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ**

Фрунзе ФАЗУЛАЙ. Күренекле милләттәшләремә. ..... 165

"Татар энциклопедиясе" битләреннән ..... 154
2009 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр ..... 167
"Казан утлары" архивыннан ..... 178
2008 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге ..... 181
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Р. МУХАМАДИЕВА "Взлететь бы птицей..." (продолжение); рассказы А. ГАФФАРА "На саван карман не пришивают" и И. ИКСАНОВОЙ "Взрослая дочь"; стихи Г. РАХИМА, Г. МУХАМЕТШИНА, Р. АРСЛАНОВОЙ, Г. ШАМСУТДИНОВА, Д. СИРАЯ.
"Память": Н. ФАТТАХ. "Детство — как первый стих", А. РАШИТ. "У каждого своя судьба", Р. МИҢНУЛЛИН. "Не легко быть поэтом" — воспоминания; Г. БАШИРОВ. "Дневниковые записи" (продолжение).
"Публицистика": Т. ВАФИН. "Отпавшие" (продолжение); Р. ЮНУС. "Решается судьба народа".
"История": Б. СУЛТАНБЕКОВ. "Татары и Игнатьев".
"Книжное обозрение": рецензия Р. ШАРАФИЕВА на книгу В. НУРИЕВА "Седьмая палата".
Страницы из "Татарской энциклопедии"
В номере отмечается 150-летие Г. РАХМАНКУЛЫЙ, 110-летие Ш. УСМАНОВА, 80-летие Х. ВАХИТА.
Из фотоархива журнала.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2008 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Зимний пейзаж"; писательница Рамзия ГАБДУЛХАКОВА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel by R.MUHAMADIEV "I'd fly up as a bird..." (continuation); stories by A. GAFFAR "Do not sew a pocket an a shroud" and I.IKSANOVA "Adult daughter"; verses by G. RAHIM, G. MUHAMETSHIN, R. ARSLANOVA, G. SHAMSUTDINOV, D. SIRAY.
"Memory": N. FATTAH. "Childhood as the first verse", A. RASHIT. "Everyone has his destiny ", R. MINNULIN. "It isn't easy to be a poet" – memoirs; G. BASHIROV. "Diary notes" (continuation).
"Publicism": T. VAFIN. "Disappeared" (continuation); R. YUNUS. "Destiny of people is decided".
"History": B. SULTANBEKOV. "Tatars and Ignatyev".
"Book review": review by R. SHARAFIEV on book by V.NURIEV "Seventh chamber".
Pages from "Tatar encyclopedia"
In this issue is celebrated 110th anniversary of SH.USMANOV,
80th anniversary of H. VAHIT.
From photo-archive of magazine "Kazan utlary".
Bibliographic list of works published in 2008.
Diary of social-cultural life.
On our covers: "Winter approach"; writer Ramzia Gabdulhakova.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.11.2008, график буенча 20.11.2008.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т-1580 Тираж 4788.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Гәрәй
Рәхим

# СӘГАТЬ ТАВЫШЫ—ГОМЕР АГЫШЫ

## Татар гимны

**Татар җыелган җирдә**
**Бәйрәмсез булмый бер дә.**
**Ике татар—бер базар,**
**Базарда телләр язар.**

**Җәйнең матур көнендә**
**Илнең бөтен җирендә**
**Җыелышып татарлар**
**Сабан туе ясарлар.**

**Анда да бергә-бергә,**
**Монда да бергә-бергә,**
**Кайда да бергә-бергә—**
**Татар бергә гомергә.**

**Татар җыелган җирдә**
**Мәзәксез булмый бер дә,**
**Дәмәксез булмый бер дә,**
**Бәйрәмсез булмый бер дә**
**Татар боекмый бер дә...**

**...Ул бары тик моңлана,**
**Шул моңы—ГИМН аңа.**

Гәрәй РӘХИМ (1941)—*шагыйрь, прозаик, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Фәндәс аланы

*Без, бер төркем татар әдипләре һәм җәмәгать эшлеклеләре (Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев, Фәндәс Сафиуллин, Марсель Галиев, Наил Камбеев, мин һәм башкалар), ел саен диярлек, июль аенда Иделнең борынгы эзе эргәсендәге һәм Казан каласы читендәге Аккош күленнән ерак булмаган матур бер аланда мәҗлес корып гәпләшеп утырабыз. Бу алан татар халкының күренекле сәясәтчесе һәм җәмәгать эшлеклесе Фәндәс Сафиуллинның җәйге йорты янәшәсендә генә. Шуңа күрә без аңа "Фәндәс аланы " дип исем куштык.*

**Сәйран кылдык Фәндәс аланында...**
**Мең елларга суздык хыялны.**
**Тарихыбыз буйлап бер сәяхәт**
**Диеп булыр иде бу ялны!..**

**Эзен салган монда ханнарыбыз,**
**Чирәменә ятып ял иткән...**
**Шул ук үләннәргә чалкан төшеп**
**Уйга талучылар без икән...**

**Уйдык-уйдык күлләр...**
**Чал Иделнең**
**Борынгы бер юлы бу, диләр –**
**Каспиена туп-турыдан чапкан,**
**Яшь булган шул Идел, и, юләр!..**

**...Шушы иске, изге бер урында**
**Җәйрәп ята Фәндәс аланы...**
**Җәйләр җитсә күңел җирси башлый –**
**Сагынабыз шушы яланны!..**

**Аннан күмәк монда җыелабыз**
**Мең елларга сузып хыялны...**
**Тарихыбыз буйлап бер сәяхәт**
**Диеп булыр иде бу ялны!..**

## Таллар турында алты дүртьюллык

*Узган җәйдә мин беркемгә дә хәбәр итмичә туган авылым Федотовкага кайтып, әти-әнием каберләрен зыярәт кылдым. Бу дүртьюллыклар шунда язылды.*

### *1. Авылга кайткач*

**Кайттыңмы, диеп, каршы алдылар**
**Күптән картаеп корыган таллар...**
**Минем яшьлеккә, дәртле чорыма**
**Бердәнбер шаһит бары тик алар...**

### *2. Хәтер*

Елый–елый күзләрем талды—
Яшь гомеркәем бик ерак калды...
Сагынам хәзер бердәнбер ярны—
Капка төбендә үскән яшь талны...

### *3. Яшьтәш тал*

Дибез: "Көн саен барабыз алга!.."
Карыйм да елыйм картайган талга...
Нишлим... Шул яшьтәш талга ияреп
Китеп барырмын мәңгелек ялга...

### *4. Яшьлектәге нечкәбилгә*

Талдин нечкә билләреңә
Ни булды инде, ярым?!.
Кочаклыйм дим, буем җитми—
Билең өч колач ярым...

### *5. ... Юлда бер уйланып алу*

Гәрәй Рәхим югалган дип,
Сөйлиләрдер Казанда.
Минем бүгенге хәлемне
Аңлый алмас таллар да.

### *6. Федотовка зиратында*

Кабер өстендә пышылдап тора
Шыбыр да шыбыр карт Федот талы:
"Шушында, улым, шушы "нигездә"
Әткәң–әнкәңнең мәңгелек ялы".

## Кайтып... китәрбез

Бер ямьсез сүз бар татарда:
"Илгә кайтып ... китәрбез...".
Мондый сүзне әйткән өчен
Барыбыз да исәр без.

Кайтасың да...
Китәсең шул
Илеңнән... Авылыңнан...
Чыгармасын иде заман
Бу сүзне авызыңнан.

Кайт та—китмә син илеңнән!
Кендек бавың шушында.
Беркемгә дә калдырма син
Нигезеңнең ташын да.

"Кайтам да, китәм",—дигән уй
Һич кермәсен башыңа!..
Кайт та—китмә!..
Кал биредә!..
Кал син монда, илеңдә,
Кендек каның тамып калган
Изге туган җиреңдә!..

## Марсель Галиевкә

Иң талантлы, иң сәләтле,
Иң популяр, иң бөек—
Кабатланмас бер шәхес ул... –
Рөстәм Мингалим кебек.

## Берәүгә

Кызганыч ки, син—мин түгел,
Бәхетемдер, мин—син түгел.

## Бер каләмдәшкә

Ниһаять, укып чыктым бит
Китабыңның ярымын.
Тулаем укый алмадым—
Укый-укый арыдым.

## Шәрә шар

*Ренат Хариска ияребрәк*

Шар нинди була дисеңме?
Шар була шәрә генә!
Тик шәрә булганга шулай
Шар оста тәгәри дә.

Әгәр шарны киендерсәң,
Кидерсәң тун, эшләпә,
Итекләр кидереп куйсаң,
Тоттырсаң зонтик-фәлән—

Шар—шарлыктан туктар иде,
Тәгәри алмас иде.
Һәм гомумән, киендерсәң
Шар һич шар булмас иде.

Шарның бөтен батырлыгы
Шар була белүендә.
Бөтен дөнья күз алдында
Шәп-шәрә йөрүендә.

# Сәгать тавышы

*"Ә сәгать "келт-келт " итә ".*
Рөстәм Мингалим

*"Иске сәгать дөрес йөри".*
Разил Вәлиев

**"Келт" тә "келт" итеп, миңа төннәрен**
**Хәбәрен сала сәгать тавышы.**
**Бигрәк тә моңлы, шомлы хәбәр бу—**
**Сәгать тавышы—гомер агышы.**

**Төндә уянып тыңлап ятканда**
**"Келт" тә "келт" иткән сәгать тавышын—**
**Күз алларыңнан кичерәсең син**
**Илләр язмышын, ирләр язмышын.**

**Сәгать тавышын ишетә алсаң,**
**Син әле җирдә яшисең, димәк!**
**Чорлар, заманнар, тарих күгендә**
**Бер яшен булып яшьнисең, димәк!**

**"Келт" тә "келт" иткән сәгать тавышы...**
**Илаһи көчкә ия тавыш бу!**
**Бу—мәңгелеккә орынып үтү,**
**Күкләрнең үзе белән кавышу!..**

**Сәгать тавышын тыңлап ятам мин,**
**Дөньяга килгән кебек мәңгегә...**
**...Тик гомер җебем өзелеп китәр**
**Аның "келт" иткән җирендә генә...**

**...Аның "келт" иткән җирендә генә...**
**Ә бу мизгелне беләсе килә.**
**"Гомерем күпме?.."—диеп сорасам:**
**"Келт" тә "келт" дия, "көт тә көт..."—дия.**

♣

Ринат
Мөхәммәдиев

# КОШ БУЛЫП ОЧАР ИДЕМ...

РОМАН

## 8

Яна Актауга летчик-истребитель кайткан, дигән хәбәр көне-сәгате белән үк әйләнә-тирә авылларны, бөтен районны инләп таралды. Декабрьнең чатнама суык көнендә, колакчыннарын төшерү кая инде ул, бүрекне чит-чите бөдрәләнеп торган куе кара чәчләре өстенә кыңгыр салып, ыспай гына шыгыр-шыгыр күн итектән узып баручы калку гәүдәле, һәрчак мөлаем көлемсерәп торган чем-кара күзле, ачык йөзле һәм тулы иренле бу лейтенантны күргәч тә буй җиткән кызлар барыр юлларын, ашыгыч эшләрен онытып, бер мәл телсез-өнсез калып торалар иде. Өлкән абзыйлар аның белән очрашканда, тукталып, ике куллап күрешә. Һәм шундук, лейтенант ниндидер бер мәзәк хәл сөйләп өлгерәме үзләренә, дәррәү көлешеп алалар. Ат чанасына салам төяп фермага таба узып баручы агайлар атларын туктатып йөк өстеннән шуып төшә аны очратканда. Аркасыннан үз итеп бер кагу өчен генә чиләк-көянтә күтәргән апалар тукталып уза. Ә малайлар, авыл малайлары исә, летчик-истребитель кибеткә барамы, клубкамы, аның артыннан өерләре белән калмый ияреп йөриләр. Аларның яшьтәше Ринат исә, ияреп түгел, абыйсы белән гел янәшә атлап йөри инде хәзер. Аңа нәрсә, дингез тубыктан дигәндәй, летчик абыйсына ошатып бүрек колакчыннарын күтәртеп куйды ул, изүләрен ача төште. Бүрегенең маңгаена йолдыз борып куйган, бишмәт якасына да летчикларда гына була торган самолет рәсеме төшерелгән тимер калай элләктергән. Аяк киеме, киез итек булгангадыр инде, абыйсыныкы кебек шыгырдамый шыгырдавын, әмма ул да килештереп дәү-дәү атлап йөрергә өйрәнде инде. Бөтен яшьтәшләре сокланып һәм көнләшеп карыйлар иде аңарга, йолдызлы бүреген дә кидертеп караса—шундук иң якын дуска әвереләләр. Моңарчы Ринатны санга да сукмый йөргән өлкәнрәк класс малайлары да хәзер аның белән дуслашырга тырыша башлады.

—Абыең саймалуты белән кайтырмы икән малай? Әйт әле, икенче кайтканда саймалутын да алып кайтсын,—диеп теңкәсенә тиеп беттеләр.

—Кайтмаска, кайта кәнишне,—дип, бик белгән атлы сөйләшеп җибәрә иде ул.—Бу юлы да саймалуты белән кайтасы булган, бакчада кар тирән бит, шуңарга гына кире уйлаган. Авылга кайтып карга батып ята алмый бит инде ул...

Килештеләр малайлар.

—Икенче юлы, алданрак әйтерсең, бакчагызда бер бөртек кар калдырмый көрәп куярбыз,—дип ышандырдылар.

---

*Дәвамы. Башы узган санда.*

Бәйрәм өстенә бәйрәм дигәндәй, нәкъ шул көннәрдә авылга кино килде. Соңгы ярты ел эчендә генә дә икенче тапкыр килүе иде инде киноның, беренчесе моннан ике ай чамасы элегрәк булгандыр. Анысының белдерүенә: "Кина пра любовь", дип язганнар иде, монысы "Кина пра войну..." икән. "Про любовь"ка мәктәп балаларын кертмәделәр, анда бер тапкыр үбешкәннәр икән—ярамый. Моны тәрәзәгә каплаган пәрдә ярыгыннан карап торган малайлар исләре китеп сөйләгән иде. Ә " про войну"га кертәләр икән. Шуңа Рафаэль абыйсы Тамара белән Ринатны да алып барды кинога. Кесәсеннән шытырдап торган кәгазь акча чыгарып түләде летчик абыйлары алар өчен. Бер уч тутырып тимер акча кайтарып бирделәр үзенә.

Шул ягы яман, кино дигәннәре русча икән. Ә авылда русчаны җүнлебашлы белгән кеше юк. Шуңа инде "пра любовь" ны авыл клубының алгы рәтенә үк чыгып басып русчаны яхшы ук сукалаган Хыбрай агай тәрҗемә итеп торган. Бу юлы да клуб халык белән шыгрым булып тулды. Әмма киноны башларга ашыкмадылар, Хыбрай агайның килгәнен көттеләр. Летчик-истребитель булып кайткан Рафаэль дә белгәндер инде ул русчаны, ләкин аны вак-төяк сорау белән йөдәтергә кыймады берәү дә. Хыбрай агайны малайлар "урра" кычкырып, өлкәннәр дәррәү кул чабып, алкышлар белән каршы алды.

Хыбрай агай да шәһәрдә укыган кеше, ул сугышка кадәр үк Уфада тракторчылар курсын бетергән. Әмма сугышта снаряд кыйпылчыгы тиеп, аның бер як яңак сөяген алып киткән. Шуңа ул көч-хәл белән авызын кыегайтып-кыегайтып тәрҗемә итә иде русчадан. Шаян малайлар, соңрак," русча сөйләшәбез" диеп, бер-берләрен уздыра-уздыра авызларын кыегайтып, Хыбрай агайга охшатып сөйли торган булып китте.

Киноның тагы шул ягы бик әйбәт икән, фашистлар гел кыек ата. Ә Совет солдатлары бер пуля белән ике-өч фрицны сузып кына сала. Шуңа безнекеләр фашистларны җиңгән саен "урра" кычкыра-кычкыра карадылар киноны. Хыбрай агай гына, нигәдер, башкаларга кушылып "урра" кычкырмады. Малайлар рәхәтләнде бигрәк тә, безнекеләр атакага барган чакта урыннарыннан сикереп торып бүрекләрен түшәмгә чөя-чөя куандылар, алгырак рәтләрдә утырганнары исә экранны алыштырган ак җәймә каршына чыгып мәтәлчек ата-ата куышып уйнадылар.

Кинодан кайтуга аларны әниләре бәлеш пешереп көтеп торган. Әтиләре Миргалим абый да торып балалары янына утырды. Сугыш вакытында ягылмаган баракларда яшәү, икешәр смена танк заводында эшләү үзенекен иткән, аның сәламәтлеге тәмам беткән иде инде. Шулай да ничә еллар күрешмәгән олы улы Рафаэльнең укып, летчик-истребитель булып кайту шатлыгыннан үзен тернәкләнеп киткәндәй хис итә башлаган иде ул.

Балалардан яшереп кенә әти белән улы, бәлеш астына дип, берәр тустаган әче бал да эчеп куйдылар. Тел ачкычлары китерде соңгысы. Алар таңга кадәр диярлек дөнья хәлләрен, үз башларыннан кичкәннәрне сөйләшеп, уртаклашып утырдылар. Кечкенә Ринат исә, йоклаганга сабышып, чаршау артында аларны тыңлап ятты. Миргалим абый сорашты күбрәк. Рафаэль сөйләде. Ул да туган авылдан чыгып киткәннән соң шактый күпне күргән, күпне кичергән булып чыкты. Үзенең Румыниядә сугыш вакыйгаларында катнашуы, андагы җирле халыкның Совет солдатларына булган нәфрәте хакында сөйләгәндә, ни өчендер, берничә мәртәбә пышылдауга күчте хәтта. Соңрак, ниндидер "Мыеклы" хакында сөйләшкәндә, ата белән ул җинелчә бәхәсләшеп тә алдылар кебек.

—Күпме халыкны урынсызга рәнҗетте. Сөргенгә җибәрде, утыртты,— дип, канәгатьсезлек белдереп сөйләде Миргалим абый.—Барысына да шул

"мыеклы" гына гаепле.

Рафаэльнең дә килешми хәле юк иде, әмма ул, үзләре "мыеклы" дип искә алган әлеге кешене яклабрак сөйләшкән кебек тоелды.

—Җину өчен ул үз-үзен кызганмый эшләде. Кимчелекләре дә булгандыр, әтием, әмма ул Ватан өчен тырыша. Гаепне анардан гына эзләмик. Бер үзе бит ул, барысына да ничек өлгерсен.

Әти кеше озак кына дәшми торды шунда, әллә хәле авырайган идеме, буылып-буылып йөткеренеп алды.

—Инде, улым Рафаэль, үзебезгә якынрак нәрсәләр хакында да киңәшләшеп алыйк,—дип, үзе башлады тагы сүзне.—Әниең белән сине искә алмаган көнебез юктыр. Уңышларың өчен куанабыз анысы. Борчылган чакларыбыз да аз түгел...

—Нигә, минем сезгә борчу китерәсем килми,әткәй,—дип, бүлдерде аны Рафаэль.—Минем яраткан һөнәрем бар. Тамагым ач, өстем ялангач түгел, минем өчен борчылмагыз хәзер. Үзегезгә дә кулдан килгәнчә ярдәм итә башлармын, бәлки.

—Әй, улым,—дип, тагы буыла-буыла йөткереп алды Миргалим абый.

Шунда, күрәсең, ата белән улның әңгәмәсенә ул да колак салган булса кирәк, әнисе кушылып алды аларның сүзенә:

—Ана күңеле—балада, бала күңеле—далада, дигәннәре дөрес икән шул, улым. Сез, кош балалары кебек, үсеп җитмәс борын бер-бер артлы чыгасыз да очасыз, чыгасыз да очасыз. Яңгыр явып торган көзге көнне пычрак ерып чыгып киткәнең әле дә күз алдымда. Менә кайтыр, менә кайтыр дип җиде ел көттем. Көн туса, хатларыңны көттек, урамнан бер-бер кеше узса, почта китермәгәннәрме дип, йөгереп барып тәрәзәгә каплана торган идем. Ә инде ул Румыния дигән җирдән хатларың да килми башлагач, ниләр генә уйлап бетермәдек...

—Хатларны чыгармадылар шул, әни.

—Ә без бит берни дә белмәдек. Кара кайгыга баттык.

—Менә, кайттым бит, әнкәй, зарланырга сәбәп юк.

—Югын юк та, санаулы көннәр бик тиз уза шул ул, тагы чыгып китәм дип торасың бит әнә. Нур белән Рим дә өйдә түгел...

—Аның каравы, Тамара сеңел үсеп җиткән. Ринат та менә дигән егеткә охшап килә...

—Алар да шул, улым, кайчан буйга җитеп, кайчан кай тарафларга чыгып киту турында гына хыялланып үсә. Картайган көнебездә авылда ялгызыбыз калырбыз димәгән идек бер дә.

—Калмассыз, әнкәй, борчылма,—дип, урыныннан торып, җылы мич каршында тагы ниләрдер пешерү белән мәш килгән әнисенең аркасыннан сыйпап килде Рафаэль.—Борчылмагыз, боерган булса, барысы да яхшы булыр, менә күрерсез.

Күңеле нечкәрдеме, Хафаза апа алъяпкыч итәге белән күз төпләрен сөртергә кереште.

—Ярар инде, житәр, монда балавыз сыгып утыра торган чак түгел. Сезгә әйтәм...—дип, урындыгын олы улына табарак күчереп куйды Миргалим абзый.—Сиңа тагы шуны әйтәсем килгән иде, улым, яшең бара, башлы-күзле булу турында да уйлый башларга вакыттыр бит инде.

Рафаэль аңламаганга сабышып яисә сүзне бүтәнгә күчерергә уйлап маташмады. Өлкәннәр соравына олыларча җавап эзләде:

—Рәхмәт әти, вакыт икәнен үзем дә беләм. Әмма...—дип, уйга калып, сүз таба алмыйчарак төртелеп калды ул бер тынга.—Моңарчы ара булмады, инде чара юк дип әйтимме соң... Өйләнү, гаилә кору житди эш бит, кем очраса, шуңа өйләнеп булмый.

—Шулай улым,—дип, куанып һәм хуплап кабул итте ул улының бу сүзләрен.—Дөрес әйтәсең, теләсә кемгә өйләнү ярамый. Бар теләгәнебез шул, үз кешебез, игелекле кеше баласы булсын иде инде, улым.

—Әйе, үзем дә шулай уйлыйм,—диде ул. Башка сүз әйтмәде.

Әтисе анарга текәлеп карап торды бертын. Ул аның, улына сынап карап торуы булган икән. Һәм ипле генә сүзен дәвам итте.

—Авылга көн дә кайтып тора алмассың. Әллә, улым, үзебезнең авыл тирәсеннән, йә булмаса якын-тирәдән бер-бер кызны димләп карыйргамы икән, дим...

Рафаэль утырган җирендә сискәнеп куйды.

—Юк, әти, мин Совет армиясе офицеры. Димләү дигән сүзне оныт. Мин бары тик үзем яраткан һәм үземне яраткан кызга гына өйләнәчәкмен.

—Бик яхшы. Бик әйбәт булыр иде дә бит, улым. Отпускаң тагы җидесигез көне калып бара. Кай арада үзең дә яратып, үзеңне дә яраттырып өлгерерсең икән соң...

—Бер читенә ут капмаган. Бер очрамаса, икенче очрар, кызлар үсә тора,—дип, бар дөньясы белән балкып елмаеп куйды ул шунда.—Әйдә әти, бүтән күңеллерәк нәрсәләр хакында сөйләшүгә күчик әле.

—Тагы нәрсә сөйләшәсең инде,—диде Миргалим абзый, көрсенеп.— Безнең кояш түбәнгә тәгәри инде хәзер. Офыкка да ерак калмагандыр...

—Юк, әти, бу хакта сөйләшмибез. Гөрләтеп яшибез әле бергә-бергә,—диде Рафаэль, күкрәгеннән ташып торган дәрт белән уртаклашасы килеп.

—Боерган булса, диген, улым.

—Әйе, Алла боерса, яшибез, яшисең әле, әти. Син зарланма гына, авыру турында уйлама. Әнкәй сине үзе җыйган шифалы үләннәр һәм урман җиләкләре белән аякка бастыра әле, менә күр дә тор.

—Ярар, яшәмәдек түгел, яшәдек, язганы булыр, улым.

—Авыл ничек, авыл хәлләрен сөйлә әле,—дип, берочтан сүзне дә башкага борырга теләп, сорап куйды егет әтисеннән.

—Авылны искә алма инде улым. Авылны искә алсак, тагы зарланырга, сукрана башларга туры килә.

—Зарланмыйча сөйлә, әти. Барысы да ул тикле начар түгелдер бит инде.

—Зарланмыйм дисәң дә зарланырга туры килә шул. Авыл хакында, авылда яшәгән кеше хакында уйлаучы юк инде ул хәзер. Сугышка киткәннәрнең яртысыннан күбесе кире әйләнеп кайтмады. Кайтканнары да берсе аяксыз, икенчесе кулсыз дигәндәй, сәламәт ир-ат табу авыр бүген авылда. Бөтен эш, бар михнәт хатын-кыз һәм тол хатыннар җилкәсендә. Башта колхоз төзибез дип таладылар халыкны. Сугыш вакытында Җиңү хакына дип ачлы-туклы яшәдек, Җиңү өчен дип тырыштык барыбыз да. Инде сугыш та бетте, Җиңү дә килде. Ә яшәргә бирмиләр халыкка. Кая карама дошман эзлиләр, бер сәбәпсезгә кулга алалар, себергә озаталар. Кеше милке дип тормыйлар, ишегалдыңа кереп берданбер бозавыңны, соңгы казыңны да алып чыгып китәләр ич. Иккән игенең үзеңнеке булмасын, үстергән мал-туарыңа үзең хуҗа булма—кая бара бу дөнья, кайчанга кадәр һәм күпме түбәнсетергә мөмкин шул әлеге дә баягы бер авыл кешесен?! Исемен искә алмыйм дисәң дә дәшми калып булмый, шул "Мыеклы" дан килә бар яманлык. Бетерәләр улым авылны, бетерәләр. Авыл белән бергә халык та, ил дә бетүгә бармыймы?.. Мылтык һәм тукмак белән куркытып, төрмә-сөргеннәр белән бәхетле итеп булмый шул туган илне.

Менә нәрсәләр борчый мине, улым. Без китәбез инде, безнең җыр җырланган. Ә сезнең бит әле яшиселәрегез бар, балакайлар...

—Зарлансаң зарланырлык нәрсәләр бар инде ул, әткәй,—дип көрсенеп

алды Рафаэль.—Әмма Совет иленә дә җинел түгел ич. Һәр тарафтан дошман урап алган үзен. Империалистлар карап кына тора. Безгә йомшаклык күрсәтергә ярамый, эти. Әйдә, бүгенгә җитәр, башкача зарланмыйбыз, ярыймы, әткәй...

Өстәл артыннан таң беленә башлаганда гына кузгалып китте алар. Әтисе чаршау артындагы йомшак түшәгенә барып ятты. Рафаэль ишегалдына чыгып анда торып керде озак кына. Әти-әнисен, туганнарын гына түгел, туган авылын, аның урамнарын, әйләнә-тирәдәге урман-кырларын, кыскасы, мондагы бар нәрсәне, монда калган бала чакларына кадәр сагынып кайткан иде шул ул. Бергә уйнап үскән дуслары—Нурулла белән Фәрвазны очратырга өметләнеп кайткан иде, бер класста, бер мәктәптә укыган авылдаш егет һәм кызларны... Ник берсен очратсын икән. Нибарысы җиде ел вакыт узган югыйсә, ә шул арада җирнең асты өскә килгән диярсең. Егетләрнең күпчелеге сугыш кырларында ятып калган. Кайтканнары да төрлесе төрле якларга таралган.

Ишегалдындагы каралты-кура һәм бар нәрсәне, хәтта утын сарае янында торган зур тумранга кадәр, беренче кат күргән кебек, озак-озак карап, күзәтеп чыкты ул тагы бер кабат. Акрын гына искән җилдә шаулашып утырган каеннарга карап сокланып торды башта. Лапас кыегыннан мәче мыегыдай берөзлексез очып торган кар тузанын сокланып күзәтте. Күктәге йолдызларга текәлеп торды озак кына. Кайчандыр, сабый чакларында, шул зәңгәр күккә карап төн йокыларын оныткан чаклары була иде бит аның. Шул хыяллары тормышка ашты. Йә, ничек кыюлыгы җитеп, бәхетсез саный алсын иде икән ул үзен. Максатына иреште—ул очучы-истребитель хәзер. Туган авылыннан иске биштәр асып чыгып киткән гади бер малай, лейтенант погоннары тагып, очучы-истребитель булып кайтып керсен дә, үз-үзеннән канәгать булмасын, имеш, кем ышана алсын шуңа. Бәхетме бу?!. Бәхет, әлбәттә.

Әтисенең тирән борчу белән әйтелгән сүзләрен һич онытырлык түгел иде. Шуларны сөйләгәндә аның тирән җыерчыклар баскан йөзендә күпме аяныч һәм нинди тирән кичерешләр булуын да күреп торды ләбаса ул. Нигә бу дөнья шул кадәрле дә камил түгел икән. Гомер буе балалар укытып, аларны туган илләрен яратырга, сөяргә өйрәткән әтисен үз улына шундый сүзләр сөйләргә нәрсә мәҗбүр иткән?.. Аңлый алмый газапланды ул. Күпме генә тырышса да, бу сорауны уратып, каплап торган куе томанны үзе өчен генә булса да тарата алмады. Туган авылның табигате, әйләнә-тирәсе аның бала чакларындагы кебек үк матур иде бит югыйсә. Бу кышкы төн дә әкияткә тиң серле бер тынлык белән өретелгән. Ә барыбер җанда тынычлык юк. Күңелнең бер почмагына ниндидер канәгатьсезлек кереп оялаган. Ул ачык форточкадан ялгышып өй эченә очып кергән, әмма чыгу юлын таба алмыйча берөзлексез тәрәзәгә килеп бәрелгән бал корты сыман бәргәләнә иде җанда. Куып та җибәрәм димә, качып та булмый үзеннән.

## 9

Санаулы көннәр бигрәкләр дә тиз узып китә. Ничә еллар дәвамына сагынып һәм зарыгып көтеп алган отпускаsucc соңгы көннәре килеп җитте. Аның бит әле Уфада тукталып, андагы туган-тумачаларны күреп, Әсма апасы белән Мәсгут җизнәләрендә бер кич булса да кунып китәсе бар.

Әле һаман бригадир булып эшләвен дәвам иткән Фәрсәй карт колхозның карап торган иң әйбәт айгырын җигеп аны озатырга килде.

—Үзең борчылып йөрмәсәң дә ярар иде инде, Фәрсәй агай, бер-бер яшь җилкенчәк кенә җибәрәсең булган,—диде, улын капка төбенә озатып чыккан Миргалим абзый.

—Юк, Миргалим туган, синең өчен ул малайларыңның берсе булса, Рафаэль—авыр сугыш елларында минем иң ышанычлы, бөтен авырлыкларны җигелеп тарткан колхозчым да иде бит әле. Шундый егетне чатнама кышкы суыкта башка берәүгә ышанып ерак юлга чыгарып җибәрәммe соң! Ул бит хәзер безнең Яңа Актауның горурлыгы, тагы кайсы районда, кайсы авылда бар икән шундый әфисәр һәм лүтчик-эстребител. Районда эшләрем дә бар, үзем озатып барам...

Чана башына кочагы белән йомшак печән түшәлгән. Утырып баручыга җылы, йомшак булсын өчен монысы һәм берочтан атның ашарына да, әлбәттә. Печән өстенә зур толып салынган. Фәрсәй агайның үз өстендә дә җылы тун, аягында олтанлы киез итек.

Чанага тагы ике юл капчыгы чыгарып урнаштырдылар. Боларның берсе Рафаэльнеке булса, икенчесендә Әсма апаларына һәм Уфадагы башка туганнарга атап җибәрелгән күчтәнәчләр.

—Улым, өстең юка, аягыңа киез итек кияргә иде бит. Әллә алып чыгыйкмы,—дип хафаланды әнисе.

—Әйе, улым, тимер юл станциясенә кадәр генә булса да киез итек киеп бар. Суык аяктан тия ул, әниең дөрес әйтә. Үзеңә кирәкмәсә, Фәрсәй агайга салып җибәрерсең аннан,—дип, үгетләп карады әтисе дә.

Әмма Рафаэль кырт кисте.

—Кеше әллә нәрсә дияр, офицер кешегә килешми алай йөрү! Туңсам, чанадан төшеп ат артыннан йөгерермен. Минем өчен борчылмагыз.

—Асма апаңа, Мәсгут җизнәңә бездән сәлам әйт. Зәүҗан апаң белән Усман абыйларыңны да күрергә тырыш,—дип, киңәш итте Миргалим абзый. Уфадагы башка туганнарны да санап чыкты берочтан.

—Хатларыңны язып тор, улым,—диде әнисе, улының аркасыннан кагып. Әмма бу юлы инде яулык очы белән күз читләрен капламады.

—Миңа да язарга онытма, яме абый. Икенче кайтканда тагы йолдыз алып кайт, ярыймы,—дип, энесе Ринат та зур йомыш кушты.

Уфа вокзалына поезд белән килеп төшкәч тә, ике юл капчыгын ике иңсәсенә салып, халык телендә Затон дип йөртелгән поселокка юл тотты Рафаэль. Затон Агыйделнең аръягында урнашкан. Елга аша ул заманнарда күпер салынмаган иде әле. Яз һәм көз вакытлары түгел, юлның туры чагы—боз өстеннән генә элдертте ул. Декабрнең 30нчы көне, Агыйделдә бозның иң ныклы чагы. Ара-тирә күренгән машиналарның үз эзе бар, атлыларның үз юлы, җәяүленең—үз сукмагы. Җәяүлеләр сукмагы киң һәм иркен. Өйлә вакыты булгангамы, халык арлы-бирле йөреп кенә тора. Ара-тирә яшь кызлар да очраштыра. Кем-кем, әмма кызлар матур икән бу Уфада. Шунысы гына кыен, аларга текәлеп караулары оялдыра. Узып киткәч, чыркылдашып борылып карап калулары тагын...Үзе дә борылмый түзә алмаган булыр иде дә бит, җилкәдәге капчыклар ирек бирми.

Көне дә матур, күбәләк кар явып тора иплe генә. Декабрь суыгы колакларны чеметеп-чеметеп алса да, түзәрлек. Җәт-җәт барган көйгә уч төбенә җылы сулыш өреп, кызлар күрмәгәндә, колакларны уып җибәрәсең—берни түгел, туңу кая инде ул, ут булып кызыша башлыйлар әле хәтта.

Бер тапкыр да туктамыйча барып житте ул Әсма апаларына. Өйләрен табу авыр булмады. Затонның үзәк урамында, яңа салынган мәктәп каршында гына яши иде алар. Икесе дә шул мәктәптә укытучы булып эшли. Бүген исә, көтеп алган кунак хөрмәтенә, эштән иртәрәк кайтканнар, мич торбаларыннан төтен чыгып тора. Мәсгут җизнәсе капка төбендә кар көрәү белән мәшгуль иде. Аны танымады бугай башта, үзләренә таба борылгач кына, көрәген читкә куеп колачларын җәеп каршы атлады.

—Рафаэль, кайнеш, син түгелме соң бу! Ерактан ук күрдем, югыйсә, танымадым. Танымадым, димәк, бай булырсың,—дип, кочаклап алды ул аны.

Ул да түгел, онга буялган кулын алъяпкычы читенә сөртә-сөртә, өйдән Әсма апасы атылып килеп чыкты.

—Җанашым, Рафаэль, сине күрер көнем дә булыр икән. Киттең дә югалдың. Бөтенләй оныттың бугай безне... Кил әле, кил әле, үзеңне кысып бер кочаклыйм әле...

Капка төбендә шау-гөр килеп кочаклашып, күрешеп алгач, инде өчәүләшеп өйгә кереп китәбез дип торганда урам яктан ягымлы һәм йомшак тавыш ишетелде:

—Исәнмесез, Әсма Миргалимовна.

—Ә-ә, Лена, күрми дә торам, син икәнсең, исәнме. Бертуган энем кайтты бит менә.

—Мәсгут абый белән мәктәптә күрешкән идек инде. Сау булыгыз,—диде дә, ялт кына мәктәпкә таба борылып, яшь болан баласыдай уйнаклап, җиңел адымнар белән йөгерә-атлый китеп тә барды.

Болытлар арасыннан ялт итеп кояш чыгып алды да шундук кереп тә югалгандай булды Рафаэль өчен. Инсәләренә салып килгән ике капчыкның берсе, үч иткәндәй, шуып китеп кар көртенә барып төште шунда. Башы әйләнеп киткәндәй булды. Үзе чигенә-чигенә хуҗаларга ияреп өйгә керә, ә күзләре мәктәп ишегалдына кереп югалган кызны эзли. Ни булды бу—өнендәме, әллә төш кенә булдымы... Ярый әле, аның бу халәтен Әсма апасы белән җизнәсе абайламый калган кебек булды. Әллә абайлап та сер генә бирмәделәрме...

Кызган таба исләре килеп торган өйгә килеп кергәч тә Рафаэльнең беренче соравы шул булды:

—Кем иде ул, апа?

—Кемне сорыйсың,—дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды апасы. Әллә шаяртуы иде, әллә чынлап та аңламады.

—Теге, капка төбендә синең белән исәнләшеп, мәктәпкә кереп йөгергән кызны әйтәм.

—Ә, аны сорыйсың икән... Лена исемле кыз ул. Безнең мәктәптә укыта.

Нигә сорыйсың аны, димәде. Җавап бирде һәм, әйтерсең, ул хакта шундук онытты да. Әсма апасын Рафаэль яхшы белә—акыллы һәм сабыр ул. Кирәк чакта хәйләкәр дә була белә. Игътибар итмәде түгел, игътибар итте, әлбәттә, һәм мыегына чорнап куйды, әмма сер бирмәде.

Чираттагы сорауларын бирергә дип ачкан авызын йомарга мәҗбүр булды Рафаэль. Бар сабырлыгын җыеп ул хакта башкача сүз кузгатмады. Ипле генә өстен-башын чишенде, ишек катындагы урындыкка утырып күн итекләрен салды. Шунда гына ул юлда килгәндә аяклары шактый ук туңганлыкны аңлады. Кышкы итек саналса да, авылда басылган киез итек түгел инде.

—Өегез жылы икән,—булды, сүз югында сүз булсын—исәнме, кодагый, дигәндәй әйткән беренче сүзе.

Ул арада өстәлгә кайнап торган самавыр менеп кунаклады. Көтеп алынган кунакны түргә утырттылар. Апа белән җизни бер-берсен уздырып кыстарга керештеләр. Кысташкан арада сорау арты сорау да яудыра тордылар. Рафаэль ни җавап биргәнен дә хәтерләми, уе башкада иде шул. Әледән-әле урам як тәрәзәгә таба борылып, теге кыз күренмәсме диеп, үрелеп-үрелеп мәктәп ягын күзәтеп ала иде ул.

Әсма апасының әллә үртәве иде инде, Рафаэльнең урам якка каравы була, ул һаман бер үк сүзләрне кабатлый:

—Синең киләсеңне туганнарга хәбәр иткән идем. Күренмиләр шул әле...

Туганнарын да сагынган иде сагынуын, әмма аның энесе башканы эзли, тагы бер тапкыр гына, тәрәзә аша гына булса да, теге укытучы кызны күреп каласы килә иде бит. Ләкин ул хакта янадан сүз кузгатырга кыймады.

Озак көттермәделәр, ишектә буран уйнатып, Зәуҗан апасы белән Усман җизнәләре килеп җитте. Үзләре белән Роза исемле биш-алты яшь чамасындагы кызларын да ияртеп килгәннәр. Өс-башын салып өлгердеме-юкмы ул кыз, Әсма апа белән Мәсгут җизнинең Айрат һәм Рамил исемле малайлары белән дөнья бетереп уйнарга керештеләр. Ул да түгел, абыстасын унга салып, Бәкер абзыйлары күренде тәрәзәдән.

Өстәлгә тәмле хуш исләре белән инде байтактан тамак төбен кытыклап торган бәлеш килде, ниһаять. Сагынып көтеп алынган энеләре һәм якынлашкан Яңа ел хөрмәтенә шампан шәрабе ачылды. Өй шау-гөр килеп торды. Рафаэльгә төрле яктан сорау арты сорау яудыра башладылар. Соңгы җиде елда башыннан кичкәннәрне менә ничәнче кат янабаштан сөйләп чыгарга мәҗбүр иде ул. Совет иленең авиациясе, яңа самолетлар хакында да сораштылар. Ир-ат халкы ул самолетларның техник күрсәткечләре һәм башка нечкәлекләре белән кызыксына башласа, ул, гадәтенчә офтана төшеп, әмма үзенә күрә бер горурлык белән: " Боларын әйтә алмыйм. Хәрби сер", дип котылды.

Билгеле инде, сүз иярә сүз чыгып, аңарга өйләнергә вакыт икәнлеген дә искәртергә онытмадылар. Шундук бергәләшеп Рафаэльгә кәләш эзләшергә керештеләр.

—Иртәгәсен таң белән поездга утырасым бар. Үзем югында мине өйләндереп тә куя күрмәгез тагы,—дип, шаяру белән генә җавап кайтарды ул аларга.

Шунда түр өстәл өстендә утырган ике рәтле гармунын алып килде Мәсгут җизнәсе. Һәм, идән ярыгына кереп качмаганнармы дигәндәй, бер-бер артлы басып гармунның бакаларын барлап чыкты.

—Рафаэльгә кәләш эзлибез эзләвен дә туенда нинди җыр җырларбыз икән соң?—диде ул, уен-көлке белән сүзне җырга таба борып. Җавап биргәннәрен көтеп тормады, өздереп уйнап та җибәрде. Һәм үзе үк тын гына җыр башлады:

Аклы ситса күлмәгемнең
Якаларын кем уйган;
Әй, Рәйхан, исемең матур—кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган...

Мәсгут җизни ни уйнарга икәнлекне белә иде күрәсең, икенче-өченче сүзләреннән үк ул башлаган җырны иң элек Асма апа күтәреп алды. Аннан инде башка кунаклар, шул җөмләдән, Рафаэль дә кушылып китте җырга. Җаңга ятышлы, моңлы җыр иде шул "Рәйхан", аны берәү башласа, читтә калып битараф кына тыңлап утыра алмыйсың инде. Ул җыр, аның күңелгә сары май булып ягыла торган сүзләре һәм халыкчан моңы, ирексездән, үзенә ияртеп алып китә, җырлый беләсәңме-юкмы—җырчы итә сине.

Аклы ситса күлмәгемнең
Табалмадым ишләрен...

Безнең татар, башкорт халыклары моңнан яралгандыр ул. Гомер-гомергә шулай, бергә чәй өстәле артында җыелыштымы—җыр башлап

җибәрә. Көндәлек тормышта әйтә алмаган хис-тойгыларын, йөрәк түрендә саклап йөреткән ихлас сүзләрен, кайгы-хәсрәтләрен һәм хәтта кайчандыр тыелып калган күз яшьләрен дә ул шул җыр аша дөньяга чыгара. Җырлый беләме-юкмы, сүзләрен беләме-юкмы, һәркем кушыла ул җырга. Башкалар җырлаганда, авызын чүмеч итеп, су капкандай тик утырмый берәү дә. Табын җыры ул, үзенә күрә, рухи бергәлекне раслау, туган-тумача һәм кардәшләрнең тугрылыкта анты да булса кирәк. Бик ерак борын-борын заманнардан ук дәвам итеп килгән милли йола да...

Менә шуңа да кеше җырлаганда сөйләшмиләр, көлмиләр бездә. Тавышың тегеләй-болай дип, җырның көен бозасың дип тә гаеп итү юк. Җырның ертыгы юк, дигән халык. Ашау-эчү онытылып тора. Хәтта дөньяның астын өскә китереп уйнап йөргән сабый балалар да, җыр башланса, сабырлана төшеп, тынып кала торган иделәр әүвәл заманнарда. Күрше бүлмә ишегеннән яисә чаршау артыннан башларын тыгып, "минем әти-әни җырлый", диядия бер горурлык белән күзәтәләр иде шул чакларда. Тәрбия—шуннан башлана. Чөнки табын әйләнәсендә исерек әти-әни булмый торган иде, сүгенүләр хакында әйтеп тә торасы юк. Халык җырларыннан инсафлылык, иман нуры бөркелеп тора.

Җыр арты җыр бер-беренә үрелеп бара. Кайчан кайсы җыр буласын, һәм ул җырны кем башлап җибәрәсен алдан ук килештереп куйганнар диярсең. Филармония һәм театрларың бер читтә торсын. Яңгыраган һәр яңа җыр таң чыгыдай чиста һәм саф мәхәббәт хисләре белән өретелгән. Ник бер җайсыз сүз, ник бер әдәпсезлеккә ишарә тоемланып китсен икән... Бернинди цензура һәм ясалма киртәләр булмаган ләбаса. Күңелләрне буын-буыннардан дәвам итеп килгән әхлак, рухи хәзинә һәм әдәплелек нуры балкытып торган анық каравы. Шулар өстенә тагы, әлбәттә, югары зәвык...

Күмәк җыр тынып торган арада Зәүҗан апалары, рухланып китеп, сүз башлады:

—Рәхмәт, Мәсгут кияү, туйганчы бер җырлаттың ичмаса. Ләкин, шулай да күңел булмады әле. Әсма туганым белән бергәләп "Асылъяр"ны да җырлап куйсагыз, дөнья тәмам түгәрәкләнеп китәр иде.

—Дөнья болай да түгәрәк ич ул. Ышанмасаң, әнә, Әсмабикә-сылуым ахирәттән сора, ул география укыта,—дип елмайды Мәсгут, иңбашындагы гармун каешын рәтләгән арада.

—Җырлагыз инде, ялындырмагыз. Рафаэль хөрмәтенә генә булса да?..

Җырларгамы-юкмы дигәндәй, Рафаэльгә күз төшереп алды җизнәсе. Карашлары очрашкач та, җыр-моң бишегендә онытылып изрәп утырган егет, хуплап баш какты.

—Җырлагыз, җизни, минем дә ишетәсем килә.

Шунда, кухня ягыннан кереп килгән Әсма апа, ике уйлап тормастан, туп-туры үзенең ире янәшәсенә килеп басты:

—Ялындырып утыра торган чак түгел, этисе. Әйдә булмаса, алай бик сорагач, җырлап җибәрәбезме соң әллә?.. Сагынып сөйләрлек булсын бер.

Шул тикле дә матур һәм бирелеп җырлыйлар иде ки алар, ул җырга башка берәүнең, шулчак бик җырлыйсы килсә дә, килеп кушылуы мөмкин түгел иде. Тавышлары шушы җырны парлап җырлау өчен махсус яратылган иде диярсең. Бер-берен рухландырып, күңелләрендәге хис-тойгылар белән тулыландырып җырлый иде алар бу җырны. Икесе дә озынча туры гәүдәле, бераз бөдрәләнеп торган чем-кара чәчләре һәм күз карашлары да бер үк. Җырның билгеле бер урынында, йөрәкләрне өтеп ала торган иң нечкә җирендә, нибары бер мизгел эчендә күзләре очрашып китә иде аларның.

һәм шулчак икесе дә елмая төшә, шул елмаюдан бер юлы балкып китәләр. Шул кадәр дә бер-беренә тиң, бер-беренә хөрмәтле һәм пар килгән гаилә булыр икән! Жыр тәмамлангач та табын артында аларны тынлап утырган туган-тумача бертын сүз башларга кыймый онытылып торды. "Асылъяр", әйтерсең лә, алар парлап жырласын өчен генә махсус язылган жыр.

Жыр тәмамланды. Мондый жырдан соң жинел генә башкага күчү мөмкин түгел. Беренче мәхәббәт һәм олы хисләрдән соң, чарасызланып, бушап калган үсмер халәтендә тоясың үзеңне. Өй эче генә түгел, гүя, бар дөнья тынып калды. Ул тынлыкны бүлеп сүз кузгату мөмкин түгел иде шул мизгелдә. Жыр дулкыныннан бераз арына төшкәч, Әсма апа үзе башлады сүзне, кунакларын сыйларга кереште.

—Тамак кайгысы онытылды бит әле, Әсма балдыз. Мондый жырдан соң урамга чыгып берне көйрәтеп керми торып, тынычланып булмас ахрысы, шулаймы егетләр,—дип, урыныннан торды Усман абзый.

Тәмәке белән дуслыклары бармы-юкмы, һәммә ир-ат анарга иярде. Капка төбенә чыгып ирләрчә сөйләшеп, бер аралашып керү мондый мәҗлесләрнең үзенә күрә бер йоласы инде ул.

—Башкорт туганнар әйтмешли, "көнне һындырган ахыры",—дип, шаяртып алды Мәсгут жизни.

—Шампан да эч, бәлеш тә аша—сындырмас жиреннән сындырыр,—дип жавап кайтарды Усман абзый.

—Шампанский түгел, шайтанскийны эчсә дә сынатмый әле ул минем Усман абый,—дип сүз кыстырды Бәкер.

"Шайтанский" дигәне кызык булып китте ахыры, дәррәү көлешеп алдылар.

Усман жизнәләре кесәсеннән "Прибой" чыгарып кунакларына тәкъдим итте.

—Рәхмәт жизни, әллә минекен тартабызмы,—дип, Рафаэль "Беломор канал" чыгарды.

—Әйдәгез, булмаса, Беломор с каналом тартып карыйк. Министрлар һәм летчиклар юкка гына тартмыйлардыр аны...,—диде Бәкер, Рафаэльгә таба кулын сузып.

Затлы папиросны озак кына бармак очларында әвәләп, килештереп кенә көйрәтеп жибәрделәр бер-бер артлы.

Мәсгут жизнәсе Рафаэльгә мөрәҗәгать итте шунда:

—Туган якларны сагынгансыңдыр, кайнеш, бер киттең дә бик озакка югалдың бит?

—"Сагынасыңмы дип сорыйсыз, сагынмаган кая ул",- дип, теленә килгән жыр сүзләре белән жавап кайтарды Рафаэль, елмая төшеп.—Сагынсаң да түзәргә туры килә инде.

—Өйләнергә уйламыйсыңмы әле? Вакыт бит инде...

Уф, тагы шул ук сорау. Әмма туганнарга кирле-морлы жавап кайтарып булмый. Яманлык теләп яисә үртәп сораулары түгел бит, кайгыртудан кызыксыналар.

—Беләм, жизни. Әмма кемгә эләкте, шуңарга өйләнеп булмый бит.

Нәкъ шул чакны, аркасына жылы пәлтәсен салып, ашыга-кабалана өйдән Әсма апасы килеп чыкты.

—Минем карчык ул кадәр ашыгып кая китеп бара икән...—дип, ипле генә сүз кыстырды Мәсгут жизнәсе.

—Мәктәпкә кереп күренеп кенә булса да чыгыйм дигән идем. Чыршы бәйрәме ич. Мин хәзер, сез тарткан арада йөгереп керәм дә, йөгереп чыгып та житәм.

Болай да бертуктаусыз мәктәп ишегалдын күзәтүдән туктамаган

Рафаэльнең дә апасына ияреәсе килеп куйды.

—Мине дә үзеңә иярт әле, апа...

—Соң, мин бер минутка гына, күренеп кенә чыгыйм дип керүем.

—Ә мин кеше күзенә дә күренмәм,—дип, малай чакларындагыча, апасы артыннан иярде ул.

—Соң, әйдә алайса, безнең эш урынын күреп чыгарсың.

Мәктәп ишегалды бала-чага белән тулы. Берәүләре керә, икенчеләре кайтырга чыккан. Өченчеләре исә, дөньяларын онытып, ап-ак карга батып чыр-чу уйнап йөриләр. Әсма апасын барысы да таный, малайлар, суык диеп тормый, аның белән бүрекләрен салып исәнләшә. Башлангыч класста укучылар үзләренең әби-бабалары белән килгән бәйрәмгә.

Инде мәктәп бусагасын атлап керергә торганда, нindидер якын танышларын очратып, Әсма апа чираттагы мәртәбә тукталырга мәҗбүр булды. Апасына ияреп килүче буларак, Рафаэльнең дә тукталмый чарасы юк. Тукталып күрешкән һәр кеше, хәл-әхвәл сорашкач та, бу ят хәрби кешенең кем булуы белән кызыксына. Тәмам йөдәтеп бетерделәр. Ул Әсма апасының чираттагы танышы—өлкән яшьтәге фронтовик белән күрешеп, сәлам алмашып тора иде, көтмәгәндә-уйламаганда мәктәп ишегеннән, әлеге дә баягы, теге кыз килеп чыкмасынмы! Бер мизгелгә карашлары очрашты аларның, әмма шундук икесе дә читкә борылдылар, сер бирү кая инде ул. Рафаэльнең башы әйләнеп киткәндәй булды, оялу һәм уңайсызланудан үз-үзен кая куярга белми торды бертын. Укытучы кыз үзе кебек үк бер яшьтәше белән иде, анысы да укытучы булса кирәк, Әсма апа белән бик җылы хушлаштылар.

—Сау булыгыз, Әсма Миргалимовна,—диделәр бертавыштан.

—Сау бул, Елена Рәхимовна...Сау бул, Сәрия Мөдәрисовна...

Алар тукталып тормады, мавыгып сөйләшә-сөйләшә кызу-кызу атлап урам ягына таба китеп тә бардылар. Әллә Рафаэль булганга махсус ашыктылар инде...

Рафаэльнең күрешергә дип сузган кулын, җибәрмичә, үч иткәндәй озак кына кысып торды теге фронтовик. Үзенең кайсы армиядә, нинди шәһәрләрне азат итүдә катнашуын сөйләп китте аннан соң. Фронтовик дусларын хәтерләргә керешге...Уңга да тартылып карады егет, сулга да, әмма ташлап китә алмады абзыйны. Апасының якын танышларын үпкәләтүдән курыкты. Алардан аерылганда инде вакыт узган иде, ник кычкырып еламыйсың шунда. Әрсезлек күрсәтеп, Әсма апага ияргүдән, шул рәвешле, уңай нәтиҗә килеп чыкмады.

—Әйдә, Рафаэль, мәктәпкә керәм дигән идең...

—Ярар инде, апа, мин кереп тормам. Син бар, мин урамда булырмын,—диде ул, балтасы суга төшкән кешедәй чарасыз калып.

Әсма апасы артыннан мәктәп ишеге ябылгач та, йөгереп диярлек, урамга атылып чыкты ул. Кызлар шактый ук ераклашкан иде инде. Ялгышып та кире борылып карамады алар, ашыга-ашыга Уфага таба китеп бардылар. Үз-үзен кая куярга һәм ни эшләргә белми бертын онытылып торгач, әле дә булса капка төбендә гапләшеп торган җизнәләренә барып кушылудан башка чарасы калмаган иде аның.

## 10

Куйбышевтан ерак түгел Кинель исемле шәһәр бар. Шул шәһәр янәшәсендәге ачык далада урнашкан иде аларның авиакорпусы. Әле сугыштан соң гына формалашкан часть иде бу. Шуңа күрә әллә ни уңайлыклары юк, бар нәрсә төзелеш һәм корылу этабында гына. Офицерлар һәммәсе вакытлыча корылган барак тибындагы тулай торакларда яши.

Гаиләлеләр Кинельдә фатирга кереп, көн дә кайтып-килеп йөрергә мәжбүр. Рафаэль исә, үзе кебек үк авиаполкка әле яңа гына килеп кушылган ике очучы белән, тулай торакның бер бүлмәсенә урнашкан иде.

Лейтенант Смаков әле монда яңа кеше. Шуңа да карамастан, тиз дуслашучан һәм аралашучан, һәрчак ачык йөзле бу очучы хәрбиләр арасында үзен яраттырып өлгергән иде инде. Аның ялдан кайту хәбәрен ишетүгә эскадрилия тулы составында диярлек җыелып килде . Юл капчыгын чишеп анда булган барлык ризыкны өстәлгә чыгарып тезде Рафаэль. Каклаган каз, тутырган тавык, әнисе пешереп тыккан пәрәмәчләр, кош теле, бавырсак һәм, билгеле инде, башкорт балы. Керосинканы кабызып чәй кайнатырга куйдылар...

—Егетләр, күрегез инде, яшәп тә күрсәтә икән бу башкорт байлары,—дип, гадәтенчә, шаян сүз кыстырды өлкән лейтенант Зайцев.

—Юк, егетләр, авылларда хәлләр алай ук мактанырлык түгел әлегә,—дип, ачыклык кертергә ашыкты Рафаэль.—Авыл сугыштан яраланып кайткан солдатлар хәлендә—берсе кулсыз, берсе аяксыз дигәндәй. Шулай да халык тырыш инде ул безнең якларда.

—Безнең Оренбург якларында да шул ук хәл, кая карама җимереклек,—дип, өстәп куйды, Рафаэль белән бер үк вакытта отпускада булып кайткан лейтенант Балченков.—Авылда тормыш җиңел түгел...

—Егетләр, очучы-истребительләрме без, юкмы... Безгә зарлану килешми,—дип, төшенкелеккә урын калдырмаслык итеп, күтәреп алды шунда эскадрилия командиры Биязович.—Йә, лейтенант Смаков, тәмтомнарны чыгардың, самогонын кая соң?..

—Мин гаепле, иптәш майор, анысы юк миндә. Безнең татар авылларында самогон куарга өйрәнмәгәннәр шул әлегә.

—Самогон миндә бар. Әйдәгез, Оренбург осталары житештергән эчемлектән авыз итеп карыйк,—дип, җәт кенә, үзенең кием шкафыннан газета кисәге белән бөкеләнгән бер шешә тартып чыгарды Балченков. Һәм яхшы ук шапылдатып аны өстәл уртасына китереп куйды.

Авиаполкта аракы эчү бик сирәк күренеш иде, әлбәттә. Шулай да ир-ат булган җирдә, юк-юк дигәндә дә, гел ансыз гына булмагандыр. Бәйрәм көннәрендә, туган көннәрдә, чамасын белеп кенә булса да эчү бар иде инде ул.

Үткен пәке чыгарып каклаган казны турарга кереште Рафаэль. Вак-вак итеп кенә, тел очына салгач та эреп китәрдәй итеп турады ул аны. Тутырган тавыкны да ботарлап өеп куйды. Ә самогонны, бер-берләрен Яңа 1953 нче ел белән котлашып, кырлы стаканнан, сугыш елларында кабул ителгән гадәт белән, чиратлап эчтеләр.

—Лейтенант Балченков, ай-һай зәһәр икән сезнең Оренбург чишмәләрендәге су,—дип, шаяртып алды кырлы стаканнан беренче булып уртлап куйган майор Биязович.

—Первач, иптәш майор. Арыш янына дала үләннәре дә кушылган,—дип, горурланып алды, мактау сүзләреннән күңеле булган лейтенант.

—Ә бу нәрсә, казмы, әллә колбасамы,—дип хәйран калды авызына бер кисәк каклаган каз телеме салган майор.—Кырыкка житеп, шундый затлы кабымлык күргәнем юк иде әле.

Үз чиратларын үткәреп кырлы стакан читеннән бер йотып алган һәр очучы күчтәнәч каз итенең шундый тәмле булуына исләре китеп тордылар. Самогонын кем күбрәк йоткандыр, кем азрак, кырлы стакан өстәлне өч мәртәбә әйләнеп чыкты дигәндә ярты литрлы шешә бушап калды. Унлап ир-ат өчен, аз да түгел, күп тә түгел, ярап кына куйды. Әмма, каклаган каз һәм тутырган тавыктан берәве дә баш тартмады, аларны хәзерләп җибәргән

кеше—Рафаэльнең әнисенә—уңнан да, сулдан да рәхмәт сүзләре кабатланып кына торды.

Утны сүндереп яткач та күзләренә йокы кермәде Рафаэльнен. Туган яклары, әти-әнисе, туганнары торды күз алдында. Һәм, барысыннан да бигрәк, әлеге дә баягы, теге, Затондагы мәктәп каршында ике тапкыр күзгә чалынып киткән кызны онытa алмый азаплана иде ул. Поездда килгәндә дә юл буенча шул кызны уйлады, менә хәзер тагы—нигә шул тикле дә йөрәгенә уелып калды соң әле ул. Югыйсә, үзара ләм-мим сүз алмашмадылар, хәтта танышмадылар да. Болытлар арасыннан нибарысы бер мизгелдә ялт итеп күренеп калган кояш нурларыдай күзгә чалынды да, юк та булды. Аның йөзен дә ачык кына хәтерләп кала алмаган иде бит ул хәтта. Ә менә күз карашлары, елмаюы, вак-вак атлап уйнаклап китеп барулары һәм Әсма апасы белән күрешкәндәге тавышлары—барысы да күз алдында, колак төбендә. Менә хәзер дә аның тавышы ишетелгән кебек. Әле хәзер генә, әнә, ул мәктәп ишегалдына ашыгып кереп бара кебек. Нигә һаман да күз алдыннан китми, нигә һаман да оныта алмый изалана соң әле ул аны...

Хәрби хәзерлек мәшәкатьләре һәм даими очулар башланып киткәч тә дәвам итте бу хәл. Көндезләрен баш борыр аралары да булмый, сугыш вакытындагыдан бер дә ким түгел иде киеренкелек. Көн узганы да сизелми кала. Тулай торакка, арып-талып, караңгы төшкәндә генә кайтып керәсең. Ә шулай да, урын өстенә яттың исә, күзгә йокы керми йөдәтә. Туган авыл түгел, үзенең матурлыгы белән аны сокландырган Уфа каласы да түгел, әлеге дә баягы шул, Агыйделнең аръягында урнашкан Затон поселогы, Әсма апасы эшли торган мәктәп ишегалды һәм Лена атлы укытучы кыз килеп баса күз алдына. Ни эшләргә дә белгән хәл юк...

Башка егетләр, әнә, ике көннең берендә кызлардан хат алалар. Үзләре дә утырып хат язалар. Кызларының фоторәсемнәрен күрсәтеп, "кемнеке матуррак..." дия-дия, үзара мактанышалар, бәхәсләшәләр. Бер түгел, өчәр кыз белән хат алышучылар да бар иде алар арасында. Бүген берсенең фоторәсемен кочаклап йоклап китсә, икенче көнне икенчесенә сокланып утыра. Яшь чак, егет чаклары бит, ни эшләсәләр дә гаеп итеп булмый.

Рафаэльнең дә түземлеге бетте, ниһаять. Кәгазь һәм каләм алып ул да хат язарга утырды көннәрнең берендә. Шунысы кызганыч, кызның өй адресын, торган җирен белми икән бит әле ул. "Елена Рахимовна" дип дәшкәннәрен хәтерли хәтерләвен, әмма фамилиясен белми. Исеме дә сәер тагы. Татар кызы ничек Лена, ягъни Елена булсын икән?.. Керәшен кызы дияр идең, әтисенең исеме Рәхим булгач, алай да түгел. Хәер, Башкортостан татарлары исем сайлаганда бик исләре китеп тормый. Рафаэль дә, төпченә башласаң, татар исеме түгел ләбаса. Аның бертуган сеңлесенә, әнә, Тамара дип исем кушкан әти-әнисе. Ә инде Света, Альбина һәм Ларисалар белән дөнья тулган. Бу—безнең халыкның бер чире инде үзенә күрә, балаларына чит халыкларның исемен кушып, Советлар системасына ярарга тырыша, алдынгы карашлы интернационалист була янәсе. Ә бәлки татарлыгыннан качуыдыр. Ни булса булыр, чиста ак кәгазьнең башына: "Исәнме, Елена!" дип язып куйды ул.

"Сезгә бу хатны алу берникадәр гаҗәп булыр. Бер күреп сөйләшмәгән кешедән хат килеп төшкәч, гаҗәпләнмәс җиреңнән гаҗәпләнерсең... Хәтерлисез микән, 1952нче елның 31декабрендә Затондагы мәктәп каршысында сезне күреп калган Рафаэль Смаков мин. Игътибар иткән булсагыз, хәрби киемдә идем.

Сезне күрү белән минем күңелемдә танышу, сөйләшеп аңлашу теләге кабынды. Әмма хисләремне сезгә җиткерер ара булмады ул көнне, бер иптәш кызыгыз белән бик ашыгып каядыр китеп бардыгыз. Ярар, үткән эшкә

салават диләр, үткәнне искә алып, баш ватып утырып булмый инде.

Әмма минем бик тә беләсем килә, сезнең йөрәгегездә минем шушы хат кисәгемә җавап бирерлек бер-бер очкын табылырмы. Шуны аңласагыз икән, минем йөрәк ул көнне сезгә ияреп китеп барган, үземдә аның бары шәүләсе генә калган. Минем ул көнне мәктәпкә кереп баруым да сезне күрер өчен генә иде. Очратырмын да, бәлки, бер форсаты чыгып, танышырга насыйп булыр кебек иде. Нишлисең, язмаган булган икән.

Елена, мин әллә ниләр өмет итмим. Шулай да җавап бирсәгез икән. Ул җавапны мин йөрәгемнең, синнән сәлам алып, кире үземә әйләнеп кайткан көне диеп белер идем.

Минем адрес: Куйбышевская обл. г.Кинель,

в/ч 3130, Смакову Рафаэлю М.

Сезгә сагынычлы сәламнәр җибәреп, эшегездә уңышлар һәм исәнлек теләп, Рафаэль.

5.01.53. г.Кинель.

P.S. Сезне борчуым өчен гафу итегез!"

Хатны хәрби частьтагы почта тартмасына салмады ул, ышанычлырак булсын өчен дип, икенче көнне смена тәмамлангач та Кинельга барып шәһәр үзәгендәге почтадан, хәерле юллар теләп, үз кулы белән озатып җибәрде.

Кинель белән авиаполк арасы ерак булмаса да җәяүле өчен шактый ара. Юлда берничә машина куып җитеп туктаса да утырырга теләмәде ул аларга. Карлы юлдан изүләрен ачып, рәхәтләнеп, үзалдына татарча җырлап кайтуга ни җитә соң. Тагы кайчан, кайда чыгар иде әле шундый форсат. Күңелнең дә канатланган, киләчәккә зур өметләр белән ашкынган чагы. Елена һичшиксез үзен аңлар һәм ул көткәнгә караганда да җылырак итеп җавап юллар кебек тоела иде аңарга. Әгәр дә җавап хаты килә икән—нинди шатлык, нинди бәхет булачак бу Рафаэль өчен. Хаты ничә көн эчендә барып җитәр дә, ничә көн эчендә җавап килеп җитәр—ул инде боларны көне-сәгате белән диярлек алдан ук хисаплап куйды. Куйбышев белән Уфа ерак ара түгел, күп дигәндә, бер биш-алты көннән артык вакыт узмаска тиеш кебек иде аның исәбе буенча.

Шундый уйлар уйлап атлагангамы, һәр яңа адым белән өстәмә көч һәм гайрәт тула бара иде аның йөрәгенә. Йөгереп, сикергәләп тә алды инде ул берничә мәртәбә. Сабый чакларындагы сыман, башындагы бүреген салып аны күккә чөйде һәм тотып алды. Таулар тишеп, ташлар күтәрерлек егәр тоя иде бит ул үзендә.

Егетләргә кызлардан, кызларга егетләрдән хат килеп төшү гаҗәп хәл түгел иде ул еллар өчен. Кая барасың, транспорт яклары җиңел түгел, шәхси машиналар юк, телефонның барлыгы билгеле булса да, ул әле гади кешеләргә тәти торган хәзинә түгел. Телевизор юк, компьютер һәм кесә телефоннарын әле ишеткән дә юк. Бердәнбер аралашу чарасы булып, шул, әлеге дә баягы дүрт почмаклы конвертка салынган хат кала. Хәер, хәрбиләрдән килә торган хатлар, кагыйдә буларак, өч почмаклы була торган иде.

Көннәрнең берендә үзенә өчпочмаклы хат килеп төшкәч, моны нигә юрарга да белмәде Лена. Хат килү гаҗәпләндермәде аны. Аның кебек буй җиткән чибәр кызларга, шуның өстенә ул еллар өчен иң абруйлы һөнәр иясе—укытучы бит әле ул, хат килү түгел, хат килмәү гаҗәп булыр иде. Аннан килеп ул бит әле сугыш елларында Ленинградтан Уфага күчерелгән хәрби заводта эшләп, "Школа рабочей молодежи"ны тәмамлады. Бергә укыган, эшләгән дуслары кайсы-кайда таралышты, күбесе кире Ленинградка кайтып китте. Алар сугыштан соң да бер-берләре белән озак кына үзара

хәбәрләшеп, хат алышып яшәделәр. Ләкин солдат хаты алганы юк иде әле аның.

Көтмәгәндә килеп төшкән бу хат аны гажәпләндерде һәм уйга да салды, әлбәттә. Беренчедән, хәрби очучы формасындагы ул егет, күренеп кенә китсә дә, хәтеренә уелып калган иде аның. Һичкемгә әйтмәде ул хакта, берәүгә дә сер бирмәде. Әмма хәрбилегенә күрә төз гәүдәле, бераз бөдрәләнеп торган чем-кара чәчле, әллә каян үзенә җәлеп итеп балкып торган зур кара күзле, калын иренле ул егетне очратып та искәрми калу мөмкин булмагандыр. Шуның өстенә бит әле ул тыйнак һәм сабыр да сыман тоелып калган иде...

Ә барыбер, бер күрүдә ошату һәм бер күрүдә ярату, дигән сүзләргә ышанмый иде ул. Һәм шуңа күрә дә хәрби очучы хакындагы уйларны күңеленә якын җибәрмәскә тырышып йөргән көннәре иде Ленаның. Саф татар телендә язылган хатны ул кайтып-кайтып укыды. Җавап бирергә ашыкмады, берничә көн дәвамына икеләнеп-уйланып йөрде. Ул хакта киңәш-табыш итәр кешесе дә юк иде бит аның. Өйдә алар әнисе белән икәү генә. Ә аны, болай да кызы өчен ут йотып яшәгән авыру әнисен, борчыйсы килмәде. Шулай да бер кеше бар иде инде барын—Әсма Миргалимовна. Ләкин, бер коллективта эшләүләренә дә карамастан, аңардан да бу хакта кызыксыну, ничектер уңайсыз тоелды башта. Бер көн түзде, ике көн, ә аннан, барыбер, сорамый булдыра алмады. Укытучылар кабинетында икәүдән-икәү генә калган чаклары иде. Сорау, бәлки, бераз җайсыз һәм урынсызрак та килеп чыккандыр, нишлисең, дулкынлана иде шул. Дулкынлануын яшерә алмады.

—Әсма Миргалимовна, әйтегез әле, Смаков Рафаэль кем ул?

—Кем булсын, минем бертуган энем,—дигән җавап ишетте ул.

—Аның хакында миңа бераз сөйли алмассызмы икән?

Әсма Миргалимовна, аңа караганда шактый өлкән һәм тәҗрибәле укытучы. Бөтен мәктәп коллективының хөрмәтенә лаек булган кеше. Ә ул аны шундый сорау белән борчый. Үзенең бертуган энесен мактасынмы, яманласынмы—ни дип җавап бирсен инде ул. Елмаеп, күзләрен тутырып үз итеп карады ул аңарга. Биргән сораулары өчен оялып куйды Лена.

—Үскәнем, Лена,—дип, җиңелчә аркасына кагылды ул аның.—Син уңайсызланма, хат яз аңарга, аның үзенә бир ул сорауларны. Шулай итсәң, дөрес булыр, һичкайчан үкенмәссең.

Әңгәмә шул җирдә өзелде, бер төркем укытучы килеп керде яннарына.

Шул кичне үк, әнисе йокларга яткач, җиделе лампа яндырып, хат язарга утырды ул. Гомер булмаган хәл, бер күреп сөйләшмәгән егеткә хат язарга җөрьәт итте. Хатны ул рус телендә язды, шулай уңайлырак иде аның өчен. Әмма һәр сүз һәм һәр җөмләне кат-кат уйлап, җиде кат үлчәп кенә төшерде ак кәгазь битенә.

"Исәнмесез, Рафаэль!

Сездән хат килеп төшүе минем өчен көтелмәгән бер хәл булды. Шулай булмый ни, гомердә бер тапкыр күрешмәгән, хәл белешмәгән чит һәм ят кешеләр ич без. Һәм мин башта җавап бирергә дә җыенмаган идем. Әмма, уйладым-уйладым да бер-ике сүз булса да язып салырга булдым әле менә. Сезгә сорауларым бар: ничек шулай бер күреп калган кешегә хат язарга булдыгыз әле? Ә очрашкан чакта ни өчен танышырга теләмәдегез? Кыймадыгызмы, әллә кеше күреп калудан курыктыгызмы?

Миннән җавап көтәм дисез. Ә кыз кеше өчен таныш булмаган берәүгә хат язуның кыенлыгы хакында уйлап карадыгызмы соң? Шулар өстенә, мин бит сезнең ни уйлап һәм нинди ният белән хат язуыгызны да белеп

бетермим. Турысын әйткәнгә үпкәләмәгез, "йөрәк" һәм "хисләр" дигән сүзләрегез, миңа калса, ышандырмый һәм берни хакында да сөйләми әлегә. Кинәшем шул, тагы да хат язарга булсагыз, миңа үзегез хакында языгыз күбрәк. Кем сон сез, ничек яшисез, ниләр укыйсыз, нинди хыял һәм омтылышлар белән яшисез...Мин бит сезне бөтенләй белмим.

Өй адресымны сорагансыз. Хат язар өчен булса, сез Уфадагы үзәк почтага языгыз, "до востребования" дип.

Сезгә исәнлек-саулыклар теләп калучы, Лена дип белерсез! (Мин татар кызы, "Елена" түгел, Лена. Мәктәптә дә йөдәтеп бетерделәр инде шул исем белән).

12.01.1953 ел. Уфа каласы."

Кыз җавап язарга теләмәде, дигән фикергә килеп йөри иде инде Рафаэль. Ә шулай да өметен бөтенләй үк өзеп бетермәгән иде әле. Кызлар, аеруча безнең татар кызлары, башта ялындыручан була бит инде алар. Шуны истә тотып, тагы бер хат язып карарга кирәктер. Алай да булмаса, озакка сузмыйча, ике-өч көнлек кенә булса да ял алып, Уфаны урап килергә дип, ниятләп йөргән көннәре иде.

—Рафаэль, биеп күрсәтәсеңме, әллә җырлап бирәсеңме,—дигән сүзләр белән каршыладылар аны көннәрнең берендә.

Очышлар уңышлы гына тәмамлануга да карамастан, эштән борынын салындырып, үзалдына уйланып кайтып килүе иде аның.

Сергей Клименко гел юктан гына үртәп тормас иде, бер бүлмәдә яшиләр ич. Дустының өзгәләнеп кызлардан җавап хаты көткәнлеген ул бит яхшы белә.

Эченә җылы керде Рафаэльнең, ә бәлки ул хат аны йокысыз калдырган, аны көн-төн сагыш утларында янарга мәҗбүр иткән укытучы кыз Еленадан килгәндер.

—Шаярма, Сергей, зинһар өчен әйт, кемнән килгән хат ул?

—Иң элек шартымны үтә. Хатны шуннан соң гына бирәчәкмен. Син көткән хат. Кызлардан...

Рафаэль, теләсә-теләмәсә дә, кулларын чәбәкләп әпипәгә барыняны кушып тыпыр-тыпыр биеп алырга мәҗбүр булды. Хат Уфа шәһәреннән килгән иде, конвертына кемнән икәнлеге язылмаса да ул күнеле белән сизде—бу аңардан—Еленадан.

Зур булмаган бүлмәнең тәрәзә янындагы түр почмагында урнашкан караватына барып утырды Рафаэль. Бүлмәдә кеше барын гына түгел, гүя бөтен дөньясын онытты ул шул мизгелдә. Сак кына кагылып конвертны ачарга керешт е. Әйтерсең лә, аның эчендә бер кәгазь кисәгеннән гыйбарәт булган хат түгел, ә ниндидер җан иясе тыгылган да, ул шунарга зыян китерүдән курка иде. Бер кат укып чыкты ул анда язылганнарны. Икенче кат укып чыкты. Анда язылган һәр сүзне, һәр тыныш билгесен аерым бер игътибар белән кат-кат күздән кичерергә тырышты. Хатны кулына алып күз йөгертеп чыккач та яхшы аңлады ул, хәрби очучыдан хат алдым дип, тиз генә җебеп төшәргә җыенмаган бу кыз. Ул үз дәрәҗәсен, үз кадерен белә, горур да икән әле шулар өстенә. Әмма, шул мизгелдә, хатта ни генә язылмасын, аның килү факты мөһим иде. Җавапсыз калмаган ич аның хаты. Җавап биргән, димәк, танышу һәм бер-берен белән аңлашу өчен юл ачык. Шуннан да зуррак тагы нинди җиңүгә өметләнә ала иде соң ул...

Ашау-эчү турында онытып, кичекмәстән, җавап хаты язарга утырды.

"Исәнмесез, Лена!

Сезгә үтә сагынычлы кайнар сәламнәремне җибәреп, үзегезгә дә исәнлекләр, көндәлек тормышыгызда уңышлар теләп калам! Сезнең

12.01.1953. язган хатыгызны мин бүген 16.01. алып укыдым, анда язылганнарның һәммәсен дә аңладым һәм шатландым. Хат язуыгыз өчен зур рәхмәт!

Сез минем хатны алгач та Әсма апага: "Смаков Р. кем була?" дип сорау биргәнсез икән. Бу сорауга мин хәзер үзем җавап бирермен. Ләкин, сез тагы да "Нигә күрешкәндә танышырга кыюлыгың җитмәде, ә хат аша гына танышырга булдың?.." дип сорамасагыз иде. Лена, мин, гомумән, турысын әйтеп сөйләшергә күнеккән, сездән дә шуны ук үтенәм. Килештекме?

Үзем Бүздәк районы Яңа Актауныкы. 1927 елда туганмын. 1944 елны урта мәктәпне бетергәч, үзем теләп армиягә киттем. Байтак кына хезмәт иткәч, Борисоглебсктагы авиаучилищега кереп, летчик-истребительга укып чыктым. Күптән түгел генә Кинельдагы авиаполкка килеп урнаштым. Очучы-истребитель.

Авылда әти белән әни бар. Әти укытучы иде, хәзер пенсионер. Туганнарым кайсы армиядә, кайсылары урта мәктәптә укый. Ә Әсма апамны беләсез. Менә быел (1952 ел) отпускага кайткач, аларның өйләре каршындагы мәктәп янында мин сезне күрдем. Күңелемә кереп калдыгыз, бик тә ошадыгыз. Әмма сезне, юлыгызга аркылы төшеп, туктатырга җөрьәт итмәдем, кыюлыгым җитмәде. Хәрби частька әйләнеп кайткач та, хат аша гына булса да таныша тораек дип, сезгә хат язарга булдым.

Максатым, әлбәттә, танышу. Шулай икәнлеге болай да аңлашыла бит инде, Лена. Без бит инде эч пошканнан уйнап кына хат язышa торган яшьтән узган. Күңелеңдә яисә башыңда бер-бер җитди уй булмаса, нигә кешене борчып торырга. Монысын аңлыйсыздыр. Әлбәттә инде, барлык сорауларны да хат аша гына хәл итеп булмас. Үзем турында менә шулар. Якын көннәрдә фотокарточкамны да җибәрермен. Ә инде март айларында, кыска отпуска алып, кайтып та килә алсам, шунда барын да аңлашыр идек. Билгеле инде, моның өчен сезнең яктан да танышырга теләк булу кирәк.

Лена, хатымны мин татар телендә язам. Инде менә тугызынчы ел татар-башкортлардан бер үзем генә булган частьларда хезмәт итсәм дә туган телемне онытырга уйлаганым юк, чөнки мин аны бик тә яратам ( рус телен дә яратам, билгеле). Буш вакытларымда кулыма каләм алып шигырьләр дә язам. Бер очрашсак, сезгә дә укырмын әле мин аларны.

Нигә икән серле карашыгыз
Китми һаман минем күңелдән.
Күзем йомсам—йокы керми күзгә,
Бөтен дөнья назга күмелгән...

Бала-чаганың менә шул инде, кулына каләм алса, кәгазьгә сызгаларга керешә...

Әле бүген генә күккә күтәрелеп, аткан уктай оча торган тимер кошым белән дөнья гизеп төштем. Күк ап-аяз, болытлардан югарырак күтәрелгәч ул һәрвакыт якты һәм зәңгәр була. Һавасы да саф, салкын. Һәм шундый кинлек, шундый иркенлек, моны сүзләр белән генә аңлатып булмый торгандыр. Шулай да тизрәк язлар килеп җитсен иде инде.

Без монда бер бүлмәдә өч кеше яшибез. Үзем кебек үк очучылар, берсе—рус егете, икенчесе—украинлы, кыскасы—чын интернационал бездә. Әмма, бик тату һәм үзара аңлашып, дустанә яшибез.

Лена, мин хат көтеп калам синнән. Мөмкин булса, үзең хакында язарга тырыш күбрәк.

Сезгә күп сәламнәр җибәреп, Рафаэль!

16.01.53. Кинель"

Хатны тәмамлап, конвертка салгач кына үзенең кайда икәнлеген һәм

күпме вакыт хат язу белән мәшгуль булып, әйләнә-тирәдән аерылып торганлыгын аңлады ул. Кичке аш вакыты узып киткән иде инде. Бүлмәдәш дуслары, аны борчырга теләмичә китап укып яткан җирдән, бер-бер артлы йокыга талганнар. Кышларын кичке караңгы бик тиз төшә шул. Иртә таңнан аяк өстендә ич алар, ардыра да торгандыр. Аннан көн дә кызыл почмакка җыелып домино уйнап утыру да туйдыра, ялыктыра. Гаиләсез кешегә тагы нинди шөгыль табарга кирәк кичләрен?..

## 11

"Исәнме Рафаэль!

Хатыгызны беркадәр кичегеп алдым, гаепләмәссез. Чөнки мин шәһәр үзәгенә атнага, күп булса, ике мәртәбә күтәреләм. Кыш бит, көннәр суык тора.

Сез миңа үзегез хакында кайбер мәгълүматлар язгансыз. Шулардан чыгып инде мин хәзер үзем белән хат алышучы кешенең кем булуын күзалларга тырыша алам. Әмма, биографиядән чыгып кына кешенең кемлеген белә торган түгел. Кешенең карашлары, холкы-фигылен аңлау өчен үзара аралашып яшәү кирәк.

"Сез нинди кеше—яхшымы, яманмы?"—дип, сорап булмый бит. Сораудан да файда юк. Һичкем үзен начар дип әйтмәс. Шуңа күрә безгә миңә хәзер, үзара хат алыша башлаган көннәребездән үк, килешеп куюы артык булмас. Үзара хат алышканда без бер-беребезнең кайбер уңай сыйфатларын тапкан кебек, җитешсезлекләренә дә тап булачакбыз. Чөнки кеше—ул бик катлаулы, аны тиз генә аңлап, өйрәнеп бетерү мөмкин түгел. Гомер-гомергә шулай булган.

Без дә тора-бара бер-беребездә күңелебезгә ошап җитмәгән сыйфатлар күрәчәкбез. Мондый очракта чын дуслар нишли? Әлбәттә инде, ачыктан-ачык ул кимчелекләрне уртага салып сөйләшә. Һәм һәр ике тараф төзәлергә, аңлашырга тырыша. Булмый икән, үзара килешә алмый торган кешеләр икәнлекне аңлагач та, матур гына икесе ике тарафка китеп бара. Мин дә, миңә хәзердән үк, соңыннан үпкәләүләргә урын калмасын өчен, болар хакында сезне кисәтеп куярга кирәк дип саныйм. Сез ничек уйлыйсыз, Рафаэль?

Үзем хакында ниләр языйм икән соң? Минем биография бик катлаулы һәм авыр. Миңа яшьли бик күп кыенлыклар кичерергә туры килде. Алар турында инде искә дә аласы килми. Сез отпускага кайткач, очрашсак, сөйләрмен әле бер... Әлегә ике-өч сүз генә язып китәм. Минем әниемнән башка бер кешем дә юк. Яшьли Ленинградта хореографик училищеда укырга туры килде. Бар хыялым балетта бию иде. Укытучыларым зур өметләр баглый иде үземә. Әмма, бәхетсезлегемә каршы, сугыш башланды. Сугыш елларында Уфада хәрби заводта эшләдем. Ә кичләрен "Эшче-яшьләр мәктәбе"ндә укып, урта белем алдым. 1952нче елда Башкорт дәүләт педогогия институтының чит телләр факультетын тәмамладым. Хәзер миңә 46 номерлы урта мәктәптә инглиз теле укытам.

Сез миннән төгәл адресымны сорагансыз. Мин Уфада Аксаков урамындагы 41 йортның 1нче фатирында яшим. Әмма, отпускага кайта калсагыз, шуны онытмагыз, мине анда түгел, Затонда табу җиңелрәк булыр.

Мин сездән тагы шуны үтенәм, безнең хат алышуыбыз хакында Әсма апа белән аның иренә әйтмәсәгез иде. Без бер коллективта эшлибез, юкса миңа бик читен булачак. Килештек, ярыймы, Рафаэль!

Сез миңа фоторәсемегезне җибәрергә вәгъдә иткән идегез, көтәм. Юкса, урамда очрашканда үзегезне танымыйча узып китәрмен. Килеп эндәшә

калсагыз, "Таныш түгел кешегә бәйләнү яхшы түгел" дип, үзегезне битәрләп атармын йә. Мин шулай усал да була беләм!

Шигырегез өчен рәхмәт. Мин рус поэзиясен бик яратам. Ә үзебезнең татарлардан Тукайны, Такташны аеруча якын күрәм. Әмма үземә шигырь язу сәләте бирелмәгән. Шуңа, сездән аермалы буларак, хатымны коры сүзләр белән генә тәмамларга мәҗбүрмен.

Нинди китаплар укыйсыз, нинди кино һәм спектакльләр карарга яратасыз, шулар хакында языгыз. Һәм шул китап, кинолардагы вакыйгалар турындагы үзегезнең ниләр уйлаганыгызны, фикерләрегезне язып җибәрсәгез аеруча әйбәт булыр иде. Бу бер-беребезне яхшырак белү һәм өйрәнү өчен зарур.

Вакыт инде бик соң. Миңа әле иртәгесе дәресләргә әзерләнергә дә кирәк. Шул урында хатымны тәмамларга мәҗбүрмен.

Яхшылыклар теләп, Лена. 25 январь 1953 ел."

Бу юлы да Рафаэльгә хат бик күттереп кенә килде. Әллә ниләр уйлап бетергән иде инде ул. Барыннан да бигрәк җавапсыз калу куркыта иде аны.

Буйдак очучылар барысы да бер үк тулай торакта торалар. Кемнең кемгә хат язганын яисә кемнең кызлардан хат көткәнлеген монда һәркем белеп тора. Бер нәни хат өчен Рафаэльне биетергә өч-дүрт егет каршы чыкты бу юлы да.

—Хат кайдан килгән?—дип сорап куйды арадан берсе.

—Башкириядан.

—Димәк, Рафаэль Смаков башкаруында башкорт халык биюе башкарыла,—дип игълан итте хатны кулында тотып килүче Балченков.

Болар белән бәхәсләшү файдасыз. Хатны тизрәк укырга телисең икән, биеми котылам димә. Хат килү хәбәреннән кинәт күңеле үсеп киткән Рафаэль, аэродромнан арып-талып кайтуына да карамастан, күн итегенең очларына басып, Урал егетләренә генә хас дәрт белән биеп җибәрмәсенме, мин сиңа әйтим. Хәйран калып, кул чәбәкләп, көлешә-көлешә карап торды дус-ишләр.

—Болайга китсә, биюче итәбез без сине,—дип, озак көттермичә, хатны кулына бирделәр.

—Хаты гына килеп торсын, егетләр, эш биюдән генә тормас,—диде ул, хатны кулына алгач та үз бүлмәсенә ашыгып.

Хатны бу юлы да, гадәтенчә, тимер караватка сузылып ятып, иркенләп, бер рәхәтлек кичереп укыды ул. Йотлыгып укыды башта. Икенче тапкырында инде ашыкмыйча, тәмләп укырга кереште. Хатның аерым урыннарына җиткәч, туктап-туктап уйланырга да мәҗбүр булды. Үзалдына елмаеп та алды әле хәтта. Хаттагы һәр сүздән, һәр җөмләдән аның авторының укытучы булуы һәм ул укытучы кызның шактый ук горур һәм үз-үзен дәрәҗәле тотуы сизелеп тора иде. Рафаэль өчен яңа, моңарчы күрелмәгән бер дөнья бит бу. Үзе күпме кетеп, күпме хыялланып тапкан яңа һәм искиткеч могҗизалы дөнья. Һәр сүз, һәр җөмлә артында нindидер серләр, тирән мәгънә һәм бары тик аңарга гына атап юлланылган хисләр өермәсе яшерелгән кебек тоела иде аңарга.

Юк, хаттагы бер генә сүз дә кәефен төшермәде аның, киресенчә, шундый белемле, эрудицияле кыз белән танышуына һәм чын-чынлап хат алыша башлавына чиксез куаныч хисләре генә биләп алган иде аны.

Ул бит әнә нинди! Ленинградның үзендә балет мәктәбендә укыган. Институт тәмамлаган, югары белемле укытучы. Татарча һәм русчаны гына белү түгел, инглизчәне дә су кебек эчә инде болай булгач. Мондый кызга

лаек булырга да кирәк бит әле...

Кыз сер бирмәскә тырыша, әлбәттә. Шулай да, әнә, дәрескә әзерләнүен дә бер читкә куеп торып, төн йокыларын калдырып, хат язган бит әле ул аңарга. Фоторәсем көтүен дә искәртергә кирәк тапкан. Димәк, ул тарафтан да күпмедер кызыксыну бар. Ә бу аның күңелендә тагы да зуррак өметләр уята. Зур өмет һәм хыялларга нигез булып тора. Әлбәттә, беренче чиратта аңарга хәзер фоторәсем кирәк.

Кинельдәге бердән-бер фотограф—бер аяксыз Иван дәдәйгә барып эшләткән дә иде инде ул рәсемен. Ләкин бик уңышлы чыкмаган. Чәчләре дә җүнле-башлы таралмаган кебек, иреннәре дә, ничектер, салына төшкән, шулар өстенә тагы йөзе дә бик карангы күренә. Сугыш инвалидының осталыгы шул чама гына булгандыр. Үзенә охшамаган фоторәсемен Ленага җибәрә алмый бит инде. Куйбышевта әйбәт фотографлар бар диләр. Ял көне җиткәч тә Куйбышевка барып, анда төшеп карарга ният итте ул. Шул сәбәпле, хатын да бераз кичектерергә мәҗбүр булды.

"Бик ашыгыч" дип эшләтелгән фоторәсемне дә, ике бәя түләп, өч көн көтәргә туры килде. Аның каравы фото шәп килеп чыккандай булды. Һәрхәлдә, Рафаэльнең үзенә ошады монысы. Һәм шул күтәренке күңел белән хат та язып ташлады ул. Күңелендә йөрткән бер җылы сүзне дә кызганмады, яшереп калмады, бар хисләрен дисбе төймәләре сыман тезде дә чыкты. Хат сәхифәләренә күңелендә туып, үзен тынгысызлап йөргән шигырь юллары да матур гына кереп урнашты. Һәм, әлбәттә, бу хат белән Рафаэль хыялындагы Ленасына беренче тапкыр үзенең фоторәсемен дә салып җибәрде. Ә фотоның арткы тарафына, озак уйлап тормый гына түбәндәге сүзләрне сырлады:

" Лена!

Йөрәгемнең иң түрендә—синең исем,  
Дөньядагы бар матурлык—синең төсең.  
Күктән йолдыз җыйдым—синең өчен.  
Хисләремә җавап көтәм, син ни дисең?..

8.02.53. Куйбышев шәһәре. Рафаэль Смаков».

Февраль карлы-буранлы булды ул елны. Шәһәр белән шәһәр, авыл белән авыл арасында юллар өзелеп торды. Машиналар юлга чыкмады. Идел белән Урал арасында тимер юл хәрәкәте хәтта бер атна чамасы тукталып торды. Хәрби самолетлар күккә күтәрелмәде. Аларны кар көртләре күмеп китә язды. Солдатлар берөзлексез көрәкләр белән очу юлын кардан арчыдылар. Ә очучылар хәрби частьның кызыл почмагында сугыш тактикасы теориясен өйрәнделәр, агымдагы сәяси хәлләр турында доклад арты доклад тыңладылар. Һәм, әлбәттә инде, коммунистлар партиясе тарихын һәм аның классиклары В.И.Ленин белән И. В. Сталинның фәнни хезмәтләрен ятладылар.

Көткән кеше өчен иң яманы, хатлар килми торды. Почта эшләмәде. Язган хатына җавапны Рафаэль, гәрчә ул җавап февраль урталарында ук язылган булса да, бары тик март аена чыккач кына алды.

"Исәнме, Рафаэль!

Хатыңны һәм фотосурәтеңне кичегеп булса да алдым. Һәр икесе өчен дә рәхмәт. Җавабым бераз тоткарлана төшкән булса, ачуланмассың шәт. "Фото бик уңышлы чыкмаган кебек", дисең. Зыянлы түгел. Аның каравы хәзер күрешкәндә танымыйча узып китмәм инде. Тагы шуны да әйтим, сез Әсма апагызга бик тә охшагансыз икән. Фоторәсем артындагы шигырь юллары өчен аерым рәхмәт. Әмма сез арттырыбрак та җибәрәсез төсле күренә, бик купшы сүзләр язгансыз. Турысын әйткән—туганына ярамаган,

дисәләр дә, әйтим, сез шигырь юлларына салып язганнарга мин ышанып бетмим. Ничек итеп бер тапкыр читтән генә күреп калган кеше ихластан шундый сүзләр яза алсын. Әле бер-беребезне белеп, яхшы ук аралашкан булсак та ул сүзләрнең дөреслеге шик уяткан булыр иде.

Инде менә шундый сүзләрдән соң, күз алдына китереп карагыз, без күрешә калсак һәм сез мине охшатмасагыз, ни булыр? Чөнки сез мине артык идеаллаштырып, шуңарга җирлек әзерлисез. Сез язганнар белән чынбарлык арасында зур аерма булуы да ихтимал бит. Шуңа безгә гади танышлар, дуслар буларак кына хат алышу кулаерак булыр. Ямщик әйтмешли, атларны алай ук бик куаламыйк...

"Иван Иванович" дигән роман хакындагы фикерләрегез бик тә кызыклы. Чынлап та бу әсәр бүген бик күп бәхәс һәм фикер каршылыклары уята. Тормышчан әсәр булганга шулай. Бүген безнең җәмгыятьтә аз түгел ич андый кешеләр. Ир кеше үз эшендә зур уңышларга ирешә, хөрмәт казана. Ә гаиләсенә аның вакыты калмый. Һәм ул үз гаиләсенә бераз югарыданрак карый башлый. Гаиләнең кадере һәм әһәмиятен ул бары тик өйдә ялгызы калып, үз-үзен кая куярга белми башлагач кына аңлый. Миңа калса, автор үзенең әсәрендә, хезмәт алдынгысы булуына да карамастан, Иван Ивановичны шактый ук тискәре һәм бәхетсез кеше буларак та күрсәтүне максат итеп куйган. Менә шул каршылыклары белән дә әсәр киң катлам укучыны үзенә җәлеп итә инде.

Сез тагы үзегез язып җибәргән шигырьләр хакында да фикер әйтүемне үтенгәнсез. Югарыда язылганнарга өстәп, тагы ни дип әйтим. Сез табигатьне бик яратасыз икән. Шигырь төзелеше һәм техникасы ягыннан мин үземне алай ук белгеч санамыйм. Әмма җиңел язасыз, матур күренешләр тудырасыз—бу бик әйбәт инде.

Үзем менә сезгә хат язам, ә шул ук вакытта уйлыйм һәм икеләнәм, карточкамны җибәрергә микән—юкмы... Сез кат-кат гозерләп сорагансыз. Ярый, мин сезгә фотомны җибәрәм. Әмма, шуны истә тотыгыз, мин аны кызлар үзләренең сөйгән егетләренә җибәргән кебек итеп түгел, дусларча гына юллыйм үзегезгә. Соңгы сулышыма кадәр сезнеке булырга җыенам дип вәгъдә итмим, әмма, дус буларак, сез миңа ышана һәм таяна аласыз. Бу хакта шик кермәсен күңелегезгә.

Мин, бәлки, артык катгый сөйләшәмдер, ачуланмагыз, аңларга тырышыгыз. Мине тормыш шулай өйрәтте. Бер карашка бик каты бәгырьле тоелсам да, хакыйкатьтә мин андый ук түгел, күңелем бик нечкә минем.

Менә, сез минем карточкага карап утырасыз хәзер. Ул артык уңышлы килеп чыккан. Үземә караганда да матуррак. Гәрчә, һичнинди бизәү һәм ясаулар кулланылмаган. Инде хәзер сез дә очрашканда мине танырсыз дип ышанам.

Бүгенгә шуның белән житәр. Безнең Затонда бит XIXнчы гасыр авылларындагы кебек, электр уты бик сирәк була. Бу хатымны да керосин лампасы яктысында яздым менә. Әле эшлисе эшләрем байтак, хатны тәмамларга рөхсәт итегез.

Иң яхшы теләкләр һәм сәлам белән, Лена.

16 февраль 1953 ел".

## 12

Кызлар белән хат алышулары күңелле. Хат кешеләрне бер-берсенә якынайта, бер-берләрен аңларга ярдәм итә. Әмма шулай да хат сагыну һәм сагышларны басмый. Хат—ул йөрәк яраларын яңартып кына тора. Юкка гына борынгылар, бер күрешү—бер гомер, дип әйтмәгәндер. Рафаэль, Лена белән хат алыша башлаган көненнән башлап, язның беренче аен—мартны

көтте. Чөнки, хәрби-тактик хәзерлек һәм очуда аеруча зур уңышларга ирешкән өчен, бу—анарга, чират буенча, алдан ук вәгъдә итеп куелган бер атналык отпуска вакыты иде. Ул инде отпускага кайтам дип, барлык туган-тумачага хәбәр итеп өлгерде. Күчтәнәчләр хәстәрләп куйды. Билет алырга дип, жыенып йөргә иде. Һәм, әлбәттә инде, барыннан да бигрәк, зарыгып һәм зур өметләр белән Лена белән беренче очрашу, беренче күрешү сәгатьләрен көтә иде ул.

Көтмәгәндә, кояшлы мартның бер иртәсендә, аяз көнне яшен суккандагыдай, кайгылы хәбәр таралды илгә. "Иптәш Сталин вафат булды". Илдә траур игълан ителде. Әллә кайчаннан көтеп алынган очрашу турындагы хыяллар шуның белән челпәрәмә килде. Хәрби частьлар бөтен ил буенча "особое положениега" куелды. Ялга киткән офицер һәм солдатларны да егерме дүрт сәгать эчендә кире хәрби частьларына әйләнеп кайтырга мәжбүр иттеләр.

Гадәттә, зур житәкче вафатыннан соң, траур-фәлән игълан ителсә дә, күпчелек кеше моны үз күңеленә артык якын алмый. Аеруча житәкчеләргә ышаныч юкка чыгып беткән безнең көннәрдә бу шулай. Әмма ул заманда Сталинның үлемен, күпчелек, бигрәк тә гади эшче һәм колхозчылар, ихластан бер милли трагедия сыман кабул итте. Капка төбендәге чана эзеннән шаулап аккан гөрләвеккә карап мышык-мышык елап торган чаклар хәтердә. Бишенче яшь белән киткән малайлар. Аякта абыйлардан калган тишек күн итек булгандыр, башта колакчынлы иске бүрек. Тамак ач булгандырмы-тукмы, әйтүе кыен ул кадәресен. Әмма, Сталин бабай үлгән дип, елап торуларны һич онытасы юк. Бөтен авыл елый иде чөнки. Бөтен ил елыйдыр төсле иде. Тол хатыннарның: "Юлбашчысыз калдык, инде нишләрбез. Безне дошманнан кем саклар, балаларымның тамагын кем туйдырыр...",—дип, юеш кар өстенә ятып тәгәри-тәгәри үксеп елаганы һич истән чыкмас.

Инде отпускага кайтам дип торган хәрби очучы лейтенант Смаков та авыр кичерә әлеге югалтуны. Зур кайгы итеп кичерә Сталинның үлемен. Жан атып, үзенә атлыгып яшәгән кызга да хат язарга жөрьәт итми ул кайгылы көннәрдә. Совет офицерына сәяси хата ясау ярамый бит, ул шуңардан сагая.

Хатны шактый ук кичегеп язды.

"Исәнмесез Лена!

Хатыгызны һәм фоторәсемегезне алдым. Исәнлекләрегезне белеп бик шатландым, рәхмәт! Әмма вакытында жавап язмавым өчен кичерерсез дип ышанам. Чөнки, хат безнең туган илебез өчен бик тә кайгылы көннәрдә килеп төште, жавап язырга күңелем тартмады. Инде, ниһаять, отпускага кайтам да менә-менә күрешәбез, дип йөргән көннәрдә эшләр әнә ничек бөтенләй икенче төрлегә борылды да китте бит әле. Шулай итеп отпуска дигән нәрсә әлегә онытылып тора. Өйдәгеләр дә кайта диеп көтәләр иде инде. Аларга кайта алмыйм дип телеграмма суктым һәм 3 мең сум акча жибәрдем әле менә.

Эш бик күп, бер караңгыдан икенчесенә кадәр самолетлар янында кайнашабыз. Үзем исән-сау гына яшәп ятам. Яз көннәре дә килеп житте менә. Карлар эри, аяк аслары суланды. Безнең торган урын элек колхоз басуы булган, язгы пычрак сезнең Затонныкыннан бер дә ким булмас дип торабыз.

Фотокарточка артына язылган сүзләр сезгә ошамаган икән, берни эшләп тә булмый. Мин аларны ихлас күңелдән язган идем тагы. Без бит инде телгә ни килде шуны язып, шуны сөйли торган яшьтән узган. Мин уйладым исә—эшлим, әйткән сүземне үтим. Бала чактан ук үз-үземә очучы булам

дип сүз биргән идем, тормыш юллары нинди генә каршылыклар китереп чыгарса да, үземнекен иттем—очучы булдым. Сиңа да, эч пошканнан кызык итеп түгел, күңелемә ошап калганга хат язам һәм үз күңелемдә, үз телемдә булган сүзләр белән язам. Һәм мин, сездән аермалы буларак, бер күрүдә гашыйк булуга ышанам. Кешене беренче күрүдә үк, бөтенләй үк булмаса да, 99% анлап була дип саныйм. Сез башкача уйлыйсыз, ә мин менә шундый, нишлим соң... Мин кешегә ышанырга кирәк дип саныйм һәм ышанам. Кешедән гел мәкер һәм яманлык кына түгел, яхшылык көтәргә кирәк дип уйлыйм.

Аннан килеп, мин сез язган һәр сүзне йөрәгем аша уздырып кайтып-кайтып укырга яратам. Ләкин хатларыгызда миңа ышанмау, минем һәр сүземә тәнкыйть күзлегеннән карауны сизеп, вакыт-вакыт үз-үземне кая куярга белмим, кәефем кырыла. Күңелемә шикләр дә кереп куя кайчак: бәлки, бу хатларым белән мин сезнең тынычлыкны гына югалтам, бәхетегезгә каршы төшәмдер... Әгәр шулай икән, ачыктан-ачык әйтегез. Мин ничек тә түзәрмен. Мин авырлыкларга да, ялгызлыкка да күп түздем инде, алга таба да түзәрмен.

Шулай да ашыгып нәтиҗә ясаудан сак булыйк әлегә. Мин сезне югалтырга теләмим, Лена. Бер күрешеп сөйләшергә кирәк безгә. Сезнең хакта барын да беләсем килә минем: ничек эшлисез, буш вакытларыгызны ничек үткәрәсез, әниегез ничә яшьтә, аның сәламәтлеге ничек һәм башкалар турысында. Әниегезгә минем хакта сөйләгәнегез бармы, ул мине беләме? Юкса, сез югында ишегегезне шакып, ул мине кисәү агачы белән куып җибәрсә, кая качарга белмәссең. Алдан ук белеп торыйм дим.

Бу хат белән тагы бер фоторәсем җибәрәм. Әмма бу юлы үзем генә түгел, Балченков Володя исемле дустым белән төшкән идем. Сайлау көнне.

Сезгә исәнлекләр теләп, сәлам белән, Рафаэль.

21.03.53ел. Кинель шәһәре."

Лена бу хатны озак көтеп алды. Үзенең, сер бирәсе килмәүдән килеп чыккан кайбер саксыз сүзләре белән егетне үпкәләттем ахыры дип уйлый башлаган иде инде ул. Һәм дөрестән дә шулай булып чыккан түгелме соң...

Рафаэль үзенең бу хатында, ничектер, үзгәргән кебек тоелды аңарга. Җитдиләнә һәм кырыслана төшкән. Һәм, иң гаҗәбе, беренче тапкыр ул үзенең хатында шигырь юллары китермәгән. Баксаң, егетнең хатларындагы ул шигырьләрне зарыгып көтеп ала торган булган икән ич ул. Әле генә анлады шуны. Ул шигырь юлларындагы хисләр кайнарлыгы, эчкерсезлек һәм җанны иркәли торган сүзләр җитмәде аңарга бу юлы. Беркадәр купшы тоелсалар да кадерле һәм бик кирәк булган икән ич алар аның өчен. Рафаэльдән башка әле беркемнең дә аңарга атап шигырь язганы юк иде ич. Ничек рәхәт иде ул шигырьләрне уку. Кайтып-кайтып уку... Аларны бит әле ул бергә туплап, җыеп та килә иде. Кызганыч, Рафаэль аңарга бу юлы шигырь багышламаган.

Шундый уйлар кичерде кыз. Һәм шул көнне үк кичен, керосин лампасы яктысында утырып, хат язып салды. Хаты озын булып чыкты бу юлы. Рафаэльгә әйтәсе, аның белән киңәшәсе килгән фикерләре күбәеп киткән иде шул. Сер бирергә теләмәсә дә, Рафаэль белән хат алышу, аннан хатлар көтү иң зур һәм бердән-бер куанычка әверелеп бара иде ич аның өчен. Бу егетне югалтасы килми иде аның. Ул хакта хәтта уйлап карарга да курка иде ул. Әмма, ялгышып та егетнең үзенә сиздермәде боларны.

## 13

Җәй килеп житте. Ике арада хатлар өзелеп тормады. Җавап килеп житкәнен дә көтеп тормастан, атна эчендә икешәр-өчәр хат язып сала иде алар бер-берсенә. Җавап белән дә көттермәделәр, Рафаэль—Ленага, Лена Рафаэльгә ашкынып хатлар яудырды бу язда. Ул язда гөлләр матуррак чәчәк атты, кошлар моңлырак сайрады. Елга һәм инешләр гомер булмаганча тыңгысызланып, чишмәләр челтерәбрәк акты. Кичләрен зәңгәр күктә йолдызлар кабынды. Бер-беренә омтылып яшәгән гашыйкларның күз явын алып жемелдәде алар. Шуңамы күзләренә йокы керми тинтерәтте үзләрен...

Инглиз теленнән укытучылар житмәү сәбәпле, Лена берьюлы ике мәктәптә дәресләр алып барды. Шуның өстенә, яшь укытучы буларак, җәмәгать эшләре белән дә күмәләр иде үзен. Әнисе хасталанып тора, шул сәбәпле шәһәр белән бистә арасында йөгереп тә уза иде бик күп гомере. Әмма хат язарга вакыт барыбер табыла иде. Яшь кыз күтәрә алмастай тоелган авырлыкларны җиңәргә дә шул хатлар дәрт һәм егәр өсти иде аңарга.

Рафаэль исә хәрби хезмәттә. Ә хәрби кеше үз-үзенә хуҗа түгел. Алар көндәлек мәшәкать—самолетларны хәстәрләү һәм очыш, хәрби күнегүләр, тактик һәм сәяси дәресләрдән тыш, әле тиздән кайтырга тиешле булган яңа төр самолетларны өйрәнеп, зачетлар тапшыру белән дә мәш килделәр. Яшь ВКП(б) әгъзасы буларак, солдатлар арасында тәрбия сәгатьләре алып бара иде ул шулар өстенә. Һәм әледән-әле Куйбышев шәһәренә төрле конференцияләрдә һәм пленумнарда чыгыш ясау өчен дә хәрби часть исеменнән аны җибәрәләр иде. Чөнки, хәрби авиация өлкәсендә генә түгел, агымдагы сәяси хәл, халыкара мөнәсәбәтләр, партиянең милли политикасы уңаеннан сүз чыкса яисә чыгыш ясарга кирәк булса—лейтенант Смаков һәрвакыт әзер, сөйли башласа теле телгә йокмый, кушылган эшне җиренә җиткереп үти һәм һичбервакыт командирлары йөзенә кызыллык китерми торган иде.

Егетнең күңелендә, бәлки, май бәйрәме көннәрендә дүрт-биш көнгә генә булса да рөхсәт алып туган якларына кайтып килеп булмасмы дигән өмет чаткысы яши иде әле. Очышлар яхшы бара. Командирлары үзен хөрмәт итә, Смаков фамилиясен башкаларга үрнәк итеп искә алып торалар. Нигә өметләнмәскә?.. Әмма, хәерчегә җил каршы, дигән сыман, нәкъ шул көннәрдә хәрби частьларга СССР оборона министрының халыкара хәлнең киеренкеләнә баруы турында чираттагы хаты килеп төшә. Отпуска хакында уйланыр урын да калдырмыйлар.

Ул да түгел, Рафаэльләр эскадрелиясын, махсус задание үтәү өчен дип, май урталарында ашыгыч рәвештә Саратовка командировкага юллыйлар. Саратовтан артык ерак түгел генә Разбойщина дигән авыл бар. Шул авыл читендәге урман эченә килеп урнашты алар. Монда тәүлекләр буена, чиратлашып, стратегик мөһим объектны саклау белән мәшгуль булалар. Яңа урын, яңа шартлар һәм зур җаваплылык—болар барысы да Рафаэльнең күңеленә хуш килә.

Тик менә Лена белән генә очрашып аңлаша алмадылар, шунысы пошыра иде аның күңелен. Инде хәзер ноябрьга кадәр көтәргә каламы?.. Шунсыз ял булмаячак. Димәк, әле тагы ярты ел дигән сүз ич бу. Ярты ел дип әйтергә генә җиңел. Ничек түзәргә кирәк... Ә кыз көтәрме аңарчы, хат язып, хат көтеп яшәүнең дә бер чиге булырга тиештер бит инде. Ул кул селтәп, үзенә шәһәрдә башка берәүне тапса, Рафаэль ни эшләр. Әллә нинди уйлар керә иде аның башына.

Көннәрдән бер көнне, чираттагы хатында, ул Ленаның җәйге каникул

көннәрендә ни эшләргә җыенуы белән кызыксынып, аны берничә көнгә Саратовка кунакка чакырырлык кыюлык тапты үзендә. "Ял көннәренә туры китереп килсәң, мин дә шәһәргә чыгармын. Музейларга йөрер идек, театрга, Идел буендагы паркларны бергә-бергә гизәрбез. Бик күрәсем килә бит үзенне, җаным...", дип йомгаклап куйды ул әлеге тәкъдимен. Каян килгәндер шундый кыюлык, үзе язганнарга үзе ышанмый торды байтак кына. Ятып калганчы, атып калуың хәерле, дигән сыман килеп чыкты инде бу.

Ни гаҗәп, җавап ул көткәннән дә тизрәк килде. Укытучылар җәйге ялга чыккан иделәр инде. "Минем Саратовта бергә укыган иптәш кызым бар. Ул бик күптән чакыра иде үземне. Июнь урталарында аның янына килергә җыенам, берочтан, вакыт таба алсаң, бәлки, синең белән дә күрешербез..." дип язган иде Лена үзенең хатында. Менә бит ул, бәхет дигәнең, гел көтмәгән җирдән үзе каршыңа йөгереп килә. Канатлар үскәндәй булды Рафаэльгә, атлап түгел, очып йөри башлады ул әлеге хәбәрне алгач. Ленаны каршы алырга хәзерләнә башлады.

Хәер, хәзерләнү дигәне бик шартлы төшенчә иде инде. Ничек хәзерләнә ала соң ул? Аның кунак каршылар урыны бармы?..Үз вакытын үзе теләгәнчә планлаштырып кую хокукы бармы?.. Монда ич алар үзләре дә вакытлыча командировкага килгән кеше. Торулары да шәһәрдә түгел, авылда түгел, әллә кайдагы бер урман эчендә. Походтагы кебек, зур хәрби палаткаларда яшиләр. "Разбойщина" диеп якындагы авыл исемен атагач та күпләр басып торган җирләреннән чайкалып китә. Әмма, исеме җисеменә тиң дип, әйтерлек түгел иде шулай да. Матур урман, янәшәдән генә зур булмаган елга агып үтә. Кечкенә генә булсалар да, үзенә күрә күлләренә тикле бар. Табигать искиткеч матур, күп кенә яклары белән аларның туган авылы Яңа Актауны хәтерләтә иде бугай әле ул. Тик бер нәрсә үзгә, алар урнашкан урман эчендәге зона гади кешеләр өчен ябык, анда керү өчен Идел буе хәрби комиссарының үзеннән рөхсәт алу кирәк.

Ни генә булмасын, Рафаэль күптән көтелгән очрашуга әзерләнде. Соңгы хатында хәтта Саратовка килү юлларына кадәр аңлатырга тырышып язды. "Куйбышевка кадәр поезд белән. Ә аннан, Идел буйлап, рәхәтләнеп, пароходта йөзеп төшә аласың...",—дип киңәш итте ул, бу якларны яхшы белгән кеше буларак.

"Мин 13 нче июнь көнне Саратовта булам. Шәһәр үзәгендәге кунакханәләрнең берсендә урнашырмын", дип телеграмма сукты кыз. Һәм тәүлекләр буена селкетеп бара торган поезд, пароходларга да утырып азапланмады, Куйбышевта күчеп утырырга туры килсә дә самолетта гына очып килеп төште Саратовка.

## 14

1953 нче елның 13нче июнь иртәсе. Саратов. Аэропорттан шәһәргә бердән-бер автобус йөри икән. Шулай да урын җитәрлек иде автобуста, студент чаклардан калган гадәт буенча, арткы урыннарның берсенә кереп утырды кыз.

—Сезгә кая кадәр?—дигән сорау белән, каршысына кондуктор килеп басты ул да түгел. Кондуктор хатын шактый ук юан, тавышы көр, йокысы туймагангадыр, күз төпләре шешенгән. Муенына асылган ачык сумкасын рәтләгән атлы булып, андагы акчаларын шылтыратып алды ул.

Гаепле кеше сыман, каушап калды Лена.

—Белмим шул...—Һәм, озак көттермичә, ачыклык кертергә ашыкты.—Шәһәр үзәгенә.

—Кайсы тукталыш икәнен дә белмисеңмени?—дип, ачыlyбрак китте

кондуктор.—Шәһәр үзәгендә ни кирәк сон сина, сенлем...

—Кунакханә.

—Күптән шулай дип әйтергә иде. Анлашылды,—диде ул һәм вак акча белән билет калдырып ары китеп барды.—Игътибарлы булыгыз, барып җиткәч тә мин сезне кисәтермен.

Шәһәр үзәгендә кунакханәнен "Центральное" дип аталганын эзләп тапты ул. Бу анын үз гомерендә беренче мәртәбә кунакханә ишеген атлап керүе иде. Администратор өстәле артына килеп басты.

—Миңа бер урын кирәк иде.

—Урыннар юк.

—Ә миңа бик кирәк иде.

—Башка кунакханәләргә барып карамадыгызмы соң?—диде администратор хатын. Ул шактый ук җитди сөйләшүенә дә карамастан, кырыс түгел, кешелекле сыман күренә иде.

—Миңа сезнең кунакханәдә урнашырга кирәк иде шул,—дип, уйга калып торды кыз. Рафаэльгә бит ул "шәһәр үзәгендә" дип язган иде. Әлбәттә инде, ул аны эзләп "Центральное" дип аталган кунакханәгә киләчәк. Килер дә, аны таба алмыйча кире кайтып китсә, ни хәл итәр. Шуна башка җирдән урын эзләп чыгып китәргә ашыкмады әле ул, икеләнебрәк торуында булды.

Администратор хатын да сизеп алды моны, һәм анын хәленә кереп, сорап куйды:

—Студент түгелме соң сез?

—Юк шул. Мин инде укуны тәмамладым, укытучы булып эшлим.

—Шуна соравым, безнең монда читтән торып укучылар өчен калдырылган урыннарыбыз бар иде. Бик озакка булмаса, бәлки, шунда урнаштырып торсак кына инде. Ничә көнгә килдегез сон?

Шатланып куйды Лена. Куанычыннан елмаеп та җибәрде бугай әле.

—Мин озакка түгел. Иң күп дигәндә дә ике-өч көннән артык калмам.

Кунакханәнең ян коридорында, иң ерак почмакта урнашкан бер бүлмәдән урын бирделәр үзенә. Анда бер студент яши икән инде, шунын күршесенә. Шартлары чамалы гына булганга бәясе дә кыйммәт түгел иде. Монысы да мөһим иде анын өчен.. Менә ич ничек кулай килеп чыкты. Администратор хатынга күп рәхмәтләр әйтеп, ул үз бүлмәсен эзләп тапты. Урнашты. Анда яшәүче студент кыз институтта булу сәбәпле, бүлмәдә һичкем юк, тыныч иде. Урын өстенә ятып бераз хәл алырга да тырышып карады. Әмма, төн буе юлда булуга да карамастан, күзләренә йокы кермәде. Рафаэль турында уйлады. Беренче күрешүләре булачак ич. Бер-берләрен ошатырлармы? Ошатмасалар нишләргә?.. Ничек сөйләшергә, үз-үзенне ничек тотарга—мең төрле билгесезлек, мең төрле сораулар бимазалый иде анын күнелен...

Егет, анын уйлавынча, очулары тәмамланганнан сон, димәк, сәгать дүртләр тирәсендә килеп җитәргә тиеш иде шәһәргә. Шулай да дүрткә кадәр бүлмәсендә түзеп утыра алмады ул, өч тулып узгач та, киенеп түбәнгә төште. Ачкычны тапшырды. Һәм кесәсеннән блокнот чыгарып, анда кунакханә исемен һәм үзе урнашкан бүлмә номерын язып куйды, онытa күрмәсен тагы. Инглиз язучысы Мунронын "Энгер-менгер" дип исемләнгән хикәясе этәрде бугай аны болай эшләргә. Анын герое бит, шулай, чит шәһәрдәге кунакханәгә килеп урнашкач, үзе урнашкан кунакханәнең исемен һәм бүлмә санын онытып адашып йөри озак кына.

Кунакханә шактый ук борынгы бинага урнашкан икән. Фойеда төрле скульптуралар байтак, диварларында тарихи бизәкләр һәм язулар. Шулар белән кызыксынып, шуларны өйрәнеп вакыт уздырып йөрүе иде кызның.

Һәм, әлбәттә, күз чите белән берөзлексез урамнан керү ишеген күзәтте.

Администратор янындагы стенага эленгән зур сәгать төгәл 15 сәгать 40 минутны күрсәтә иде. Кинәт, тышкы яктан керә торган ике катлы зур ишек ачылып, аннан житез һәм нык адымнар белән хәрби киемдәге калку буйлы бер кеше килеп керде. Ул җәт кенә үзе артыннан ишеген япты да, әйләнә-тирәсендәге һичкемгә игътибар итмичә, ныклы һәм зур адымнар белән туп-туры администратор өстәле каршысына барып басты. Яшел ырмаулы фуражкасын килешле генә кыйшайтып куйды, көн эссе булгангадыр, гимнастеркасының иң югаргы сәдәбен ычкындырды. Һәм сорау белән мөрәҗәгать итте. Хәрби офицерга аерым ихтирам күрсәтеп, администратор шундук, зур дәфтәрен ачып, кабаланмый гына кемнеңдер фамилиясен эзләргә кереште.

Лена акрын гына аңарга якынлаша төште. Һәм тыныч кына эндәшергә җөрьәт итте:

—Рафаэль, бу мин—Лена.

Тавыш ишетелгән тарафка борылды офицер һәм, янәшәсендә үк басып торган кызны күреп, балкып елмаеп җибәрде. Аны менә шулай җиңел генә очратырмын дип һич көтмәгән иде бугай ул. Болытлар артыннан кояш килеп чыккандай булды аның бу елмаюы.

Кыз, үзенең уңайсызлануын сиздермәскә тырышып, күрешергә дип аңарга кулын сузды.

—Исәнме, Лена! Саратовка ничек килеп җиттең?..

Ул арада Лена, әле булса журналларын актаруда булган, администратор хатынга эндәште:

—Рәхмәт сезгә, эзләп мәшәкатьләнмәсәгез дә була, мине таптылар.

Алар, бер-берләренә карашларын текәп, үзара елмаешып баскан җирләрендә катып тордылар байтак кына. Икесе дә бәхетле иде. Икесе дә бу очрашуга һәм бер-бере белән күрешүгә ышанып җитмиләр иде бугай әле. Алты ай хат алышып та, хатлар аша күпме серләшеп тә, беренче кабат кына күрешүләре ич. Мәһабәт гәүдәле очучы белән юка һәм җиңел җәйге күлмәк кигән, биек үкчәле ак босоножкалы, күз явын алырлык матур һәм зифа бу кыз үтеп-сүтеп йөрүчеләрнең игътибарын җәлеп итеп өлгергән иде инде. Аларның килеш-килбәте һәм үз-үзләрен тотышы кеше игътибарыннан читтә калырга мөмкин түгел иде шул мәлдә.

Тораташ кебек баскан җирләрендә катып, шулай сүзсез генә карашып торуларыннан уңайсызланып, сүз булмаганда сүз булсын, өч көн үткәч—исәнме кодагый, дигән сыман, Рафаэль сорап куйды:

—Сез шушы кунакханәдә урнаштыгызмыни?

—Әйе. Мине табу сезгә җиңелрәк булсын дидем...

—Дөрес эшләгәнсез,—диде егет. Һәм тагы бер мәртәбә, кызның болай да менә сикереп чыгам-менә сикереп чыгам, дип типкән йөрәген яндырып, бар табигате белән балкып эчкерсез елмаеп җибәрде.—Без нигә дип әле болай һәм менә монда басып торабыз соң. Әйдә, урамга чыгыйк, монда бик матур бакчалар бар. Анда җырларда җырланган Саратов юкәләре үсә. Шунда кереп бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк.

Янәшә атлап бакчага таба үтте алар. Әмма кызны култыклап алу түгел, җитәкләшергә дә кыюлыгы җитмәде әле Рафаэльнең. Бер-берләренә сиздермәскә тырышып, кыз—егетне, егет кызны күзләде. Әмма сер бирергә ашыкмадылар әлегә.

Ленага туры карарга куркып барды Рафаэль. Ул өзелеп көткән, ул шигырьләр багышлаган, аның тынгылыгын югалткан һәм үзе еракта булса да аңарга бетмәс-төкәнмәс дәрт һәм гайрәт биреп торган кыз бара ич аның янәшәсеннән. Бу инде ул күз алдына китергән кыз гына да түгел.

Теге вакытта кышкы киемнән, читтән генә күреп калган иде бит ул аны. Ә бүген исә ул һинд киноларындагы гүзәлләрне онытырырлык. Юка җәйге күлмәк аның гәүдәсендәге һәммә борылыш һәм чигелешләрне ничек бар шулай күрсәтеп тора. Җыйнак гәүдә, нечкә бил, уттай янып торган зур күзләр, иңбашына сузылып төшкән чем кара чәч толымнары—беренче күрүгә үк аның күз явын алды, башын әйләндерде. Ходайдан сабырлык сорап, ике кулын йомарлап, иреннәрен кысып, күңелендә туган хисләрне авызлыклап чак түзеп барды ул шунда. Ул төшләрендә күреп саташканга караганда да күпкә нәфисрәк, ягымлырак һәм, күренеп тора, акыллырак та икән бит аның Ленасы.

Билгеле инде, үзалдына кыз да кайбер нәтиҗәләр ясап өлгергән иде. Иң элек, бары тик хәрбиләргә генә хас, төз һәм җыелган мәһабәт гәүдәсе белән җәлеп итте аны Рафаэль. Тугыз ел хәрби хезмәттә узган яшьлек үзенекен иткән. Таза дип тә әйтеп булмый иде үзен, ябык дип тә, анардан көч һәм гайрәт бөркелеп тора. Кояшта каралган озынча йөз, киң мангай, куе кара кашлар һәм бераз бөдрәләнеп торган чем кара чәч. Туры борын уртасында ниндидер яра эзе күренеп тора. Ап-ак тешләр, ул көлеп тә җибәрсә, кояш чыккан сыман яктырып китәләр. Гомумән, елмайганда һәм көлеп җибәргәндә, аның калын иреннәре һәм коңгырт кара күзләре генә түгел, бөтен йөзе, бар булган табигате балкый, тантана итә төсле иде. Ә инде ул кычкырып көлеп җибәрсә—дөньяда булган бар кайгы, хәсрәтең онытылыр. Хатлары аша аз гына да аңламаган, күз алдына китерә алмаган икән бит аны Лена. Тормышта ул күп мәртәбәләр кызыклы һәм күңеленә якын , үз тоелды аның.

Беренче тәэсирләр әнә шундый иде. Бер-берен алар шундый итеп күрде. Әмма бу хакта ник берсе, ялгышып кына булса да, бер сүз әйтсен. Кыскасы, сер бирмәделәр. Бу тәэсирләр һәр икесенең үз күңелләрендә калды.

Кунакханәдә чакта алар ни сәбәпледер, күрәсең кеше арасында булгангадыр, рус телендә сөйләштеләр. Бакчаның тыныч бер почмагында урнашкан агач эскәмиягә килеп утыргач, Лена тәкъдим кертте:

—Әйдә әле, Рафаэль, үзебезнең татар шәһәре Сары тауда бер рәхәтләнеп татарча сөйләшеп утырыйк әле, дан булсын.

—Мин бик шатланып риза. Татар телен мин гел сагынып яшим. Авылдан киткәч тә беренче елларда русча сөйләшеп телләрем ара торган иде. Инде ияләштем, тел көрмәкләнми хәзер,—диде дә, тыйнак кына көлеп алды Рафаэль. Һәм шул көлүе белән ике арада булган бөтен рәсмилекне юкка чыгарды да куйды. Гаҗәп көчкә ия иде аның көлүе—башкаларны да үзе артыннан ияртә һәм сихерле торган көлү, тылсымлы көлү.

Кыз да анарга кушылып көлде. Һәр икесенә дә рәхәт һәм җиңел булып китте шунда.

—Тагы бер тәкъдимем бар,—диде Рафаэль, тәмам ияләшә төшеп.— Рәсмилекне ташлап “Син”гә күчикме әллә...

—Әлбәттә, без бит инде алты ай танышлар.

—Йә, Лена, инде сөйлә: юлда нинди газаплар кичердең, ничек килеп җиттең?

—Бернинди газап та кичермәдем, бик яхшы килеп җиттем. Смышляевкада (Куйбышевтагы аэропорт исеме- авт.) көтеп утыру да булмаса әллә кайчан Саратовта булыр идем инде. Самолет тиз оча икән ул.

Самолет турында сүз чыккач, Рафаэльнең күзләре яна башлады.

—“Тиз оча” дисең. Кукурузникның очуы да тиз булса. Менә без очкан самолетларны күрсәң иде син, Лена. Артларыннан күз иярми. Ә бераздан менә тавыштан да тизрәк оча торган самолетлар көтәбез. Алары инде дөньда тиңе булмаган самолет булачак...

—Тавыштан тиз дисеңме? Шундый тизлек тә буламы?!. Самолет ничек шулай очсын икән?—дип, гаҗәпләнүен белдерде кыз. Үз колаклары ишеткәнгә ышанасы килмәде аның.

—Безнең Советлар Союзы авиациясе кешенең хыялына сыеша алмас уңышларга ирешәчәк, Лена. Тиздән, хәтта, мин сиңа сер итеп кенә әйтәм, җирнең тарту көченнән ычкынып, космоска, башка планеталарга оча торган самолетлар да булачак. Советлар Союзының уйлап табучы конструкторлары дөньяда беренче хәзер. Мин әле, боерган булса, күрерсең, шул планеталарга очу турындагы хыяллар белән дә яшим. Һәм бу хыялымның да тормышка ашарына өметем зур.

—Ул планеталарда кызлар бик чибәр булса...

—Әлегә әйтә алмыйм, күреп төшкәч, беренче булып сиңа сөйләрмен, яме,- дип кенә куйды ул бу юлы. Шярмады, көлмәде. Күзләре зәңгәр күккә текәлгән иде...Һәм шундук җиргә дә әйләнеп кайтты тагы үзе. Сорашырга кереште.—Эшләрең ничек бара соң? Мәктәптә эшләү артык авыр түгелме?..

—Укытучының көне шул ыгы-зыгы белән үтә дә китә инде аның. Балалар тыңлаулы анысы, тырышлар. Әмма инглиз телен өйрәнү һәркемгә дә бер төрле үк җиңел генә бирелми. Ачуны чыгарган чаклары да була... Мин бит үзем аспирантурада калу турында хыяллана идем. Өч ел мәктәптә эшләү мәҗбүри диделәр.

—Мин дә хәрби академиягә керү турында хыялланам. Әмма мәктәптә алган белемне, онытып бетермәгән булсам, яңартырга туры киләчәк. Немец телен дә оныта башлаганмын инде, сугыш вакытында су кебек эчә башлаган идем...

Рәхәт иде аларга шулай үзара сөйләшеп утыру. Әйтерсең лә, гомер буе аралашып яшәгән күптәнге танышлар иде алар. Очрашуларына бер сәгать узмаган, ә инде бер-берен ярты сүздән аңлый башладылар.

—Монда бик яхшы театр бар. Әллә шунда барып карыйкмы,—диган тәкъдим кертте Рафаэль бераздан.

Лена бик теләп ризалашты, үзенең театр яратуы турында хатларында да язган иде инде ул. Константин Симонов әсәре буенча куелган спектакль карады алар. Ниндидер космополит галимнәр турында. Эчтәлеге әллә ни хуш килмәде күңелләренә. Ә актерларның уены әйбәт иде, алары ошады.

Театрдан соң да, урамда йөрмәделәр, алдан планлаштырган программасы булган икән әле Рафаэльнең.

—Хәзер ресторанга барабыз,—диде ул, күңел күтәренкелеге белән.

Ресторан турында ишеткәч тә куркуга төшә язды Лена. Ресторанны ул бик байлар гына йөри торган һәм шуның өстенә җүнле кешеләр читләп узарга тиешле урын кебегрәк кабул итәргә күнеккән иде. Аның ресторannарда һичкайчан булганы юк. Шуңа, кабалана төшеп, каршы килде ул.

—Юк, Рафаэль, мин укытучы кеше, ресторannарга йөрү килешмәс. Әйдә, берәр столовойга керик тә ашап чыгыйк.

Шунда егетнең көлеп җибәрүен күрсәгез икән сез. Кеше-кара күренми иде әйләнә-тирәдә, рәхәтләнеп кычкырып көлде ул. Әмма башкаларны үпкәләтә торган көлү түгел, киресенчә, юата, иркәли торган көлү иде бу.

Рафаэль генә шулай көлә белә.

—Беренчедән, кичке жидедән соң, Саратовта гына түгел, бөтен Советлар Союзында ашханәләр ябык була, эшләми, Лена. Икенчедән, без бит ял итәбез. Син отпускада. Ә мин синең белән очраштым. Бу вакыйгамы? Вакыйга! Бер истәлек булыр, рәхәтләнеп утырып чыгыйк, мин сине чакырам, Лена,—диде ул.

Шул чак кызның күзләренә шундый итеп карады ки, аңарга карышу,

аны тынламау мөмкин түгел иде.

—Ярый, барыйк алай булгач, монда безне танучылар булмас,—дип ризалашырга мәжбүр булды кыз.

Шәһәр үзәгендә, Лена тукталган кунакханәгә якын гына урнашкан ресторанга килделәр. Ишегенә "Урыннар юк" дигән такта элеп куйганнар. Атна ахыры булу сәбәпледер, чират торучылар да бар иде булса кирәк. Рафаэль исә, югалып калмады, Ленаны житәкләп алды да, ышанычлы адымнар белән туп-туры зур калын ишеккә таба узды. Ишек төбендә, керүчеләрнең юлына аркылы төшеп торган швейцар, хәрби офицер килүен күргәч, аларга ишекне үзе ачты һәм "хәерле кич" теләп каршы алды.

Ресторан шыгрым тулы, шау-гөр килеп тора. Залнын ин түрендә бердәнбер өстәл буш булып, аларны шунда утырттылар.

—Монда сине һәркем белә. Бик еш буласыңмы әллә,—дип, сорамый булдыра алмады кыз.

Фуражкасын өченче буш урындыкка салып, чәчләрен сыпыргалап торган Рафаэль чираттагы мәртәбә, балкып, елмаеп жибәрде.

—Юк, бу ресторанга беренче керүем. Шимбә киче булганга, сине эзләп барышлый, мин алдан ук урыннарны сөйләшеп куйган идем. Дөрес эшләгәнмен, шулай бит, әйеме, Лена?

—Дөрес эшләгәнсен...

—Бу матур кыз Саратовка килгән беренче көнендә үк ачтан үлмәсен әле дигән идем.

Урта яшьләрдәге официант хатын килеп басты аларның каршысына.

—Нәрсәләр ашарга-эчәргә жыенасыз,—диде, бер кызга, бер егеткә битараф карашын текәп. Ул инде көне буе эшләп шактый ук арыган күренә. Шулай да дорфа кыланмый, ихтирамлы иде үзе.

—Миңа чәй белән печенье булса, житәр...- дип жавап кайтарды кыз, дәшми торудан уңайсызланып. Һәм, ялгышмадыммы дигән сыман, Рафаэльгә карап куйды.

Егет меню өйрәнү белән мәшгуль иде. Официант анарга да сузган иде ул катыргы кәгазь кисәген, кыз баш тартты, аны кулына алмады. Барыбер бер ни аңламый ич, ресторанның тәртибен дә белми, әнә, Рафаэль ни эшләсә, шуны кабатларга тырышып утырган көне.

Көттерә төшеп кенә, аркалы урындыгында ипле генә киерелеп, заказ бирергә кереште Рафаэль. Әллә ниләр санап чыкты. Ул әйткәннәрне тәртибе белән язып барды официант хатын. Итагатьле һәм игътибарлы иде ул алар өчен, ашыктырмады, кабаланмады. Кайбер киңәшләр дә бирде бугай әле үзләренә. Аларның ризык сайлап сөйләшүләренә кысылмады Лена. Ни китерсәләр дә, тизрәк кенә китерсеннәр, дип уйлап утырды. Тамагы нык кына ачыккан иде шул анын. Саратовка килеп төшкәннән бирле авызына ризык капканы юк. Моңарчы уена да кереп карамады. Ә монда килеп кергәч, аш-су исе тамак төпләрен кытыклый башлады әнә.

Кергәч тә Рафаэль аңарга урынны түрдән тәкъдим иткән иде. Шунардан файдаланып ул инде, берочтан, бу биек һәм тарихи залнын диварларындагы рәсемнәр һәм скульптуралар белән дә танышып чыгарга өлгергән иде. Ошый иде аңарга монда утыру.

Официант киткәч тә, тамак кайгысын онытып торасы килүдән, Рафаэльдән Саратов шәһәренең тарихи урыннары хакында сораштырырга кереште ул. Белгән кадәресен сөйләде егет.

—Мин бит, Лена, үзем дә синең кебек командировкага килгән кеше монда. Саратовны әле бик белеп бетермим. Ә менә Куйбышевка килгән булсаң, ул шәһәрне яхшы беләм. Ул зуррак та, матуррак та шәһәр, тәүлекләр буе таныштырып йөрер идем үзеңне.

Ул арада, официант хатын озак көттермәде, подносына дөнья кадәр ризык төяп килеп тә житте. Өстәл сый белән тулды.

—Болар барысы да безнең өченме?—дип сорамый булдыра алмады Лена. Гажәпләнерлек тә иде шул, ниләр генә алмаган иде Рафаэль.

—Безнең өчен. Кирәксә, тагы да китертербез,—диеп куйды егет, күнеле булып.

—Әмма мин болай күп ашарга өйрәнмәгән. Шуның өстенә, кич бит инде хәзер, йокы алдыннан...

—Ресторанда күңеленә ошаганны ашыйсың, ошамаганын калдырасың. Монда үзебез хужа, һичкем безне куаламый, мәжбүр итми, Лена.

—Шулай дисәң генә. Әмма мине тәлинкәгә салынганны ашап бетерергә өйрәткәннәр.

—Һәм дөрес тә. Безнең татар халкы ризыкны олыларга, кадерләргә өйрәнгән бит ул. Мине дә бала чактан шулай өйрәттеләр—ипинең валчыгын да жиргә төшермәскә, ашаган тәлинкәне ялап ук куярга. Кемгәдер сәер тоелырга мөмкин, әмма дөрес тәрбия.

Рафаэль каршыдагы ике фужерга ашыкмый гына кызыл шәраб салды.

—Әйдә, безнең очрашу хөрмәтенә күтәрик,—диде ул, үзенә якынрак булганын кулына алып.

Лена карышмады. Алар, матур зеңгелдәү авазы чыгарып, шәрабларын чәкештереп алдылар. Рафаэль эчеп жибәрде. Лена авыз гына итте дә кире өстәлгә куйды шәрабын.

Егет, нигә инде алай иттең, бераз гына булса да эчмәдең, дигән сыман карап куйса да, сүз куертырга кирәк санамады. Кызның шәраб эчмәвенә куанып та куйды булса кирәк әле ул. Гомумән, уе изгелектә булган ир ат һичкайчан кыстый-кыстый шәраб яисә исерткеч эчертми ул хатын-кызга.

—Рөхсәт булса, Рафаэль, мин иң элек рәхәтләнеп чәй эчәр идем,—дип, өстәл читендә торган чәйнеккә үрелде Лена.—Уфадан чыгып киткәннән бирле чәй эчкәнем юк. Чәйне сагындым.

—Унайсызланма, ни теләсәң, шуны аша, эч, Лена. Монда син үзең хужа, күңелең ни теләсә шуны эшлә,—дип, кызны кайгыртуында булды егет, чәйгә диеп алынган тәм-томнарны да аның каршынарак күчереп куйды.

Бер-берен кысташып, аш арасында дөнья хәлләрен дә сөйләшеп-уртаклашып озак кына утырдылар алар ресторанда. Әмма, барыбер, алынган ризыкларының байтагы артык булып чыкты. Өстәлдә калды.

—Сез нигә шулай нәзберек булып чыктыгыз соң әле, бик аз ашагансыз ич. Утырырга иде әле, ашарга иде. Мин сезгә иң тәмлеләрен генә соратып китергән идем,—дип, аларны, аналарча кайгырту белән, кыстарга тырышып карады официант хатын.

Зур рәхмәтләр әйтеп чыгу юлына юнәлделәр. Һәм, ни арада, алар инде Лена урнашкан кунакханә ишеге төбенә барып житкәннәр иде.

Туктап калдылар. Кичке урам бушап, тынычланып калган. Бер-беренә карашып торды алар бертын. Кочаклашу-үбешү турында уйлаган да юк, кая ул. Ялгыш кына житәкләшкән, куллары-кулга тиеп киткәндә дә унайсызланудан колакларынача кызарып чыга иде аларның. Тәрбия башка һәм заманы бүтән иде шул!.. Хәзерге яшьләр генә бит ул, бергә йоклап аерылышкан чакларында, "между прочим" дигән сыман, бер-берләренен исемнәрен сорашалар һәм телефон номерларын алышалар.

—Театр өчен дә, ресторан өчен дә рәхмәт сиңа, Рафаэль,—диде кыз, ихлас күңеленнән.—Онытылмаслык дәрәжәдә матур булды бу кич...

—Үзенә рәхмәт. Тыныч йокылар. Иртән мин сиңа шалтыратырмын, ярыймы Лена.

—Ә син ничек, иртүк килеп тә житәргә уйлыйсынмы?

—Мин бит ерак китмим. Мин дә шәһәрдә кунакханәгә урнаштым,—диде Рафаэль.—Моннан ерак та түгел, жәяүләп ун-унбиш минутта кайтып житәм.

—Хәерле юл һәм тыныч йокылар алай булгач...

Хушлашып кулын болгады да калын ишекләр артына кереп югалды Лена. Хушлашу жинел булмаса да, Рафаэльнең күңел күтәренке, кәеф әйбәт иде. Ул тиз-тиз атлап, күңеленә хуш килгән көйләргә сызгыра-сызгыра, төнге Саратов урамнары уртасыннан үз кунакханәсенә таба ашыкты.

## 15

Ярты төнгә кадәр күзенә йокы кермәде Рафаэльнең. Йоклый торган көн идемени соң. Күпме вакыйга, күпме хыял, хис, тойгылар кичте ич бүген аларның башыннан. Төне буе боргаланып чыкты.

Ә нәкъ шул вакытта шул ук шәһәрдәге икенче бер кунакханәдә, тәрәзәдән төшкән ай нурлары яктысында, икенче бер кеше—Лена исемле кыз, узган көндәге очрашу тойгыларыннан аерыла алмыйча газапланды. Бер көн, ягъни бер кичкә сыйган вакыйгаларны барлады, шуларга нигезләнгән уй-хыяллар бишегендә тибрәнеп ятты.

Иртәгесен унберенче яртылар тирәсендә бүлмәдә телефон шалтырады. Рафаэль... Лена инде юынып-киенеп, инглиз теленнән зачетка әзерләнүче күршесенә консультация бирү белән мәшгуль иде. Күршесе—утыз яшь чамасындагы ике балалы хатын—Саратов өлкәсендәге бер авылда укытучы булып эшли икән. Сонлап кына педагогия институтына читтән торып укырга кергән. Танышу гына түгел, дуслашып та өлгергәннәр иде инде. Кешеләр бер-беренә игелекле, ачык һәм ярдәмчел дә иде шул ул елларда.

Рафаэльнең күңеле гадәттәгедән дә күтәренкерәк иде бүген. Моны Лена шундук сизеп алды. Үзеннән затлы хушбуй исләре килеп тора, "Шипр" иде булса кирәк. Йөзеннән, күзләреннән һәм үз-үзен тотышы, һәр хәрәкәтеннән гайрәт нурлары сибелә.

Исәнләштеләр, хәл белештеләр.

—Көн кояшлы, аяз һәм искиткеч матур булырга ошаган бүген. Бу—синең хөрмәткә, Лена,—диде егет, кызның болай да күтәренке күңелен тәмам очындырып.

Лена аңарга мөлаем елмаю белән җавап кайтарды, күңелендәген аңлатып бирерлек сүзләр таба алмады шул мизгелдә.

Юкә күләгәсе төшеп торган тыныч урамнардан саф һава сулап янәшә атлап бара торгач, Идел ярына барып чыкты алар. Иске бер дебаркадерга урнашкан кафега кереп тамак ялгап, чәйләп чыктылар.

—Идел буйлап сәяхәткә чыксак?—дигән тәкъдим кертте Рафаэль. Кыз бик теләп ризалашты.

—Үзебезнең Агыйделдән башка бер елганы да күргәнем юк иде әле минем.

Катерга утырып Идел уртасындагы зур булмаган комлы утрауга барып төште алар. Ял көне булу сәбәпледер, пляжда халык мыжгып тора. Алар исә, бераз арырак китеп, зур ябалдашлы ялгыз агач күләгәсе астыннан урын алдылар.

—Су коенабызмы?—дип сорады Рафаэль.

—Бик коеныр идем дә бит. Белмәдем, син дә кисәтмәдең, киемем туры килми.

—Мин үзем дә уйламаган идем шул...

Ленага, юка ефәк күлмәктән генә булу сәбәпле, әллә ни эссе түгел, түзәрлек иде әле. Ә Рафаэль хәрби формадан, өстендә калын китель,

аякларында кара ботинка. Башта ул берәм-берәм кителенең сәдәпләрен ычкындырып утырды, анннан, кыздан рөхсәт сорап, аны салып ук куйды. Үзе берөзлексез кызыклы һәм мавыктыргыч әңгәмә дә алып бара иде ул. Сүзгә шул тикле оста ки, һич кайчан төртелеп тормый, югалып калмый. Вакытын белеп кенә, җаен чыгарып кына, җитди темага да кереп чыга, шаяртырга, мәзәк хәлләр сөйләп алырга да вакыт таба. Нәрсә турында сөйләшсә дә ул мәгълүматлы һәм белеп сөйләшә иде.

—Хәрби хезмәттә булу бик авырдыр?—дип, сорап куйды аңардан кыз.

—Туганнардан, туган яктан читтә булуы гына читен. Ә хәрби тәртипкә мин тәмам күнегеп беттем инде. Башка төрле тормыш, башка төрле яшәү юктыр сыман тоела вакыт-вакыт.

—Ә очучы булу теләге кайчан туды?

—Гомеремдә беренче тапкыр самолет күргәч тә. Бала чагымнан ук...—һәм шул урында бераз уйга калып торды Рафаэль.—Ә бәлки тагы да иртәрәктер. Үзебезнең капка төбендә каз бәбкәләре көткәндә, минем өйгә кереп китүемне көтеп, баш очымдагы зәңгәр күкне иңләп очучы тилгәнгә соклана идем мин. Сәгатьләр буе карап утырсам да туймый идем, шундый тыныч һәм горур, шундый матур итеп оча иде алар, канатларын җилпегәннәре дә күренми торган иде. Малайлар яратмый иде аларны, тидерә алмасалар да, ташлар атып куркытмакчы булалар иде. Ә мин исә, тилгән күрү, тилгәннең очуына карап соклану өчен генә булса да урамга чыгарга ашкынып тора идем. Яшел чирәм өстенә чалкан ятып күзәтә идем мин тилгән очышын... Мин үзләрен яратканны белептер, күрәсең, алар үзләре дә мин саклаган бәбкәләргә тимәделәр...

—Тилгәнне яраталар диме. Ерткыч кош ич ул, каз бәбкәләрен, чебешләрне алып китә.

—Сакласаң, тими ул,—дип, шаяруга күчәргә ашыкты егет. Һәм шунда Идел өстен иңләп очкан акчарлакларга текәлде.—Карале, Лена, су өстендә акчарлаклар да шулай ук матур оча икән бит. Алар да бит балык аулый, балык тота. Әнә, дельтоплан сыман, ничек тыныч һәм ипле генә күзәтеп йөриләр-йөриләр дә, кинәт кенә уктай атылып су өстенә ташланалар. Балыкны эләктереп алуга, кире югары күтәреләләр, суга канатлары тими кала хәтта. Нинди камиллек, нинди югары пилотаж... Безгә, хәрби очучыларга, әле өйрәнергә дә өйрәнергә генә икән кошлардан. Исең-акылың китәрлек бит ә!.. Идел яисә башка бүтән бер зур елга буенда үскән булсам, кем белә, бәлки мин дә, шагыйрьләр, рәссамнар кебек, акчарлакларга сокланып үскән булыр идем. Нишлисең, искиткеч матур табигатьле Башкортостанда үскәнмен. Һәм Агыйдел буенда түгел, нәни генә инеш булып агышын башлаган Идәш буенда. Анда акчарлаклар очмый. Әмма тилгән бар, сандугач һәм былбыл оялары, тукран, көртлек, сыерчык һәм тагы йөз төрле сайрар кошлар.. Мин шуларны сагынып яшим, миңа алар кадерлерәк. Шуңа да аңлый алмыйм, һич кенә дә аңлый алмыйм, ни өчен дип акчарлакны сокланып күзәтәләр дә, тилгәнне тиргиләр, куалар—хаксызлык бит бу. Юкса, алар арасында һичнинди аерма юк. Очулары бер үк төрле матур, табигать шул дәрәҗәдә камил итеп, канатлы итеп яраткан ки үзләрен... Яшәгәч, очкач, билгеле инде, һәркемнең ашыйсы килә. Ашыйсы килгәч, ауга чыгалар. Тилгән ит ярата, акчарлак—балык, аерма бары шунда гына...

Рафаэль шул дәрәҗәдә кызыклы һәм мавыктыргыч итеп фикер йөртә иде ки, аны сәгатьләр буе күзеңне алмый тыңлап утырсаң да туйдырмас төсле тоела иде. Алар, байтак кына янәшә утырганнан соң, аяк киемнәрен кулларына тотып, яланаяк су читләтеп йөреп тә килделәр. Аксыл сары ком өстеннән йөгереп яр читләрен сыйпап-сыйпап киткән вак-вак дулкыннар аларның йөрәк тибешенә кушылып сулыш аладыр иде сыман шунда.

Вакыт сизелми дә үтә. Инде Кояшнын төшкә авышуына да байтак ара узды. Көннен кыскарганнан-кыскара баруын, кичнен якынаюын искәргән саен, кызның йөрәге ныграк тынгысызлана барды. Якынлашып килүче кич куркыта иде аны. Чөнки белә, Рафаэльнен бүген Саратовта соңгы көне. Бик теләсә дә ул артык кала алмый. Бүген кичке уннан да кичекми ул үз частена кайтып житәргә тиеш. Иртәгесен таннан—хезмәт урынында. Ә ул кала. Кем белән кала? Рафаэль булмаса, ни калган аңарга бу шәһәрдә. Аны монда кем белә? Ул бит монда бер ялгызы, анын монда башка һичкеме юк. Һәм кирәк тә түгел. Егет китәр, әмма алга таба ни булыр? Алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең киләчәге бармы-юкмы, ул хакта авыз ачып бер сүз дә сөйләшмәде бит әле алар. Андый сүзне кыз үзе башлый алмый иде, әлбәттә. Бик теләсә дә башлый алмый. Ә егет исә, ул хакта, нигәдер, ялгышып та сүз кузгатмый. Әллә соң ошатмадымы ул аны, вакыт уздырып кына йөрүеме?.. Ул аңарга битараф түгелме—кызнын күнелен торган саен әнә шундый сораулар, уйлар телгәли башлады.

Рафаэль исә мавыгып сөйләшүеннән аерыла алмый һаман. Һәм, уйламаган жирдән, бөтенләй көтелмәгән, кешенең башына килмәстәй сораулар биреп куя.

—Ничек уйлыйсын, Лена, синенчә ничек, кошларнын кеше буласы килгән чаклары бармы икән?

Сискәнеп китә язды кыз. Кара инде, гомер кеше башына килми торган сорау бит бу. Һәм үзенә дә кызык булып китте шунда.

—Кошларда фикер йөртү сәләте һәм хәтер булуы хакында укыганым да, ишеткәнем дә бар, Рафаэль. Әмма белмим шул. Һәм иң акыллы, тугрылыклы кош кара карга дип әйтүләрен дә беләм. Ләкин, мин хайваннар, кошлар турында бик аз беләм шул, кызганычка каршы... Ә син ничек уйлыйсын?

—Кызыкмый торганнардыр, дип уйлыйм. Чөнки, кошны үзе янында тоту өчен кеше читлек уйлап чыгарырга мәжбүр булмас иде. Кенәриме ул, попугаймы, әллә күгәрченме, читлеген ачсан—ул кош шундук ирекка чыгып очарга омтыла... Ә менә кеше гомер гомергә канатлы кошларга сокланып, кош сыман очарга хыялланып яшәгән. Берәүләр оча торган ашъяулык турында хыялланган, икенчеләр оча торган ат, оча торган барска табынган, ак бүрегә атланып диңгез һәм тауларны кичкәннәр... Ишеткәнен бардыр ич, халкыбыз яратып жырлаган жырларның берсендә шундый сүзләр бар: "Жил булып исәр идем лә, кош булып очар идем..." Ләкин, дәвамын гына искә төшерә алмыйм әле менә.

—Әйе, ишеткәнем бар кебек,—дип жөпләде кыз да.—Ләкин, тынларга яратсам да, оятыма каршы, мин халкыбызның борынгы жырларын бик белеп бетермим шул.

—Авылда үсмәгәнгә шулай ул,—дип тынычландырырга ашыкты аны Рафаэль.—Мин дә бит, әнә, чит жирләрдә йөри торгач, үзем жырлап үскән жырларны оныта башлаганмын.

—Юк, Рафаэль, син татарча шундый матур сөйләшәсең һәм мина шундый матур итеп үзебезнең туган телебездә хатлар, шигырьләр язасың. Мин синең, чит жирләрдә күпме яшәп тә, телне шулай онытмавына, чиста һәм саф итеп саклавына сокланам да әле хәтта.

Үзе турындагы мактау сүзләренә артык исе китмичә, тагы үз стихиясенә әйләнеп кайтты Рафаэль.

—Ә син беләсеңме соң, Лена, Жирнең Кояш тирәли әйләнүе хакында, Коперниктан күпкә алданрак, бер татар шагыйре: " Сөхаил Гөлдерсен янында Жир Кояш тирәли әйләнгән кебек бөтерелде" дип язган? Тарихи ачыш ич бу!

—Ишеткәнем бар. Минем әни Казанда чыга торган "Совет әдәбияты"

һәм "Азат хатын" журналларын алдыра. Шуларның берсендә язганнар иде аны. Ялгышмасам, ул шагыйрнең исеме—Сәиф Сараи.

—Әйе, бар ул андый шагыйрь. Әтидән ишеткәнем бар, ул бит безнең Уфада Галия мәдрәсәсендә укып чыккан кеше, Сәйфи Кудаш белән бер сыйныфта укыганнар. Әдәбияттан Галимҗан Ибраһимов үзе укыткан аларны.

—Менә ничек...Сәйфи Кудаш ул минем әнкәй белән бер авылдан. Син үзең дә бик күп укыйсыңдыр, шулаймы Рафаэль?

—Безнең хәрби часть китапханәсе шактый ук бай анысы. Ләкин, кызганыч, татар китаплары юк.

—Ә мин менә Уфада яшәп тә Тукай белән Такташтан башканы белмим.

—Тукай... Такташ...—дип, уйга бирелеп торды Рафаэль.—Мин аларның күпчелек әсәрләрен яттан белә идем. Хәзер дә еш кына үзләрен хәтергә төшерәм. Ничек дигән әле Такташ? "Шлем кидертербез айга да..." дигәнме? Менә шулай, әле космоска очу турында хыялланучы да булмаган, ә безнең татар шагыйре әнә нинди юллар язган... "Шлем кидертербез айга да"—шәп әйткән бит, ә!.. Боерган булса, кидертәбез дә без аны...

Рафаэльнең, очынып, канатланып сөйләгән бу сүзләре, фикерләре, өермәдәй күтәреп алып, Ленаны да үзе артыннан ияртеп китә язды тагы. Сабыйдай куанып сүзгә кушылырга ашыкты ул.

—Ә беләсеңме, Рафаэль, мин дүртенче курсны тәмамлаганда нинди курс эше язган идем... Тукайны инглиз теленә тәрҗемә итү проблемалары хакында.

—Тукайның инглизчәгә тәрҗемәсе бармы?

—Менә шунда да хикмәт, юк шул. Ә дөньяга таныту өчен андый тәрҗемәләрнең булуы кирәк. Мин шуны нигезләп, Тукайның берничә шигырен тәрҗемә дә итеп караган идем.

—Кызык... Миңа да укып күрсәтерсең әле ярыймы?

—Хәтерләмим шул.

—Оныткан булсаң, башка чакта укып күрсәтерсең. Минем бик тә тыңлап карыйсым килә—инглиз телендә ничек яңгырый икән Тукай... Ә син аның менә мондый юлларын тәрҗемә итмәдеңме:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы...

—Юк, ул шигырьне тәрҗемә итмәдем. Укыганым бар.

—Син аны минем өчен генә тәрҗемә итә алмассыңмы, Лена. Мин аны самолетта күккә, бик биеккә күтәрелгәч, укыр идем. Татар һәм рус телләрендә бик еш кабатлыйм мин ул юлларны. Безнең эскадрелиядагы һәммә очучы яттан белә аның русчасын. Үзем өйрәттем!

"Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы..." Гаҗәп көчле әйтелгән бит, күпме кабатласаң да туйдырмый, уңмый, киресенчә тирәнәя, тагы да мәгънәлерәк кенә була бара торган сүзләр...

Шәһәргә алар шактый кичегә төшеп кайтты. Иң элек, Идел буендагы бер кафега кереп тамак ягын кайгырттылар. Ашагач-эчкәч, елга читләп сузылган бакчада бер тыныч почмактан үзләренә урын таптылар. Әле аерылу, хушлашу турысында сүз башлаучы булмаса да, ул мизгелнең якынлашуын һәр икесе сизеп, тоеп тора иде. Читләп кенә булса да Лена башларга мәҗбүр булды ул хактагы сөйләшүне:

—Рафаэль, миңа кайтып китү өчен билет ягын кайгыртырга да вакыттыр инде,—диде ул, бер уңайлы форсат табып.

Анардан мондый сүз көтмәгән иде бугай Рафаэль. Ул кинәт тынып, балтасы суга төшкән кешедәй чарасыз торып калды. Ни дияргә, нәрсәдән

башларга белми торды сүзен. Ә Лена бит аны, шатланып ук риза булмаса да, бу тәкъдим белән бик тиз килешер дип көткән иде. Чөнки, аның үзләре арасындагы мөнәсәбәт һәм киләчәк хакында сөйләшер арасы бар иде бит. Ул хакта, ике көн бергә булып та, ялгышып та сүз кузгатмады Рафаэль. Димәк, кирәк дип тапмаган...

Рафаэль җавапсыз калды. Кызның күңеле булырлык ник бер сүз әйтсен икән шунда. Дәшмәве белән үтерде. Әмма, үзенә карасаң, ул торган саен кәефсезләнүендә иде. Очып барган җирдән канаты каерылып җиргә егылып төшкән кош диярсең. Янып торган күзләрен моң басты, елмаеп туймаган иреннәре җансыз калды...

Күпме көтеп тә җавап ишетмәгәч, кыз үзе йомгакларга ашыкты башлаган сүзен.

—Күрештек тә менә... Мин синең бик яхшы кеше икәнлегеңне белдем. Синең белән җинел һәм бик кызык та икән. Әмма китәргә вакыт...

Бу сүзләрне сөйләгән кызга күзләрен тутырып, берни аңлый алмыйча, колагы ишеткәннәргә ышанмыйча карап торды Рафаэль. "Яхшы кеше" имеш. Бу нәрсә дигән сүз инде? Очраштык, күрештек һәм шуның белән вәссәлам, дигәнне әйтергә теләдеме...Мондый финал көтмәгән иде ул.

—Миңа тизрәк кайтып китәргә кирәк, Рафаэль. Никадәр тизрәк кайтып китсәм, шулкадәр яхшырак. Чөнки мин синең эшеңә зыян китерергә теләмим. Менә шул,—дип, әле булса әйтер сүз таба алмый югалып торган егеткә күтәрелеп карады ул.

—Син миңа зыян итмисең. Киресенчә,—дигән сүзләр чыкты, ниһаять, аның авызыннан.

Кыз, үзе дә белешмәстән, елмаеп куйды шунда. Аның йөзендәге аязуны күргән Рафаэльгә дә җан керде кинәт.

—Син чынлап та минем кайтып китүемне теләмисеңме?—дип, кайтарып сорарга кирәк тапты кыз, колагы ишеткәннәргә әле булса ышанырга теләмичә.

—Син башка сыймастай сорау бирәсең, Лена. Ничек инде мин синең кайтып китүеңне телим. Мин бит сине, сине... шундый көтеп алдым.

Кызның иңнәренә пар канат үсеп чыккандай булды шул мәл. Әйләнәсе, биисе, кош булып очасы килде аның шунда. Колак төбендә Штраусның "Вена урманы әкиятләре" вальсы яңгырый башлагандай булды кинәт кенә.

Рафаэльнең исә, кызны кочып аласы, күтәрәсе һәм аны кулыннан төшермичә торып йөгерәсе килде шунда. Әмма кочып алырга гына кыймады һәм кай тарафка йөгерергә икәнлекне белмәде.

Күңелләрен кинәт кенә өермәдәй биләп алган хисләр ташкыны тыныч кына утырырга ирек бирмәде аларга. Күңелдәге шул хисләрне инде аңлатып бирергә генә кала бер-берсенә. Ике яклап төрле-төрле агачлар һәм чәчәк клумбалары тезелеп киткән сукмак буйлап атлап китте алар. Үзенең көтмәгәндә бирелгән соравы белән Лена ярдәмгә килде.

—Карале, Рафаэль, монда без бөтенләй күрмәгән агачлар да үсә икән бит?

—Саратов бит шактый ук көньякта. Шуңарга агачлары да башкачарак. Ә мин шулай да үзебезнең як урманнарын яратарак төшәм.

—Ә иң яраткан агачың нинди?

—Каен, әлбәттә,—диде егет, аз гына да уйлап тормыйча.—Беләсең килсә, безнең Яңа Актауга каен урманы терәлеп кенә тора иде. Кызганыч менә, сугыш елларында аларны шактый ук сирәкләргә дә туры килде, утынга кистек. Мин үзем кистем аларны... Фронт өчен утын хәзерләдек.

—Кызганмадыгызмы?

—Кызганмаган кая, кызгандык. Фронт өчен дигәч, кистек инде... Аның каравы, үзебезнең өй каршысына, урам уртасы дип тормадым, мин йөздән артык яшь каен алып кайтып утырттым. Һәм, беләсең килсә, алар шундый матур булып үсеп киткәннәр ки, быел отпускага кайткач, үз күзләремә ышанмый сокланып карап тордым.

—Менә ничек...

Кинәт, җитдиләнә төшеп, кызның каршысына ук чыгып басты Рафаэль. Алар туктап калдылар. Тирән итеп сулыш алды ул һәм бар кыюлыгын җыеп әйтеп салды:

—Мин сине югалтасым килми, Лена. Мин синең китүеңне теләмим. Мин сине үземнеке, бары тик үземнеке генә итеп күрәсем килә. Син китсәң, мин канатсыз калачакмын. Ә минем ике канатлы булып яшисем, очасым килә... Бик күптән әйтергә теләгән тәкъдимем шул: чык миңа... Бергә булыйк!

Җавап көтеп кызга таба ике кулын сузды ул шунда. Һәм тынып калды. Сулыш та алмый көтте.

—Аңладым,—диде кыз, шактый ук көттерә төшеп. Ризалык билгесе итеп, нәфис һәм йомшак кулларын Рафаэльнең үзенә сузылган ике уч төбенә салды.

... Вакыт ул мәрхәмәтсез. Ул берөзлексез ашыга, һич туктап көтеп тора белми. Егетнең минутларны санап торган чагы иде инде. Ул ашыгыч рәвештә машина тотып, якын көннәрдә үк килеп чыгарга вәгъдә биреп, үзенең Разбойщинасына китеп барды. Лена берьялгызы калып кунакханәгә юнәлде.

## 16

Икенче көн инде, кунакханәдән дә чыкканы юк, кыз Рафаэльне көтә. Икенче көн инде ул үз-үзен кая куярга белми, тамагыннан ризык үтми. Шәһәргә чыгып, музейлар белән танышып, бераз дөнья гизеп кайтканда да зыян итмәс иде дә бит. Әмма аягы тартмады, ул чыгып кына китәр, шул чак аны эзләп Рафаэль килеп керер сыман тоелды аңарга. Аны таба алмыйча, кире китеп барса, ни хәл итәрсең... Ярый да аны көтеп торырлык вакыты булса, ул бит хәрби хезмәттәге кеше, минуты да кадерле булырга мөмкин. Үзе белән инглиз телендәге бер китап—Джек Лондонның “Мартин Иден” романын алган иде ул. Йә караватта ятып, йә утырып дигәндәй, иртәдән кичкә кадәр шул китапны укыды.

...Сишәмбе көн. Уналтынчы июнь. Кояш мәрхәмәтсез рәвештә кыздыра. Көн гадәттәгедән дә эссерәк. Ярый әле бүлмәләре күләгәле якта, шул коткара. Ул китап укып ята иде. Кинәт ишекне шакыдылар. Бу икеләнеп, сак кына шаку түгел иде, тыныч бүлмәне дер селкеткән шаку.

Күршесендәге читтән торып укучы хатын янына группадашлары да кергән чак иде, шулар барып ачты ишекне.

Ишекнең ачылуы булды, анда, килүче түгел, ул күтәргән бер кочак чәчәк күренде иң элек. Шул чәчәкләр артыннан тавыш ишетелде. Таныш тавыш.

—Минем Ленам монда яшиме? Кайда ул...—дип, бүлмә уртасына ук кереп басты ул артык кыстатып тормый гына.

—Ул кадәр тавышланма инде, монда мин, монда...

Лена, уңайсызланып, югалып калды бер мәлгә. Бүлмәдә үзе генә түгел ич, студент кызлар алдында уңайсыз. Һәм җәт кенә яткан җиреннән торып басты. Ярый әле юка халат кигән иде өстенә.

Рафаэль туп-туры аның каршысына килде һәм кочагындагы чәчәк белән күмеп куйды үзен.

—Безнең киләчәк гомеребез шушы чәчәкләрдәй матур һәм гел бергә булсын, Лена-гүзәлем.

Лена ни әйтергә дә белмәде. Алай да бүлмәдәге кызлар килде ярдәмгә. Алар бер-берсен бүлдереп букетның зурлыгын һәм матурлыгын мактарга керештеләр. Һәм шул арада кыз җәт кенә, шкаф ишеге артына качып, киемен алыштырып өлгерде. Чәчләрен тарап куйды.

—Паспортыңны алырга онытма,—диде Рафаэль, анарга якыная төшеп.

—Ул нәрсәгә тагы?.. Паспорт үзем белән.

—Тамак ялгап алабыз да бүген үк ЗАГСка барабыз.

—Әйе, анда безне генә көтәләр, ди...

—Барысы да сөйләшенелгән, килешенгән. Безне тагы нәкъ бер сәгатьтән чынлап та көтәләр анда.

—Шаяртма инде, Рафаэль, дөресен генә сөйлә. Болай да башым әйләнгән чак.

—Бернинди шаярту юк. Тимерне кызуында сугалар, Лена. Ишеткәнең бармы шундый сүзне?

—Ишетмәскә... Мин татар ич.

—Безнең минутлар санаулы. Киттекме?..—дип, ишеккә таба юл күрсәтте Рафаэль.

—Боларны нишләтәбез—алабызмы, калдырабызмы,—дип, өстәлне тутырып торган чәчәк букетына ым какты кыз. ЗАГС дигәне дөрес булса, аны үзләре белән алырга кирәктер бит.

—Чәчәкләр синеке!

Тагы аз гына икеләнеп, бер чәчәкләргә, бер Рафаэльгә каранып-каранып торды да, букетны кочагына алды кыз.

—Минеке булгач, минем белән булсын,—дип пышылдады, егетнең үзенә генә ишетелерлек итеп.

Чынлап та Рафаэль шаяртмаган булып чыкты. Кунакханә буфетында тиз генә тамак ялгап алдылар да туп-туры Саратовның үзәк ЗАГСына юл тотты алар. Чәчәк букетын Рафаэль Ленага кочаклатты.

—Күрсеннәр. Бөтен Саратов күрсен! Бүген бу шәһәрдә иң матур кыз син, Лена!

—Ә син, үзең?

—Мин—иң бәхетле кеше,—диде егет, озак уйлап тормый гына.

“ Мин дә бик бәхетле, Рафаэль”, дип әйтәсе килде кызның. Әмма, нидер тыеп калды үзен.

ЗАГСка барып житкәч кенә үзләренең кайда һәм нинди ният белән килүләрен аңлап алды Лена. Адымнарын сагайта төшеп, Рафаэльгә мөрәҗәгать итте.

—Бераз уйларга, әни белән булса да киңәш итәргә иде бит...

—Нинди уйлау, нинди икеләнү инде ул, Ленам.

—Пожар чыкмаган ич, ул кадәр ашыкмасак та ярар иде дим...

—Мин инде яна-яна күмергә кала яздым, Лена-гүзәлем. Артык көтәр хәлем юк. Яратам...

—Мин дә...- дип кенә әйтергә өлгерде кыз.

ЗАГС ишеген киереп ачып куйды егет, һәм иң алдан Ленаны кертте. Шуннан соң гына үзе узды. Ак блузка һәм чем кара озын итәк кигән урта яшьләрдәге хатын, хуҗаларча мөлаемлек күрсәтеп, сәламләп каршы алды үзләрен.

—Бу тикле чәчәк күргәч югалып кала яздым, бу сезмени, очучы иптәш. Танымый да торам, бай булырсыз болай булгач.

—Миннән дә бай кеше юк бу дөньяда. Һәм булмаячак та. Күрмисезмени, нинди хәзинә, жанлы хәзинә белән килдем бит мин сезнең янга,—дип, елмаеп җибәрде Рафаэль.

Юк, бу елмаю гына түгел иде бугай. Күңел күтәренкелегеннән, үзен биләп алган бәхеттән, күптән зарыгып көткән хыяллары тормышка ашудан егет балкый иде гүя. Бәхет дигән төшенчәнең җанлы гәүдәләнеше иде кебек ул. Анардан да бәхетлерәк кеше дөньясында булмагандыр шул мизгелдә.

—Күрәм. Күрәм...—дип кабатлады хатын. Һәм эшлекле генә кыяфәт белән өстәл өстендәге кәгазьләрен актарырга, барларга керешге.—Шул тикле ашыгыч рәвештә язылышырга теләвегезнең сәбәбен менә хәзер генә аңладым.

ЗАГС мөдире, ачык йөзе белән генә түгел, үзенең аналарча кайгыртып сөйләшүе белән дә күңелләренә хуш килде аларның. Тыныч кына, ипле генә башкарды ул үз эшен. Яшьләрнең һәр икесенә күңелләренә ятышлы сүзләр тапты. Кыскасы, ишекне атлап кергәндә аларның һәр икесен биләп торган киеренкелек тиз арада юкка чыкты, онытылды.

Күрсәтелгән урыннарга бер-бер артлы имзаларын куеп чыкты алар...Һәм шуның белән эш тәмам да булган икән, юкка гына дулкынланып, куркып торганнар. Әлеге гаять мөлаем һәм итәгатьле ханым, ир белән хатын итеп игълан итте дә куйды үзләрен, аңышмый да калдылар. Музыка уйнамады... Патефон һәм магнитофон кебек нәрсәләр юк иде булса кирәк. Шаһитләр һәм котлаучылар да юк иде. Әти-әни һәм туган-тумачадан да ник бер кеше булсын икән яннарында. Ул гына да түгел, туган-тумачалары бит әле бу хакта хәбәрдар да түгел. Аларның язылышуы хакында һичкем белми. Менә шулай башлы-күзле булды алар—кыз кияүгә чыкты, егет өйләнде. Аның каравы, алар хәзер ялгыз түгел, алар икәү. Алар бер пар булды!

Урамга чыктылар. Һәм кай тарафка китәргә белмичә туктап калдылар. Кояш баш түбәсенә үк күтәрелгән. Җәйге эссе көн. Аның каравы шәһәр шундый матур. Тротуар читләп утыртылган юкә агачлары шау чәчәктә утыра. Саф һава. Дөньяның матурлыгына хозурланып туймаслык...

Кызганыч, каршы алучы, үзләрен көтүче, шатлыкларын уртаклашучы юк иде яннарында. Аның каравы, кирәкмәгән ыгы-зыгы, аларның игътибарын читкә җәлеп итүче дә юк. Бер-беренә елмаю бүләк итеп, дәшми-тынмый гына үзара карашып тордылар байтак кына.

—Урам уртасында болай басып тору яхшы түгел. Әйдә, берәр бакчага кереп сөйләшеп утырыйк булмаса,—дигән тәкъдим кертте кыз бераз кичегә төшеп.

Егет, сәгатенә күз төшереп алды һәм ризалашты. Бер-бер ресторанга кереп утырганда да яхшы булыр иде, әлбәттә. Әмма аның вакыт яклары бик чамалы гына иде шул. Кичке дүрттән дә кичекмичә ул хезмәт урынында булырга тиешле. Болай да сорап кына киткән иде.

Юлда очраган беренче бакчага кереп аулак урын тапты алар. Чәчәк бәйләмен янәшә куйдылар. Рафаэльнең Ленаны кысып кочаклыйсы килде шунда. Һич булмаса, үз итеп җилкәсенә кулын саласы иде. Әмма уңайсызланды, шәһәр уртасы ич, кеше үтеп-сүтеп йөри. Аларның бит әле, кул биреп күрешүдән тыш, бер-берсенә якын да килгәннәре юк. Кочаклашу-үбешүләр кая инде ул...

—Болай итәрбез, Лена,—диде ул, үз-үзен тынычландырырга теләп күкрәк тутырып сулыш алгач.—Без Саратовта әле ай ахырларынача калырбыз кебек тоела. Тагы ике көннән Разбойщинада бер бүлмә бушарга тиешле. Боерган булса, мин сине шунда алып кайтырмын. Һәм ай ахырына тикле шунда торып торырбыз. Димәк, син тагы ике көнгә кунакханәдә калып торасың. Ә миңа хәзер китәргә кирәк. Унтугызында төш вакытларында мин сине килеп алырмын, килештекме.

—Килешми хәлең юк,—диде Лена, ягымлы һәм үз итеп.—Мин сине күпме көтәргә дә риза, Рафаэль. Эшеңә зыян китерә күрмә.

Алар шундук урамга чыгып такси тоттылар. Лена үзе урнашкан кунакханә каршысында төшеп калды. Рафаэльнең машинадан төшеп торыр арасы да юк иде, шул утырган машинасында хезмәт урынына китеп барды.

## 17

Июньнең унтугызынчы көне. Көндезге сәгать ике якынлашып килә. Көн кыздырыпмы кыздыра. Урамга чыксаң, сулыш алырлык түгел, эссе. Саратовның урам һәм диварлары мунча ташы сыман кызган. Рафаэльнең килүен көтеп, каршы алырга дип урамга чыккан кыз, чемоданын күтәреп, кире кунакханә холлына борылып керергә мәҗбүр булды. Тәрәзә каршысына басып урамны күзәтә башлады. Көн кызуында урам гел бушап кала икән. Кешеләр дә сирәгәя, машиналар да әллә нигә берәү күренсә, күренә.

Ниһаять, кунакханә каршысына такси килеп туктады. Ул да түгел, аның алгы ишегеннән, хәрби фуражкасын кулына тоткан Рафаэль атылып чыкты, чыгу белән фуражкасын киде. Кителенең өске сәдәфләрен каптырды һәм, як-ягына җәт кенә күз төшереп алгач, зур адымнар белән кунакханә ишегенә юнәлде.

—Мине көтә-көтә көтек булгансыңдыр инде, шулаймы, Лена?—дип, каршысына килгән кызның кулыннан чемоданын алды ул.

—Син эш кешесе, Рафаэль. Ә мин ялда. Нинди көттерү ди ул... Урамда бик кызу булганга кире эчкә кергән идем.

—Дөрес эшләгәнсең...

Үзләрен көтеп торган таксига чыгып утырдылар да китеп бардылар.

Егеткә якын ук елышып утырган кызның күзләре юл буе диярлек тәрәзәдә булды. Мондагы табигатьнең Башкортостанныкыннан шактый ук аермалы булуына игътибар итеп барды ул. Инде күпме ара уздылар—урман да юк, агачлар да, тирә-якта бары тик бушлык кына. Әле июнь уртасы гына булуга да карамастан, үлән һәм басулар яшел төсләрен югалтырга өлгергән, сап-сары булып янган һәм кибеп беткәннәр. Бары тик ниндидер бер авылга килеп керер алдыннан гына зур булмаган катнаш урманга юлыктылар. Бу—аларның Разбойщиналары булган икән. Ә хәрби шәһәрчек аз гына арырак.

Разбойщина дигәннәре уртача зурлыктагы бер рус авылы булып чыкты. Авыл читендәге ерак бер тыкрык башында урнашкан иске, бераз янтая башлаган өй каршысына килеп тукталдылар. Капка төбендә аларны Рафаэльнең якын дусты Володя Балченков һәм хуҗалар—карт белән карчык каршы алды. Хәер, карт белән карчык дигәч тә, алар бер карашка гына шулай күренгән булып чыкты. Чынлыкта исә, икесенә дә шул, күп булса, алтмыш-алтмыш биш яшьләр тирәсе булгандыр.

Аларны китергән такси кире китеп барды.

—Таныш булыгыз, бу минем законлы кәләшем Лена була,—диде Рафаэль.

Кыз, таныш булмаган кешеләр каршында, уңайсызлык кичереп тора иде. Елмаеп исәнләшергә мәҗбүр булды. Аны да җылы сәламләделәр.

—Ә, Елена... Исеме гел безнеңчә икән,—дип, аерым игътибар күрсәтте хуҗа хатын.

—Елена түгел, Лена,—дигән иде дә Рафаэль, әмма аның бу искәрмәсенә колак салучы булмады да кебек, ул алар өчен барыбер Елена булып калды.

Шау-гөр килеп сөйләшә-сөйләшә өйгә юнәлделәр. Алар өчен хәзерләнгән бүлмәгә уздылар. Бүлмә артык зур түгел. Аның бер почмагында сиртмәле тимер караваты тора. Һәм урта бер җирдә зур гына өстәл. Кием элү өчен стенага калаклар кагылган. Өстәл әйләнәсендә берничә урындык, ә өстендә—

сулы пыяла банкага утыртылган чәчәк букеты. Кыр чәчәкләреннән...

—Нинди матур чәчәкләр...—дип, соклануын белдерде кыз.

—Иртүк торып урман читеннән үзем җыеп кайттым,—диде Рафаэль, чәчәкләрнең Ленага ошавына күңеле булып.

—Керегез, урнашыгыз, уңайсызланмагыз, үз өегездә кебек хис итегез,—диде, ачык йөзле хуҗа хатын.

—Бернинди уңайсызлану юк, бүген үк, менә хәзер үк туй башлана,—дип, бар тавышка өйне янгыратты Володя Балченков. Һәм өстәл өстенә, ике уйларга урын калдырмаслык итеп, шапылдатып шампан шешәсе чыгарып утыртты.

Ленаның чемоданын карават астына шудырган арада, алдан ук хәстәрләп куелган җирдән ике банка "тушенка" һәм бер банка шпрот тартып чыгарды Рафаэль. Ленаның кул сумкасында шоколад конфет бар иде, ул да кунаклады өстәлгә. Хуҗа хатын кар базыннан тозлы кәбестә һәм чүлмәк белән кәҗә сөте алып керде. Ниһаять, туйга әзерлек ыгы-зыгысыннан моңарчы читтәрәк калып торган хуҗа—Иван дәдәй дә әйтте үз сүзен. Бер чирек самогон күтәреп килеп керде.

—Монысы миннән,—диде, тамак төбен хәйләкәр генә кырган атлы булып.

—Үзең мавыгасы булма, кара аны Иван, төнгелеккә каравылга чыгасыңны онытма,—дип кисәтергә кирәк санады карчыгы.

—Кызык икән син, Марфа, шешәнең бөкесен ачмас борын кисәтә дә башладың,—дип елмайды хуҗа.—Рафаэль фронтовик. Мин фронтовик. Ничек итеп мин бер почмакта посып утырмак кирәк. Сугыштан качып калган дезертирмы әллә мин?!.

Карчыгы, ирләр хәленә керә белә икән тагы, шундук йомшара да төште:

—Кызып китмә дип кенә әйтүем. Бер стаканнан артып китмәсен, кара аны.

—Өч солдатка бер чирек тә эчмәгәч, ул нинди туй була инде ул,—дип кеткелдәде фронтовик. Үзенчә хатынын ирештерде.

—Ә безне кая куясың? Елена белән мине кешегә дә санамый бит, кара инде аны, карт пистунны...—дип, елмайды Марфа түти.

—Карт ат буразнадан чыкмый ул аның каравы...

Күңелле кешеләр булып чыкты ахыры аларның бу хуҗалары. Яшьләрнең бар тартыну һәм уңайсызланулары юк булды да куйды шунда.

Өстәл артына утырыштылар. Карт белән карчык һәм Володя самогон эчтеләр. Рафаэль белән Лена исә шампан гына йоткалап утырды. Артык кыстап, яшьләрнең теңкәләренә тиюче булмады, хәлләренә керделәр тагы.

—Туй булгач, җырсыз утыру килешми,—дип, хуҗа хатын, әйбәт кенә төшереп алгач, җырлап ук җибәрде. " Во поле березенка стояла..." дип җырлады.

Рафаэль, алдан ук хәстәрен күреп, карават астына мандолинасын китереп куйган булып чыкты. Шуны тиз генә тартып алып, җыр көенә чиертә дә башлады. Марфа түтинең тавышы көчле һәм шактый ук моңлы да, тын алмый тыңладылар үзен. Сүз дә юк, шәп җырлый иде. Мандолина тавышына кушылгач, җыр тагы да моңлырак янгырарга кереште. Кемнәрдер кушылып та җырлады, ә кемнәрдер тыңлап кына утырды.

—Минем карчык авылда беренче җырчы инде ул. Миңа чыгып кына әрәм булды. Юкса, үзен күптән, Саратовка гына түгел, Мәскәүгә үк алып киткән булырлар иде,—дип, сүз кыстырды хуҗа җыр тәмамлангач та.

Әллә чынлап та горурлануы идеме, әллә шаяруы—анламассың.

—Искиткеч матур жырладыгыз, рәхмәт Марфа түти,—диде Лена. Бу жыр, гомумән, элек-электән үк бик ошый иде анарга.

Володя Балченков та жырчыны мактап куйды:

—Минем әни дә жырларга ярата торган иде бу жырны. Аны искә төшердегез, рәхмәт,—диде ул, кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып, күз төпләрен һәм борыны читен сөртә-сөртә.

Рафаэль, күңеле нечкәреп киткән дустының хәленә кереп, аның аркасыннан кочып алды.

—Ә сез беләсезме соң бу жырны кем язган?

"Мин белмим, ә син..." дигән сыман, бер-берләренә сораулы караш ташлап алды туйда утыручылар.

—Рус халык жыры инде,—диде хужа хатын, икеләнүләргә урын калдырмаслык итеп.

—Әйе, бу жыр халыкныкы булып киткән. Рус халык жыры булып. Ә бит аның авторы бар һәм ул белгечләр арасында күптән билгеле. Бу жырны Казан университеты профессоры Нигъмәт Ибраһимов язган. Татар кешесе...

—Булмаганны?..—дип куйды Иван дәдәй.—Ничек инде рус халкының иң борынгы һәм иң яраткан жырларының берсе булган "Березенканы..." татар кешесе язсын икән?..

Башкаларның да монарга ышанасы килмәде. Хәтта Лененың да бу хакта ишеткәне булмаган икән.

—Ышанасы килмәсә дә ышанырга туры килә, бу—хакыйкать. Китапта язылган,—диде Рафаэль, бу сөйләшүне бәхәскә күчерәсе килмичә.

Китапта язылган сүз шик астына куелмый торган заманнар бар иде шул. Хужалар, килешүләрен белгертеп, дәшми генә бер-бер артлы баш селкеп куйдылар.

Ул да түгел, жырлавын ошатуларына күңеле булган, Марфа түти эчкерсез сүз башлап жибәрде:

—Мин сезгә турысын әйтәм, әнә Иван үзе монда, алдашырга бирмәс. "Фатирга керергә жыенучылар татарлар икән" дигәч, мин аяк терәп каршы идем башта. Төрле имеш-мимешләрне күп ишетергә туры килсә дә татарлардан беренче күргән кешем Рафаэль булды, әнә. Һәм инде менә Елена... Һич тә белми идем, баксаң, безнең кебек үк кешеләр икән ич сез дә.

—Син, Марфа, читкә чыккан кеше түгел шул, гомерең буе шушы Разбойщинада яшәдең. Ә мин менә сугышта татарлар белән ризык бүлештем, бергә атакага бардым—шәп егетләр иде...

Күңелле утырдылар. Өстәл артыннан беренче булып йорт хужасы Иван дәдәй торып китәргә мәжбүр булды. Төнге сменада авылның икмәк амбарларын саклый икән ул. Шуның өстенә әле тагы хатынына биргән сүзендә дә торды, бер стаканнан артык эчмәде самогонны.

Ире киткәч, Марфа түти дә тоткарланмады өстәл артында.

—Сез, яшьләр, үзегезчә утырыгыз, ял итегез. Күршедә ахирәт дустым Мария яши. Ире сугыштан кайтмады, үзе генә калды. Аңарга да бер ялгызы читендер,—дип, хәерле төннәр теләп, чыгып китте.

Бераздан, караңгыга калам юкса, дигән сылтау табып Володя да китәргә жыена башлады.

—Кызык килеп чыга бит әле бу, кәжә белән бүре турындагы әкияттәге кебек бер-бер артлы качышып бетәсез түгелме,—дип, шаярткан атлы булды Рафаэль. Гәрчә, күңеленнән, моның өчен шатланса да...

—Так положено, дустым,—дип, юл аягына тагы бераз самогон уртлап алды да ишеккә юнәлде Володя.—Мин өйләнгән көнне болай озак утырсаң,

үзенне куалап ук чыгарырмын, ярыймы.

—Килештек,—диде Рафаэль.—Әмма, өйләнү белән озакка сузасы булма, ярыймы.

Кул бирешеп хушлашты ике очучы. Ишектән чыгып киткәндә, шаярган атлы булып, Рафаэльнең үзенә генә күз кысып алырга да өлгерде Володя.

—Кара аны, иртәгә очасың барын онытма...

Ниһаять, шау-гөр килеп торган өй эче тынып калды. Алар икәү генә. Шунда гомерендә беренче тапкыр сак кына Ленаның биленнән кочып алды Рафаэль. Кыз да карышмады, киресенчә, аңарга, тартынып кына булса да, тагы да елышарак төште. Бер-беренә тартылып торган кайнар иреннәре очрашты. Иреннәрнең кайнарлыгы сулышларына капты...

## 18

Иртүк торып чәй эчкәч тә эшкә ашыкты Рафаэль. Дөньяда иң бәхетле кеше итеп хис итте ул үзен шул иртәдә. Тәрәзәдән төшкән иртәнге нурларны көнләштереп балкый иде ул.

Ул иртәдә дөньясында аның кебек бәхетле кеше булмагандыр, икенче берәү булса—анысы да Лена гына булгандыр. Урамга чыккан ачык тәрәзәдән башын чыгарып кул болгап озатып калды ул үзенең бердән-берен. Йөгерә-атлый эшкә ашыккан Рафаэль тыкрыкның аргы башына җитеп борылышта күмелгәнче карап калды ул аның артыннан.

Рафаэль эшеннән төрле ризыклар төялгән зур сетка күтәреп кайтты. Лена да, булдыра алган кадәр кайгыртып, өстәл әзерләгән, хуҗа хатыннан сөт, йомырка һәм яңа пешкән ипи сатып алган булып чыкты. Беренче тапкыр бер гаилә булып икәүдән-икәү генә серләшеп чәй эчте алар. Ә аннан соң бер кешелек тар тимер караватка аркаларын стенага терәп янәшә утырдылар да, киләчәккә планнар корырга керештеләр.

—Без заманча гаилә корырга тиеш, Рафаэль,—дип, сүз башлады Лена. Ул ипле генә, җиренә җиткереп, сендереп аңлата иде үзенең һәр фикерен. Бер ни эшләп тә булмый, укытучы! Ә укытучы халкы, билгеле инде, кинәш итәргә, өйрәтергә оста.—Икебезгә дә укуны дәвам иттерергә, белемебезне тагы да тирәнәйтергә кирәк булачак. Мин үзем, күптәнге хыялым булган, аспирантурага керергә җыенам. Ләкин менә анда укырга керү өчен, ким дигәндә, өч еллык педагогик стаж булу мәҗбүр. Бер елын инде эшләдем, тагы ике ел мәктәптә балалар укытырга туры киләчәк.

—Хыял—яхшы нәрсә инде ул. Миндә дә бар ул. Хәрби академияга керергә иде дә бит,—дип, уйга калып торды Рафаэль.

—Теләгең бар икән, димәк, керергә һәм укырга кирәк. Нәрсә тота соң үзенне? Моны мин бик шатланып хуплыйм.

—Мәктәпне тәмамлаганга байтак еллар узды. Булган белем коелып бетмәдеме икән, шуңардан куркам.

—Нинди фәннәрдән имтихан?

—Математика, физика һәм чит телдән. Математика белән физиканы мин яхшы белә идем анысы...

—Димәк, куркырлык бер сәбәп тә юк.

—Ә чит телдән?

—Ә син оныттыңмы, мин бит инглиз теле укытучысы. Чит телдән үзем консультацияләр бирермен.

—Шулай дисәң генә,—җанланып, очынып китте Рафаэль. Юктан гына да кәефе күтәрелеп китә иде аның шулай. Шул күтәренке күңел белән Ленаны кочып алды ул һәм җәт кенә күтәреп алып үзе тирәли зыр әйләндерә башлады.

—Чү, төшереп җибәрә күрмә, башымны әйләндерәсең,—дигән атлы

булды Лена.

Хужалар үз мәшәкатьләре белән каядыр чыгып киткән булып чыкты. Шул форсаттан файдаланып, ташып торган гайрәтен кая куярга белмәгән Рафаэль мандолинасын тартып чыгарды тагы һәм "тел-дин-татын, тел-дин-татын" китереп уйнарга кереште. Халык җырларын бик ярата иде ул. Үзе уйный һәм үзе үк тыныч кына җырлый да башлады. Аның җилкәсенә үз итеп башын салган Лена да кушылды җырга. Җыр аларны бәхетле дөньяга—үзләре туып үскән, дөньяның иң матур төбәге булган, Башкортостан якларына алып кайтып китте:

Әйдә киттек сәхрәләргә, сәхрәләргә,
Гөлләр араларына, Асылъяр,
Матур яр, гүзәлем,
Өзелә лә үзәгем.

Рафаэль бар тавышка җырлый иде инде, аның тавышы күр. Җырның көен генә түгел, сүзләрен дә яхшы белә. Ә Лена анарга кушылып, ипле генә, сизелер-сизелмәс кенә җырларга тырышты. Чөнки ул җырның көен яхшы белсә дә сүзләрен төгәл генә хәтерләп бетерми иде. Әмма аларның мандолинага кушылып бергә җырлавы шул тикле дә матур янгырый иде ки, үзләрен белмәгән бүтән берәү шул чакны читтән генә тыңлап торса, ул, һичшиксез, болар чын җырчы икән бит диеп нәтиҗә ясаган булыр иде.

—Син бик матур җырлыйсың, Рафаэль. Сиңа җырчы буласы калган,—дип, Лена егетне мактап та алды әле хәттә.

—Ә мин чынлап та җырчы ич. Сөйләмәдем бит әле үзеңә,—дип, кычкырып көлеп җибәрде ул шунда. Һәм "Урман кисүчеләр ансамбле" мажараларын сөйләп чыкты.

Үзе сөйләде, үзе көлде. Яшүсмер чакларын хәтерләп, дус-ишләренең җорлыгын искә төшереп көлде ул. Анарга ияреп Лена да көлде. Чынлап та кызык вакыйгалар иде ич. Шулар өстенә әле Рафаэль сөйләргә дә оста, теле телгә йокмый аның бер мавыгып сөйләргә керешсә.

—Алай җырлавымны бик ошаткач, мин сиңа көн дә җырлап кына торырмын инде болай булгач,—дип, уенын-чынын бергә кушып әйтеп салды Рафаэль.

—Җырлап кына яшисе иде шул,—дип офтанып куйды Лена.—Әмма үзебезне алданиләр көткәнлеген белмибез бит әлегә.

—Ничек яшәү безнең үзебездән тора, Лена-җаным. Инде хәзер без бергә. Бары үзебездән генә тора.

—Шулай гына булсын иде дә бит ул...—диде яшь кәләш суза төшеп.—Бу фатирга да менә ай ахырына тикле дип кенә керттеләр дисең.

—Ә безгә артык кирәкми дә, ай ахырында безнең командировка тәмамлана, үзебезнең Бобровкага кайтып китәбез,—диде Рафаэль. Ул ышанычлы, көчле тавыш белән сөйләшә иде. Аның һәр сүзеннән, үз-үзен тотышыннан киләчәккә ышаныч, гайрәт сирпелеп тора.

Ленаны да тынычландырды аның үз-үзен тотышы. Шулай да, хатын-кыз буларак, ул алдын-артын уйлап хәл итү ягында иде. Ул бит монда җәйге ял вакытында шәһәр күрергә генә дип килгән кеше. Аның да эше бар. Авыру әнисе бар. Аны да берьялгызын Уфада калдырып китә алмый бит инде ул... Ә монда—Рафаэль. Ул аңарга шундый тиз ияләште ки, анардан аерылып тору, анардан башка яшәүне дә күз алдына китерәсе килми хәзер. Рафаэль янында узган һәр көн, һәр сәгать тоташ бәхеттән гыйбарәт бит аның өчен. Ни рәвешле шул бәхетенне калдырып кайтып китәргә мөмкин? Беркая китмәс иде дә, башкача чарасы юк...

—Бобровкага китәбез, дисең дә бит, Рафаэль, мин анда ни эшләрмен? Кайда торырбыз?

—Анда офицерлар өчен фин йортлары салырга җыеналар, шуннан урын бирерләр дип уйлыйм, гүзәлем.

—Йорт салынмаган. Ә син Бобровка дисең... Мәктәп бармы соң анда?

—Әлегә юк. Әмма берничә елдан соң башлангыч мәктәп ачылырга тиеш, диләр.

—Берничә ел һавадагы торнаны көтеп утырырмынмы?

—Башка офицерларның хатыннары утыра ич, син дә утырырсың, гүзәлем.

—Ә өч еллык стаж һәм аспирантурага керү турындагы хыял ни эшли?

—Ул хыялларың да тормышка ашар, боерган булса.

—Ничек?..

Рафаэль, уйга калып торды байтак кына, һәм уңай җавап таба алмыйча җилкәсен сикертергә мәҗбүр булды.

—Бәлки бер-бер җае табылыр иде әле...

—Башка чарабыз юк әлегә. Ничек кенә авыр булмасын, Рафаэль, миңа Уфага кайтып китәргә туры килер. Ни торыр, ни эшләр урын юк бит әлегә. Ә инде бер-бер почмак бирсәләр, шундук янына килермен, килештекме...—дип, иренең кочагына сыенды Лена. Юмалый белә иде ул.

Юмалауда гына да түгел, аның сүзләрендә хакыйкать бар иде шул. Килешмәс җиреннән килешерсең.

Күңелле иде аларга шулай бергә-бергә утырулары. Сөйләшеп сүз, серләшеп сер бетәрлек түгел. Тик менә алда билгесезлек һәм үзләрен ни көткәнлекне белмәү генә, искә төшкән саен, җаннарын тырнап тора. Бу билгесезлекне аеруча, ир-ат буларак, Рафаэль авыр кичергәндер. Моны ул, әлбәттә, сиздермәскә тырыша иде. Кешегә сөйләргә оят бит—ул Ватан сугышында җиңеп кайткан солдат, ярты Европаны фашизм коллыгыннан азат иткән данлы Совет Армиясе офицеры, югары квалификацияле очучы-истребитель. Хезмәт иткән җирендә иң яхшы кадрларның берсе санала. Эшләгән урынында гаилә корып, хатының белән бергә яшәрлек кечкенә генә почмак табу да зур проблема булсын инде. Гарьләнмәс җиреннән гарьләнерсең...

25 нче июньдә эштән соң алар яшәгән бүлмәгә Рафаэльнең иң якын дуслары җыелып килде. Володя Балченков, Лева Лисин, Паша Кузнецов һәм Юра Крюков. Крюков күптән түгел генә өйләнгән булып чыкты, ул үзенең хатыны Кираны да алып килгән иде. Аз гына кызыл шәраб эчтеләр, ашадылар һәм Рафаэльнең мандолинасына кушылып берсеннән-икенчесе матуррак җырлар җырладылар. "Катюша"ны, "Подмосковные вечера"ны һәм билгеле инде ул елларда гаять популяр булган кинодагы «Летчиклар җыры"н:

> ...Первым делом, первым делом самолеты.
> Ну а девушки, а девушки потом...

Җыр үзләренә бик ошаса да, очучыларга кушылып җырласалар да, яшь хатыннар, назлана төшеп, ирләренә үпкәләгән дә булып кыландылар.

—Без нәрсә, шул тимер самолетлардан да кадерсезрәк мени инде хәзер,—дигән булды алар берсен икенчесе бүлдерә-бүлдерә.

—Җырның сүзләренә игътибар итегез,—дип, шундук җавабын да тапты Рафаэль.—Җырда сүз кызлар турында ич, ә сез безнең кадерле хатыннарыбыз. Шулай бит, Юра...

Юра дустын хуплап, урыныннан ук сикереп торды һәм тост тәкъдим

итте:

—Безнең сөекле хатыннарыбыз өчен. Өйләнмәгән егетләрнең сөйгән кызлары өчен, аягүрә басып, терсәкне югары күтәреп, өч тапкыр "Урра" белән...

Очучылар, кыядагы оядан атылып чыккан бөркетләр сыман, сикерешеп тордылар һәм нәкъ кушылганча башкарып та чыктылар. Кызларның да күңеле булды, әлбәттә.

Кич сизелми дә узып китте. Кунаклар таралышты... Ә тагы ике көннән Рафаэль үзенең Ленасын Саратов һава аланыннан Самара аша Уфага очучы самолетка утыртып озатып калды. Аерылганда бер-берләренә сер бирмәскә тырышсалар да, икесенең дә күзләрендә кайнар яшь бөртекләре иде. "Бергә булулары бик күңелле, әмма аерылышу бик яман" дип, юкка гына җырламыйлар икән ул...

## 19

Һәр ике көн саен хат язышырга сүз куешкан иде алар. Әмма Рафаэль ике көн узганны көтеп тора алмады. Ленасыз узган бер көн дә озын-озак бер гомер сыман тоелды анарга. Очулардан әйләнеп кайткачтын да хат язарга утырды:

"Гүзәлем Лена!

Сиңа сагынычлы кайнар сәламнәремне җибәреп исәнлекләр теләп калам!

Белсәң иде, җаным, узган көнне сине озатып калу, синең белән аерылышу шул кадәрле кыен булды. Син утырган самолет күздән югалганчы баскан җиремдә катып карап калдым. Аерылышканда синең хушлашып кул изәвең күз алдымнан китми. Синең белән бергә узган көннәрнең һәр сәгатен, һәр минутын әллә ничә мәртәбә барлап чыктым бугай инде. Син киттең. Һәм үзең белән бергә минем йөрәгем һәм җанымның да бер өлешен алып киттең кебек тоела миңа. Мин монда бер канатын югалткан кош сыман торып калдым. Башымны түбән салындырып һава аланыннан ялгызым гына, ерак диеп тормадым, җәяүләп кайтып киттем. Трамвай һәм автобуслар да йөри иде югыйсә. Утырасым килмәде, аларга утырсам, синнән ерагаермын кебек тоелды. Синең хактагы уйлар белән әкрен генә үз җаеңа атлауга ни җитә соң...

Саратовтан Разбойщинага автобус белән кайттым. Үзебез яшәгән өйгә якынлашкан саен йөрәк тагы да ешрак, ашкыныбрак тибәргә кереште. Бүлмәнең ишеген ачып керермен дә, ни гаҗәп, анда сине очратырмын кебек тоела башлаган иде. Өйгә кердем, үзебезнең бүлмәгә дә уздым. Син юк. Өй караңгы һәм тынчу. Син булмагангадыр, ул гел бушап калган, тып-тыныч... Йә, әйт, ни эшләргә һәм ничек яшәргә тиеш мин андый шартларда? Хуҗа хатын кайтканны көтеп утырдым да, анарга рәхмәтләремне тапшырып, үзебезнең кунакханәгә күчтем. Анда да һичкем юк. Очучы дусларым кайсы кая, күрәсең, шәһәргә китеп беткәннәр. Кичке ашны бер ялгызым ашадым да, эч пошуын баса алмыйча, караватка барып яттым. Минем хәлемә керептер, нәкъ шул мәлне һава шартлары да бозылып китте, янгыр сибәләргә керешә.

Иртәгә без юлга чыгарга җыенабыз. Саратовтан Куйбышевка пароход белән кайтачакбыз. Анда кайтуга мин Кинельдә квартир һәм синең өчен эш эзләргә керешәчәкмен.

Ленам, инде үзең сөйлә: ничек кайтып җиттең? Куйбышевта күчеп утырулар озакка сузылмадымы? Бик йончыткандыр инде... Әнкәй-"карчык"ның хәлләре ничек анда, әйбәт кенә торганмы? Син тиз генә әйләнеп кайтмагач, көтә-көтә көтекләр булып беткәндер инде.

Яңалыкларыбыз турында сөйләгәч, ничек, орыштымы соң үзеңне, әллә шатланды гынамы?.. Ничек кенә булса да миннән үзенә бик күп сәламнәремне тапшыр. Ә инде буш вакытың табылгач та китап кибетенә кереп миңа дәреслекләр юлларга тырыш.

Үзең бик йончымадыңмы соң? Күбрәк ял итәргә, тазарырга тырыш инде, каникул вакытлары ич. Минем хакта бик уйлама. Ләкин шуны бел, син—минем бердән-берем. Буш вакытым булса, күңелем һәм уйларым синең белән генә булыр. Һәм, әлбәттә, кулымда китап булыр.

Кабат сәламнәр белән, исәнлекләр теләп һәм үзеңне үбеп калучы Рафаэль дип белерсең!

29.06.53. Саратов (Разбойщина)".

Җавап озак көттермәде. Хәер, җавап түгел, Лена да бер үк көндә, өенә кайтып җитмәс борын ук язып салган булып чыкты. Анда да ярату, Саратовта узган онытылмас көннәрне сагыну һәм юксыну хисләре иде. Һәм шул рәвешле, һәр ике көн саен бер-берсенә хат юллап торды алар. Язып салган хатка җавап килгәнне көтеп тормадылар, юлда ике яктан да икешәр хат булды берөзлексез. Ике ай чамасы шулай дәвам итте, сагыну һәм сагышлары кимемәде, торган саен арта гына барды.

Рафаэль язган хатларның берсендә мондый юллар бар: "Гүзәлем-Ленам, тәүлектә егерме дүрт сәгать диләр, ә беләсеңме мин синең хакта егерме биш сәгать уйлый торганмындыр. Нәкъ шул кадәрле үк сагынам һәм сиңа таба омтылам. Үзем очкан самолет булып, ул да аңлый ахры минем бу хәлемне—маршрут Уфа тарафларына борылганда гадәттәгедән күпкә тизрәк һәм җиңелрәк оча кебек тоела ул миңа. Шул тимер канатлы дустыма утырып "эх" дигән арада кайтып кына җитәр идем дә бит яннарыңа, маршруттан аз гына да читкә тайпылырга ярамый шул безгә. Хәрби тәртипләрне үзең беләсең. Кош булырга иде ул... Кош булып, канатларым булса, ике дә уйламас идем, һәр көн синең янга очып барыр идем, ә икенче көнне таң белән кире яраткан эшемә очып кына әйләнеп кайтыр идем... Миңа кош булып туарга кирәк булган. Кош булып булмады шул, гүзәлем-Ленам".

Ленаның да күңеленә бик хуш килде Рафаэльнең бу матур, әмма тормышка ашмас хыяллары. Андый мөмкинлек булса, ул үзе дә бик озак уйлап тормаган булыр иде, мөгаен. Сагынды шул Рафаэльне, бик тә нык сагынды. Кош булып, канатлары булса, һичшиксез, ике дә уйлап тормастан бер-берenә каршы очар иде алар. Ә алар кеше булып туган. Кеше—сагынса да, саргайса да түзәргә тиеш икән.

Чираттагы хатларының берсендә Рафаэль Ленага бер гыйбрәтле мәхәббәт тарихы турында язып җибәрде. Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дип язуы булгандыр инде.

Сугышка кадәр үк үзенең хәрби һәм профессиональ осталыклары белән бөтен илгә танылган Анатолий Серов атлы летчик була. Ул шактый ук билгеле һәм бик тә чибәр актриса Валентина Серовага гашыйк була һәм өйләнә. Бу кыз артыннан, дөньясын онытып, шул елларда Константин Симонов та йөргән һәм аңарга атап лирик шигырь цикллары багышлый. К. Симонов исеме һәм аның шигырьләре ни дәрәҗәле булмасын, актриса очучыга чыга. Һәм алар арасында легендага лаек чын ярату була. Мәхәббәт дөньяда бар нәрсәдән дә көчлерәк. Көннәрдән бер көнне летчикнын сәламәтлегенә зыян килә һәм аны ил житәкчелеге, мәҗбүри рәвештә, көньяктагы санаторийларның берсенә юллый. Аерылырга бик теләмәсәләр дә очучы китәргә мәҗбүр. Ә актрисаның спектакльләре бара, кинога төшерүләр дәвам итә. Мәскәүдә тимер юл вокзалында күз яшьләре коеп хушлашалар.

Юлга чыккач та, һәр тукталыш саен поездан төшеп, вокзаллардагы почтага кереп сөйгәненә телеграмма җибәреп бара Анатолий Серов. Ул елларда поездлар акрын йөри һәм бик еш туктала торган була. Кыскасы шул, һәр ярты сәгать яисә кырык минут саен, очучыдан, үзен бик тә, бик тә яратуын раслаган телеграммалар алып тора актриса. Унлап телеграмма килә ярты көн эчендә. Һәм туктала...Телеграммалар килми башлый. Пошаманга төшә Валентина, үз-үзен кая куярга, ни эшләргә белми башлый. Бер сәгать уза шулай, ике сәгать, өч... Авыруга сабыша башлый актриса, кемнән сорарга, кая барып бәрелергә белми башлый. Ул да түгел, күпмедер ара узгачтын, ишектә кыңгырау авазы ишетелә. Ачса—ишек катында Анатолий үзе басып тора. Бар нәрсәне җиңәргә әзер һәм куркусыз очучы яратуына, сагынуга түзә алмыйча, ярты юлдан кире борылып кайтып төшкән.

Валентина үзенең барлык мәшәкатьләренә һәм спектакльләренә кул селти дә шул ук көнне ире белән бергә икенче бер поездга утырып китеп бара санаторийга. Димәк, алар өчен мәхәббәт бар нәрсәдән көчле, өстен һәм югары булган. Ленаны тәмам тетрәнергә мәҗбүр итте, тирән уйларга салды бу мәхәббәт тарихы.

Рафаэль үзенең хатларын шигырь юллары белән башлый, шигырь белән тәмамлый торган булып китте. Лена исә аның хатларын болай да аерым бер дәфтәр ясап җыеп бара торган иде. Ә инде үзенә багышланган шигырьләрне һәрчак үзе белән йөртә торган куен дәфтәренә дә күчереп барды. Әлеге дәфтәрне ул көненә, биш кенә түгел, аз дигәндә йөз мәртәбә ачып карый торгандыр. Дәфтәрнең беренче битендә Рафаэльнең фоторәсеме. Һәм шигырьләр... Алар барысы да анарга багышлап язылган. Шунын өчен алардан да кадерлерәк шигырь юллары юк иде аның өчен. Татар мәктәбендә укымагач, ул татар китапларын бик сирәк кенә кулына ала торган иде. Рафаэльнең шигырьләре анарда татар теленә һәм татар әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләде. Татар шигыренең нечкәлекләрен, бетмәс-төкәнмәс матурлыгын аңлауга юл ачты.

Рафаэль үзенең хатларында әйләнә дә бер фикергә кайта, әйләнә дә кайта—ир белән хатынга болай аерым яшәү мөмкин түгел! Лена үзе дә аңлый иде бу хакыйкатьне, аеры-чоеры яшисе булгач тормышка да чыгып торасы булмагандыр. Бер-берсенә тартылып яшәделәр, яратышып өйләнделәр һәм кияүгә чыкты. Ә нигә аерым соң алар?.. Анда—Рафаэль. Билгеле инде, ул эшен, хәрби хезмәтен вакытлы-вакытсыз ташлап китә алмый. Бик теләгән очракта да булдыра алмый ул бу эшне. Отпускасы исә, бары тик ел ахырында, кыш айларында гына булачак. Ә Лена—Уфада, аның монда эш урыны бар. Рафаэль янына китсә—ул эшсез калачак. Анда әле мәктәп ачылмаган һәм кайчан ачылачагы да билгеле түгел. Аның бит әле аспирантурага керү турындагы күптәнге хыялы да бар. Эшсез калса—стаж өзеләчәк. Өч ел педогогик стажың юк икән, сине һичкем аспирантурага алмаячак. Хәрби гарнизонда мәктәп ачылган тәкъдирдә дә югары уку йорты һичкайчан булмаячак. Димәк, аспирантурада укып йөрүнең нинди мәгънәсе кала? Башлангыч мәктәптә укыту өчен гыйльми дәрәҗә сорамыйлар?.. Әнә бит нинди югалтулар кичерергә тиеш ул үзенең мәхәббәте хакына. Шулар өстенә, Лена китү хакында сүз кузгаткан саен, әнисенең авыруы көчәя торган булып китте. Ул китеп барса, әнисе кем белән кала...

Уйласаң—башың әйләнерлек! Уйларының очына чыгарлык түгел, чияләнгән төен сыман менә...

26 июльдә Рафаэльгә яңа салынган фин йортыннан бер бүлмә бирделәр. Бу шатлыклы хәбәр билгеле булгач та, ул үзенең бердәнберенә ашыгыч телеграмма сугып хәбәр итте. Хат озак йөри ич, түзеп тора алмады. Өйләндем, хатыным белән яшәр урыным юк, дип бертөзлексез тукый торгач,

бирделәр аңарга ул фатирны. Билгеле, хәрби хезмәттәге уңышларын да искә алмыйча булмагандыр. Чөнки СССРның хәрби һава көчләре командующие килү уңае белән уздырылган күргәзмә очулар вакытында Рафаэль Смаков, бик күп асслардан да зуррак осталык күрсәтеп, җитәкчелекнең иң югары бәясенә лаек булды шул көннәрдә. Командующий әмере белән аның хакында, хәтта, махсус хәрби листок чыгарылды һәм илнең бөтен хәрби һава көчләре урнашкан частьларына таратылды.

Инде хәзер, шундый авырлыклар һәм казанышлар белән алынган фатиргa күчеп бергә-бергә яши башламасалар, нинди кыен хәлдә калдырачак ул үзенең сөекле Рафаэлен. Гаиләләре булып та фатирсыз яшәргә мәҗбүр булган хезмәттәшләренә нинди йөз белән карарга тиеш була инде ул?..

Аннан тагы шунысы да бар—үзеңнеке генә булган аерым бүлмәдә яшәү Ленаның бик күптәнге хыялы иде. Уфадагы коммуналь квартирада әнисе белән икесенә бер кечкенә бүлмә иде аларның. Анда да үзләре генә яшәгәннәре булмады. Сугыш вакытында Ленинградтан эвакуацияләнгән заводта эшләүче кызларны керттеләр аларга. Сугыштан соң, әнисенең туганнары килеп тора башлады. Һичкайчан тынгылык булмады.

Рафаэль инде көн саен телеграмма суга аңарга хәзер. Аларда бер үк сүзләр: "Кайчан киләсеңне хәбәр ит. Кинель тимер юл вокзалында үзеңне каршы алырмын. Яратып, Рафаэль". Шундый эчтәлектәге өченче телеграмма белән аның чираттагы хаты да килеп төште:

"Кадерлем минем, Ленам!

Синең 1 августта язган хатыңны менә бүген алып укыдым һәм шундук җавап язарга утырдым. Синең хатың белән бергә әткәйдән дә хат алдым, бәйрәм өстенә бәйрәм дип тә әйтергә була. Ул сиңа да хат язып салган икән, алып укыгансыңдыр дип уйлыйм. Синең белән миңа бирелгән бүлмә белән кызыксынгансың, менә мин аның төгәл план-схемасын сызып җибәрәм үзеңә. (Буй-буй сызыклы дәфтәр битендә бүлмәнең җентекләп сызылган схемасы китерелә. -Автор искәрмәсе). 1—коридор, 2—күршеләр бүлмәсе, 4-5—шулай ук күршеләр бүлмәсе, аларның берсендә безнең врач яши, 6—монысы инде безнең бүлмә. Аның ике тәрәзәсе бар, ул тәрәзәләр зур, бүлмә бик якты. Вакытлыча кулланып торыр өчен өстәл һәм ике урындык таптым. Калган мебельләрне аннан-моннан тапкан такталардан үзем ясармын дип торам. Электричество якын араларда булыр дип өметләнәбез. Эчү өчен суны коедан китерәбез. Кое йөз илле метр чамасында гына. Ә хуҗалык кирәк-яраклары өчен суны машина белән елгадан ташыйлар. Киләчәктә водопровод та үткәреләчәк. Йортның тирә ягына агачлар утыртылган. Бер егерме елдан монда да, без синең белән Саратовта яратып йөргән, матур парк һәм бакчалар үсеп чыгачак. Әлегә исә ул агачлар минем тездән генә. Шуңа күрә аз гына җил чыгып алса да монда ком бураны тузгый башлый.

Иртәгә Авиация көне—безнең бәйрәм. Сине дә ул бәйрәм белән тәбрик итәм, чөнки син дә авиациага турыдан-туры мөнәсәбәтле кеше бит инде хәзер. Син килгән көнне үк зурлап билгеләп үтәрбез, боерган булса, без ул бәйрәмне. Августтан да соңга калмассың дип көтәм, гүзәлем.

Сагынычлы сәлам белән, сине сагынып һәм үбеп, Рафаэлең!

8 август, 1953 ел."

Көн саен хат яисә телеграмма алып торды Лена. Рафаэль аны чын-чынлап сагына иде. Ул да сагына, аның да күңелендә тынгылык юк инде күптән. Иң гаҗәбе шул—эштә гаме калмады. Ярый, ул үзе ничек тә түзәр иде әле. Әмма Рафаэль бит гаять катлаулы техника белән эш итә. Күңелендә

тынычлык булмагач, аны уйлап йокысыз төннәр уздыргач, аллам сакласын, төзәтә алмаслык хата ясап куйса. Юк-юк, әлбәттә! Андый уйларны ераккарак куарга тырышты ул үзеннән. Шулай да ул Рафаэль янында булырга тиеш! Аңарга авыр һәм җаваплы эшендә ярдәм итәргә тиеш! Хатын-кыз шунсыз үзенең сөйгән ярын бәхетле итә алмый. Һәм, әлбәттә, үзе дә ул чын бәхетне бары аның янәшәсендә булганда гына таба ала. Тәвәккәлләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килде Лена. Никадәр генә авыр булмасын, яраткан эшен, уку турындагы хыялларын һәм әнисен калдырып, сөйгәне—законлы ире янына китәргә карар кылды.

Икенче көнне иртән иртүк мәктәп директорына үзен эштән азат итүләрен сорап гариза кертте ул. Директор телсез калып торды бер мәл.

—Лена Рәхимовна, сез нәрсә, үз акылыгыздамы? Пычаксыз суясыз ич мине. Йә, кайдан табарга тиеш мин сезгә алмаш! Инглиз теле укытучыларына булган кытлыкны беләсез ич. Ашыкмагыз, калып торыгыз бер ярты елга гына булса да.

—Аңлыйм хәлегезне, әмма булдыра алмыйм. Гафу итегез, мин законлы ирем янында булырга тиеш.

—Соң чиктә, бер чиреккә генә булса да?..

—Бер чирек түгел, бер атна яисә бер көнгә дә тоткарлана алмыйм,—диде ул ике уйларга урын калдырмыйча.

Һәм юлга чыкты. Уфаның тимер юл вокзалында Ленаны күз төпләрен яулык очы белән сөртеп әнисе, ике малае белән аның бертуган абыйсы озатып калдылар. Нидер әйтергә теләгән сыман, ул утырган поездны таккан паровоз йөрәкләреңне ярырдай аваз чыгарып өч мәртәбә сузып-сузып кычкыртып җибәрде шунда.

*Ахыры киләсе санда.*

---

*Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Гөлчәчәк
Галиева

## ГАЗЗӘБАНУ

РОМАН

Тасвирланган хәлләр 1921 елгы ачлык вакытында бара. Әсәрнең үзәгендә – өзелеп яраткан иренең яшь хатынына көндәш булып яшәргә дучар ителгән, реаль тормыштан алынган татар хатынының (автор аның хәтта исемен дә үзгәртмәгән) тетрәндергеч язмышы. Тагын бүтән катлаулы язмышлар белән уралып-чорналып, ул гаҗәеп бер вакыйгалар йомгагын хасил итә.



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# АГЫМСУГА БАШЫН ИГӘН ТАЛ МИН

РОБАГЫЙЛАР

***

**Һәр таңымны каршы алам өмет белән,**
**Сәлам бирәм елмаеп һәм көлеп кенә,**
**Дөнья иркен, хәят матур—яшик әле**
**Бу тормышның кадерләрен белеп кенә.**

***

**Ашкына күңел һаман да яхшыга,**
**Талпына гел изгелеккә, яктыга—**
**Тугры калып яшьлегендә эткәйләрдән**
**Иман итеп кабул иткән антына.**

***

**Табам димә бу дөньяда яшәү ямен,**
**Үз итмәсәң сине үстергән халык гамен—**
**Харам ашап йөрәгеңне май басканчы**
**Иңнәреңә куәт бирсен үз тәгамең.**

***

**Еллар белән үлчәп булмый гомерне,**
**Юллар белән үлчәп булмый гомерне,**
**Күпме кылган игелегең кала җирдә -**
**Гомер үлчәүләре шушы түгелме?!**

***

**Бер карасаң тормышыңа—уйланырсың,**
**Гафләт йокысыннан җитез уянырсың,**
**Гомереңдә кылганнарга бер күз салсаң,**
**Билләһи дим, үз-үзеңнән оялырсың.**

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941)—*шагыйрь; «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Гомерлек язым» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге һәм "Татнефть"нең С. Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты. Балтачта яши.*

***

Җитте вакыт—басып торам ызанда,
Кылганнарым салып куйдым мизанга,
Изгелекме, яманлыкмы—кайсы өстен,
Шуңа карап Раббем бирер низам да...

***

Агымсуга башын игән тал мин—
Уйларымның очын таба алмыйм,
Бер талпынам, агымсудан калмыйм,
Тамырларым монда, китә алмыйм...

***

Бу дөньяда яшәмәгән кем генә—
Бары да әйткән, гомер дип өч көн генә,
Бирелә ул бу дөньяда яшәүләрнең
Фанилыгын тик аңлар өчен генә.

***

Гамьсез тормыш кочагында кинәнеп
Йөргән чакта, китәм кинәт имәнеп—
Гап-гади бер карга булып чыга ул
Менә тоттым бәхет кошын дигәнем...

***

Сабырлыгын җуя кайчак күңелем
(Белә, юкса, унсигездә түгелен)—
Сындыра гел сабыр канатларын бәреп,
Буе җитмәс нәрсәләргә үрелеп.

***

Тәүге коймак булмый икән төерсез—
Үзегез дә әле беркөн тоерсыз,
Тоерсыз да, чигәгезне кашый-кашый,
Хак әйткән бит бу Гарифҗан диерсез.

***

Яшьлектәге ак хыяллар, кайда сез,
Беләм, хәзер сезне эзләү файдасыз,
Тик шулай да хәтер аша әле мине
Яшьлегемә көн дә алып кайтасыз.

***

Ялган менсә, алдау менсә мөнбәргә,
Сулау өчен һава бетә меңнәргә -
Бу ил бүген тынчулыктан тыны бетеп,
Давыл көтеп тынып калган бер мәлдә...

***

Илнең канлы сугышлары көндәлек...
Кемнән генә каһкаһәләп көлмәдек...
Берәүгә дә тыныч тормыш бирмәдек.
Үзебез дә рәтле тормыш күрмәдек...

***

Гайрәт бездә, кодрәт бездә җитәрлек,
Акыл такырлыгы тик ис китәрлек—
Булганнарын сүтәбез дә җимерәбез,
Төзегәне чыпчык алып китәрлек.

***

Тормыш дилбегәсе бүген «текә»ләрдә,
Туя алмый тияләр бит теңкәләргә,
Шулар йөген тарта-тарта гомер буе
Сөялләнеп бетте инде җилкәләр дә...

***

Акыл сатар, менсә, биек мөнбәрләрдән
Уздырыйм, дип үзеннән дә элгәрләрдән,
Йә Ходаем, үзең сакла «бөреләнми»
Биек-биек мөнбәрләргә менгәннәрдән.

***

Кырык якка ташлый-ташлый үз эшен,
Галәмнәрдән эзли кеше үз ишен,
Күрми, бахыр, күршедәге үз ишенең
Бәгыреннән саркып чыккан күз яшен...

***

Бер җылы сүз кирәк кайчак күңелгә
(Минем күңел дә салкын таш түгел лә!),
Тик сүзләрең керсез, ихлас булмаса
Күңелемнән гөл өзәм дип үрелмә!

***

Гомеремдә үрелмәдем кылычка,
Бурычка алмадым тәгам бер уч та,
Йөрәгемә алып читләр хәсрәтен,
Үз гомеремне өләштем бурычка...

***

Нәрсә булды әле безгә, нишләдек,
Әллә инде үз-үзебезне көчләдек,
Ил җимерек, халык гаҗиз, кеше ят—
Ник гомерне болай ямьсез очладык?

***

Әле генә якты таңнар аткан иде,
Күңелемдә гөлләр чәчәк аткан иде...
Эңгер-меңгер инде җитеп килә икән—
Гомер кояшым яртылаш баткан инде...

***

Мин хәтерлим тәүге очрашу мизгелен,
Йөрәк шашты—кысып тоттым тезгенен,
Шулай таба булыр кеше гомер буе
Иркәлисе, сугарасы үз гөлен...

***

Башым куеп синең назлы күкрәгеңә,
Бер ашасым килә күңел күкләреңә,
Тургайлардан көнлим, алар көн дә
Җир куенынннан оча зәңгәр күкләренә.

***

Тормыш сыный мәхәббәтнең ныклыгын—
Араларда ялган-харам юклыгын,
Тормыш сынауларын үткән сөю генә
Җиңә ала язмышларның шуклыгын.

***

Мин бу җирдә иң тиңдәшсез бәхтияр—
Сөям, диеп миңа бүген дәште яр,
Яшьлекнең шул сәгадәтле мизгелендә
Фәрештәләр «Афәрин!» дип дәштеләр.

***

Гомер буе сөю диеп янабыз,
Гүзәлләрне күрсәк арттан чабабыз,
Сөю китә, гүзәл кала, үзебез
Сөю дигән шул тозакка кабабыз.

***

Бу тормышта күп нәрсәдән туйдым мин,
Күп ләззәткә инде нокта куйдым мин,
Туйдырмады ләкин сөеп яшәү гаме—
Яши-яши менә шуны тойдым мин.

***

Җырла, диеп минем сөю хакында,
Зар ялварып үтендем мин акынга,
Җавап бирде, бу сөюне бәһаләрлек
Сүз табарга көче җитмәс Хакның да!

***

Сөю нәрсә?—сүнми торган уттыр ул,
Йөрәккә кадалган хәнҗәр-уктыр ул...
Ак сакаллы бабай әйтте, көрсенеп:
—Чын сөюне тиңләр мисал юктыр ул!..

***

Диңгез кипкән, текә таулар ишелгән,
Мәрмәр ташны тишеп гөлләр тишелгән,
Мәрмәр таштан каты бәгырьләрне тишеп
Сөю гөле шыта җанның кай төшеннән?!

***

Тукта инде, ни эшлисең, юләр, дисең,
Күрсә әгәр бездән кеше көләр, дисең,
Ә мин уйлыйм, ул көлгәннәр сөю-назсыз
Үткән көннәрнең әҗерен түләрме соң?!

***

Күп татыдым бу язмышның тукмагын,
Вак тормышның бу көндәлек юк-барын,
Җитте, диеп нокта куйдым барына да,
Өстен күреп хәләлемнең уклавын.

***

—Касәләргә шәраб тутыр әйдә, сакый,
Шәраб барда дөнья иркен, гомер—бакый.
—Тизрәк күтәр касәләрне әйдә, тәкъсир,
Газраил килгән кунакка, ишек шакый!

***

Кичтән безне кайнар шәраб бөркет итә,
Иртәгесен бөркет баскан көртлек итә,
Таңнан кабат бөркет булу җаен эзләп
Күкрәкләргә сыймый йөрәк, дөп-дөп итә.

***

Карлыкканнар инде җырлап тургайлар да
Җыр яңгырамый инде иркен тугайларда,
Җиргә иңгән сары көзләр моңсулыгы—
Көзләр кебек моңсу мин дә бу айларда...

***

Чаба гомер бәйгедәге чаптар кебек,
Юлда булса Иблисне дә таптар кебек,
Шуның белән зая узган гомерләрнең
Бар бушлыгын, бар гөнаһын аклар кебек...

***

Җиләк исе бөркеп торган пакусларым,
Җырларыма моң иңдергән аккошларым,
Мин кайтара алмам инде сезне кабат,
Шушы җырым бары сезгә багышладым...

***

Җиде утның уртасында кала кеше,
Җиде юлның чатларында кала кеше,
Ак өметен югалтмаса авыр чакта—
Үз кыйбласын, үз бәхетен таба кеше.



Әхәт
Гаффар

# КӘФЕНГӘ КЕСӘ ТЕКМИЛӘР

ХИКӘЯ

...—Менә болайрак ул, брадән: әгәренки шушы мәлдә синең белән минем телебезгә үткән зур сугыш турындагы сүз кергән икән инде, ул бөтенләй бүтән нәрсә—Рәсәй киноларында күрсәтелгәнчә... сурәтләнгәнчә генә түгел. Һәммәсе дә дөрес шикелле үзе. Тик чын түгел. Анда ни юклыгын син әйбәт беләсең: анда без—татарлар юк. Юкка мин үзем дә тук, дигәндәй, юк—бетте китте. Шуның белән эшең бетте, кодагый. Син безнең бу зиратыбыз юлына төшкәнче, авылыбыз уртасындагы һәйкәлгә йөз дә сиксән тугыз исем язылганны күрмичә үталмыйсың. Һич юк... Дәшмә, энем!.. Әйе, синең миннән дә күбрәк белгәнеңне беләм. Сталинградны без—татарлар алып калганыбызны да беләсең син... Эндәшми тор дим ич. Сал, күчтәнәчеңне үзең дә уртлап куй. Мине дә онытып бетермә. Менә, рәхмәт яусын... Шулай итеп, энем, ул кино әкиятчеләренә каршы кулга ни туры килсә шуны тотып—чалгымы анда, өч җәпле сәнәкме, бастырыкмы эләктергән килеш, җан ачыйгысы белән соңгы атакага барган шикелле итеп, капма-каршы чыгасыңмыни инде. Хәзер, кирәге барые... Бәдрәфкә керергә дә ярамаслык мльённарын учлап, ул киночылар үзләре тышка чыксын. Алар бит—ни, нәрсә әле—дизентериклар. Калганын әйтеп тормыйм. Шуңа күрә алар "сортирда манчыйбыз" дигәнне элеп алып күккә чөйделәр дә. Ие... Ә без, әйтик, мин, кәпрәя димә, алгы чакыру белән үк сугышка чыгып киткәннәрдән. Дары исен тансыклаганга күрә түгел. Кичкә кырын белдерелгәннең иртәнге таңында ук. Шуннан чыгып киттем. Ягъни без инде. Типсә тимер өзәрлек ир-атлар. Киттек. Баскан җирләреннән ут чыгара торган җыен җегет-җилән. Райвоенкоматта тиешле тикшерү үткәченнән соң. Миңа бронь бирмәкче булып маташканнарые. Тракторчы бит. Җитмәсә—бригадир. Гадукларымнан каласым җук дип, кырт кына кистем. Минем тәртибем бүтән иде—үземчә. Уптым илаһи бөтенебезне тезеп фотокарточкыга алдылар. Без авылдан унбиш җан идек. Мен дә тугыз йөз дә алтынчы елгылардан башлап. Егерменче елгыларны кертеп. Иң кирәклеләребезнедер инде. Аннары гына алдын-артын санап тормастан киткән ул... Шуннан соң без гармун алдык та күз-кан елаш катыш җыр белән чыгып киттек. Озатышуны сүз белән әйтеп бетерерлекме соң аны... Чүәгемдәге тузанны кульяулык белән сөрткәләгән атлы кыланып, әледән-әле борылып карап алгалаганымны гына хәтерлим. Мин генә түгел, һәммәсе

шулай иткәндер инде. Җыенның бергә булганда бөтенең бер иш. Аннары сун, шәмәхә карандашыңны тәкерекләп, хатлар язганда гына җанны телгәли-телгәли искә төшкәли икән... әйтелгәне дә, әйтелми калганы да. Сүзнең иң кадерлесе—әнә шул әйтелми калганы. Алдагы кырыгынчы елны иген хәтәр унганые. Инде аласы алынган, кертәсе кертелгән. МыТыеСтан тагын бер йөк килеп төшсә, син аны капка төбеннән кире борып җибәрәсең. Яңага хәтле җан башына исәпләгәндә болай да хәттин ашкан. Кош-кортка, күзгә мал-туар симертергә, әз-мәз сатлыкка үтә чыккан. Тик безнең сыман ир-атның, бигрәк тә минем шикелле тракторчыларның җаннарын кайбер шик-шөбһә сызылып таңнар атканда өшетеп-өшетеп алгалаган мәлләр яшерен-батырын түгелие инде. Мүкәләп кулыңа таянган килеш көйгән иреңеңне, тамагыңны сулыга-сулыга салкын чишмәдә чылатканда Җир куеныннан килгән тирәнтен су агымын сизми ятмыйсың. Ул чагында бөтен дөнья безнең биш йөз дә егерме биш өйле авылыбыз иде. Кендек бавыңның киселеп, әнкәң сөтеннән аерылган җир. Бер дә бер заманны иреңеңне бөреп үреләсең дә... әле баягынак иң татлы дип күнеккән төшкә йә тоз сипкәннәр, гәрчич сылаганнар, йә морҗа корымы сөртеп куйганнар булып чыга. Борының очына чиртмиләр, үрелгән кулыңны читкә тибәрмиләр анысы. Иреңеңә әнкәң чәйнәгән арыш ипие имезлеген каптыргач, ирексездән аерыласың инде. Кая китмәк кирәк. Беркая баралмыйсың. Телисеңме, теләмисеңме—әкренләп үзең яши башлыйсың. Яшисең килсә әгәренки. Югыйсә әлегә син терегә тере, ә янәтәдән анаң карынына кереп булмый ич инде. Моны истә тотмаган адәм заты әнкәсенең карынын ни иртәләрен, ни кичләрен һич тә хәтерләми. Ә каберен онытыр да онытыр... Сугышларга әллә нәрсәләр төяп чыгып китеп була. Ә туган йортыңның имән матчасында сине тирбәткән бишегең асылынып торган тимер элмәк калган—беләсең. Ул биштәреңә генә түгел, ә бәлки бөтен дөньяга сыймый торган әйбер. Аны күзеңнең соңгы нуры төшеп өлгергән ни кояшка, ни айга, ни бер-бер йолдызга да боргычлап куеп булмый инде. Шунда гына тора—матчада. Моны сиңа беркем әйтми. Һичкем өйрәтми дә. Тегесе дә, бусы да үзеңә генә кала. Фәкать әлегә син исән, тик инде үлеп барганыңны тойган, аңлаган чагында бигрәк тә. Сугышта моны әллә күпме тапкыр кичерәсең. Мәгънәсез, беркемгә дә кирәге булмаган сугышта... Ие, без күптән көттерелгән, көтелгән дошманга каршы киттек. Дошманның шуннан башка бүтәне юк иде. Ул мәңге безгә кызыкты. Ә без ач-ялангач лабаса. Аларны чабата үрә-үрә бишкуллап көтеп торганмыни?! Суң инде, җанкай-җанаш дошман... Сине әнкәң яхшылыкка тапканын яман ниятең котырыгы баскан икән—башыңны тык, кер, тик кереең алдыннан чыгарыңны уйла. Ие... Ә болардан да аламарак дошман без киереп ачып чыгып киткән басу капкасының теге ягында калды. Шул—күмәк хуҗалыкта... колхозда инде... Аңа язылырга аяк терәп каршы торган әби белән бабайны, алардан күрмәкче әти белән әнине, алар белән бергә без ике апа, өч угланны шөкер генә торган өебездән куып чыгарган затлар. Җук, оятсызлар! Җәберләр! Язның җылы бер көнендә. Сабага төшү хәстәрлеген тәмам күреп бетергәч. Шулар инде—чабатасыз-нисез җыен-җыентык әтрәк-әләмнәр. Кешелеккә генәме сун, ни көзге, ни сабанга чыгарлык эш чабаталары да үрә белмәгән затсызлар. Аларгамы суң безнең эшләребез тынып торган арада Донбассмы, Кузбассмы шахтыларында күмер чабып, Азау, Каспий дингезләрендә путина тотып, шул зимагурлыктан гармун күрегедәй елык-елык уйнап торган, бакыр кадаклар белән төпләнгән җыелмалы шыгырдавык чып-чын күн үкчәле ялавай итекләр киеп йөрү! Күн сәгатен болар ише чамалап түгел, ә көмеш чылбырлы көмеш сәгатьләребезнең капкачын ачып кына әйтү. Чырт кына иттереп. Музыйкалаттырып. Тәкәбберләнми-нитмичә генә. Тәүлек

сәгате тегеләрнеке дә, безнеке дә төп-төгәл чыга иде анысы. Минутлап. Ә авылда минут кеменә кирәк? Әтәч кычкыра да күкәй салган тавык әйтә. Секундлап... Авылда таң белән зират арасы гына бар. Ә сугышта, энем, әтәч белән тавыкка караганда өлгеррәк икәнсең, дошман—синеке. Безне дә өебездән мунчабызга куып чыгардылар. Теге очтагы берәүләрне алып ук та киттеләр әле, ә безне калдырдылар. Бәлки калдырып торганнардыр. Ак мунча буралы, дранча түбәле. Идән өрлекләре—имәннән, түшәм такталары буй-буй усакка утыртылган. Гомер черерлек түгел. Чишмә бурасы белән улагы усактан икән—бөтенен гомеренә житәрлек. Ләүкә бар, ике сәндерә ясап куйдык, өч идән ятагы, алачыкка әкренләп тыштан саман кирпеч өйдек. Күзгә кергәч, йортыбыз тирәли агачлардан һәммә коелган яфрак киселгән дә чабылган чия бакчабыздан үрелгән нигезгә түшәлде. Ә мунчабызның әчкелтем-төчкелтем тәме исен мин ярты Аурупа буйлата таратып йөрдем. Карасам, боларда мунча дигән нәрсә гупчым юк икән. У-у, болар. Имеш. Өеннән куып чыгаргач та кертеп ябарлык мунчасы булмаган адәм страмнары. Мин андыйларны дошман күрергә дә хурланам. Менә ичмаса безнең мунчабыз коры, жылы иде. Кысанлыкка кысан анысы, ә ыгы-зыгы дигән нәрсә булмады. Әле дә онытасым жук: ләүкә астында йодрык-йодрык симез ике гөберле бака торды. Мич аралыгында төннәр буена мыеклы күрән чикерткәләр сайрашып чыга иде. Сандугачларын бер якта торсын. Әйтеп, сөйләп бетермәле түгел. Билләһи газим! Ә без аларны салкын урамга куып чыгармадык, ачлык-патшага бирмәдек. Алай итәргә без теге комса-ач корсак активлармыни. Кызгану гына түгел, ә өйдәшләребезгә тиң санап тоттык. Бетләмәдек. Кандалага кан эчермәдек. Кычу кертмәдек. Трахум эләктермәдек. Без—тегеләр түгел. Мунчада торабыз бит. Ә юынуыбыз—селтеле. Ягъни көл дигән сүз инде. Әгәренки белсәң. Тик алай гына түгел ул: бакча башыбыздагы тирән ерганактан язгыдыр, хәтмәледер жәйге ташулар агып төшкәндә без шулардан калган алсу, зәңгәрсу, яшькелт ташларны жыеп алып юына торган идек. Элек өебездән өзелмәгән "Гөлжамал" исле сабыннарын бер якта торсын—ике-өч тапкыр шул ук суда кулыңны, аягыңны шулар белән ышкып юынсаң әйбәт була торган иде. Тәненне—кычытканлап. Һәрхәлдә көне буена эшләп яргаланган кулыңа шул ташлардан кала дару-фәләннең кирәге юк... Соловьевкадагы, Имәнкискәдәге болыныбыз чабылмыйча, үләне чәчәк атып, пышкып, картаеп ята. Мал-туар апчыгып кителгән. Амбар буш. Кара тараканнарга, жир бәбкәләренә хәтле кайсы-кая таралышып бетте. Жон тегермәнендә жон тетү, талкыда сүс талку диярсең. Анадан-тума ише шәп-шәрә калдырдылар. Хурлыгы гына да ни тора. Әти күмәкләшеп хужалык итүгә—колхозга инде—язылмады. Аның жыен-жыентык, тәмам яраксызга әйләнеп беткәннәр белән бер тәртәгә керәсе, әтрәк-әләмне мичәүдә тартып барасы килмәде. Утыз тугызынчы елдагы вафатына хәтлек ничек кирәк алай үз-үзен, без—гаиләсен тотты, шуна күрә һәммә хокукларыннан мәхрүм иде. Сайлау, сайлану хокукыннан. Кол. Тик—буйсынмас. Кем әле? Әйе—Спартак. Буй сындырмаган икән—азат. Ә азат кешегә бөтен дөнья—төрмә. Ул мине Ленинградка чыгарып жибәрде. Баладан баш-аяк дигәндер инде. Мин утыз өченче-утыз дүртенче еллар сезонында "Лендорхоз" трестына жир казучы булып эшкә яллandым. Әгәренки бухгалтерия сумманы алай-болай итә икән, тиешлесе суд тәртибендә табыла иде. Ике яклы имза салынган ике арадагы килешүдән соң булуы ихтимал һәрбер бәхәс тиешле юнәлештә РККАда яисә халык судында карала. Эшнең, әйтергә кирәк, беркайчан да шуңа хәтле килеп терәлгәне булмады. Тиене тиенгә барды. Шул тәртипне бозып кара. Тәртип катгый иде—көмеш акча шикелле коеп куелган. Ак патшалар заманындагыдан һич ким түгел. Тәүлеккә түләү генә

дә ике сум да кырык тиеннән барды. Анда-санда юл чыгымнары—яллаучы исәбеннән. Әйбәт ашатып-эчертеп тордылар. Ермитажга алып баралары. Әллә ничә тапкыр. "Буре" фирмасының көмеш кесә сәгатен чип-чиста йоннан тегелгән бостон кәчтүм-чалбарның сул як кесәсенә салып кайткан кеше идем мин. Өстәвенә—шундый ике пар шивыйут кәчтүм-чалбар тегебу күчтәнәч, бүләк-мазар. Чуты-исәбе юк. Өйләнәсем дә булыр дигәннәребез "Зингер" атлы тегү машинкысы апкайта. Ә этине ул арада еНКеВеДе сулыш алырга да ирек бирмичә тилмертеп торган икән. Өзлек-төлексез. Тегү машинасының орчыгы урынына. Анда-сандагы юл арасы—кырык чакрым. Безнең Казанга, Мәскәүгә генә түгел, ә Петербурга хәтле йөртә торган юртакларыбызны апчыгып киткәннәрие ич инде. Күз алдына китер, энем: ике җиңгәбез Балык Бистәсе базарында ачтан үлмәс өченгә тана сатканнар да боларны кайтышлый ике кызылгвардияче, тагын берәү булган әле, куып җитеп атып үтергәннәр дә талаганнар. Аларның—кайсысындыр инде—алты яшьлек бер малае да булган. Белә күрмә, зинһар, энем, тик мин, башлаганмын икән инде, әйтеп бетерим: болар теге сабыйның башын арба көпчәге тугымына бәргәннәр. Без боларның кемнәр икәнлеген белмәдекме соң? Шулай ди, ие... Ә эти үзенә бармак белән кагылу түгел, бер-бер кыңгыр сүзне дә кабул кылмаган. Күрәсең, үзенә карата тик тормастан хаксыз сүз сөйләүне, дорфалыкны, атасы-анасы белән сүгүләрне... күп инде... кабул кыла алмаган. Нигә дигәндә—аның алтыны булган. Тегенди-мондый түгел, ә—империаллар. Алтыны бар—бакыр учлап үлмәс. Ә империалны империядә урлап булмый. Ул банк аша гына бирелә. Тиешле, ышанычлы кеше икәнсең. Анда син кем дә, тиенең-тиенгә туры киләме-юкмы икәнен үтә шәп белеп торалар булган инде. Шәкүр карак өше шухыр-мухыр икәнсең, энәтанагыңа хәтле теркәлеп куелган. Әтинең эш йөртмеш вакытында биш-алты урыс авылы кинәнеп тук, дәүләтле яшәгән. Урыс авыллары, брадән, мыегыңа чорнап куй. Белгән инде. Тирә-юньне тотып торган җир биләүче бер кеше булган—Макашин. Капитоныч. Алпут дип йөртәләр иде. Сез укыган дәреслекләрдәгечә әйткәндә—алпавыт. Ул вакытларда хәзергечә каһәрлектән вә бөлгенлектән ничарадан бичара булгачыннан соң җыен эте-бетенә димәктәй шикаятьме, кызгандыру хатымы инде шунда—булмаган. Нигә димәктән—сәбәбе юк. Әйтелгән, аңлатылган: сиңа шул-шул хәтле дисәтинә җир, өстәп—күпме чабасың—печәнлек болын. Ик, чәч, җый—уннан берсе хәтлесен вынь да положь. Тирес түк, белгәнеңчә ик. Калганы—үзегезнеке. Ә бер шикаять киткән. Казан генерал-губернаторына. Әтигә карата. Эш патшага хәтле барып ирештерелгән. Әле дә булса телдәгечә: ышансаң ышан, ышанмасаң, иренеңә шайтан төкереге, әтигә патшадан депеша килеп төшә—хат. Янәмәсе, дөрес сүз йөртәсез икән, әфәнде. Хатын-хәбәрен иншалап әйтеп торганда нәкъ менә әфәнде дигән... Ул заманда урам себерүче дә—әфәнде... Ие, дигән, дөрес фикер йөртәсез икән, хутырларга тарату Россия империясен таркатуга тиң. Анда-санда һәр хуҗалыкның үзүзенә аерым-аерым торуы Россия империясенә килешми, бигрәк тә татарларның мәхәллә булып яшәү-торуларына бу бер дә ярамый. Очрагы килеп чыгу белән фикерегезне предсовмин Столыпин Петр Аркадьевичка әйтермен. Үзе нәрсә чәчсә, шуны урсын. Калганын мировой җыеныгызда хәл итегез—шунысы дөрес булыр. Ә пока Казан губерниясе губернаторы аша сезгә, господин хороший, "За усердіе" медале бирүне тапшырам. Өстәп, синең карамактагы уникe ярым дисәтинә җиреңә тагын өч дисәтинә җир кисеп бирүләрен, печәнлек болыннарың күпме булса, шул кадәрле үк өстәмә җир, Корноухово, Түллинкә урманнарыннан диләнке билгеләнергә тиешлеген боердым... Мин, энем, теге "За усердіе" медален бик яхшы хәтерлим. Андагы "і" хәрефен дә. Алгы ягына дәфнә—синеңчә лавр инде,

янәшә—имән яфраклары ботагы сурәтләре коелган. Ә теге ягында император Николай Икенченең сурәте... "Я возвращаю ваш портрет"—сакал-мыегы, колак, борын шәрифләре үз урынында... тик муен төбе турысы балта чапкандай әзрәк сулкыйлатыбрак төшерелгән. Хикмәт инде. Аннары соң ишетеп, укып белүемчә, аны мангаена атып үтергәннәр булса кирәк. Теге медальнең дә баш очында тишек бар ул: аны әни үз чулпысына тагып йөрткән. Талир тәнкә, империал, көмеш ун тәнкәлекләр янында. Талир тәнкәнең ни нәрсә икәнен беләсенме? Тыштан—алтын, эчтән—көмеш. Напрасны татар халык җырларына кермәс иде. Хәзер—миллион сум. Коръән чыгуларда, бәгъзенең өчесенме, җидесенме, кырыгынчымы мәҗлесләрендә тыңлаган әлеге чулпының алтын-көмешләре аннары өзелеп-өзелеп, кисеп-кисеп, таланып алынганда, әни шуны апкалган—"За усердіе"не. Сурәтенә ни төшерелгәнлеген чамалап алган булсалармы? Чәче-толымы белән тартып апкиткән булырларые. Ә ул—ак алтыннан коелган. Шундыйлары да булган. Әйбәт икәнсен—ни тагылганын әйтмә. Моны белсәләрме? Патша галиҗәнапләренең әтигә теге хат-ниендәге хәл-әхвәлен кирәк урынга житкергәннәр. Губернатор почтасын—белэм—фельдъегерь пар атта махсус көне-сәгате белән житкергән бит. Ул хатны... юк, депешаны мин үз хәтеремдә әле дә тотам әле. Минем теге-бу, ул-бу сүзләрне әйтүемә исен китмәсен. Белемем дүрт кенә сыйныф булса да, "эскюзе муа" дигәнне шәп беләм мин. "Хенде хох" белән абзардан бер сарыгынны да куалап чыгаралмыйсын. Кире кереп китүе бар, ие. Аннары изалан. Куып чыгарыр өчен. Ферштейн? Ул хатны ачкан чагында сөргечле икәне исемдә. Көрән. Ә уңлы-суллы дигәндәй, тәреле тилгән төшерелгән "водяной" билгене син белмисен... Беләсенмени? Белмәскә, әме. Андый тамга кәгазь акчаларга гына сугыла торганые. Өчлекләр, бишлекләр, унлыклар. Йөзлеген, хәер, күргәнем булмады. Андыйлары—сөлге буйлылар—әтинең пыяла банкысында гына түгәрәкләп, төргәк-төргәк төрелеп тотылганын беләм... Боларның бөтенесе НКВД өчен зур табыш бит инде. Әтине тинтерәтергә. Талкырга. Җан заһиләсенә төшеп. Имеш, патша булып патша белән элемтәдә торган. Теге—канәчкеч Николашка Икенче белән инде, янәмәсе. Бөтенрәсәй императоры бит, самодержец, едрит. Офыкта үчлек белән дошманлык—вражба да вражда—балкырга керешә. Столыпин үтерелде. Уйлавымча, моны, язганнарынча, теге эсэрлар кылмады. Аны шулар кулыннан патша үзе үтерткән. Кайсы нәчәлник, хет патша булсын, үзеннән акыллыракнымы... җүләррәкнеме үз янында тотасы килсен? Берәү: "Нет человека—нет проблем" дигәнме әле? Әйе, бөтен нәрсә германнар өчен эшләнелгән. Алар без барында тыныч йоклый белми. Әйе, брадән. Аларга гел сугыш кирәк. Үзебезнекеләргә кирәк булганы кадәрле үк. Тегеләр ягыннан—үз ахмаклыгы, безнең яктан—үз аламалыгыбыз. Бер сүз белән әйткәндә, ике яктан да—кабахәтлек. Ике яклап. Гыйнвар этләре шикелле, әләгешешми кала алмаганнар инде. Эт—эткә, бака бакага әләгешкәндә таяк белән дә аралап булмаганы ише. Ә таяк башы безгә төште бит... Әйтик, мина. Ике шайтан бер мунчага сыймас. Болар—сыйды. Ә? Мильон халык... кеше... боларга чүп тә булмады. Болар мильоннарны үтерә алуга хушландылар, брадән. Аларга гашыйк булу, өйләнешү, баланның дөньяга килүе... ни диим инде... кирәк түгел иде. Болар хакимияткә килү белән үк халыкларны ачлыкка, хәтта мәет ашарга дучар иттеләр... Мунчага трактор кертеп була. Ә инде шул ук мунчага танк сыймый. Сыймый инде—бетте-китте! Танкны каенмы, имәнме себеркесе белән ничек чабындырмак кирәк? Бигрәк тә мәтрүшкәләп. Урып, бәбкәләргә төйнәлеп, баш-баш итеп көрнәленгән уҗым ашлыгын болар Суслонгер, Освенцим концлагерьларының тәгам икмәге итмәс өчен... үз бункерларында качып... ну... аракы эчеп, хатын-кызлар көчләп яттылар.

Ә безнең әти азат кеше иде. Аны җан газаплары тетмәгән. Шөпшә дә үзенә кагылганны гына чага. Менә шуңа күрә без үзебезгә каршы чыкканнарны алдырырга дип чыгып киттек. Дене, дине булмаган немчурага каршы. Төп-төгәл "Лендорхоз"лар белән төзелгән килешүләргә, райкомнар чакыруына, кушуына карап түгел. Без немецка каршы тәгам өчен түгел, ә бәлки азатлыгыбыз хакына киттек. Башта аларны якаларыннан элеп-салып, аннары сун, җинеп кайткач, ниһаять, үзебезнекеләрнең кызыл үнәченнән буып алыр өчен дип. Намусыбыз, вөҗданыбыз кушканча. Тамак төбебезгә укмашкан ачыткыны йотар-йотмас, саруыбызны мең ел буена кайнаткан үтебезне косар-космас. Без болыннарыбызның чабылмыйча, богыллап өелмичә калганы өчен дә, "Герман көе"н, "Порт-Артур" җырларын тальянга тамак житкәнчә көйли-көйли чыгып киттек. Шундый-шундый җырларны бүтәннәрдән эзләп кара син, брадән—табалмассың: Герман иле кайда да, Порт-Артур кайда? Татар кайда булса,—шунда. Бүтән беркайда да түгел. Айда гына булмавыбыз бар-барын. Тик анысы да—шикле. Ул җырларны хәзер җырлап тормыйм инде. Урыны бу түгел. Озаккарак китүе дә ихтимал. Алардан да хәтәррәкләре күп. Без сугышка бишегебезнең имән матчабыздагы тимер ыргагы үз урынында торсын дип чыгып киттек. Нык торсын дип. Боргычланып. Мәңгелеккә исәпләнгән көенчә. Өйләребез каршындагы канәферләрдән чәчәк атканда шөпшәдер, төклетурадыр, бал кортларыдыр үзләренә сут җыйсын, ә без үзебез шуларның хуш исләреннән һуш булыек дип. Ә ул канәфер—сирин инде—бер дә бер заманны, тәмам шау чагында яшел корттан—сасы яшел кандаладан тәмам гажиз була. Коткарыр ни чарасы, ни әмәле юк. Ә басса—басыласың инде, бастырык астында. Ә бастырыкны юкә бауга тарттырып кысасы арткы ыргак бездә иде ул. Без дөньядагы иң татлы ис—кырдан кайткан әңкәләребезнең тир исен, үз бала-чагаларыбыз әнкәсенең ислемай исе онытылмасын өчен, үз күз яшебезнең тозлы икәнлеген исбат итәр өчен киттек. Ә инде ары таба җип-җинел: җәйге челләдә атта ыргылып килгән шәттән буа суына кереп чумган шикелле генә. Коръән әйткән бит: хатыныңны көчләргә, балаларыңны кол итәргә, үзеңне үтерергә кергәнне үтер дип. Минем бөтен иманым шушы гына иде. Фәкать. Актыкта әйтермен әле, торып тор... Шуннан соң кайнар канлы Днепрны, апрельдәге салкын Шпрее елгаларын ничек кичмисең ди?! Иделдә дә... Сталинградта да зәм-зәм суы акмады. Хәер, мин бер генә чишмәдән дә кулымны юып, битемне сихәтләндергәнне белмим. Кул юасы булса—керосин танкта ич. Танкына су эчереп кичәсең дә—әйдә, малкай. Тегеләрнең Ауропаларын аркылый-торкылый. Тукта, шып, ашыга күрмә: ниме, тегеләрнеке булсын ди ул? Ә? Тотсыннар ди. Үзебезнекен. Татарныкын. Тоттырсак. Йомгак очыннан керешсәң, без Аттиланыкын кире кайтардык. Шундый-шундыйны беләсеңме? Белгәнеңне беләм. Аннары инде Чыңгыз ханыбызныкы. Шуннан соң бер карышы да чит-ятныкы булмаган үзебезнекен. Ауропа шул гына ул. Фәкать шул гына—үзебезнеке. Безнең җирләребез күз карашы иңләмәстәй, уйласаң, акыл ирешмәстәй киң бит ул. Идел бит ул—кин бит ул... Күк йөзе шикелле. Тик инде теләсә нинди килмешәк килеп керсен дә бозсын өченгә түгел... Шуңа күрә керерләре алдыннан чыгарларын уйласыннар иде. Кушаяклап, абына-сөртенә. Чакырылмаганнарга шуннан гайре бүтән юл юк. Татар гайрәтенә каршы чыгарга ярамый. Монда аларны әндри казнасы көтеп тора диярсең. Әтинең теге алтыннарын да табып бетергән юк әле. Мәңге табасыбыз юк икән—кайдадыр ята дигән сүз инде. Аныштынмы?.. Өстәп куй әле, пычак калынлыгы хәтле генә. Нигәдер тамак төбем кипшенгән шикелле булып китте. Менәтерә, яхшы иде—шәп булды... Шулай итеп, мин бәйрәм эстәп йөрмәдем. Сугыш—Сабан туе түгел ул. Туп-турылай бардым да кердем.

Көзенме, язынмы иң беренче бураզна ерганым сымаграк шунда. Артыгы миңа кирәк түгел, тик кименнән дә кимрәк кую гадәтем юк. Бер изеп тапталганнардан тагын да саман кирпече ясамасыннар дип. Шуннан сон нишлим,—колхозлаштырылган Туры атыбыз урынына үземнең хатыным янына, ике кызым белән улым, чиялегебезгә һәр ел май аенын унөчунбишләрендә сайраргa тотынган сандугачыбызга, авылыма кайтып керер юлымдагы һәммә нәрсәне аркылы-торкылыга сөрдем дә чыктым инде. Мин анда-санда сугышта йөрегән арада улыбыз вафат булган. Вафат түгел—һәлак булган. Атасы туды-сюды орден-медаль жыеп йөргән арада. Уйлавымча,—тыл герое. Берәү үлмәсә, бүтәне тумый ул. Ялгышмыйммы? Ялгышсам да—хата түгел... Эндәшмә, энем, шушылай гына торып тор. Артык таптанма—үләннәрне изүең бар... Үземә бирелгән КВ танкын—Климент Ворошилов дип атыйларые—минем ХТЗдан һич тә кайтыш жире юк—авызлыклап иярләп алдым да... Киттем. Үзебездәге бөтен аламалык өчен үч алырга. Алманнарны әйтәм: әй башсызлар да булган икән сун. Үзләре грамотный тагын, танкыларын әйбәт йөртәләр. Тик—мисезләр. Безгә каршы кергәннәр имеш тә, имеш болар безнең, кабатлап әйтүем, күпме мәртәбәләр изеп-тапталган жиребезне, һичкемгә баш имәгән, буй сындырмаган—минем авылымны яулап алмакчылар, име. Безнең бит үз әби-бабаларыбыз кабере янында гына башыбызны июебез ихтимал. Өндәп әйтүем. Кисәтеп. Ихтимал гына. Фәкать. Искәреп куй... Энем, минем сөйләвем әллә ничек бик ипле шикелле, әме... Аркалыкмы, түшлек, тәжеләрнең уны-сунымы, ахыр килеп, чөелдерекме бөтен торамы икәнлеген чамалаган сыман гына инде. Шуннан ни артыгы, ни киме юк аның. Нindидер чыгышка йә кичүгә төшешли арба көпчәге тырнакларына аркылы бер-бер күсәк тыгылганлыгын без сугышның башыннан алып ахырына хәтле белеп бардык. Ә безнең тугымыбыз нык төпләнгән иде. Ык итмәгәйләре мык итсеннәр. Хикмәт бөтенләй бүтәндә иде. Хикмәт сүздә түгел. Менәтерә үз техниканны иртә таннан шәфәкъкача үзебезнең Олы Әшнәк басу-кырлары буенча керосин беткәнчегә хәтлек йөртә-йөртә дә бер генә тургай оясына да кереп туздырганым булмады. Кыр куяннарын әйткән дә юк. Башта карлыгачларның, аннары сыерчыкларның кара болыттай жыйнаулашып әллә кая очып китеп барулары—боларның һәммәсе минеке, минем жанымныкы кебек иде. Синең техникаң сугышта менә шуларның барчасын үз исеңдә тота. Әгәренки үзен алай-болай онытып жибәрмәгәең шәтендә. Синең танкың—ызан арасы гына ул: бишеген, үлем түшәген, ясин чыгарылган ястыгың. Телисенметеләмисенме—ни генә уйласаң да,—ләхетләп күмелмәгән каберең. Анда барганда колхозың хезмәт көненә ике таяк өстәсә дә, ана ат тизәге дә алалмаслыгынны уйлап маташмыйсың. Көнлек эш, хезмәт хакың—нуль, иң кимендә юк таяк. Анда—артта, үз илеңдә, туган-үскән өеңдә үз-үзеннең колдан да ким дәрәжәдә икәнлегең жиреңдә. Колларны әзрәк-күбрәк ашатканнар, эчерткәннәр. Ә без сугыштан жиңеп кайткач та черек бәрәнге боламыгы, кысыр аш, алабута коймагы ашап торган совет офицерлары идек, брадән! Төрмәдә дә кәбестә, чөгендер ашын ипи телеме биреп ашаталар. Безгә тәтемәде. Маңгайларыбызга кыздырылган келәймә тамгалары басмасалар да, без үз дошманыбызга да теләмәгән тамгасыз коллар идек. Жан-бәгырьләребез саф-әнсән булса да... Тик һичкемгә кара йөз күрсәтмәдек. Дуска түгел—дошманга да. Аны уйламыйсың ич инде. Терсәктән узышлый краганны киясең дә сулдыр, ундыр рычакларынны тарткалап та эткәләп ишеп барасың. Шлемофоның колагынны тондырган. Шунда әллә кайдагы, төштәге генә сыман, туган йортындамы, теге мунчабыздагымы ярык-йорыкларда сайрашкан чикерткәләр искә төшкән мәлләр булгалап куя. Йә анда ата сандугачның чия бакчабыздагы кырык

төрлегә сайраплар торып җибәрүләрен әйткән дә юк инде анысы. Әйе. Боларның һәммәсе—шлемофоныңдамы, күңелеңдәме, җаның түрендәме—менә күз-колак салып тормыйсың. Фәкать күз үткерлегең генә кирәк. Боргаланмый-сыргаланмыйча, бигрәк тә чапаланмыйча. Туп-туры. Маңгаеңнан сызылыплар-сыгылыплар агып төшеп, кашың, күз кабагың, керфекләреңне яндырган тән тиреңне уч төбенә, җиң очына сөртеп ата-ата, немецларны күзеңә сарган тузан, күз яшең аша күрә-күрешкә изә-сыта. Кукуруз басуларыннан киләләр бит, ахмаклар. Шул кукуруздан әллә күпме силус чыгасын да белмичә, өнәмичә, санга сукмыйча. Ул шмайссерлы тараканнар минем танкым трактыннан әллә ни тайпылып калырга өлгералмый. Миңа аларның аткан гранатыларын үз аяк асларына төшеп шартларлык итеп ерып барам. Чөнки өйгә әйләнеп кайтасым бар. Нигә димәктә, энем, алар безгә дөреслекнең ни икәнен белмичә кертелгәннәр. Боларын, белмәгәннәре өчен, ни хакның ни хак икәнлеген өйрәтеп алырга туры килде. Яшерен-батырын түгел, танкыма теге-бу снарядлары төшеп шартлаган чаклары булды. Бер-бер үрнең теге ягыннан. Аларның да кемнең кайдалыгын әйтеп, өйрәтеп, төзәтеп торучылары бар ич. Үтә дә хәтәр нәрсәләр. Тере каласың килсә, сиңа үз техникаңны болар тапшырган кординаттан бер-ике сажин уңгамы, сулгамы читкәрәк борып өлгерергә кирәк. Теgeләрнең әйтәсе сүзләреннән дә алданрак. Ыргым вакытларында минем шып туктап кала торган гадәтем барые. Теgeләр тизлегеңне чамалап, “упреждающи” белән аталар. Шып туктагач,—тидереп кара! Ие. Туп-туры өсләренә барып керәсең дә ары узасың. Ну тигәли, каһәр. Искә-анга киләсең инде, тегене-моны иңеңнән селтәп торып атасың, селкенәсең, терелеп китәсең. Әгәренки исән-сау булсаң. Кулыңамы, кочагыңа алыпмы, якасыннанмы туры килгән сугышчан иптәшеңне сөйрәп торып чыгармакчы буласың. Әллә сулый, әллә тере, әллә инде теgeләй дә болай—үтерелгән... Чыгарасың да бит... яртысы эчтә кала, апчыкканың үзең шикелле үк төтенләп көйри. Шулай итеп аны өскә сөйрисең дә—кулдан төшеп китә. Бүтәненә ябырыласың. Әллә өске, әллә аскы люкка. Аның да үз өенә кайтасы бар ич. Үнәченнеме, бугазыңнымы дыңгычлап тутырган төтеннән, корым, уттан котылып калып, тегене үзебезнекеләр ягына сөйрисең. Ә пулемет—тетә генә. Үзебезнекеләрнеке. Чигенмәскә дип. Җәйге болындагы чикерткәләр сыман сайратып. Дошманнан исән калып була, үзеннекеләрдән тере калу юк иде! Саранчалар. Җан саранчалары... Бөтен колхозың чикерткәләре кинәнеп, тирләп-пешеп печән чапканындагыча—пулеметлар моңы. Иң кимендә әле дә гүелдәп торган шлемофоныңнан шулай ишетелгәндәй тоела. Нинди шлемофон? Ул өзек инде. Колак төбендә генә тора. Миең миңгерәгәнгә, колагың томаланганга күрәдер. Белмәссең тагын. Андый чакта бернәрсәне белерлек түгел. Командир дәшми. Димәк,—һәлак. Су астындамы, кайбер бик кирәк чагында бар куәтенә эшләп торган авыл су электр станциясебезнең турбина залына керергә кирәк булган чагында шулай итүчәние: син—берүзең. Бәлки хәтерлисеңдер, беләсеңдәдер үк: ул станциянең имән субайларын илле өченче елны без алты куллы агач суккыч белән тәя-тәя бөтен авылны яңгырата-яңгырата какканыек. Күкләрне тетрәндерә-тетрәндерә. Артдивизионның тоташлый атканыдай итеп. Үзебезнекеләрнең дә, теgeләрнекенең дә. Андый чакта син сангырауга әйләнәсең. Инде һәлак лейтенантыңны үз ягыңа таба сөйрисең дә сөйрисең. Бераздан үзебезнекеләрнең заградотряды көтеп кенә торганын тәгаен белеп торсаң да. Менә шул: кара тукымадан тегелгән, майланып, ышкылып, эт каешы булып беткән, теткәләнгән, янган, көйрәгән, тик һичкайчан бетләмәгән—танкист белән летчик бетләми, калганын белмим—комбинезонындагы уң як күкрәк кесәсеннән бар күк документларын аласын

да, үзендәге ераккарак урынга яшереп тыгасын. Башкача ярамый. Югыйсә яндырылган танкыннан нигә үзен генә исән-сау котылып калганлыгынны особисткамы, НКВД прокурорынамы ничек исбатламак кирәк? Ә инде тегенең орден-медальләрен эчтән борып алып, тыштан ычкындырып, көч-әхвәлең житкәнчә тегендә-монда ераккарак чәчепләр торып жибәрәсен. Дошман мыскыл итмәсен дип... Сүз унаеннан, энем: минекеләр дә юк инде, берсе-бер калмады. Орден-медальләрем. Бердәнбер көмеш тәрене тапмаганнар—көмеш фашист тәресен. Үземнекеләреннән ераккарак тыгып куелган булган. Кеше-кара күрмәсен дип. Нумеры... Торып тор, хәзер әйтәм. Яттан. Мең дә сигез йөз унбишенче нумерлы. Утыз тугызынчы елгы. Польшаны алганнары өчендер инде. У, пионер, бәреп кергән, имеш, биргәннәр. Менә мин алдым инде аны. Кенингсбергка алны-артны карамый туп-туры барган чагымда бу бичара каршыма чыккан булган. Танкымны чәпәде-чәпәвен. Ә көмештән коелган ордены миндә бит. Сугышта жә—син, жә—ул. Өйгә кайтып житәсе бар ич. Теге таланган чип-чиста көмешле шистирналы, икешәр килолы герләре чип-чиста алтыннан коелган—тыштан, болай, бакырдан коелган шикелле иде анысы—сәгатебезне өебезгә алып куеп кайтарасым бар бит. Апкайттым. Кайткач. Гәлифи чалбарым кесәсеннән бармагымны тырпайткан гынаем, име, энем, шунда мин килгәнне көтеп торган милиционер терәп торып мина атты да жибәрде. Мин шул ядрәне, теш куярына кирәге чыгар дип, учына китереп салдым. Тан күзеннән канәфер куагына кинәнеп торган тәрәзәбезне үтә сак кына чиертә-чиертә гозерләп револьверын сорап алдылар. Мина ут коралы нәрсә ул? Чүп. Мин кемнең, нәрсәнең көлен күккә ничек очырырга кирәклеген өйрәнеп кайткан. Ие. Йомшак итеп әйткәндә. Ялынып сорагач. Ул да кеше баласы ич... Читкәрәк тайпылдым бугай, әйеме. Техникаң астына кереп ятасың. Берүзең. Юк бит—үз өеңә кайтыр юлыңа аталар да аталар. Уйда бер генә уй: туган өең мичендә кулынны куеп жылыту. Тегесен-монысын әйтеп тормыйм инде, иң жылы урынның кайда икәнлеген үзен дә шәп беләсеңдер... Ә хәзергә—танкыңны "тигр" яннан бәргән вакытта иң ышанычлы, жылы урыны шунын астында гына. Моторы исән бит. Гөберле бака нишли? Әллә ниткән кырау да төшмәслек бер-бер таш астына кереп ята да поса. Тып-тыныч кына итеп. Ә янының узган бер озынборынны калдырмый инде, ялмап кына ала. Таш астына су үтми бит. Шуның ише, бер яндырылган танкка да бүтән атмыйлар. Аларның да боеприпасы санаулы. Танкың бер исемлектән төшкән, бүтәненә—кергән. Сугыш ич ул, колхоз-малхуз уен-муены түгел. Бәргәннәр икән—түбәтәенне жуйма. Әйтәм ич: син танкың астына шуышыпмы, үрмәләп, чалкан, йөзтүбәнме кереп ятасың да авылыңдагы хуже дошманнар бау салып алып чыгып киткән сыерыңның—сыерыбызның—төнге абзарда тыныч кына, яхшы итеп күшәп яткан мәлен исенә төшереп куясың. Сыер—сыер да бит, тегенең снайперы исән-сау чыккан танкистларны чүпләп торырга куелган. Ә минем үтереләсем килми. Әллә ниткән чит-ят жирләрдә. Кабереннең кадере туган жирендә генә. Ә чит жирдә үлеп калырга мин адәм әтрәге түгел. Шуннан нишлисең инде: комбинезонын төтенле, аркаң яна, пешә, ә мин шул снайперның үземне атып үтергәнен көтеп торыйм димени? Авылга—өйгә кайтасым бар ич. Мин ул снайперның ызанына кергәнмени? Мине нигә үтерә ул. Танкымнан чыгышлый эләктереп өлгергән пыпышы автоматымнан өстән аска, астан өскә айкый-чайкый патроны беткәнче жирдә яткан буе чамасына туры китереп аттым инде. Тугызлы чалгым белән болында печән чапкандагыча итеп. Анда исән-сау калмыйсын. Энгер-менгер төшкәннән соң, техникам астыннан чыккач, барып караганыем: уң инбашын чәрдәкләгәнмен дә маңгаеның кыл уртасына чәпәгәнмен. Снайперның

Моның өчен үзе бер орден тиешле. Бирделәр дә. Аннары. Бирми кая куйсыннар. Үземә бер патрон да калдырмаганыем. Соңынтын гына исемә төште дә йөрәгем өшеп киткәндәй булды. Мыегына чорнап куй да борыныңа чиртлә: мылтыгында соңгы бер-бер патрон кала торган булсын. Әнәне жеп-очсыз калдырырга ярамаган шикелле. Патронымны калдырмаганмын дип әйттем мәле? Анын кирәге жугые. Авылга—өйгә кайтып җитәсе бар ич. Акыллы эткә жиде чакрым ара юл мыни ул?! Ә киноларда безне күрсәтмиләр. Күрсәтмәгән булалар. Ә бит без—Жигүле тауларында Чыңгыз ханның Сүбәдәй баһатурын чәлпәрәмә китергән халык. Без бит Наполеонның Парижына атка атланып кергән кешеләр, Һитлерның рейхстагы гөмбәзенә байрак кадап куйган кавем. Әллә ниткән бомбалар уйлап чыгарып атмасыннар шунда, энем: татар трансмиссиясен, өстәп, инжекторын алдыра алмаслар. Ышанмасаң, бар, Борым, Әуди, Новосилкә, Брюхово, Пучинкә авылларыннан белеш. Хәер, алар юк инде. Килмешәкләр булганнар да кайгы-хәсрәтсез генә таралыштылар да беттеләр. Ә—жәлке. Бергә-бергә күңелле ие. Сабан туйларында. Күңел өчен бер-береннән кәҗә бәтие сатып алсаң да әйбәт. Иде. Алга бер-бер “чәти” куеп. Тәмәкеме көйрәтеп. Хәзер инде мин әйткән салалар урынында арышмы, бодаймы, арпамы башаклары гына чайкалыша. Жилдә. Хетә Зюзино—үз йөзен тота әле. Ул—базар авылые. Базар авылы бетми ул. Мәчете, чиркәве торса. Бездә бер тилегә—биш җүләр. Берсе—менә мин дип торам. Беренче, Икенче Дан орденым. Сугышчан Кызыл байрак, өченче дәрәжәле Ватан сугышы орденнарым. Кенигсбергны, Берлин, Праганы алганнарыма бирелгән медальләрем. “За отвагу” медалем... юк инде. Урладылар. Бәлкем Жинү көннәрендә кемдер тагып йөридер. Әйбәт итеп. Жир шары зур. Ул орденнарны миңа гына бирмәгәннәр ич. Ә минем жаным аша—бөтенебезгә. Минем танкымда янып үлгәннәргә дә... Урласыннар. Бу ил—угрылар, бурлар иле. Яшәү хикмәтенә ярамаган нәрсә кылган затны хәтта тәмугка илтеп тыгар өчен дә галәмәт көч-куәт кирәк. Ниме дип әйтим икән инде: бәлкем жилпучыбыздагы иләктән иләнмәгән соңгы куш уч оныбызны юмаган да куллары белән күгәрек төпле чиләгенә сыпырып торып апчыгып киткән затлар ишеме? Аларны беркая да кертмиләр—тәмугка да. Без ул эчке ыштансыз йөргәннәрне гафу кылдык. Алар үзләренә чабата да кайтара белмиләрие. Бу хәл аларның гаебе түгел—бәласе. Аларны уйлап торырга безнең вакытыбыз тимәде. Без аларны гафу иттек-итүен. Тик безнең аларны әлмәсыйккача да кичерәсебез юк. Беркайчан да. Алар үлеп бетте инде. Менәтерә бер минем генә жаным калды. Кем тели—алсын. Кирәге чыккан шәттә. Тик мин үз жанымны болай гына алдым-бирдем ише кыйдырмам. Әнә ич, әллә кайлардан әйләнеп кайтылган—үз өемдә торам. Ялгызым. Хәзер мине егерме биш сутыйлы, бәрәңге утыртылган жиремнән өч аршынлы каберемә генә куып кертергә мөмкиннәр. Өч аршынлы кабереӊ бишегеңнән дә тазарак. Һәй, әйтеп тә куям инде, име. Жен белән жен, шайтан белән шайтан сугышмыйча калмый. Вакыт “Ч” дигәнне тракторчы белмичә йоклый димени инде. Аң бар ич. Тирәнге. Бәлки син мондый исәп-хисапны аңышмый да торасыңдыр. Чөнки сезнең дошманыгыз жук. Бүлешер ызаныгыз беткән. Мунчадагы гөберле баканың тере жан иясе икәнен белүчеләр кая? Хәзер дөнья буйлап калашников автоматы гына йөри. Атып. Унга-сулга, аркылы-торкылы. Россия шикелле. Каен суын эчүне оныттылар. Юа кыягын өзеп, тәмен татып карауны әйтеп тә тормыйм. Үзең беләсең. Әгәренки бер-бер ир кеше чиратлап аерылыша-аерылыша бишенче хатын белән торып ята икән, болар миңа беркем түгел инде. Андыйларны танкыда керосин жагып бушка йөртмәдек—атакадамы, штурмыдамы—давай, бар, ычкын. Чөнки алар үләргә бармыйлар иде. Алар үлемнән үз гомерләренә караганда да

куркаларые. Ә гомер—тормыш—бүген бар, иртәгә юк ул. Кем белә тагын... Синең, брадән, тоюымча, теге-бу сүз-фәләнгә сизгерлегең хәттин ашкан. Шуңа күрә, әмерикәннәрнең Әфганга да Гыйракка кергәннәренең очы ни икәнен исеңнән чыгарма. Ул безгә кирәк түгел. Әмерикәннәр сугыша белми ул. Кытайлар да. Вьетнамнар—белә. Аныштыңмы? Аңладың булса кирәк. Өйдәгеләрең тук булсын дип акчага сатылу—ул сугыш түгел. Ул бер-беренне кырыш та үтереш кенә. Кем кемне дигәндәй инде. Андый чакта—баягынак әйттем—сине үтерергә теләгәнне үтереп өлгерергә кирәк. Әз генә алданрак. Өйгә кайтасы бар ич. Сугышта кеше бер-берсен үтерми, үз-үзен үтерә. Кем—алдан, кем—арка яктан. Арттагылары үзебезнекеләр—заградотряд... Син туфрак сал, сал әле. Зират туфрагы—ашламасыз ул. Шулаймы? Шулай түгел икән—әйт... Сугыш, энем, сугыштан соң башлана ул. Анда—тере калыр өчен, ә монда—яшәр өчен. Ике кеше бар икән,—сугыш бетмәс. Ә минем үз гомерлегемә бирелгән алты гектар пай жиремне дә талап алдылар. Әби-бабайдан, әни-этидән калган жиремне. Мина хәзер бар да ярап тора инде: авызлык тотардай теш-уртым арыш ипие имезлеген имәрлек кенә. Мине жөгәнләгәннәр жаныма ыңгырчак аша аркалык-түшлек үткәргәннәр, камытлап, чөелдерекләп... Мин үз хәтеремнән боларның һәммәсе хакына ваз кичәм. Трусикларын, оекбашларын үзләре юа белмәгәннәр бүтәннәрне талый. Алар өзелеп төшкән күлмәк төймәсен тагарга инә дә саплый алмый. Немчуралардан да болайраклар. Әйткән сүзләрендә жүн юк. Без—шуларның оккупированныйлары. Сугышсыз-нисез. Жинүсез, жинелүсез, килешүсез. Әнәтерә, Жинү көне алдыннан капка төбенә бер йөк салам кайтарып аударганнар әле. Жәй житәр алдыннан. Хажәте бер тиен. Ә сыерыбыз иректә—язгы әйбәт үлән ашап йөри. Көтүдә. Минем үз жирем—минем жанымда. Аны беркая алып китеп булмый... Туфрак кой әле. Әйбәт каен үсентесе бу. Үсәр. Үсмичә нишләсен. Кабергә каен килешә... Хәер дисең инде. Йа Иллаһы Илаллаһы Мөхәммәдеррәсуллаһ. Безнең гомеребез СССРга хәер иде, жаныбыз—урыс дәүләтенә сәдака. Ә татар дәүләтен ләхетсез-нисез күмгәндә кәфенлегенә бәзе дә булмаслыгын хәтереңдә ныклап тот. Без яшәвен яшәп бетердек. Үлә генә белеп бетергән жук әле. Хәзер минем үз зиратыбызны кочарга колачым житми. Менә бу яшь каенлы каберне талый алмыйлар инде. Монда—минем хатыным. Өч аршын жир—түштәге орден, түшәктәге акча түгел. Алып, төяп китәсеңмени. Кәфенгә кесә текмиләр...

# Гаилә елы уңаеннан



*Ирле-хатынлы С. Г. Вәгыйзов (1908-2007) һәм Р. Г. Вәлитова (1914-2002) татар телендә дәреслекләр, шул исәптән 30дан артык басма күргән "Әлифба" авторлары. 1997 елда алынган рәсем.*



*Язучы Нурихан Фәттах хатыны Руфина ханым белән. 1964 ел.*



*Көй һәм җыр хәкем сөрә бу гаиләдә. Маликовлар гаиләсе. Гүзәл һәм Рөстәм Маликовлар уллары Муса, Гайсә белән. 1997 ел.*



*Галимнәр гаиләсе. Уртада басып торалар—Ибраһим Нуруллин һәм Розалина Нуруллина. 1976 ел.*



*Ирле-хатынлы П. В. Абрамов (1914-1992) һәм А. Ф. Хәсәнова (1912). Павел Абрамов 60нчы елларда Казан финанс-икътисад институтында ректор, Асия Хәсәнова 20 ел (1957-77), "Азат хатын" (хәзерге "Сөембикә") журналының баш мөхәррире булып эшләде.*



*Ижау шәһәрендә яшәүче шагыйрь Ренат Баттал гаилә хозурында. 2002 ел.*



Рушания
Арсланова

# МОҢНАР БҮЛӘК ИТӘМ...

## Мин

*(Акрошигырь)*

Р әшәдә коенган чәчәкләрне
У чларыма җыеп алам да,
Ш атлык бөркеп торган иртәләрдә,
А к томанга төренгән урамда,
Н азлар алып йөрим таң җиленнән,
И лһам бирә миңа киң җиһан.
Я кын итә мине су буйлары,
А дашмаска куша карурман.
Р әхмәтлемен өлешемә тигән.
С абыр холык биргән Тәңремә.
Л әззәтләнә беләм гүзәллеккә,
А зсынмыйча сөенәм бәхетемә.
Н арасый күк үзем, ышанучан,
О лы яшьтә инде булсам да.
В акыт узды, димим, гөрләп яшим,
А к төс чәчләремә кунса да.

## Ирләр

Без, без, диеп мактансак та,
Чәт-чәт килеп торсак та,
Алай түгел, болай, диеп,
Чәчрәп, аһлар орсак та,
Без барыбер хатын-кызлар,
Пазлар өчен туганбыз.
Хатын-кызга, анага хас
Нечкә хисле булганбыз.

Рушания АРСЛАНОВА – *шагыйрә; "Моңнар бүләк итәм" исемле китап авторы. Казанда яши.*

Аерылсак та, сагынсак та,
Хәзер күзләр дымлана.
Ирләр күз яше күрсәтми,
Ирләр гел эчтән яна,
Ирләр гел эчтән сыза.

Гаиләдә ир—таяныч,
Илдә ир-егет—терәк.
"Назлыбикәләр"гә ирнең
Кадерен белү кирәк.

Давылдан ышыклап безне
Күкрәгеп куя ирләр.
Кирәк булса, диңгез кичә,
Кирәксә, гизә илләр!
Ирләр,
ирләр,
ирләр...

* * *

Дөньяда иң якты ни?—дисәләр,
Көн,—диярмен.
Дөньяда иң гүзәл ни?—дисәләр,
Моң,—диярмен.
Дөньяда иң йомшак ни?—дисәләр,
Җылы сүз,—диярмен.
Дөньяда иң кыйммәт ни?—дисәләр,
Ике күз—диярмен.
Дөньяда иң тугрылыклы кем?—дисәләр,
Ана,—диярмен.
Дөньяда иң кадерле кем?—дисәләр,
Бала,—диярмен.
Дөньяда иң куркыныч ни?—дисәләр,
Хыянәт,—диярмен.

* * *

...Төн.
Табигать тын.
Сызгырынып йөргән җилләр дә
Яшеренеп йоклап ята бугай
Әллә кайсы гына җирләрдә.
Ябалак карлар куышып туйганнар да,
Тынычланып җиргә төшкәннәр.
Бәсләр кунган таллар,
Топольләр дә
Тынлык саклап йоклап киткәннәр.

Төн.
Табигать тын.
Җирдә ята үтә ап-ак кар.
Йокламыйм мин,
Минем уйларым бар,
Әле тагы туасы җырым бар.
Минем әле таңда
Кешеләргә
Яңа бер җыр җырлыйсым бар.

## Сөенәм таңнарга

Керсез күңелем,
Түземле үзем,
Юлдаш булалдым шуңа күпләргә.
Эзләрем табып,
Хәйраннар калып,
Борылып-борылып карыйм үткәнгә.

Ат казанмадым,
Дан казанмадым,
Кайда инде ул миңа шөһрәт?
Акрын гына җырлап,
Ил гамен тыңлап,
Яшим Ходайдан алып кодрәт.

Кемгә киңәшем,
Кемгәдер ашым
Насыйплар булды, Аллага шөкер.
Җаның саф булса,
Йөрәк җырлап торса,
Картайгачтан да күрәсең кадер.

Мине серле диләр,
Мине моңлы диләр,
Елларның моңы күчә җаннарга.
Шаулап яз килсә,
Сыйпап җил иссә,
Сөенәм әле, сөенәм таңнарга.

* * *

—Нигә?—дип, сорама, карышма,
Тиз генә җыен да, кил әле.
Сөйлисе сүзем бар, серем бар,
Син миңа бик якын бит әле.

—Нигә?—дип, сорама, карышма,
Тиз генә җыен да, кил әле.
Ялгызлык сине дә, дускаем,
Телгәли торгандыр бит әле.

—Нигә?—дип, төпченмә, карышма,
Тиз генә җыен да, кил әле.
Кояшны алып кил,
Йолдызлар табып кил,
Аларга мин гашыйк бит әле.

—Нигә?—дип, төпченмә, карышма,
Тиз генә җыен да, кил әле.
Яктырт син дөньямны,
Балкыт син дөньямны,
Мин һаман сагышта бит әле.



Илсөяр
Иксанова

# ҖИТКӘН КЫЗ

ХИКӘЯ

Бая каты итеп ябып чыгып киткән ишекне әкрен генә ачып керде дә үз бүлмәсенә бикләнде Иркәгөл. Кухняда тәрәзәдән очып чыгар булып талпынып урамны күзәткән әнисе—Гөлфаяз кызының кайтуын ишетеп торса да йөгереп каршы чыгудан үзен-үзе тыеп кала алды. "Аллага шөкер!" дип өстәл артына килеп утырды. Өстәлнең ике читеннән аңа салкын чәй белән тулы ике касә карап тора иде. Берсен уртлап куярга дип кулына алуы булды, әчке киеренкелектән калтыранган кулында чайпалып китеп, чәй итәгенә түгелде. Шул чайпалу гына кирәк булган икән: әле бәргәләнеп ярсыган, әле сызлап сызган, әле шик-шөбһәләрдән шомланган күнеле—дулкынланудан арыган, тулган, мөлдерәгән күңеле—түгелде. Өстәлгә салган кулларына башын куйды да тавышсыз гына сулкылдады Гөлфаяз. Кызының исән-имин әйләнеп кайту сөенеченнәнме, бердәнбер газиз кешең белән аңлаша алмау гаҗизлегеннәнме, язмышның гаделсезлегенә әрнепме, үз-үзен кызганыпмы... елада да елады. Тәгаен генә ни өчен елаганын да аңламады ул. Бәлки барысы бергә җыелгандыр.

Бер түгелеп алгач, бераз тынычлангандай итте. Сулышы тәмам җепшегән иде. Еш-еш борын тарткан тавышы тып-тын фатирда янгырап ишетеләдер төсле тоелды. "Иркәгөл ишетә күрмәсен тагын" дип уйлады ул. Сабый чагыннан—дүрт яшеннән—ялгызы үстергән кызы янында һәрвакыт көчле, шат, бәхетле булып күренергә күнеккән иде Гөлфаяз. Бүген исә бигрәк тә Иркәгөл әнисенең көчсезлеген, "җинелгәнлеген" күрергә тиеш түгел. Моннан авыр чакларында да күз яшен, җан әрнүен яшерә белгәнне, бүген... бер юктан... Шушы уйлардан аның күнел төпкеленнән тагын икенче дулкын күтәрелеп, борынны әчеттереп, күздән бәреп чыкты... Мышык-мышык, мышык-мышык... Инде борын сызгыруына эчтән, бәгырьдән бәргән сангырау-тоньк аваз да өстәлеп куйгалады. Тавышын сиздереп, каты итеп ынгырашса, җинелрәк булыр төсле тоелды Гөлфаязга. Иркәгөл ишетмәсен дип кабат үз-үзен тыйды. Шул мәлдә күнелендә "Иркәгөл ишетсен иде, минем елавымны белсен иде" дигән теләк калкынуын тойды. Бәлки, әнисе кадәр әнисен, нинди генә авырлыклар кичергәндә дә көчле кала белгән әнисен елатуына үкенер, үзенең хаксыз булуын аңлар, күзләре ачылып,

Илсөяр ИКСАНОВА—*шагыйрә; «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Сингзган язмышым», «Кырык кыл» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

әнисе күрсәтергә теләгәнне күрер...

Гөлфаяз инде күнеленнән кызы белән сөйләшәсе сүзләрен барлый башлады. "Мин аңлыйм сине. Синең яшьтә бөтен нәрсә дә бик гади тоела, бөтенесе дә ничек күрәсең, шулай гына кебек. Тик син күргәне—айсбергның өсте генә. Ана бәрелмәскә дә, аны урап үтәргә дә мөмкин сыман. Ләкин син аның су астында нинди зурлыкта, нинди формада булуын күрмисең, нинди фаҗигагә китерергә мөмкин икәнлеген аңлап житкермисең... Фаҗига дигәне артыграк булыр. Нинди күңелсезлекләргә китерүен... Юк... күңелсезлек кенә түгел, нәкъ менә фаҗига булырга мөмкин.." Артык тирәнгә, фәлсәфәгә керә башлавын тойды Гөлфаяз. Уйларыннан арынырга теләп, урыныннан кузгалды. Юыну бүлмәсенә кереп, шаулатып су агызды. Ут булып янган йөзенә салкын су тигәч, ничектер авыр уйлар чигенгәндәй булды. Бөтен авырлыкны юып төшерергә теләгәндәй, битен салкын су белән кат-кат юды. Күтәрелеп көзгегә карады. Авыз-борын зурайган, күзләре, киресенчә, кечерәеп калган. Шешенке күз тирәләре дә, күзләренең агы да кып-кызыл. Күзләре әчетә, ә борын һаман да мышкылдаган иде.

Кинәт Гөлфаяз үзен моннан унбиш еллар элеккеге хәленә кайткандай хис итте. Күзләрен кызартып татлы елаган чакларына. Әй рәхәтләнеп елаган көннәре бар иде лә аның! Юктан гына елаган чаклары. Ул вакытта елаткан сәбәпләр хәзер генә юктан булып күренәдер. Вакытында бик җитди тоелгандыр. Бәхетенә түзә алмый елап яткан төннәре исенә төште. Ничек еламыйсың?! Жаныннан артык сөйгән кешең янәшәңдә мыш-мыш йоклап ятсын да... Юатыр кешең булганда гына рәхәтләнеп елап була икән шул. "И елакчы кызым минем!" диеп күзләреңнән үбеп ачы-татлы яшьләреңне киптерер кешең янәшәңдә булганда гына...

Дөрес, аннан соң да елаган көннәр булды. Тик ул инде елау түгел, сыктау иде. Бик ачы, бик тозлы иде ул күз яшьләре. Юатыр кешеннең инде мәңге дә кайтмаслыгын аңлап түгелгән яшьләр... Әрнеп елауларын уртаклашыр кешесе юк иде Гөлфаязның. Дуслары, туганнары бар, дөрес, Гөлфаяз дип жан атып торган туганнары. Тик... жанны беркемгә дә ачып булмый. Жанын ачар кешесе—кызы—артык кечкенә. Сабый. Аңа болай да бик-бик авыр. Аның үзен саклыйсы, яклыйсы, тормыштан биздерми яшәтәсе. Менә ул үсәр...

... Ул үсте. Ятимлекне тойдымы, тоймадымы... хисләре белән бүлешә торган түгел иде Иркәгөл. Гөлфаяз бик яхшы әни булырга тырышты. Үз-үзенә куйган беренче таләбе—мескенләнмәскә! Үзе дә, кызы да кимлек хисе кичермәсен өчен бөтен барлыгы белән тырышты ул. Дөрес эшләдеме, юкмы... И—их... дип күнеле сызып куйган чаклары булмады түгел, булды. Ярты юлда калган докторлык диссертациясе... эзләнәсе , казынасы килгән, жаны тарткан эше... Юк! Аларга вакыт та, көч тә калмады. Фәннең, белемнең, талантның кирәксез чорына туры килде шул гомер. Әрсезлек, ялагайлык, елгырлык хөкем сөргән чорга. Бөтен кыйммәтләр дә акча белән генә үлчәнә торган вакытка. Фәнни тикшеренү институтындагы хезмәт хакы фатир өчен түләргә дә ипи-сөткә генә житәрлек. Студентның белем дәрәҗәсенә карап зачет, имтихан алып укытып йөрүнең дә сәмәне ташка үлчим... Тик... Ходай буш итмәгән кешегә акча эшләү мөмкинлеге бөтенләй юк дип әйтмәс иде Гөлфаяз бу заманда. Бер яктан сугып екса, икенче яктан тартып торгыза торган заман бу. Сузылган кулны күрә генә белергә кирәк. Ябышыр салам эзләп күз карашы жетеләнгән иде Гөлфаязның. Күрде. Бичаракайгынамнар! Баш юк. Белем юк. Катыргы кирәк. Дипломсыз үзеңне кеше итеп тә тоеп булмый торган чор лабасы. Базарда чүпрәк-чапрак сатучысына кадәр икешәр югары белемле. «Бичаракайгынамнар»га катыргылы булу өчен диплом эше дигән каһәрне язасы да бар бит әле. Яки... яздырасы. Ничә диплом язды икән Гөлфаяз бу еллар эчендә! Юк, халтурить итмәде, бишлегә язды ул диплом эшләрен. Дипломнарын бишлегә яклаганнарның фәнни дәрәҗәгә ирешәсе килүчеләре дә күбәйде. Кандидатлык диссертациясен дә "жинел" генә яздырып алдылар андыйлар. Шуларның барысын бергә кушсаң, инде

әллә ничә кат докторлык диссертациясен якларга житәр иде...

Һәрхәлдә, Иркәгөлгә матди яктан иптәшләреннән ким күренмәскә житте. Туганнары Гөлфаязга: "Артык иркәлисең түгелме? Бөтен сораган нәрсәсен алма, әйбер кадерен белми үсә.."—дип йомшак кына әйткәләсәләр дә, барыбер кызына кием-салым, кирәк-ярак алудан, дингезгә ялга йөртүдән акчасын кызганмады. Кызын теләгәнчә киендерә алуы ана бертөрле рәхәтлек хисе бирә иде. Юк, алып узмады Иркәгөл. Акчаның каян, ничек килгәнен күреп үсте. Әнисен кызганып: "Житәр инде, әнием, ял ит. Хет берәр ай эш алмый тор әле",—дигәндә, Гөлфаязның күңелләре нечкәрә иде.

Бүген кич тә компьютерына кадалып утырган жиреннән Иркәгөле куптарды: "Әйдә, әнием, чәй ясадым, куеп тор эшенне." Аш бүлмәсенә чыккач та сизде Гөлфаяз, кызы ничектер үзгәргән, эчендәге тынгысыз дулкынны көчкә тыеп тора төсле. Сөйләшәсе сүзе бар бугай, сүзен башлый гына алмый.

—Чәең суынмасын, әнием, эч инде,—дигән була.

—Уйларың суынмасын, әйдә, әйт инде, нидер әйтергә телисең бит,—дип күпер салды Гөлфаяз.

—Әнием, иртәгә туган көнгә чакырганнар иде. Кич соңрак кайтсам...

—Кемнең туган көне соң?

—Игорьның дусты.

—Нинди Игорь?

—Ну... безнең параллель класстагы... Беләсең бит инде—Эльвира, Фәрит, Гөлия белән беркөнне безгә кергәннәр иде.

—Мин аны күрмәдем дә инде анда... Тукта, Игорьның дустының туган көненә ник сине чакыралар соң әле?

—Ну... Игорь белән икебезне чакыралар.

Гөлфаязның өстенә салкын су койгандай булды. Йөрәге кинәт хәлсезләнеп китте. Шулай да күңел халәтен йөзенә чыгармаска, тыныч булырга тырышып:

—Ничек инде Игорь белән икегезне?—диде.

—Әнием! Ну нәрсәсе бар инде аның. Башта бильярд уйнарга барабыз, аннан ниндидер кафега.

—Юк, мин барыбер аңламыйм... Нәрсә, син Игорь белән дуслашып йөрисеңме?

—Син бит үзең, дус булырга ярый, дидең.

Гөлфаяз да, Иркәгөл дә инде баррикаданың ике ягына басканнар иде.

—Мин, дуслар булырга гына ярый, дидем. Очрашырга ярамый, дидем.

—Урыс булган өчен!—Кызының кискен һәм үпкәле тоны Гөлфаязны сискәндереп жибәрде.

—Кызым, без бу хакта бик күп сөйләштек...

—Артык күп! Өч яшьтән бирле тукыйсың бугай инде...

—Димәк, стенага борчак сипкәнмен.

Әнисенең кәефе тәмам кырылганны күреп, Иркәгөл аны юату, юмалау юлына күчте:

—Ярар инде, әнием, мин бит кияүгә чыгарга жыенмыйм. Ул шундый әйбәт, ышанычлы егет...

—Әйбәттер. Сүз бит ул турыда түгел, балам...

—Урыс!..

—Урыс шул. Бүген сез дуслар. Иртәгә?.. Икегезне бергә туган көнгә чакыралар икән..

—Ул мине ярата!—Монысы бөтенләй үчекләү булып яңгырады.

—Ә син?

—Просто, ул әйбәт малай. Ну, әнием... беренчедән, мин кияүгә чыгарга жыенмыйм. Икенчедән... татарга чыкканнар бик бәхетле инде алайса!

—Кызым, бәхет икенче мәсьәлә. Фәридә апаның: "Дорогая" дип торган бер урыска чыгасың да "чаплашка" дип торган өерле урыс арасына барып керәсең икән",—дигәнен хәтерләмисеңме? Бу бик катлаулы хәл.

Һәр милләтнең үз гореф-гадәтләре, үз яшәеш кануннары. Син үзеңнекен җимереп, аларга яраклашырга тиеш буласың.

–Ә нишләп? Алар яраклашсын!

–Тормышта алай гына булмый шул ул. Аларның да үзләренчә яшисе килә. Һәм бу дөрес тә. Дуслык бер нәрсә, ә гаилә.... Ул артык интим, нечкә нәрсә. Бу–үткәнең белән киләчәгеңнең тоташуы. Монда син үзең өчен генә түгел, нәселең өчен дә җаваплы, аңлыйсыңмы? Гаиләдә рухи каршылык булырга тиеш түгел...

–Син катлауландырырга яратасың инде, әнием.

Сөйләшү торган саен бәхәскә әйләнә барды. Һәркайсы үз сүзен аклардай мисалларга күчте: кемнәр ничә елдан соң барыбер аерылышканнар, кемнәр бик бәхетле гомер кичергәннәр... Тирәнәйгәннән-тирәнәя һәм кискенләшә барган сөйләшүне туктатырга теләп, Гөлфаяз:

–Ярар, мин хәзер ни генә әйтсәм дә, син–оппозициядә. Туктатыйк бу бәхәсне,–диде. Тик төп сорау ачык калган иде.

–Ә иртәгә туган көнгә...–дип сүз башлаган кызын әнисе тиз генә сүндерергә теләп:

–Бармыйсың!–дип өзде.

–Нигә?

–Игорьның дусты сиңа кем ул? Беркем түгел. Имтиханнарга әзерләнсәң яхшырак булыр, борын төбендә ЕГЭ. Быел синең бик җаваплы елың...

–Фәрит белән булса, җибәрер идең әле...

–Фәрит белән дә җибәрмәс идем. Ә Игорь мәсьәләсендә тагын бер кат уйла. Дуслык булса, гомуми дуслык кына. Аңа өметләнергә урын калдырма. Кешене өметләндереп, өметен алдау–гөнаһ ул.

–Урыс белән гөнаһ... ярашмый.

–Иркәгөл, ирониягә борма! Бу бик җитди мәсьәлә.

–Синең өчен гади мәсьәлә юк, әнием. Гади булса, син аны үзең катлауландырасың. Дөнья хәзер башка. Син аңламыйсың...

"Аңламыйсың"ы чыгырдан чыгарды Гөлфаязны.

–Әйе, мин надан, артта калган... Һәм, гомумән, мин...–сүз тапмый торды ...–гомумән, мин–динозавр!

–Юк, син–инопланетянин. Ничә еллар Җирдә яшәп, мондагы кануннарны таный алмаган марсианин! Гөнаһ, намус... ярый, ярамый... Беркем дә алай яшәми хәзер. Син диплом эше язып биргән, үзең әйтмешли, "бичаракайгыналарым"–директор да президент. Ә син һаман диплом арты диплом сочиняешь!

Иркәгөлнең русчага күчүе протестның кискенлегенә ишарә булып тоелды. Өйдә туган телдә генә сөйләшергә дигән кануннарга каршы чыгу. Димәк, өйдәге тәртипләргә каршы чыгу...

Әйе, аның башы белән дипломлы, диссертацияле булганнарның нинди кәнәфиләргә үрмәләгәнен күреп торды Гөлфаяз. Җаны әрнегән чаклары да булды. Тик... шуны да аңлый иде, докторлык диссертациясе яклаган булса да, ул алар ирешкәннәргә ирешә алмас иде. Аның өчен йә белемең саерак булса да, ир кеше булырга, йә хаким ирләргә ярый белергә кирәк. Табигать аны акыллы һәм намуслы хатын-кыз итеп яраткан шул. Кемнәрдер җиңел генә атлап чыга алган әхлак кануннары–аның өчен үтә алмаслык киртә.

–Яхшы, мин–инопланетянин. Тик җир кануннарын синнән яхшырак беләм. Кыскасы... урыска кияүгә чыксаң, балаңны чукындырачаклар. Шуны белеп тор!

Таякны артык бөгеп ташлаганын сизде Гөлфаяз, ләкин инде әйтәсе сүз кош булып очкан иде.

–Рәхмәт, әнием! Минем тумаган балаларымны чукындырып та куйдың...

Иркәгөлнең күзләренә яшь тулды. Тик ул күз яшьләрен тыеп калырга көч тапты. Әнисе төсле, ул да күптән инде кешегә күрсәтми генә елый белә иде. Иркәгөлнең "бөтен" тормышына кызыгып караучы яшьтәшләре дә,

"иркә булып үсмәсен" дип хафаланучы туган-тумача да аның җанындагы яраларны күрмәде, тоймады. Сабый хәтеренә сенеп калган әтисе белән бәйле бик аз гына якты хатирәләрне, кино тасмасын әйләндергәндәй, кабат-кабат күнелендә әйләндереп, "их, вакыт машинасы булсын иде ул", дип хыялллануларын; әнисенен һәрвакыт арыган күзләрендәге сагыштан тетрәнүләрен, ялгызы тормыш арбасын өстерәгән әнисенә берничек тә ярдәм итә алмаудан вакыт-вакыт тәмам гажизләнүләрен... берәү дә сизмәде. Ул бу хакта берәүгә дә сөйләмәде.

Рус теле укытучысы белән конфликтка кереп, болай да күнеле айкалган бер чакта килеп сүз каткан Игорьга дорфа гына җавап кайтарганнан соң, егетнең:

—Бирешмә, Иркәгөл, бөтен нәрсә дә үтә..—дию аны сискәндереп җибәрде.

—Нәрсә үтә?..

—Белмим, син нигә шулай кәефсездер, ләкин эченне тырнаган борчулар барыбер дә үтәр...—диде дә кызны тынычлыкта калдырырга кирәклеген аңлап, китеп барды.

Шул чакта Иркәгөлнең ни өчендер Игорьга барысын-барысын сөйлисе килде. Ул гына аны аңлар төсле тоелды. Юк, сөйләмәде. Тик күнеленә ничектер бертөрле якын булып китте Игорь. Быел гына Иркәгөлләр мәктәбенә килеп укый башлаган бу егет бөтенесеннән дә аерылып тора иде. Классташларыннан ике яшькә диярлек зур ул. Әти-әнисе белән Америкага киткән булган, нишләптер әбисе янына әйләнеп кайткан, әти-әнисе исә шунда яшәп калганнар. Шуңамы, үзен олыларча тота, укытучылар белән дә дустанә генә сөйләшә белә. Менә шул Игорь Иркәгөлләр классын үз итте. Тәнәфес җиттеме, алар тирәсендә бөтерелә. Беркөнне Эльвира бик зур сер әйткәндәй:

—Беләсеңме, Иркәгөл, Игорь сине ярата бит,—диде.

—Кем әйтте?

—Аны бөтен кеше дә сизә, "В" класс кызлары синнән шуна көнләшәләр дә...

"Сөйләмә юкны!"—дисә дә, Иркәгөлнең эчендә куаныч хисе уйнаклап алды. Аннан үз куанычын үзе сүндерергә теләгәндәй, "Урыс шул ул..." дип уйлап куйды. Куанычы чыннан да сүнде. Ана бик-бик монсу, күнелсез булып китте. Күнел халәтенен шулай үзгәрүенә сискәнде үзе: "Димәк... Юк!.. Әнием..." Мең төрле гөман, уй шул сүзләргә сыйган иде.

Игорь дустының туган көненә чакыргач, башта шундый сөенде Иркәгөл. Аны чакыра бит!.. Аннан сөенече борчуга алмашынды: әнием ни дияр?

Үзе сөенеч, үзе эч пошу... Шулай да була икән. Әнисенә ничек әйтергә соң?..

Ярый әнисе үзе сүз башлады.

Һәм сөйләшү менә шундый ямьсез бәхәскә әйләнде. Гомерендә беренче тапкыр ул әнисе белән әрепләште.

"Балаңны чукындырачаклар!" Әнисенен бу сүзләре Иркәгөлнең йөрәген яргандай булды. Теге вакытта рус теле укытучысы белән нәкъ шул мәсьәләдә туган иде бит конфликт. Надежда Викторовна, гомеренә бердер инде, татар спектакленә барган булган. Кирәк бит, Гаяз Исхакыйның "Зөләйха"сына туры килгән. Бик нәфрәтләнеп сөйләде: "Русларны шундый ямьсез итеп күрсәтәләр... Ниндидер көчләп чукындыруны уйлап тапканнар. Андый хәл булмаган..." Иркәгөл түзмәде: "Ничек инде булмасын, ул бит тарихи факт,"—дип каршы чыкты. Әнисенең җан дусты Гөлфинә апасы кандидатлык диссертациясен нәкъ менә "Көчләп чукындырылган татарларның мөселманлыкка кире кайтуы",—дигән темага яклаган иде. Бу мәсьәлә аның үзенә дә турыдан-туры кагыла—дүртенче буын бабасы Исмәгыйль яңадан мөселманлыкка чыгарга өндәп йөргән өчен себергә сөрелгән... Әнисе белән Гөлфинә апасының шул хакта, шуңа бәйләп Казан ханлыгының алынуы турында, дәүләтсез калу турында әрнеп сөйләшүләре,

көчләп чукындыруга нәфрәтләнүләре, нечкә күңелен тәмам тетрәткән шул ук "Зөләйха" әсәре... Иркәгөлнең аңына тирән, бик тирән кереп урнашкан иде шул. Дәшми кала алмады...

Инде менә ул үз-үзенә каршы киләме? Юк, бу бит бөтенләй башка мәсьәлә.

Әнисе, гадәтенчә, артык тирәнәйтә...

Күз яшьләре түгелә башлаганчы дип, Иркәгөл аш бүлмәсеннән, алай гына түгел, өйдән үк чыгып китте. Ишекне каты итеп, шап итеп япты. Әйтерсең, шулай иткәч, көнелдәге бөтен авырлык коелып төшәргә тиеш иде.

Урамга чыккач, Иркәгөл иң элек Игорьга шылтыратырга уйлады. Аңа ни дияргә?.. Аннан дусты Эльвирага кереп эчен бушатырга булды. Ике йорт аша гына яшиләр алар. Бәхетенә, подъезд ишекләре бикле булып чыкты. Бикле ишеккә килеп төртелгәч, ниятеннән кире кайтты—хисләренең дә бикле күңелгә килеп төртелүеннән курыкты. Кая барасын тәгаен белми генә атлады да атлады. Балалар бакчасына килеп җитте. Бакча эчендәге кечкенә беседкага кереп утырды. Үксеп еларга теләп, битен учларына каплады. Юл буе ирексездән ике күзеннән агып килгән яшьләре кипкән иде. Елап булмады... Энгер-меңгерне эретеп, бик тиз караңгы төште. Этләрен урамга алып чыгучылар ишәйде. Кара, барысы да балалар бакчасы тирәсендә йөри, тапканнар урын! Этләләргә шулай ачуы килде. Нигәдер, Казан алынганнан соң, шәһәр бакчаларының капкасына элгән "Этләргә һәм татарларга керү тыела" дигә язу турында ишеткәннәре исенә төште... Бакча читендәге көздән давыл аударган зур агач өстенә бер төркем яшьләр килеп урнашты. Сыра эчәләр... Монда бөкшәеп утыру сәер дә, куркыныч та тоелды Иркәгөлгә. Ул үзен кечерәеп калгандай хис итте. Каршы искән җилдән ышыкланып, әнисенең артыннан шушы бакчага теркелдәгән чагында да бүгенге төсле үк бәләкәй түгел иде ул! Юк, анда ул үзен бик зур дип хис итә иде бит.

Өенә ул тиз-тиз атлап кайтты. Өченче каттагы фатирларының ике тәрәзәсе дә караңгы иде, аш бүлмәсендә генә ут яна. Тәрәзәләрдәге караңгылык күңелен шомландырып, җанны өшетеп куйды.

Ишекне әкрен генә ачып, туры үз бүлмәсенә кереп ятты. Яраткан йомшак уенчык песиен кочаклап ятуга, бая кисәк кибеп киткән яшьләре күзенә кайтты. Елавын әнисенә ишеттермәскә тырышып, йомшак песие белән авыз-борынын каплады. Ул әле әнисе белән аңлашырга әзер түгел иде. Күңелдә бәргәләнгән каршылыклы хисләрен әле үзе дә аңлап бетерми... Аны бары шушы песие генә аңлый төсле тоелды...

* * *

Гөлфаяз ишекне сак кына ачып кызының бүлмәсенә күз ташлады. Өй каршындагы баганага элгән лампа утыннан бүлмәгә саргылт яктылык ингән. Урын-җирен җәеп тормый гына, киенгән килеш уенчык песиен кочаклап бөгәрләнеп яткан кызына яратып-сызланып-сокланып-иркәләп карап торды әнисе. Бөдрәләнеп торган чәчләре сибелеп киткән. Чәчләреннән сыйпасаң уяныр микән?.. Кыска кофтасы тагын да өскә сыдырылып, ярты биле ачылган. Туңадыр... Өстенә ябарга кирәк. Чишендерсәң, йокысы бүленер инде. Болай... бигрәк җайсыз ята...

И кызым, кызым! Тәмам җиткән кыз булгансың бит. Җиткән кыз... Гөлфаязның йөрәге моңа кадәр билгесез горурлык, моңа кадәр тоймаган борчу, моңа кадәр таныш булмаган татлы да, сагышлы да хис белән тулды. Җиткән кызы белән кочаклашып, кочаклап түгел, нәкъ менә кочаклашып, бер тын сүзсез генә утырасы килде аның. Шулай сүзсез генә бөтенесен, бөтенесен аңлашасы килде...

Аңлашырлар... Әле алда туар таң, яңа көн. Алда өр-яңа тормыш. Ә әлегә... ап-ак йомшак песиен кочаклап аның җиту кызы йоклап ята...



Габделхак
Шәмсетдинов

# КҮҢЕЛ КЫЛЛАРЫ ЧЫҢЛЫЙ...

***

Сандык тулы бирнә җыеп
Яшь кызлар туй көттеләр...
Хыялларда кыңгыраулы
Атлар чабып үттеләр.

... Ил өстенә афәт килде
Мәхшәр торсын бер янда.
Тәгәрмәч эзеннән кеше
Каны акты юлларда...

Кыңгыраулар онытылды.
Гармун үксеп елады...
Онытырга мөмкинме соң
Ул дәһшәтле елларны!

Яшькә томаланды күзе
Гүзәл, сылу ярларның...
Еллар гына күмә алмый
Йөрәктәге яраны.

...Сиксән яшьлек тол кызларның
Сагыш-әрнүе тынмый.
Колакларында һаман да
Җиз кыңгыраулар чыңлый...

## Кыш

(ЭТЮД)

Яңа яуган ап-ак карлар
Алмагачка кунганнар...
Алмагачка кунганнар да
Язга кадәр тынганнар.

Энҗе кар бөртекләреннән
Алмагач күлмәк кигән,
Әйтерсең кыш уртасында
Май ае кабат килгән.

Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ (1946) — *журналист, тарих фәннәре кандидаты, "Мәгариф" журналының баш мөхәррире; Казанда яши.*

## Яшьлек

Давылдан җитез,
Агымнан да тиз
Яшьлек адымы.
Үтеп китсә дә
Башка килмәскә,
Йөрәктә мәңге
Саклана торган
Эзләр калдырды..

***

Күзге төн. Караңгы.
Сибәли вак яңгыр.
Исә җил тирбәтеп
Йончыган фонарьны.

Бүлмәмә керә дә
Фонарьның ал нуры,
Сыенып ак мичкә
Ял итә төн буе.

## Окоплар

Исәннәрнең гел исендә:
Үкереп үтте танклар.
...Берәүләргә кабер булды,
Берәүләргә гомер бирде
Шул чагында окоплар.

Сугыш үткән урыннарда
Окоплар тора һаман,
Карт солдатның тәнендәге,
Җөйләнсә дә җуелмаган
Иске яралар сыман.

***

Дулкын-дулкын еллар килә,
Яшьлегемне еллар күмә.
...Арынгандай комнан алтын,
Арулана бара акыл.

***

Җил борылды. Кичә киткән
Болытлар кайтты бүген.
...Нигә соң гомер җил түгел,
Ник яшьлек болыт түгел?!.

***

Ни аяныч: бер күнеккәч,
Рәнҗешкә дә түзелә.
...Тик күңел кыллары гына
Шартлап-шартлап өзелә.

***

«Шигырь язып интекмә дә,
барыбер Тукай булмассың»,—
дигән агай шигырь язды
гомер буе, туктаусыз...

***

Өзгәләнмә, бәргәләнмә
Тынычлан әле, йөрәк.
Син бит миңа алда торган
Көрәшләр өчен кирәк.

Нурихан
Фәттах

# БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

## 11. Топография һәм этнография

Янтык—Яна Уртавыл ике ягы да сөзәк калкулыклардан торган тар гына елга буена урнашкан. Елга төньяктан көньякка таба ага һәм авылны узып, бер чакрым чамасы баргач, Бүгә барып кушыла. Авылның берләнбер урамы елганың уң ягына тигезле-тигезсез калкулык өстенә тезелеп утырган. Бүә очына таба өйләр елганың икенче ягына да чыкканнар. Уң якта шулай ук кечерәк тыкрыклар күренеп кала. Авылның озынлыгы ике чакрым, диләрие без бәләкәй чакларда.

Янтыктан төньякка таба, елга буенда—Вәрәш, Вәрәштән арырак Шатын дигән авыллар. Елга шул биш-алты чакрым ераклыктагы Шатын янынннан чыга. Елгага уңнан да, сулдан да алтымы-җидеме чишмә агып төшә. Чишмәләр гадәттә тирән чокыр төбеннән агалар. Шунлыктан авыл урнашкан сөзәк калкулык та, каршы яктагы калкулык та ергаланып, бүлгәләнеп беткән. Чишмә башланган чокырлар авылдан күренеп тора. Чокыр буйлары әрәмәләр белән капланган.

Еракта көньякта—Бүә ягында карурман белән капланган Сакаттау, Очлытау сыртлары зәңгәрләнеп тора. Төньякта мәһабәт булып ялгыз Шатын тавы күренә. Вәрәш турысында, көнчыгыш якта—Вәрәш тавы. Җәй көннәрендә кояш шул яктан чыга. Көз көннәрендә кара болытлар шул тарафтан актарылып киләләр. Таулар белән күк арасында һәрвакыт ниндидер серле дөнья бар сыман тоела. Мин еш кына сокланып, куркып һәм шомланып шул таулар ягына карап торырга яратам...

Әйтелгәнчә, авыл чокыр-чакырлы җиргә урнашкан. Карар күзгә матур, тәэсирле: таулар, урманнар, сихри әрәмәләр һәм чишмәләр. Ләкин игенче өчен бу җирләрнең әлләни кызыгы юк. Туфрак башлыча көлсу, коры. Кайбер урыннарда тоташ кызыл балчык. Түбән җирләрдә, елга буйларында гына кара туфраклы басулар очрый. Яңгыр яуса урамыннан үтәр хәл юк—аягыңа “биш пот” ләпек урала. Кыш көне юлында чана салулый.

Инәкәй белән без менә шушы авылга күченеп килгәнбез. Ул үзенең төп йортына кайтып төшкән.

Төп йорт. Иске генә. Бәләкәй генә. Ишегалды зур. Чирәм үскән. Бу ишегалды ике ягында тирән чокыр булган калкулыктан гыйбарәт. Төньякта Салкын чишмә чокырының дәвамы. Чокыр буенда абзар-кура. Абзар артында чыршы үсеп утыра. Мин бәләкәй чакта яратып ясый торган рәсем: тау, тау кырыенда бәләкәй генә йорт, аның янында йә артында ялгыз чыршы. Өйнең көнчыгыш ягында—урам дисәң урам түгел, ташландык җир дисәң, ташландык җир түгел. Ачык, иркен бер урын—озынча калкулык буе.

*Дәвамы. Башы 10 санда.*

Юл өстән дә, астан да үтә. Безнең "төп йорт" утырган озынча калкулык башында тагын дүрт-биш йорт бар. Беренче күршеләр—Нәсимнәр, алардан арырак—Закирләр, аннан Муллаканнар, иң кырыйда мунча кебек бәләкәй генә өй. Анда Галкәй өе. Аларның безгә яшьтәш малайлары юк, шуңа күрә аларны йорт хуҗасы исеме белән "Галкәйләр" дип кенә йөртәбез.

Төньякта, көнчыгышта, гомумән, күрше-фәлән юк. Салкын чишмә аша салынган күперне чыгасың да, утраусыман тагын бер калкулык башлана. Шушы калкулыкта бер оя булып өч-дүрт йорт утыра. Күпердән ун якта—Фәритләр. Башка йортларда малайлар юк, шуңа күрә алар белән безнең алыш-биреш тә юк. Хәзер бу "очны" Бушкилде дип йөртәләр. Элек Вәрәш-оч дип йөртәләр иде. Анда—авыл кырые. Анда авыл киртәсе, авыл капкасы. Капканы чыккач басу башлана. Элек Янтык бөтен яктан киртә белән әйләндереп алынган, олы юлларда капка куелган иде. Киртәне авыл халкы тота һәм карап-саклап тора. Безнең өлеш Салкын чишмә янында гына.

Салиха Кучтәвылда кияүдә чагында Вазифа Шатындагы карт иреннән качып кайта. Шуннан соң аны Ушья тау дигән авылның Салих дигән кешесенә димләп кияүгә бирәләр. Ләкин икенче мәртәбә дә Вазифаның бәхете булмый. Яшь кияү Салих жилкуар һәм зимагур булып чыга. Баласын, хатынын ташлап ул көннәрдән бер көнне читкә китеп бара. Көтмәгәндә кайтып төшә һәм өйне, сыерны сатып, баласын, хатынын үзе белән читкә алып китмәкче булып карый. Вазифа ышанычсыз кешегә ияреп ышанычсыз "чит"кә китәргә риза булмый. Шулай итеп, бердәнбер улы Зәйкәт белән, сенелләре белән төп йортта торып кала.

Инәкәйнең түтәсе Вазифаны мин яшәби димен. Нәгыймә апаны без Зәйкәт белән күпмедер вакыт аккай дип йөреттек. "Аккай" ул вакытта буй җитеп килгән кыз. Көн дә клубка чыга, аң-белемен арттыра. Ул әле олылар мәктәбендә укып та йөрде бугай. Ни генә булмасын, заманында алдынгы яшьләр рәтеннән саналды, ахрысы. Күрәсең, "аккай" сүзеннән оялып, аны "апа" дип әйттерә башладылар. Апа бездә юк. Апа—китап сүзе. Аннан соң аны укытучыларга карата гына әйтәләр.

Уразыга кияүгә киткән Галимә апаны без чибәрттәй дибез. Туганлык терминнары, өлкәннәргә эндәшү сүзләре бездә гомумән үзенчәлекле. Күршедәге Нәсим, Рәсим, Тәслимәләрнең әтәсен без Балбабай дибез, инәләрен Баләби дибез. Закирнең әтәсен Урта бабай, Муллаханныкын—Бәлкә бабай дибез. Безнең "утрау"га күрше "утрау"дагы Шәйхәттәр бабайны—Шикәр бабай, аның карчыгын Шикәр әби дибез. Ир кешегә бездә шәкерт абзый, шәкерт бабай, мулла абзый, ак бабай диләр. Хатын-кызга, яшенә, туганлык дәрәҗәсенә карап, түтәй, әбзәби, актәй, агаби диләр.

Әледән-әле безнең матбугатта, эш юктан эш булсын дигәндәй, һәртөрле кушаматларга каршы селтәнеп алалар. Янәсе, матур, дөрес сөйләшергә өйрәтәләр. Чынлыкта халык иҗатына балта чабалар. Халык кушаматны тиккә такмый. Безнең утраудан аста, юлның икенче ягында, бер кечкенә калкулыкта үзенә бер авыл булып бер өй утыра. Анда бер корткa белән аның кызы гына яши. Кортканың чын исеме булды микән, юк микән, ләкин аны Рәхимә корткасы дип йөртәләр. Рәхимә ул кортканың кызының исеме. Рәхимә корткасының Патифун дигән кушаматы бар. Чөнки, бер сөйли башласа, һич туктый белми—кычкырып-кычкырып сөйли дә сөйли. Шәйхәттәр бабайларга урам аша Садрислам бабайны, Әнисәнең әтәсен нигәдер саескан диләр. Закирнең әтәсе Мәхмүтҗан бабайны яисә Урта бабайны Куян диләр. Ни өчен дигәндә куркаграк булган бугай. Кушаматны, билгеле, кешенең йөзенә карап әйтмиләр, шулай да үзе булмаганда кушамат белән генә сиптертәләр. Малай чакта минем дә кушамат бар иде. Кылыч борын. Әлләни кимсетә торган мәгънәсе дә юк. Ләкин күзенә карап берәр яшьтәшең сиңа кылыч борын дисә, үл дә кит инде. Йә булмаса әтәч кебек

сугыша башла. Шулай да тәртипле генә кәнфит суырып, телевизор карап утыруга караганда, кушаматлы килеш үзен ише малай-шалайлар белән тәпәләшеп, жылашып үсү табигыйрак булган дип әйтер идем мин.

## 12. Мин кем?

Без кайтып төшкәндә төп йортта инәкәйнең түтәсе Вазифа, кече сеңлесе Нәгыймә һәм яшәбинең малае Зәйкәт торып ята. Дүрт кыз туганның Галимә дигәне бу вакытта Уразыда кияүдә була.

1936 елда без Зәйкәт белән беренче класска укырга кердек. Мәктәп бинасы әллә юк иде, әллә инде безгә анда урын булмаган—укырга без түбән оч мәчитенә йөредек. Без укыган класс—элекке мәчит залы иркен, якты. Бүрәнәләре эре, тигез итеп юнылган, тәрәзә төпләре биек. Идән сайгаклары киң, тигез. Шулар истә калган. Аннары шул—яна китап исе. Яна китапны тотып карау, актарып карау шатлыгы. Минем беркайчан да үз китабым булмады, ахрысы. Ике кешегә бер китап иде бугай. Аларны да өйгә бирмиләр, укытучы апа алып кала. Тагын шул: яшь укытучы апа. Чибәр, ягымлы. Халисә апа.

Укыганда мин һәрвакыт беренче булдым, алдынгы булдым дисәм мактану булмас дип уйлыйм. Миңа гел "бишле" куялар иде. Хәзергечә "бишле". Ул вакытта " бишле", "дүртле" юк. "Бик яхшы", "яхшы", "уртача", "начар". "Яхшы" алганда хурланып үлә язам. Ләкин үзем беркайчан рәтләп дәрес әзерләмим. Өйгә биргән эшне карарга нишләптер вакыт калмый. Гел уенда яисә... эштә. Класста күршеләрне көлдереп, берәр төрле этлек ясап утырам. Кайчагында укытучылардан бик каты эләгә. Бераз вакыт дөнья бетәрдәй кайгырып, укытучы күзенә күренергә оялып йөрисен дә , янадан элекке хәл башлана. Олырак классларда дәрес тыңлаудан бигрәк әдәби китап укып утырам. Иң яраткан фәннәр физика, география, тарих һәм ана теленнән язу, уку. Кайчагында алгебра, тригонометрия белән дә мавыгып китәм. Ләкин мин анда күп нәрсәне аңлый алмыйм. Бигрәк тә нинди дер почмак табу, ниндидер сызыклар сызып, ясалма фигуралар ясау. Иң яратмаганым һәртөрле формулалар, кагыйдәләр ятлау. Тормышта да минем катып калган әзер формулаларны, әзер кагыйдәләрне женем сөймәде. Әле дә шулай. Дөрес формула ул үзенчә уйларга һәм үзенчә яшәргә комачаулый.

Мәктәп тормышыннан тагын шул истә калган. Дүрт ел буена мин Садрильманов булып йөрдем. Бу әткәйнең исеменнән алынган фамилия. Ләкин аның чын исеме Садырлиман булган. Кайсыдыр укытучыга мондый ямьсез исем ошамаган, ул аны үзенчә Садрильман итеп матурлаткан. Дүртенче класска кадәр, ахрысы, Садрильманов булып йөрдем дә , ниндидер укытучыга бу тагын ошамады. Фамилия имеш ата исеме белән булырга тиеш түгел. Әткәйнең кемедер Фәттәх булган. Шуннан мин Фаттахов йөри башладым. Казанда университетта укыганда Фаттахов тагын кемгәдер ошамады. Бу ямьсез фамилияне Фәттахов итеп төзәттеләр. Минем ачу килде, һәм бер-ике шигырь бастыргач та, бөек шагыйрьләр, язучылар кебек, янгыравыклы Фаттах кушаматы алдым. Ләкин ул вакытта үз исемем Нурый дип кыскартылган иде. Минем әле Нурыйхан булып йөргәнем дә бар. Ниндидер документта шулай. Шул бер хәреф аркасында минем судка кадәр барып житкәнне белмисең әле син, Руфина Фаттахова. Акылга утыргач, белем күбәйгәч, изге гарәп теленә зыян ясаудан куркып, Фәттах булдым, исемем Нуриханга әверелде. Минем мулла кушкан, әткәй белән инәкәй үзләренчә яратып әйткән исемем Нурихан булган, билгеле. Ләкин күрше Баләби, Нәсимнең инәсе мине Нурлихан дияр иде. Казанда исә, инде картаеп буыннар каткач дигәндәй, әле торып ята торган йортка күршедәге Гата әнисе Сажидә әби беркайчан мине Нурихан дип атамады, Нурислам гына диде.

Күчтәвылда чагында, кызамык белән чирләгәч, мулла минем исемне үзгәртеп, яңадан куша. Монысында мин Миңнемөхәммәт Нурихан дигән исем алам. Андый дәрәҗәле исем белән атаучы булды микән, юк микән, әйтә алмыйм. Ләкин мулланың дога укуын, уттай янган тәнемә өр-өф итеп өч мәртәбә өрүен бик яхшы хәтерлим.

Менә шулай һәркем төзәтте, һәркем дөресләде безне. Төзәтү-дөресләү утыз алтынчы, утыз жиденче елларда гына башланмады. Хәзер инде төзәтер нәрсә дә калмады. Барысы да дөрес, барысы да төзек, иншалла.

## 13. Яшәби

Төп йортта бер гаилә, бер симия булып яшәдек. Минем өчен яшәби икенче ана булды. Минем өчен генә түгел, безнең барыбыз өчен дә ул баш кеше, ана кеше булды. Инәкәй дә, апа да аның сүзена колак салалар. Зәйкәт белән безне әйткән дә юк. Инәкәй белән апа аны түтәкәй диләр, инәкәйне апа мүлләттәй ди. Зәйкәт тә мүлләттәй ди. Заманында инәкәй абыстайдан сабак алган, аннан соң бер елмы, ярты елмы Ар Ушиада урысча укыган—хәреф танырга өйрәнгән дә , “по полу покатился мәчик” дигән шигырьне исендә калдырган. Аннан соң җәгъръфиядән дә шундыйрак бер жөмлә отып калган. Без алдынгы яшьләрне җәгъръфиядән шаккатырырга теләгәндә ул, “Балирка, Миурка, Курсика, Сиҗилиә атаулары” диярга ярата иде. Сукыр Нуртдин үзенең сөекле Салихасы өчен Казаннан гәзитләр, журналлар алдырган. Шул гәҗитләрдән ятлаган шигырьләрен дә ул еш кына безгә әйтеп күрсәтә торган иде. Туганнары арасында ул гомумән укымышлы саналган.

Яшәби үзенең сеңелләренә Салиха, Нәгыймә дип, Галимә дип исемнәре белән эндәшә. Инәкәй дә үзеннән кечеләргә исемнәре белән эндәшә. Димәк, монда нииндидер кагыйдә булган. Башлангыч мәктәптә укыган еллардан тагын шул истә калган: кыш көне күз ачкысыз бураннарда яшәби, иске шәл, яулык кебек нәрсә тотып, безне алырга килә. Күзне, борынны гына калдырып , икебезне дә шәл белән, яулык белән төреп бәйли дә җитәкләп алып кайтып китә. Шулай өчәүләшеп буранга каршы бик озак кайтканыбыз әле дә күз алдында.

Мәктәптә ул елларда безнең өчен аш пешә. Озын такта өстәл тирәсенә тезелешеп утырасың, калай күбәтәгә салып сыек, кайнар борчак ашы китереп бирәләр. Аның эре-эре бәрәңгесе дә була. Һәркемгә бер телем эпи. Зур, тәмле арыш эпие. Кайчагында ул чи була, ләкин барыбер тәмле. Олы тәнәфес вакытында кайнар аш ашау икенчеме, өченчеме классларга чаклы булды. Аш пешерүдә безнең яшәби дә катнашты. Бит ул гомере буена фермада әле сарык бәрәннәре, әле ясләдә балалар караган. Балалар белән ыгы-зыгы килү—аның өчен иң зур шатлык. Яшәбине чебиләрен канат астына җыя торган тавык белән чагыштырып булыр иде. Мин аның үз малае Зәйкәтне артыграк күреп, мине читкә тибәргәнен, мине кыерсытканын хәтерләмим. Ул минем өчен дә чын күңелдән кайгыра һәм чын күңелдән сөенә белә. Ул шулай ук үзенең Салихасы өчен дә, Нәгыймәсе өчен дә бертигез кайгыра һәм сөенә. Кайчагында Уразыдан берәр төрле күңелсез хәбәр килә. Бөтен эшен ташлап, теләсә кайсы вакытта Галимәнең, “кияүнең” хәлен белергә дип Уразыга китеп бара. Йокыдан ин беренче булып ул тора һәм иң беренче булып абзардагы мал-туарны, кош-кортны ул карап керә. Аннары казан астына ягып җибәрә, чәй куя, ашарга пешерә. Дөрес, өй эшен ул бик үк яратып җиткерми. Өч хатын-кыз арасында өй эше мәсьәләсендә еш кына тавыш та чыгып ала. Яшәби йә вакытында казан аска якмаган, йә су китермәгән була. Урманга утынга, йә чикләвеккә-фәләнгә дигәндә аны куш. Ул шулай ук кантур, амбар ягына барып кайтырга да, иртүк Янавылга базарга чыгып йөгерергә дә иренми.

Сугыш елларында безне ач үлемнән бары ул гына саклап калгандыр кебек. Кышкы бураннарда безне ияртеп йә саламга, йә утынга бару дисеңме, язгы пычракта колхозның бәрәнге жиреннән өшегән бәрәнге алып кайту дисеңме, кыш көннәрендә иске ындыр табакта калган иске кибәк өемнәрен җилгәрү дисеңме—берсенә дә иренеп тормый. Җәйгә чыгу белән какы, балтырган ише нәрсәләр җыеп алып кайта. Көз көне туктаусыз яңгыр яуганда колхоз эшенә чыгып булмый. Яңгыр яуганда уракчы да, ашлык сугучы да җиңел тын алып, ял итә. Андый чакта бары яшәби генә ял итми—капчыгын күтәреп Көек елгага яисә аннан да арырак чикләвеккә, шомыртка китеп бара. Алары беткәч, Буә буйга баланга, комалакка бара.

Һәр тапканын ул безгә, безнең өчен алып кайта. Чикләвекне базарда сатабыз, баланны бүкәнлибез, комалакны, миләшне, тал кабыгын, зелпе тамырын заготконтора вәкиле Гыйльмулла бабайга ыздавайт итәбез. Анысы үзебезнең авылда гына.

Яшәбинең бар теләге—кеше алдында ким-хур булмау. Колхоз эшендә дә анын алдынгы, мактаулы буласы килә, өйдә дә хәленнән килгәнчә бөтенесен житештереп торасы килә. Ул безнең кеше арасында яхшы, эшчән, әдәпле, булдыклы булуыбызны тели. Кеше малына кул сузуны, ялган сөйләүне, ялкаулыкны олылардан беркем яратмый. Безгә гел тукып кына торалар: алдаша күрмәгез, ишетсен колагыгыз. Әнә Фәләнне бер кесә борчак белән тотканнар, фәлән елга утыртып куйганнар... Янавылда эпигә чират торганда Әхмит хатыны халык алдында әйткән: шушы каткан эпи белән Сталинның башын ярырыем мин, дигән. Тыңлап кына торганнар да, алып та киткәннәр... Пулат Кәнифә, мескенкәем, бер кила арыш белән утырды. Яңа арыш уып алып кайткан. Өйдә балам ач—шуңа алдым, дигән сорагач. Җиде елга озаттылар. Шулай да бер тапкыр моның киресе дә булды. Бер кичне без, берничә малай җыелып, күршедәге Вәрәшнең яшелчә бакчасына, ауга киттек. Бернинди киртәсе-ние, карачкысы-каравылчысы булмаган суган җиренә барып кердек тә, утадык кына яшел кыякны. Ләкин без юк дип уйлаган каравылчы кайдадыр шул тирәдә генә булган икән. Менә бер заман безне пыр туздырып куа башладылар. Без, билгеле, тотты-рып тормадык, үзебезнең авылга таба элдердек кенә. Бер чакрым чамасы жирне күз ачып йомганчы кайтып життек тә, өйгә кереп тормыйча, туп-туры фермага чаптык. Тау астында гына, елга буенда, Патифун корткалар янында ат фермасы бар. Ферма түбәсенә, дөресрәге, түбә астына, салам арасына менеп, бик озак шунда качып утырдык.

Каравылчы хатын чәр-чәр кычкырынып, безнең арттан ук килеп житкән. Тавышка безнекеләр чыктан. Вәрәш хатыны безне танып калган, ахрысы, сезнең балаларыгыз дип, бурлар, ышпаналар дип, милициягә хәбәр итәм дип яшәбигә дә кычкырына башлаган бу. Өйдәгеләр безнең чыннан да суган басуына баруыбызны белмәгәннәр. Безнең турыда сүз барганлыгын аңлап, яшәби каравылчы хатынның үзеннән яман тавышлана башлаган. Ахырда ул аның үзен куалап кайтарып җибәргән.

Ул көнне өйгә без бик соң кайттык. Кайда йөрүебезне, әлбәттә, әйтмәдек. Икенче көнне сораштырып карасалар да, барыбер әйтмәдек. Күпмедер вакыттан соң гына без дә, яшәби дә, ничек булганын сөйләп, шаулашып, көлешеп алдык.

Яшәби үз баласы кебек якын итсә дә, өйнең кече хуҗасы Зәйкәт белән безнең еш кына борчак пешмәде. Икебез дә бер яшьтә, икебез дә буйга-нигә бер чама булсак та, ул үзен өстенрәк тота. Бик ачуы килгәндә минем монда чит кеше икәнлекне сиздереп "килмешәк" дип тә ычкындыра. Андый чак сирәк була, шулай да була. Олылар күрмәгәндә берәр ничек итеп мине өтеп алудан да тартынып тормый. Кайчагында без юк кына нәрсә өчен әләгешеп тә китәбез. Өйдә икәү генә булганда ул болай дус, тату, күндәм. Ләкин малайлар белән бергә туры килдекме,—алмаштырган кебек үзгәрә

дә куя. Көтмәгәндә берәр кимсеткеч сүз әйтә, хәрәмләшә йә булмаса анда икәү генә белә торган берәр серенне чишә. Кыш көнендә әйтми-нитми синең корырак чабатаңны, оегыңны киеп чыгып китәргә дә күп сорамый. Аның үзенеке йә тишек, йә юеш була. Мондый чакта тышка чыга алмыйча, көне буе тәрәзә төбендә тилмереп, аның малайлар белән чана шуганын карап утырасың.

Җәйгә чыгу белән олыларның барысы да эшкә китә. Өй тулысынча Зәйкәт белән безгә кала. Киткәндә олылар безнең икебезгә дә эш кушып китәләр. Мин, мәсәлән, салкын чишмәдән бер көянтә су алып кайтып куярга тиеш, Зәйкәт көтү кайтканчы бозауны алып кайтырга йә булмаса сарык көтүен каршыларга, казан аслык чыбык-чабык алып кайтырга тиеш. Яисә, киресенчә, мин утын алып кайтырга, ул суга барырга тиеш. Үземә кушылган йомышны мин төп-төгәл вакытында үтим. Карышу, этләшү, киреләнү минем өчен мөмкин түгел. Мин, кушылганча, суын да, чыбык-чабыгын да алып кайтам. Аннан соң, үземне ирекле санап, йә малайлар янына китәм, йә күнелгә якын берәр эш белән булашам.

Кушылганны, билгеле, Зәйкәт тә, ләкин күбесенчә килде-китте генә, ашык-пошык кына, теләр-теләмәс кенә үти. Кайчагында бөтенләй онытып ук җибәрә. Яисә анда әйтми-нитми Бүә буена балыкка китеп бара.

Менә бер заман арып-талып, тёлләрен аркылы тешләп, олылар эштән кайта. Кайтсалар, су китерелмәгән, казан астына ягарга утын кертеп куелмаган. Апа иртәрәк кайтса, буш бидрәләрен шалтыратып, сукранып шундук суга китә яки җылата-җылата мине Корт бакчага утынга җибәрә. Мин үземә кушылганны эшләвем, Зәйкәтнең этләшеп балыкка китүен әйтеп карыйм. Ләкин апа андый сүзләрне ишетергә дә теләми. Иртән кемгә нинди эш кушылганын ул белмәскә дә, онытырга да мөмкин. Эштән арып, ачыгып кайтканга, аның гомумән бик ачулы чагы булырга мөмкин. Аннан соң тузынганда ул алай турыдан-туры мине дә тиргәми, бары без ялкауларны тирги. Шулай да сүз арасында ялгыш “әрәм тамак”, “җык җилкә” дигән сүзләр дә ишетелеп кала. Андый сүзләр ишетелсә, бетте, үл дә кит инде. Минем өчен дөньяда яшәүнең бернинди кызыгы калмый. Күз яшьләремне агызам йә булмаса башка берәр эш эшләргә тотынам.

Озакламый яшьәби дә кайта, инәкәй дә кайта. Алар беркайчан безгә каты бәрелмиләр. Алар кайткач, дөнья ямьләнеп китә, ачу, үпкә онытыла. Казан астында дөрләп ут яна, казанда тәмле ис чыгарып, умач пешә. Кармагын, җеп очына элгән бер-ике ташбашын күтәреп, берни булмагандай шыпырт кына Зәйкәт тә кайтып керә. Олылар аны күрмиләр дә. Үзенә кушылган эшне эшләмәве турында аның исенә төшергән кеше дә юк. Мин дә тынычланам. Шулай да күнелдә энә очы кадәр генә әрнү, хурлану торып кала.

Менә шундый вак-төяк күнелсезлекләр кечкенәдән мине төгәллеккә һәм гаделлекне хөрмәт итәргә өйрәткәндер кебек.

Бервакыт шундый хәл булды. Кыш көне иде, ахрысы. Суык чак. Кич йокларга ятыр алдыннан чолан ишеген бикләп керергә кирәк. Олылардан беркемнең дә чыгасы килми. Шунда берсе Зәйкәт белән миңа карап: “Барыгыз әле, ишекне бикләп керегез”,—ди. Зәйкәт, билгеле, чыгарга ашыкмый. Ул ык-мык итеп торган арада мин ялт кына чоланга чыктым да, ишекнең келәсен эләктереп тә кердем. Сүз белән мавыгып, минем чыгып кергәнне беркем дә күрми калган. Хәтта Зәйкәт тә. Бераз вакыттан соң яңадан сүз ишек бикләү хакында чыга. “Мин бикләп кердем инде”,—дидем мин. Беркем миңа ышанмый. Барысы да мине ялганчылыкта гаепләргә тотынды. Мин аяк терәп үз сүземдә торам. Эш зурга китте. Шунда олылардан берсе түзмәде—үзе чыгып карарга булды. Караса, чыннан да ишек бикләнгән! Шаккаттылар үзләре дә.

Икенче бер вакытта тагын мин җинүче булдым. Вәрәш очында

Габдерәхим бабай яши. Озын буйлы, таза, кызу канлы. Яшьрәк чагында ул ат карагы булган. Кызыллар, аклар буталышкан чакта аклар килсә, аклар байрагы күтәреп чыга икән, кызыллар килсә, кызыллар байрагы күтәреп чыга икән. Шулай да ахырда "кызыл" булып калган бу. Әллә шуна, әллә башка сәбәптәнме, аны Партизан бабай дип тә йөртәләр. Октябрь бәйрәме вакытларында анын өй кыегы астында ак белән "яшәсен" дигән сүзләр язып, кызыл материя кадаклап куялар иде. Нишләптер без аннан курка торган идек. Олылар безне Партизан бабана әйтербез дип куркыталар, анын турында әллә нинди шомлы нәрсәләр сөйлиләр. Аннан сон аларны Пачай заты дип тә йөртәләр. Пачайны гадәттә яратмыйча әйтәләр. Габдерәхимнен түбән очта Гаптерәшит дигән абзасы да бар. Кайчагында ул безнен якка да килеп чыга. Монысы Партизан картка караганда кечерәк гәүдәле, ләкин аннан кызурак канлы. Сөйләшкәндә сүз арасына "Хөййе" дигән ымлык кыстыра. Шуна күрә аны Хөййе бабай дип кенә йөртәләр. Ләкин анын үзенә андый сүзне әйтергә ярамый. Андый сүзне ишетә калса, Гаптерәшит бабай үзен-үзе белмичә тузына башлый. Бала-чаганы кыйнап та ташларга мөмкин.

Бервакыт көз көне урам як тәрәзәдән карап утырганда шул Хөййе бабайны күреп алдым. Партизан карттан кайтып бара бу. Өстендә ак чапан сыман нәрсә, башында мескен бүрек, кулында—таяк. Тоттым да мин мона "Хөййе бабай"! дип кычкырдым. Тәрәзә аша булгач ишетмәс дип уйладым. Гөнаһ шомлыгына каршы ишетте бу, кире борылды да ашыга-ашыга капкага таба килә дә башлады. Минем котым алынды, каядыр качарга кирәк, ләкин бәләкәй генә өйдә кая качасын? Ин ышанычлы жир—мич башы. Тиз генә мич башына менеп киттем, мич арасына шуышып төштем. Миннән башка өйдә яшәби белән Зәйкәт тә бар. Ни булганын алар сизми дә калдылар.

Жилләнеп өйгә Хөййе бабай килеп керде. Килеп керде дә, Зәйкәтне күреп алды. Тотынды тиргәргә. И тирги, и тирги тегене! Яхшыдан яман туган, ди, тәүфиксыз, тәртипсез, ди, мәктәптә сине шуна үрәтәләрмени, укытучы апана әйтеп колагынны бордырам әле мин синен, ди. Зәйкәт тә, яшәби дә берни анламыйлар. Аптырап калдылар. Яшәби үз улын яклап та карый, "Ни булды, Гаптерәшит абзыкаем?" дип тә карый, ләкин Хөййе бабайны алай гына тынычландырып була торган түгел. Шулай да нидер сизенеп яшәби кисәк кенә Зәйкәтне тиргәргә тотына."Олы кешегә кычкырганы өчен сөяген он итәм әле мин анын! Үтерәм мин аны!"—ди йодрык белән кизәнеп. Анын шулай дип әйтүе булды, Хөййе бабай шундук юашланып калды. "Уу-уу, килен, ятим балага суга күрмә!"—дип Зәйкәтне яклый да башлады.

Хөййе бабай чыгып китвкәч, тузанга буялып мич арасынан килеп чыктым. Өйдәгеләр бары шунда гына анлап алдылар. Хәзер инде болар мине тиргиләр мин әйтәм. Юк. Тиргәмәделәр. Яшәби хәтта елмаеп куйды. "Һи, жүнсез"! дигән булды. Жүнсесен жүнсез инде анысы. Шулай да түзәргә була.

Жидене мин Янтыкта тәмамладым. Сигезгә Янавылга күчтем. Шуннан сон Зәйкәт белән безнен юллар аерылды. Янтыкка кайта-килә генә йөрим. Зәйкәт белән дә ара-тирә генә очрашырга туры килә. Ләкин беркайчан мин аннан тулысынча аерылмадым. Әйтерсен, безнен кендекләр бер-беребезгә береккән иде. Авылга кайткач, ул минем ин якын дустым була. Икәүләп без анын белән Бүә буйга йә Пешәлек якка чыгып китәбез, икәүләп эшкә йөрибез, серләшәбез, хыялланабыз. Шулай әйбәт кенә йөргәндә ул көтмәгәндә мина берәр төрле этлек эшләп куя. Шул чагында ул мина дөньяда ин яман явыз дошман кеше булып тоела. Шундук безнен ара суына һәм мин авылдан киткәндә бик нык хәтер калып, бүтән беркайчан ялганчы Зәйкәт янына кайтмаска дип китәм. Икенче елны исә, жәйге каникул житү белән, атлыгып, очынып янадан авылга кайтам.

Жиделән сон Зәйкәт укый алмады. Шул ундурт-унбиш яшеннән жигелеп

колхозда эшли башлады. 1944 елда ук ул тракторга укыды. Тракторчы була, тракторга ут кабып янып үлгәндә чак кала. Шуннан комбайнчы була. Тырышып эшли. Еш кына колхозда, хәтта бөтен районда беренче урынга чыга. Комбайнда эшләгәндә ел саен күпләп ашлык ала, Дуртөйле ягыннан килгән укытучы Әминәгә өйләнеп җибәрә, яңа йорт сала, балалар үстерә. Кыскасы, аякка баса. Тырышса ул бөтенесен дә булдыра. Кыш көне авылда механизаторның эше булмый. Озакка сузылган кышкы ял вакытларында Зәйкәт кием шкафы, буфет шкафы ясарга өйрәнеп китә. Ул вакытта алтмышынчы елларда авылда әле шифоньер дигән сүзне ишеткәннәре дә юк. Безнең Зәйкәт кемнәндер күреп, кемнәндер өйрәнеп, барлы-юклы корал белән, барлы-юклы материал белән менә дигән шкафлар ясый. Аның шомартып, тигез, матур итеп ясаган шкафын беренче мәртәбә кургәч, мин шаккаттым. Хәтта көнләшеп куйдым. Шкафны ул башта үзе өчен эшли, аннан соң сораган кешеләргә сатып җибәрә. Апаның тау башындагы тавык кетәгедәй бәләкәй генә өендә әле дә Зәйкәт эшләгән пыялалы буфет-шкаф кукраеп утыра.

Ләкин бик яшьләй эшкә өйрәнгән Зәйкәт бик яшьләй эчәргә дә өйрәнә. Шуның белән ул еш кына күңелсез хәлләргә юлыга. Мин авылга кайткан саен апа зарланып аның әкиятләрен сөйли торган иде. Эчә башлау белән аның элекке кире яклары тагын да көчәеп китә. Холкы белән ул барып чыккан ялганчы, аумакай һәм көнчел.

Бервакытны бу, кызу эш өстендә, совхоз конторына керә дә, “хатыным үлмә хәлдә, самолет белән Уфага алып барырга кирәк, миңа фәлән көнгә ял бирегез”,—ди. Ул вакытта безнең элекке “Очкын” колхозы якын-тирәдәге авыллар белән бергә “Буйский” совхозына әйләнгән була. Конторда моның сүзенә ышаналар, чөнки Зәйкәт хатыны Әминәнең әледән-әле авырып китүен яхшы беләләр. Аннан соң шунсын да әйтергә кирәк, Зәйкәт бик оста ялганчы. Ул шундый килештереп, ышандырып сөйли, шундый мескенләнә—артистларың бер читтә торсын. Ышаналар моңа конторда. Ун көнгәме ял бирәләр, акча бирәләр һәм безнең Зәйкәт ун көн буена эчеп йөри.

Берничә мәртәбә ул мине дә төп башына утыртты. Бер кышны инәкәйне алырга дип авылга кайттым. Иртәгә китәргә дигән көнне кичтән Зәйкәт белән сөйләшеп куйдым. Безне ат белән Яңавылта станциягә илтеп кую өчен Зәйкәт иртән иртүк ат җитеп кайтырга булды. Икенче көнне тордык, ашадык-эчтек тә, ерак юлга әзерләнә башладык. Зәйкәт чана җигеп кайтканны көтәбез, әледән-әле тәрәзәгә карап алабыз. Нишләптер бу һаман күренми. Сәгать арты сәгать үтә, көн төшлеккә якынлаша бара. Ул арада җил чыкты, буран кузгалды. Зәйкәт юк та юк. Апа борчылып күршеләргә кереп китте. Бераздан тузынып чыккан бу. Беркая китмәгән безнең Зәйкәт, тормаган да, йоклап ята, ди. Без, билгеле, иртәнге поездга өлгерә алмадык.

Бер кышны университет студенты чагында Зәйкәт миңа бик еш хат яза башлады. Өскә пальто юк, малай, Казаннан берәр пальто алып куй әле, үзем барып алырмын, ди. Әледән-әле яза. Ул чактагы авылның хәлен аңлатып торасы да түгел: пальтосы да юк, башкасы да. Зәйкәтнең җегет чагы, билгеле, яхшырак киенәсе киләдер. Казанда да тутырып куймаган. Ләкин Казанда безгә профком пальто, күлмәк-чалбар ише нәрсәләргә талон бирә. Акчаң булса, талоның булса пальтолы буласың. Шуннан соң мин үзем өчен дип профкомнан кышкы пальтога талон юллый башладым. Ни хикмәттер, талонны бирделәр. Ул вакытта мин ФЗО укучылары өчен чыгарылган кара шинель киеп йөри идем. Шинель—кышкы кием түгел. Кышкы җылы пальто минем үземә дә шәп булыр иде. Ләкин мин аны шулай да Зәйкәткә бирергә булдым. Бит аның хәле минекенә караганда начаррак. Авылга хат яздым. Күпмедер вакыттан Зәйкәт килеп җитте. Пальто бәясен

тулысынча түләде. Алты йөз чамасы иде, ахрысы.

Ярар, сөенеп кайтып китте инде яңа пальто киеп. Бу хәл кышкы каникулга кадәр булды. Кышкы каникулда авылга кайтып төшәм. Кайту белән урамда Зәйкәтне очраттым. Өстендә кырык ямаулы иске сырма. Аптырап киттем. Көн салкын. "Нишләп пальтонны кимәдең"?—дидем мин моңа. Эндәшмәде бу. Өйгә кайткач белешсәм, безнең Зәйкәт пальтоны авылдагы кемгәдер сатып җибәргән. Үз бәясеннән илле тәңкәгә артыграк алган, имеш. Ул чагында мин бик нык аптырадым да, ачу да килде, хәтер дә калды. Мин бит аңа үз өстемнән салып биргәндәй бирдем.

Университет бетереп яна эшкә тотынгач, 1951 елда, ахрысы, Казандагы тар гына, кысан гына "квартирга" көтмәгәндә авылдан Зәйкәт килеп төште. Кунак булып килгән. Үзе бик ягымлы, сүзчән. Авылдан күп итеп сәламнәр, яңа хәбәрләр алып килгән. Гадәттәгечә, без аның белән озак кына сөйләшеп, серләшеп утырдык. Кулдан килгәнчә мин аны сыйларга, кунак итәргә тырышам. Зәйкәт монда бик зур йомышлар белән килгән икән. Аңа баштан-аяк эш киеме дә кирәк, кирза итек тә, мотоцикл камерасы да, тагын әллә нәрсәләр кирәк. Мин бик кисәк кенә чыгып киттем, малай, ди, сыер сатсак акча күп була, тик минем монда азрак, син бераз биреп тормассыңмы, ди. "Күпме кирәк?"—дигәч, "Бер мең", диде бу. Кайткач почта белән салырмын диде. Ул көзне Зәйкәт капчык тутырып Казаннан әйбер алып китте. Мин булган барлык тиеннәремне җыеп бирдем тегеңә. Вокзалга үзем озатып куйдым һәм Зәйкәт китеп берничә көн үтү белән, сыер сатып җибәрәчәк акчаны көтә башладым. Күпме көткәнмендер, әйтә алмыйм...

Зәйкәткә үпкәләп мин берничә ел авылга кайтмадым. Үпкә, ачу күптән онытылды, шулай да "факт" күңелдә торып калды.

## 15. Май сатарга бару

Җәй көннәрендә кичкә таба бозау алып кайту, су, утын алып кайту, калган вакытны үзең теләгәнчә уенда уздыру шулай да безгә күп тәтемәде. Безне бик иртә олылар үзләре белән эшкә йөртә башладылар. Элек колхозның ужымнары бик чүпле була иде. Шунлыктан бөтен басуны икешәр мәртәбә утап чыгалар. Олылар безне үзләре белән утауга, алып баралар. Монысы аның колхоз эше дип атала. Утау әле ул үз бакчаңда да була. Колхозныкы беткәч, качып-посып дигәндәй бригадирдан сорап йә тиргәлеп үз бакчаңны утарга каласын. Монда да олыларның ин ышанычлы ярдәмчесебез. Утаганда кишәрлек бүлеп бирәләр. Ярышып, кем элегрәк дип эшлисең. Утау эше авыр да, күңелсез дә. Билчәннең тирәнгә киткән тамырын тартып чыгара алмый азапланып бетәсең. Утаганда ялан куллар, ялан аяклар пычранып, җәрәхәтләнеп бетә. Төш вакыты житеп, кояш түбә өстенә күтәрелгәч, корымланган бидрәгә чишмәдән су алып менеп кайнатырга куйдыңмы, бөтен нәрсә онытыла. Олылар казан тирәсендә булаша, без чыбык-чабык җыябыз.

Утаудан соң урак башлана. Уракта шулай ук кишәрлек бүлеп бирәләр. Булыр-булмас көчең белән урган буласың, көлтә бәйлисең, көлтә җыясың. Иң авыры арыш урагы. Арыш каерылып унса—сөенеч, ләкин андый арышны уруы безнең өчен газап. Солы, бодай, тары җиңелрәк. Борчак алу инде уен гына. Уенын уен түгел, шулай да анда борчак ашарга була. Кайчагында әрлән базы очрый. Көрәк алып килеп карыйсың, әрләннең җыеп куйган борчагы чыкса, үзе бер куаныч. Күбесенчә әрлән бездән тоттырмый. Тотсаң, үтерсәң, тиресен тунап киптерә алсаң, җәй буена сөйләп мактанырга була.

Шулай итеп без акрынлап кул арасына керә башладык. Кул арасына керү ул утауга, уракка йөрү генә булмаска да мөмкин. Җәйге эссе бер көндә

яшәби мине, күрше Газимәттәй белән Камиләттәйгә ияртеп, Яңавылга базарга мй сатарга җибәрде. Үзенең вакыты булмады микән, миңа инде базар эшләрен дә ышанып тапшырырга ярый дип уйлады микән, әйтә алмыйм. Аннан соң эш вакытында базарга-нигә бару өчен бригадирдан рөхсәт сорарга туры килә. Бригадир сиңа теләсә кайчан рөхсәт бирми. Ни булса булды, мине базарга, җибәрмәкче булдылар. Кичтән яшәби май язды, майны бизмән белән үлчәп, матурлап әвәләде. Икеме, өчме кадак майны яшел мискигә салып, чиста әрекмән яфрагы каплап, күрше Нәсимәләрнең карбазына төшереп куйды.

Икенче көнне мине гадәттәгегә караганда иртәрәк уяттылар. Әле таң да атмаган, караңгы. Йокы килә, күзне ачасы килми. Нәрсәдер капкаладым да, ике колагыннан юкә бау белән бәйләнгән авыр гына мискине муенга асып, ашыгып, карангыда абына-сөртенә Камиләттәйләргә киттем. Ашыкмыйча ярамый, бит алар сине көтеп тормаячаклар. Юк, китмәгәннәр икән. Менә капкадан чыктылар. Берни әйтмичә иярдем болар артыннан. Ялан аяк, ялан баш. Өстә бер кат күлмәк. Әлегә салкын. Ләкин йөргән кешегә салкын тими ул.

Яңавылга турыдан барганда сигез чакрым диләр. Турыдан ул Сакат тау аша дигән сүз. Бүә аша. Сакат тавының аркылысы гына да бер чакрым бардыр. Тауны төшкәч, Бүәгә килеп чыгасың. Бүәгә кайбер елны басма салынган була. Андый чакта басмадан чыгасың. Басма булмаса, кичүдән чыгасың. Кичү дигәне аның сайрак җир була. Кичү ике җирдә. Берсе Үрмәде дигән бәләкәй генә авыл турысыннан, икенчесе—астарак, элекке нииндидер байның тегермәне урынына якын җирдә. Революциягә кадәр тегермән гөрләп эшләп торган. Байларны бетерәбез дип "сәвит" тегермәнне сүтеп ташлаган. Без гадәттә шул иске тегермән янындагы кичүдән йөрибез. Бүәнең суы чип-чиста. Үтә күренмәле. Ике ягында яр буйларында таллар, куе әрәмәлек. Кичүнең төбе ташлы. Миллион еллар буена су кузгатып, шомартып бетергән вак кына түгәрәк, ярым түгәрәк ташлар. Яр читендә кайбер төштә эре ком җыелып калган. Ыштаныңны салып кулыңа тотасың да, яртылаш суга күмелгән килеш, әкрен генә атлап чыгасың. Иртәнге салкында Бүә суына керүдән дә рәхәт һәм татлы берни дә юктыр. Чиста, тере, салкынча суга арыган шәрә аякларың тию белән, йокың да ачылып китә, аруың да юкка чыга. Үзеңне бөтенләй икенче кеше—бәхетле, батыр һәм тук кеше итеп сизә башлыйсы. Яр буендагы таллыкта төнне йокысыз уздырган сандугачлар сайрый, чулт та чулт килеп суда балыклар сикерә. Түбә өстендә кинәт күк йөзе ачылып, яктырып китә. Кайчагында елга өстендә җинелчә, аксыл томан асылынып тора. Озынча юеш тал яфракларында тамчылар елтырый. Яр өстендә, урман ягында моңлы, сагышлы итеп нииндидер зур кош кычкырып куя. Рәхәт. Күнелле. Сихри дөнья менә шул үзедер.

Судан чыккач, тән җинеләеп кала. Соңгы көченне җыеп, Яңавылга ашкынасың. Җәй көне базарга барырга туры килсә, анда кояш чыкканчы барып та житәргә, кояш кыздыра башлаганчы кайтып та китәргә кирәк. Җәй көне базарга баруның бөтен хикмәте шунда.

Базар миңа һәрвакыт үзенә бер төрле гаҗәеп дөнья булып тоела. Базарда ят кешелар, ят исләр, ят тауарлар, азык-төлек. Анда үзенә күрә күнелле, мавыктыргыч бер гүелдек була. Ят кешеләрне, ят тавышларны, атлы арбаларны карап йөрү, бәрелә-сугыла йөрү әйтеп бетермәс дәрәҗәдә күнелле. Базарда берәр стакан гомбагыш сатып алып, хыяллана-хыяллана юл буена гомбагыш чиртеп кайтсан, бу дөньяда башка берни дә кирәк булмас кебек тоела башлый.

Базарда сатарга әйберең булса һәм сату эшең җайлы барса, тагын да яхшырак. Ләкин, әйтергә кирәк, базарда мин беркайчан уңышка ирешә алмадым. Балыкка барып миңа балык капмады, базарда сату итеп файда

чыгара алмадым. Әле Күчтәвылда чакта әткәй мине үз янына утыртып, Янавылга базарга алып бара торган булган. Бер вакытны, ачлык елны бер потмы, ярты потмы он сатып алган. Кайтканда Янавылдагы ниндидер белешенә тукталган. Атын капка төбендә калдырган да өйгә кереп киткән. Онны саклап мин арбада утырып калганмын. Бераздан әткәй әйләнеп чыкса, оннан җилләр искән! Кемнеңдер арба яныннан капчык күтәреп барганы әле дә исемдә. Ләкин ул вакытта кычкырырга, жыларга яисә анда капчыкка ябышырга мин, күрәсең, бик бәләкәй булганмын.

Сугыш елларында танышларның күбесе станциядә поездлар туктагач солдатлардан папирос, зажигалка, иске-моски кием-салым алып, базарда шуны арттырыбрак сату белән шөгыльләнделәр. Аларның эше гел алга барды.

Мин дә булашып карадым. Бер көнне түш кесәсеннән алтмыш тәңкә акчаны алдыргач, андый эшкә бөтенләй диярлек сүрелеп калдым.

Күрше хатыннарына ияреп май сатарга бару сугышка кадәр булды. Ул көнне Янавылга без бик иртә барып җиттек. Базарда кеше күп кенә. Ләкин кая карама, барысы да май сата! Майга караучы да юк. Камиләттәй башта ук мине кисәтеп куйды: синең маең әйбәт, биш тәңкәсез бирмә, диде. Яшәби язган майның әйбәтлеген мин үзем дә беләм. Ул беркайчан харамга кермәде. Бер кадакта яисә бер гөрәнкәдә—дүртйөз грамм. Яшәбинең мае гадәттә илле грамм чамасы артыгы белән була. Мае сап-сары, тыгыз, салкынча. Сатучы хатыннар янына, бастым да, торам. Әле берсе, әле икенчесе туктала, карыйлар, бәясен сорыйлар. Кайсы дүрт сум, кайсы дүрт сум илле тиен бирә. Мин бары биш сум биргәнне генә көтәм. Озакламый көнне жылыта башлады, базарда ыгы-зыгы көчәя төште. Камиләттәй белән Газимәттәй үзләренең майларын дүрт сум илле тиенгә, дүрт сумга бирделәр дә кайтып та киттеләр. Мин калдым биш тәнкәне көтеп. Май йомшый башлады, жеби башлады. Хәзер инде дүрт сум бирүче дә юк, "өч сум" диләр, оятсызлар!

Тордым-тордым да, арыгач, тәмам ачыккач, күнелсез генә мин дә кайту ягына кузгалдым. Мискидәге май инде боламыкка әйләнде, аерым-аерым йомарлаган кисәкләр бергә кушылып бетте.

Авылга кайтып җиткәнче төш булды. Кояш кыздыра. Май авыр. Ачлыктан, хәлсезлектән күз аллары томалана. Көч-хәл белән чыршылыкка кайтып җиттем. Чыршылык аша түбән төшәсе дә, елганы аша чыгасы да, ат фермасы янындагы үрне менәсе дә—анда инде өй. Чыршылыкның чыршыларына берничә адым каларак, кайтып житүемә сөенеп, хәл җыярга утырдым. Утыруын утырдым, ләкин шундук йоклап киткәнмен. Бер заман кемдер уята. Карасам, төшке ялдан соң уракка баручы хатын-кызлар. Кызгандылар, нидер сораштылар. Мин ярым йокылы килеш, ач, хәлсез килеш, мискине көчкә күтәреп өйгә таба кузгалып киттем.

## 16. Сарапулдан кайтканда

Мең тугыз йөз кырык өченче май аенда Янавылда сигездә укыганда үзем ише малайлар белән ерак сәфәргә чыгарга булдым. Малайларның берсе—Касыйм, икенчесе Мәгъсүм. Минем жан дуслар. Өчебез дә бер мәктәптә, бер класста, укыйбыз. Касыймнар станция ягында торалар. Аның инәсе каядыр шунда баракта эшли. Мәгъсүмнәр Янавылның радиоузелында, аслы-өсле агач өйнең югары катында, Алар безгә якын гына. Мин аларга еш барам, ул да безгә килә. Аның белән безнең борчак пешә. Киң күнелле, эчкерсез, юмарт. Кара чәчле. Гел елмаеп сөйләшә. Арада иң шомасы, иң булдыклысы—Касыйм. Ул теш арасыннан оста итеп, чертләтеп төкерә белә, сөйләшкәндә "тәэсирле" сүзләр кыстырып җибәрә. Станциягә туктаган хәрби эшелоннарның берсен дә калдырмый. Вагоннан вагонга йөреп, сатулашып, солдатлардан кием-салым, консервы, папирос, зажигалка ише

нәрсәләр ала да, шуны базарда көне буе сатып йөри. Әлбәттә, кыйбатрак хакка. Анда акча бар! Станциягә Мәгъсүм дә йөрештерә, ләкин аның да, минем кебек, әлләни куандырганы юк.

Безне Касыйм котыртты. Малайлар, Сарапулга барабыз, ди. Сарапулда аракы заводы бар. Аракы анда, имеш, бик очсыз икән. Биш-алты чирек алып кайтып саттың исә, шундук баеп китәргә була икән. "Чирек" дигәне аның яртысының яртысы, ягъни бернең чиреге була. Баю мәсьәләсенә килгәндә, ул чакта минем иң беренче теләк шул—баю. Баесам, иң элек мин базардан бер буханка арыш эпие сатып алган булыр идем дә, туйганчы эпи ашар идем. Юк, иң элек инәкәйгә алып кайтып бирер идем дә, аны сөендерер идем. Касыймның элек тә баргалаганы бар икән. Юлы унай. Шуңа да аның акчасы күптер әле. Әллә ике мен, әллә өч мен шунда—теге кесәсеннән дә, бу кесәсеннән дә кабарып тора. Мәгъсүмнең дә бераз бар бугай. Минем генә берни юк. Мин инде болай гына, иптәш булып кына, барам. Аннан соң минем әле беркайчан Сарапулны күргәнем юк. Поезда утырып Янавылдан унике чакрымлык Бәдрәшкә дә, егерме чакрымлык Карманга гына барган бар.

Сөйләштек, килештек тә, беркемгә берни әйтмичә киттек тә бардык Сарапулга. Барганда пассажир поезды белән бардык, ахрысы. Ул чагында билет-фәлән алу юк—вагон тоткасына тотындык та, җилгә битне куеп, чак-чак кына куркып, чак-чак кына батыраеп, масаеп, киттек билгесез якка. Янавылдан Сарапулга җитмеш чакрым чамасы. Сарапул үзе Каманың уң ягында, биек яр өстендә утыра. Станция белән шәһәр арасында—бушлык. Шәһәрнең үзенә кадәр өч чакрым чамасы җәяү барасың. Хәзер бу бушлыкка йортлар салынган, шәһәр хәзер станциядән башлана.

Барып җиттек без Сарапулга, шәһәр үзәгенә, базарга. Кая карама—биек-биек таш йортлар. Урамнарына агач бүкән дә җәйгәннәр, юл читләренә такта салганнар. Бик үк тигез түгел—анда бер такта сынган, монда икенчесе селкенеп тора. Элекке заманнан калган икән. Элекке заман калдыгы булса да, кызык. Янавылның баткак урамнары белән чагыштырганда оҗмах инде, оҗмах. Базарларында йөрдек, урамга җәелгән такталарга, биек йортларга карап шаккаттык. Базарда нидер сатып алып ашадык та бугай әле. Сытып чыгарыла торган мороженый, ахрысы. Касыйм өч-дүрт чирек аракы алды. Мәгъсүм дә, мин дә берни алмадык. Анда сугылып, монда сугылып, авызны ачып йөрдек-йөрдек тә, кичкә таба станса ягына юнәлдек.

Станциягә килеп җиткәндә караңгы төште. Ләкин без караңгыдан курыкмыйбыз. Станса безнен өчен иң якын җир. Теләсә нинди поездга утырасың да ике сәгатьтән Янавылга кайтып та җитәсең. Теләсә нинди дигәч тә, безнең өчен иң яхшысы—товарный поезд. Пассажирский да мәшәкатьлерәк—әле проводник килеп чыга, әле контролер очрап куя. Алардан качарга кирәк, түбәгә-нигә менеп китәргә кирәк. Товарныйда рәхәт. Алай-болай кораллы сакчысы гына булмасын. Мина бигрәк тә рәхәт—кул да буш, кесә дә буш, шулай ук корсак та буш.

Сарапулда товарныйларның барысы да туктамый. Дөбер-шатыр килеп, җил-давыл уйнатып узалар да китәләр. Безнен өчен җайлы поезд килгәнен төн урталарына кадәр көтәргә туры килде. Безнең өчен җайлысы бик озын буш состав булды. Көнбатышка күмер, агач-таш төяп барган да, хәзер менә яңадан Янавыл ягына, Себер якларына кайтып бара. Мондый составта кораллы сакчылар да булмый, хәтта тимер юлчылар да сирәк очрый. Күбесенчә алар азаккы вагонда, иң артта утыралар. Янавыл Сарапулдан бәләкәйрәк булса да ыстансысы зуррак. Анда бер генә поезд да туктамыйча узмый.

Без утырасы состав күпмедер туктап торды да, әкрен генә тартылып куйды. Тимергә тимер тиеп шыкылдаган, ышкылган, шыгырдаган тавышлар ишетелде. Без, сөенешеп, тоткалы буш вагоннарның берсенә сикереп мен-

дек, вагон стенасы аша эчкә, тимер идәнгә шуышып төштек.

Поезд чынлап та китте. Станция йортлары, вокзал утлары, будкалар артта кала башлады. Поезд кузгалуын көтеп ары-бире йөреп торганда бер моряк белән бер солдатны күреп алган идек. Икесе дә яшьләр, тазалар. Без малай-шалайлардан икеләтә озыннар. Икесе дә өр-яңадан киенгәннәр. Морягында кара бушлат, озын кара чалбар, башында тасмалы бескозырка. Солдаты яшькелт кительдән, яхшы күнитектән. Башында фуражка иде, ахрысы. Икесе дә өр-яңа погонлы. Безнең өчен иң кызыгы шул. Погоннарның яңа чыккан чагы. Погонлы солдатны әле ул вакытта бик сирәк очратасың. Перронда йөреп торганда, алар яныннан үткәндә, без аларның бигрәк тә погоннарына карыйбыз, погоннарындагы билгеләр буенча солдатмы, командирмы икәнлеген чамаларга тырышабыз. Алар, күрәсең, берәр төрле курсант булганнардыр инде. Ләкин нишләп үз поездларыннан калдылар икән дә, нишләп шулай икәүләшеп кенә йөреп торалар икән?

Иң гаҗәбе шул булды—без утырган вагонның артындагы "пульман" вагонга болар да утырдылар. Безнең кебек тимер тоткага тотынып югары мендeләр дә, идәнгә сикерделәр. Вагонга менгәндә без аларны шулай ук күз кырые белән генә күреп калдык. Шулай да шәп булды әле—димәк, солдатлар белән бергә кайтачакбыз. Кайткач, малайларга, погон күрдек, дип сөйләве ни тора!

Поезд кызулаганнан кызулый. Алда паровозның бик каты көчәнеп, пошкырып, кычкырып чапканы ишетелә. Өскә күмер тузаны коела, борынга ачы күмер төтене керә. Менә Кама күперенә дә життек. Күпергә килеп керү белән, рельсларның, тәгәрмәчләрнең шакылдау тавышы да көчәеп китте, тоташ бер гүелдеккә әйләнде. Баш өстендә күпернең тимер челтәрләре, утлары күренеп кала. Ниһаять, күперне дә чыктык. Паровоз ниндидер тоткыннан котылган сыман, ашкынып, женләнеп чаба да чаба.

Төн уртасы булса да, артык караңгы түгел сыман. Күз дә ияләшкән. Вагонның ике ягыннан да биек нарат урманнары тезелеп бара. Караңгы нарат очлары, куе ботаклар арасыннан аксыл күк кисәге күренеп-күренеп китә. Барабыз шулай селкенеп, шакы-шокы килеп. Сөйләшсәң сөйләшеп булмый, утырсаң утырып, ятсаң ятып булмый. Хәтта тотыныр җай да юк. Кайчагында вагон шундый нык селкетә, тотынган җирдән кулың ычкынып, егылганда чак каласың. Шулай арып-алҗып, ярым йокылы килеш барган чакта күрше вагон ягыннан теге солдат белән моряк килеп чыкты.

Караңгыда болар бөтенләй искәрмәстән килеп чыктылар. Без хәтта куркырга да, сөенергә дә өлгермичә калдык. Икесе ике яктан уратып алдылар да безне, берсе кесә фонарен яктыртты, икенчесе финкасын чыгарды. Финка дигәне аның ике яклы кыска пычак була. Сугыш елларында барлыкка килде. Бәлки, элек тә булгандыр, ләкин без аны шул сугыш елларында күрдек. Аның сабы төрле төстәге ясалма пыяладан коела, пычак белән сап арасында кулны шуудан тоткарлый торган тимере була.

Без аптырап калдык, каушап калдык. Безнең моңа ышанасы килмәде. Шундый яңа, матур өс киемле, шундый шәп погонлы моряк белән солдатның безнеңише өтәләнгән малай-шалайны таларга җыенуы мөмкин нәрсә түгел кебек иде. Бит солдатлар тегендә, көнбатышта фашистлар белән сугыша. Аларга карата безнең хөрмәтебез зур, ышанычыбыз чиксез.

Финкалы солдат Касыймны, фонарьлысы Мәгъсүмне әләктереп алды. Мин ничектер читтәрәк, караңгыдарак калдым. Мондый хәлне күреп мин тагын да читкәрәк шылдым. Күз кырыем белән генә шулай да күреп калдым: Касыймның кесәсеннән аракысын, бер төргәк акчасын тартып алдылар. Шуннан башкасын күрмәдем дә, ишетмәдем дә. Вагонның алгы ягында ниндидер ачыклык бар иде бугай. Мин, ахрысы, шул тар гына ачыклыктан кысылып чыктым да, тамбурдан икенче вагонга кереп киттем. Ул арада Касыйм белән Мәгъсүм дә ничектер итеп тегеләрдән ычкындылар да, алгы

вагонга таба йөгерделәр. Мин аларның ашыгып китеп баруларын гына күреп калдым.

Мин нишләптер алар белән китә алмадым. Көтмәгәндә тегеләр килеп чыкты. Аларны күрү белән, вагон стенасыннан үрмәләп, өскә менеп киттем дә, вагонның тышкы ягына барып чыктым. Тышкы якта, вагонның баш өлешендә, астан өскә тимер тоткалар тезелеп киткән. Тоткалар эчке якта, да булгандыр кебек, хәзер инде хәтерләмим. Күп тә үтмәде, минем арттан тегеләрнең берсе менеп тә житте. Урталай бөгелеп, вагон читенә тотынып минем арттан төшә дә башлады бу. Мин тоткаларның иң астагыларына тотынып торам. Астан беренчесенә чүгәләп басканмын да, икенчесенә ике куллап чытырдатып ябышканмын. Минем хәл бик яман. Әле аска, әле өскә карыйм. Аста аермачык булып жир өсте беленә, юл буендагы телеграф баганалары, метр саен утыртылган кыска рельс баганалар ялт-йолт килеп кала, тимер юл дамбасыннан читтәрак, астарак, кайдадыр караңгыда шомлы урман терәлеп бара, урман буеннан беленер-беленмәс булып арба юлы йөгерә. Рельслар тоташкан турыда тимерләр шакы-шокы килә, тимер вагоннар котырып, женләнеп каядыр алга ыргыла. Кайчагында жир өсте бик якын, якты булып күренә, вагон да әлләни кызу бармый сыман тоела. “Сикеримме? Сикеримме, малайлар?!” дип кычкырам мин жан ачысы белән. Иң дөрес киңәшне, билгеле, алар гына бирә алыр иде. Күрәсең, алар минем кычкырганны ишетмәгәннәрдер дә, ул дөбердектә нинди тавыш ишетелсен?! Зур гәүдәле теге күнитеге белән минем башка тибә, тимер тоткадагы чандыр кулларга тибә.

Мин әле дә төнлә төшләремдә шул каядыр караңгыда чапкан буш вагоннарны күрәм, тимер тоткаларга чытырдатып ябышкан хәлсез малайны күрәм. Әле дә ул шашып, коты алынып “Сикеримме?! Сикеримме?!” дип кычкыра сыман.



*Кучтәвылда Н. Фәттах туган йорт. 1948 елда үзе ясаган рәсем.*

Сикермәдем мин. Теге дә тибеп төшерә алмады. Нәрсәдер тотып калды.

Яңавылга житәрәк таң беленә башлады. Тегеләр, зур станция буласын белеп, каядыр китеп бардылар. Алар киткәч тә мин, вагоннан вагонга күчеп, паровозга таба киттем. Малайлар да шунда тендерда, ягъни паровозның күмер төялгән “арбасында”, күмер өстендә утыралар. Каршыда, астарак, паровоз мичендә кып-кызыл булып күмер яна. Күмер ташлаучы таза урыс малае әледән-әле мич капкачын ача да, көрәк белән мичкә күмер ташлый. Машинист та шунда ян тәрәзәдән карап бара. Без аларга сөйләп бирдек. Алар безне кумадылар, утырыгыз шунда, диделәр.

Яңавылда төшеп калдык. Инде таң ата башлаган. Жир өсте беленә. Инәкәй төне буе көтеп утырган. Макаронлы ашы суынып беткән. Күзгә, колакларга, борын тишекләренә, яка араларына—бөтен жиргә күмер тузаны тулган. Үзем суынган макаронлы куе аш ашыйм, үзем әкрен генә сөйлим. Инәкәй күз яшен сөртә.

*Дәвамы киләсе саннарда.*



Роберт
Миңнуллин

# ШАГЫЙРЬ БУЛУЛАРЫ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ

БЕР ХАТИРӘ

Шагыйрь булулары җиңел түгел. Язучылар берлеге әгъзасы булу бигрәк тә авыр. Дөресрәге, без яшь чакта авыр иде. Ә буласы килә! Бөтен талантлы язучы-шагыйрьләр дә шунда. Аларның һәрберсенең тылсымлы таныклыгы бар. Алар—Литфонд әгъзалары. Алар иҗат йортларына бара ала. Китап чыгарганда да Берлек әгъзаларына яшел җәймә. Әмма Берлек әгъзасы булу өчен шигырь язу гына җитми. Иң беренчесе—китапларың булырга тиеш. Аннары гына шагыйрьләр секциясе сине тәкъдим итә. Әгәр дә секциядән уңышлы гына узсаң, документларың кабул итү комиссиясенә барып эләгә. Анда өч СССР Язучылар союзы әгъзасының сине хуплап язган рекомендациясе булу мәҗбүри. Әгъзаларның исә биш еллык стажлары булырга тиеш. Ә документлар кабул итү комиссиясендә еллар буе да ятарга мөмкин. Бөтенесен дә рәттән үткәрмиләр. Мәхмүт Хөсәен, Мостафа Ногманнарны картаеп беткәч кенә кабул иткәннәре хәтердә. Хәзер Берлек әгъзасы булып йөргән шактый гына иптәшләр ул заманнарда язучылар билеты турында хыяллана да алмыйлар иде. Моның, әлбәттә, һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре булгандыр. Талантлы булсаң да, берәр аксакалга ошамасаң, яисә партия алдында ниндидер «гаебең» булса, Берлеккә алмаска бик тә мөмкиннәр... Шуңа күрә бик түземлелек белән, сабыр гына көтәргә туры килә. Әгәр дә инде кабул итү комиссиясе сине уздыра икән, идарә утырышына әзерләнә башлыйсың. Төп сүзне шунда әйтәчәкләр. Инде идарә әгъзаларының да фатихасын ала алсаң, документларың Мәскәүгә РСФСР Язучылар союзының кабул итү комиссиясенә озатыла... Һәрхәлдә, элекке заманнарда Язучылар союзы әгъзасы булу өчен бик күп сират күперләрен узарга туры килә иде. Марсель Галиевнең әйткән сүзе дә бар шикелле: Союзга керү докторлык диссертациясе яклау белән бер ул! Миңа да әлеге сират күперләрен берәм-берәм кичәргә туры килде. Аеруча шагыйрьләр секциясе утырышы күңелгә сеңеп калган.

Гомумән, җитди заманнар иде ул. Язучылар берлегендә дә эшләр гөрләп бара. Иҗат секцияләренең абруе зур. Шигърияткә изге бер әйбер итеп карау, шагыйрьләр иҗатына принципиаль мөнәсәбәт, аксакалларның саллы сүзләре, яшьләрнең остазларына булган ихтирамлы карашлары, әдәби бәхәсләр нәкъ менә шул чакларга туры килде. Шуңа да карамастан, әдәбиятта бүгенге кебек кәсепчеләр дә җитәрлек иде. Ниндидер юллар белән китапларын да чыгарды алар, союзына да керде...

1976 елның 10 мае иде. Шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышына яшьтәшем Фәннур Сафин белән икебезнең иҗатны куйдылар. Ул чакта инде икебез дә билгеле, яшьләр арасында шактый популяр шагыйрьләр. Икебез дә студент чакта ук «Беренче карлыгачлар»да чыккан егетләр. Минем шул елны гына беренче

китабым дөнья күрде. Фәннурныкы да чыгып ята. Секция җитәкчесе Илдар абый Юзеевның: «Бәлки, Союзга да тәкъдим итеп булыр әле»,—дигән сүзләре күңелләрне кытыклап тора. Халык шактый җыелган. Хәсән ага Туфан үзе килгән. Таягына таянып Нури ага Арсланов утыра. Ап-ак чәчле ике аксакал янында кап-кара чәчле Әхмәт ага Исхак. Татар шигъриятен ул чакта ук тартып баручы урта буын шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Әхсән Баян, Илдар Юзеев, Рәшит Гәрәй... Яшьрәк булсалар да безнең өчен авторитет саналган Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ (ул чакта әле Рәдиф Гатауллин), Равил Фәйзуллин, нәшрияттан Рәис абый Даутов, Батулла (ул чактагы Роберт Батуллин), минем белән «Яшь ленинчы»да эшләгән Хәкимҗан абый Халиков... Безнең кебек үк иҗат белән шөгыльләнүче, әмма әле китаплары да чыкмаган, Союзга да тәкъдим ителмәгән Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Мансур Вәлиев, Әмир Мәхмүдов, Җәүдәт Дәрзаманов, Госман Садә, Наис Гамбәров... Тагын кемнәрдер бар иде. Кемдер безнең хакта җылы сүз әйтергә, кемдер тамаша кылырга, кемдер аяк чалырга да килгән булып чыкты.

Утырышны Илдар Юзеев алып барды. Иң элек миңа сүз бирде. Шигырь укуымны сорады. Анысын гына булдырабыз инде. Ялкынлана-ялкынлана «Таллар», «Тукай минем яшьтә үлгән», «Лорканы үтергән пуля монологы» һәм «Сандугач белән сөйләшү» дигән яңа шигырьләремне укуым истә. Укып бетергәннән соң кул чабучылар табылмады. Илдар абый киләчәккә планнар турында сорашты. Иҗатымны зуррак, саллырак итеп күрсәтерәсе килгәндер инде. Мин яңа шигырьләр язу белән берррәттән, күләмле генә поэма өстендә эшләвемне әйттем. Чыннан да, ул вакытта мин Гакыйл Сәгыйровка багышлап поэма кебек әйбер яза башлаган идем. Аннары балалар өчен «Акбай цирк карый» исемле җыентык әзерләп нәшриятка тапшыруымны да өстәдем. Зурлар өчен дә яңа җыентыкка тотынуымны әйтми булдыра алмадым. Актив эшләгәнемне күрсәтергә кирәк бит инде.

Миннән соң Фәннур «Сез кемнәр?», «Көндәлек» исемле шигырьләрен укыды да «Ак канатлы егет» поэмасына тотынды. Озын булмаган шул поэмасын укып, дөрес тә эшләде. Ни дисәң дә, поэма поэма бит инде ул! Солидно! Равил Фәйзуллиннан башка сорау бирүче булмады. Ул Фәннурдан китабын нәшриятка кайчан тапшыруы белән кызыксынды. Фәннур исә: «Беренчесен 1970 елда, ә 1974 тә янадан бер китап әзерләп нәшриятка бирдем»,—дип чатнатып җавап бирде.

Минем иҗат хакындагы докладны Әхсән абый Баянов сөйләде. Ул—минем якташым. Беренче шигырьләремнән үк күзәтеп бара, киңәшләрен бирә. Һәрхәлдә, мине якын итә. Миннән әйбәт шагыйрь чыгар дип өметләнә. Минем дә бүген бөтен өметем анда. Төп сүзне әйтә бит. Ул үзенең чыгышын язып килгән иде. Мин аның бер өлешен укучыларга да житкерәсем килә.

—Роберт Миннуллин, белүемчә, терсәкләр белән түгел, табигый сәләте, тырышлыгы ярдәмендә эшли. Вакытлы матбугатта чыгып килгән шигырьләре дә, әле күптән түгел басылып чыккан «Бәхетле булыгыз» дигән җыентыгы да—шул тырышлыкның нәтиҗәсе. «Ояла-ояла гына Тукай яшен узып барган» яшь шагыйрьнең дөньяга карашы, үз эшенә, хезмәтенә мөнәсәбәте лирик геройның да характер сыйфатларын, яшәү нормаларын билгели, һәр китапка, бигрәк тә беренче җыентыкка, бөтен җәһәттән коеп куелган, ювелирларча эшләнгән әсәрләр генә керту мөмкин түгелдер. Шунысын да истән чыгармаска кирәк—кем өчендер шәп тоелган әсәрне икенче берәүнең бөтенләй кабул итмәве дә ихтимал бит. Һәр бәядә—күңел халәте, зәвык үсеше, шәхси мөнәсәбәт—субъективлык моменты бар. Бәхәстә критерий—поэзиянең бүгенге үсеш дәрәҗәсе. Ул инде шәхси теләкләр белән, әлбәттә, исәпләшми.

Р. Миннуллин китабында да кемдер кабул итмәслек, кире бәя бирерлек, яки, чынлап та эшләнеп, табылып бетмәгән шигырьләр бар. Бәхеткә каршы андый шигырьләр күп түгел. Киресенчә, бирелеп, сокланып укырлык, самими язылган, саф тойгылы шигырьләр өстенлек итә.

*Керфегеңдә, чәчләреңдә*
*Җылы кар, яңа кар.*

*Әллә соң кызлар урамга*
*Чәчкәнме чулпылар?!*
*Бер-берсенә орынсалар,*
*Валлаһи, чылтырар*
*Көмештәй чулпылар.*

Бу кар чулпыларда табигатьнең матурлыгы да, хатын-кызның сафлыгы да, яшәүнең яктылыгы, гүзәллеге дә чылтырый кебек. Мондый шигырьләрне укыганда, синең күңелгә дә дөньяны сабыйларча ярату хисе йога, күңел ничектер тынычланып, яңарып китә, кичерешләр салмаклана, тигезләнә.

*Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,*
*Сөн суында юган иң элек...*

яки

*Без әнкәйнең биш шатлыгы булдык,*
*Биш кайгысы булдык кайчакта.*

Бу юллар да күңелне яшәү матурлыгына, балаларча яратуга көйли.

*Җир бәхеттән оеп ята—*
*Ак әкият, тылсым инде!*
*Бу аклыкта, кулы барып,*
*кем яманлык кылсын инде!*

Табигать аклыгы шагыйрьнең, кешенең саф хисләре белән берләшә. Туган җир сурәте, бала чак, яшьлек хатирәләре тантаналы тынычлык булып гәүдәләнә. Кешене гел борчып, ярсытып кына торырга димәгән бит, аның җанына матурлык элексиры сирпеп, ял да бирергә, яшәүгә яна көч өстәргә дә кирәк ләбаса! Роберт Миңнуллинның үзенә дә, шигырьләренә дә шундый сыйфат бирелгән. Ул артык борчылмаса да, барыбер уйлана, кичерә, ләкин матур хатирәләрнең кадерен, тәмен дә белә.

Хатирәләрнең шигырьгә әверелүе—иң табигый хәл һәм, әйтер идем, шагыйрьгә җиңелрәк бирелә торган, күпмедер дәрәҗәдә җайлырак хәл итела торган нәрсә. Ә менә бүгенге хәлләрне күреп, туа гына башлаган тойгыларынны тәртипкә китереп, аларны риторикага, өстән-өстән генә язылa торган тасвирламаларга кайтарып калдырмау өчен тәмам җитлеккән шагыйрьгә дә гаять күп көч түгәргә, газап кичерергә туры килә. Бүгенге көн күренешләрен чын сәнгать фактына әвереллдерә алу табигый сәләт, профессиональ өлгергәнлек хакында сөйли. Мәсәлән, Робертның Әрмәнстанга бару тәэсирендә язылган шигырьләре шул хакта уйларга мәҗбүр итә. Алар публицистика түгел, эскизлар да түгел, чын, тирән шигырьләр.

Шагыйрьнең профессиональ яктан үсешен, ә лирик геройның гражданин буларак өлгергәнлеген расларлык юлларның барысын да санап чыгу мөмкин түгел. Шуңлыктан кайберләренең исемнәрен генә атау белән чикләнергә туры килә: «И изге йорт», «Ахак учак», «Базыда бозлар ага», «Малайлар», «Элекке «Англетер» гостиницасында», «Кларага», «Көз инде», «Ярый әле» һ. б.

Билгеле булганча, язу манерасы, стиль ахыр чиктә шулай ук характер сыйфатларына килеп тоташа. Р. Миңнуллинда стиль алымнары төрле, ә күзгә ташланып торганы—афоризмга охшашлык. «Яхшылыкка тик яхшылык...», «Беребез дә алдан белә алмый», «Дөнья бит ул», «Мәхәббәт» кебек шигырьләре шундыйлар рәтенә керә. Алар халыкчан, гадилек белән аерылып торалар.

Шагыйрь халык, ил, җир хакында заман проблемалары зурлыгын тоеп фикер йөртә. Ул шигырьләрне укып чыккач, якты хисле, тыныч холыклы тыйнак кеше образы күңелдә кала.

*Аптырыйсыз. Әйтерсең лә*
*Андыйлар бер без генә.*
*Әйбәтме, әйбәт түгелме—*
*Шундый инде без менә.*

Минемчә, андый булу әйбәт. Кирәгеннән артык дәгъвалы кешеләр күбәйгән вакытта тыйнакларның кадере бермә-бер арта.

Аерым юллар, строфалар, бөтен шигырьләрнең дәрәҗәсен күтәрә алырлык: «Берәүләрне Алып итә, тик барыбер алып китә—дөнья бит ул», «Сагышыннан сары чәчәк аткан каберендәге сәрби куагы», «Уйланырга куркып басып торам» (Есенин үлгән гостиницада), шулай ук тайларның кояшны тешләмәкче булып ыргылулары һәм башка шундый кызыклы тәгъбирләр, язу осталыгы хакында сөйләү белән бергә, яхшы күңелле, сизгер, эшлекле лирик геройның—совет кешесенең—матур сыйфатлары булып та гәүдәләнәләр."

Әхсән абыйның иҗатыма карата әйтелгән җитди сүзләре мине канатландырып җибәрде. «Союзга алырга кирәк!» дигән сүзләрне дә ишеткәч, бөтенләй эреп киттем. Каушаулар, дулкынланулар да бераз басылган шикелле булды. Аның ул чакта әйткән җылы сүзләрен, шигырьләремә биргән югары бәясен мин әле дә күңелемдә саклыйм. Яшь вакытта, бигрәк тә секция утырышында, аксакаллар, яшьтәшләр янында, синең әдәби язмышың хәл ителгәндә әйтелгән мактау, хуплау сүзләре ул, чыннан да, гомергә истә кала икән. Югыйсә, өлкән шагыйребез анда шактый гына тәнкыйть сүзләре дә әйткән иде. Ләкин кимсетмичә генә, акыллы итеп, ышандырырлык итеп.

Фәннур турындагы беренче сүзне мөхтәрәм Әхмәт ага Исхак әйтте. Ул да минем яшьтәшемне яратып, аның иҗатын күтәреп сөйләде:

—Ф.Сафинның «Ак канатлы егет» поэмасыннан башлыйсым килә. Әсәрне бик яратып, бирелеп укып чыктым. Шундый җылы хисле, зур җаваплылык тоеп язылган бу поэмада нидер җитеп бетми кебек. Әсәр героеның җанын күрәсе килә. Данга лаек булырлык ни кылган, ни эшләгән ул? Моның өчен әсәргә бик аз гына кул кертәсе бар: һәммәсе үз урынына басар. Гомумән әйткәндә, егет талантлы. Аның лирик шигырьләре, табигать һәм мәхәббәт турында, ил һәм халык язмышы турында язылган әсәрләре миндә соклану тудыра. Мисалга «Яз» шигырен алыйк. Ул миңа бик ошады. Менә бу юллар—искиткеч матур шигъри юллар.

*Чирәм көтә*
*малайларның*
*яланаякларын,*

яки

*Карап тора бөреләрдән*
*язның яшел күзе.*

Димәк, шагыйрь уйлый белә, чын шигырь детальләре белән эш итә. Ә аның мондый чын әсәрләре күп.

Соңгы вакытта язылган әсәрләрендә Фәннурның фикер һәм осталык ягыннан тагын да бер адымга үсүен күрәбез. Моны КамАЗ турындагы поэмасы раслый. Шундый әйбәт шигырьләрнең китап булып чыкмавы үкендерә. Бу эшне тизрәк җайга саласы иде.

Шулай да яшь шагыйрьнең әсәрләрендәге кимчелекләргә күз йомып үтәргә ярамый. Нигездә алар зур, куркыныч кимчелек түгелләр. Күбесе тел, стиль кимчелекләре. Мәсәлән, «юлчым» түгел, бәлки «юлдашым»дыр. Шигырьләрендә ритм, рифма төгәл, ипле. Алар әзер, стандарт булмаулары белән куандыралар.

Кыскасы, китапны берсүзсез чыгарырга кирәк. Аннары талантлы яшь шагыйрь

Ф. Сафинны, минемчә, Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәргә бик вакыттыр. Мин, һәрхәлдә, шулай уйлыйм.

Шулай итеп, ике докладчы да безгә унай бәя бирде, икебезне дә Союзга тәкъдим итте. Икебез дә бик тә канәгать булып, бер-беребезгә карашып алдык. Эшләр шәп, янәсе. Әмма бу әле секция утырышынын башы гына иде. Илдар абый докладчыларга рәхмәт әйтте, аннары «фикер алышуларга күчәбез» диде. Иң беренче булып, әлбәттә инде, безнен аксакалыбыз Хәсән ага Туфан сүз алды:

—Роберт Миннуллинга килгәндә, мин аны күптән беләм. Иҗаты белән кызыксынып барам. Шигырьләренә ритмик төгәллек хас. Бу яктан ул ритмик белемле. Ә инде таләпчәнлек күзлегеннән караганда, анын иҗаты мине бик үк канәгатьләндереп бетерми. Дингез турында шигырь язгач, ул әсәр үзе дә дингезгә охшарга тиеш. Монда мин дулкынландыра торган юл тапмадым. Югыйсә, шигырь камил кебек. Кояшны да әнис алмасы белән генә чагыштырып булмыйдыр. Кояш турында башкачарак, ялкынлы әсәр язарга кирәк иде. Робертнын мәхәббәт турындагы шигырьләре дә, нигездә, әрнүле, сагышлы мәхәббәткә кайтып калган.

Есенинга багышланган шигырен алыйк. Автор шагыйрь үлемен салкын фаҗига дип, аны аклап та, яклап та булмый дип күрсәтә. Шагыйрьнен җанын, рухын анламыйча шигырь язган, һәм ул әсәрне дөньяга чыгармау яхшырак булыр иде кебек. Ә Лорка турындагы шигырьне сыйнфый позициядән торып язарга кирәк булгандыр...

Хәсән ага тагын нindидер сүзләр әйтте, шигырь техникасы турында сөйли башлады. Туфан тиклем Туфаннан үз иҗатын турында фикер ишетү, әлбәттә, яшь шагыйрь өчен олы мәртәбә иде. Шуна күрә дә анын тәнкыйте дә мина олы мактау булып ишетелде. Чын күнелемнән әйтәм. Аннары ул соныннан барыбер мине Союзга алу ягында булуын әйтте. «Роберт ул ритмик яктан төгәл яза. Әхсән Баяновнын унай бәя бирүе белән, анын фикере белән килешәм»,—дип тә өстәде. Алгарак китеп тагын шунысын да әйтим, минем Союзга алгандагы идарә утырышында Хәсән ага, киресенчә, мина унай яктан гына бәя биреп: «Мин Робертнын шигырьләрен студент чагыннан ук укып киләм. Җыентыгы да чыкты. Гомумән, әйбәт китап. Әз генә кайнау җитми. Язганда күз яше чыгарлык булсын. Янарга кирәк. Ирекле шигырьләре әз-мәз бар. Алардан саклансын. Ә менә балаларга язганда ул балаларча уйлый белә. Бик матур шигырьләр»,—дигән иде.

Туфаннын Фәннур Сафин турындагы сүзләре дә тәнкыйтьлерәк булды:

—Аны без берничә мәртәбә секциядә тикшергән идек инде. Дөресен әйтик, яхшы әйберләре бар. Ә инде бу поэмасына килгәндә, монда ритмик төгәлсезлеккә юл куелган. Ирекле шигырьне ритмиканы сиземләү сәләте булмаган кеше генә яза бит. Тукай бүгенге көндә яшәсә, болай язмас иде, башка язу алымын табар иде. Шигъри әсәр буларак, монда мин мәгънә тапмадым. Фәннурнын бер адым артка чигенүе мине борчый, гаҗәпләндерә. Зур әйберләр, тирән эчтәлекле әсәрләр язарга сәләтле егеткә болай эшләү ярамый.

Рөстәм Мингалимов та секциягә җентекләп әзерләнеп килгән иде. Ул яшьтән үк оригинальлекне ярата торган, уйлаганын яшермичә турыдан ярып әйтә торган, бер генә чыгышында да тәнкыйтьләми калмый торган шагыйрь иде. Бу юлы да шулайрак булды. Икебезне дә бетереп ташлады, аеруча Фәннурга эләкте:

—Әхмәт абый Фәннурнын китабын җентекләп тикшереп килгән. Анын байтак фикерләре белән килешәм. Ләкин шуны әйтергә тиешмен: әллә сез әдәбиятны бөтенләй укып бармыйсыз? Инде күптән билгеле булган матур юлларга кызыгасыз.

«Язнын яшел күзе»—бу юлларны мин зур ачыш дип саный алмыйм. Ул бит башкаларны кабатлау гына. Чын дөресен әйткәндә, Фәннурнын үзенеке генә булган шигырьне табуы читен. Безнен поэзиягә болай килеп булмый, һәркем үз юлын тапсын. Союзга алырга ашыкмаска кирәктер. Икенче китабынын чыгуын көтик. Бу яктан алганда, Марсель Галиев белән Эдуард Мостафин кызыклырак. Алар, беркемне дә кабатламыйча, үзләре язарга омтылалар. Ялгышудан курыкмыйлар.

Робертка килгәндә, егет салкын кан белән эш итә, дияр идем. «Без кемнән ким

әле» шигырен алыйк. Анда язылганча, шул хәтле тыныч яшәргә була микән? Акыл белән яза. Иң мөһиме—эзләргә, табарга кирәк, һәм ялгышудан да курыкмаска кирәк.

Ә инде егетне Союзга алуга килгәндә, мин каршы түгел. Диалектика законы буенча сан үсеше сыйфат үсешенә китерә.

Рөстәмнең чыгышыннан соң безнең кикрикләр шинә башлады. Аркалар тирләп чыкты. Ул минутларда мин үземне дөньядагы иң бәхетсез, иң пүчтәк бер шагыйрь итеп тойганмындыр, мөгаен. Фәннурның да карарлыгы калмаган иде. Тәнкыйтьләсә тәнкыйтьләсен иде, бер сүз дә юк. Иң ачу китергәне—безне Марсель, Эдуард белән чагыштырып сөйләве булды. Аларга да чират җитәр, аларның да иҗатлары секция утырышында тикшерелер. Шул чагында мактаган булыр иде... Нури ага Арслановның гөрелдәвек тавышы гына айнытып җибәргәндәй итте:

—Рөстәмнең сүзе дә, гәрчә үзен башкачарак позициядә тотса да, дөрес. Күзгә карап, төгәл итеп әйтүләр дә кирәк. Шагыйрьне гел генә мактап сөйләсәләр, ул тынычландырыр иде. Битарафлыкка этәрер иде. Бу яктан, әлбәттә, Рөстәм хаклы. Хәсән абый да хаклы. Тик ул да таякны тоткан урыныннан сындырмакчы булып, артык кистереп әйтте.

Әйе, мондый чыгышларда кимчелекләрне күпертеп күрсәтүләр була. Ләкин егетләрнең уңышлы яклары алдында да күзне йоммаска иде. Мисалга Робертның «Тайлар» шигырен алыйк. Никадәрле динамика, никадәрле киеренкелек! Чын шигырь өчен кирәк булганның бөтенесе бар. Шул тайларга карт атлар кызыгып, көнләшеп карап торалар, ди автор. Хәсән абый, шул карт атлар без түгел микән? Егетләрнең кимчелекләрен күрүдән элек, уңышларына сокланасы иде, фатиха бирәсе иде.

Хәсән ага Туфан түзмәде: «Менә бу шигырь, чыннан да, нәкъ безнеңчә!»—дип соклануын белдереп алды.

Н. Арсланов дәвам итте:

—Мин «Казан утлары»нда эшләгән чорда берсеннән-берсе талантлы егермеләп автор күтәрелеп чыкты. Никадәрле ялкын иде аларда. Аларның йогынтысы мина да тимичә калмады. Шулар арасында Фәннур Сафин белән Роберт Миннуллин да бар иде. Әхсән әйткәнчә, Роберт тыйнак егет. Әмма гел тыйнак кына булмаска иде. Күбрәк ут булу кирәк безнең заманда.

Фәннурның бер характерлы сыйфатын әйтеп үтмәкче булам: ул журналга килгәч, безнең матур гына сөйләшеп килгән сүзебез шактый күңелсез бетә иде. Хикмәт шунда, ул шигырен төгәлли белми иде. Хәзер исә, дөресен әйтик, егет бу кимчелектән котылды. Үсешкә иреште. Чын мәгънәсендә шагыйрьгә әйләнде.

Егетләрнең иҗатына башка шагыйрьләр йогынтысы булуны кимчелек итеп күрсәтергә ярамый, һәр шагыйрьдә тәэсирләнү була. Мәсәлән, Илдар Юзеев Такташка ияреп килде. Ә бүген ул бөтенләй башка, яңа юл белән үсеп китте. Димәк, иҗади иярү—объектив күренеш. Мин аны мөмкин хәл һәм хәтта кирәкле дип саныйм.

Шулай итеп, мин ике иптәшнең дә иҗатына хәерхак. Аларга бәхет, уңыш телим. Икесе дә безнең сафка, Союзга керергә хаклы дип саныйм.

Нури аганың чыгышыннан соң без Фәннур белән җиңел сулап куйдык. Ул елларда аның абруе яшьләр арасында ифрат дәрәҗәдә зур иде. Озак еллар «Казан утлары» журналының поэзия бүлегендә эшләгәнлектән, барыбыз да аңа килә идек. Ул үзе дә яшьләргә игътибарлы булды, бервакытта да ярдәменнән ташламады. Булырдайларыбызның шигырьләрен бастырып барырга тырышты. Шул ук вакытта турысын да әйтә белә иде. Бу юлы да шулай булды. Безне җәберләргә ирек бирмәде.

Фикер алышу барышында Фәннурның нәшриятка тапшырылып та һаман чыкмый ятучы китабы турында да сүз күтәрелде. Шуңа күрә ул чакта нәшриятның бүлек мөдире булып эшләгән Шәүкәт абый Галиев аңлатма биреп китүне кирәк тапты: «Нәшрият вәкиле буларак, белешмә йөзеннән шуны әйтим. Без Фәннурның китапларын әзерләдек. Иптәшнең фотосы да бар. Әхсән Баян кереш сүз язды. Китап

редакцияләнгән. 77нче елның башында производствога бирербез, дип өмет итәбез. Чөнки башка мөмкинлек юк», диде ул. Аннары минем иҗатка тукталды. «Бәхетле булыгыз» китабы турында җентекләбрәк сөйләде. Бигрәк тә балалар өчен язылган шигырьләремә югары бәя бирде. Секция утырышы алдыннан гына ул «Акбай цирк карый»ның кульъязмасын карап, үзенең унай фикерен үземә дә әйткән иде:

—Моннан җиде-сигез еллар элек Роберт Миңнуллин шигырьләре яшь язучыларның республика семинарында тикшерелгән иде. Ул чакта яшь авторның үзенчәлекле, табигый сәләте, ихлас шигырьләре күңелгә хуш килеп, киләчәгенә өмет баглаткан иде. Моннан соң үткән арада Роберт сабыр гына, төпле генә үсте, осталыгы артты, үзенә ышанычы ныгыды. Шактый сайлап, үзенә таләпчән булып әзерләнгән «Бәхетле булыгыз» исемле китабында яшь шагыйрьнең иҗат йөзен күзалларлык шигырьләре тупланган.

Соңгы вакытта мине Роберт иҗатындагы яңа сыйфатлар сөендерә: лирикасына бик мөлаем, табигый булып юмор кушыла башлады. Мөгаен, юморга тартымлык аны балалар әдәбиятына китерәдер—ул балалар өчен дә яза башлады һәм бу өлкәдә мин аңа зур өметләр баглыйм. Эзләнүләре тагын да нәтиҗәлерәк, табышлары тагын да зуррак булыр, Роберт бу жанрда да әле иркенләп бер ачылып китеп эшләр дип ышанам. Бу өлкәдә эшләүче яшьләр бик сирәк килә, булганнары да киң колач белән ачылып китә алмыйлар. Ә Робертның балалар өчен әзерләнгән җыентыгыннан күренгәнчә, аңарда чын балалар шагыйреннән көтелгән төп сыйфатлар бар: балаларны ярата, аңлый, алар "дулкынына" көйләнә белә. Туган телнең нечкәлекләрен, тәмен тоя. Балалар өчен әзерләнгән бу җыентыгын мин нәшриятка тәкъдим иттем һәм авторны яңа яктан күрсәтүдә беренче лирика китабыннан бер дә ким булмас дип уйлыйм.

Роберт Миңнуллин безнең күз алдында житди әзерлек чоры үтте, төрле жанрларда кыю иҗат итү чорына керде. Мин моны өлгерү, мөстәкыйльлек билгеләре дип саныйм.

Шулай итеп, Шәүкәт абый минем иҗат турында өздереп, ышанычлы итеп әйтте. Секция утырышына мине дә, Фәннурны да яклап чыгыш ясарга әзерләнеп килүчеләрнең берсе ул булса, икенчесе—Рәдиф Гаташ иде. Безнең иҗатларыбызны яхшы белә. Минем «Бәхетле булыгыз» китабына уңай рецензия дә бастырып чыгарды. Үз сүзен әйтә белә торган, кирәк чакта гайрәтләнеп нотык тотучы, яшьләр иҗатына бик тә игътибарлы Гаташның чыгышы шулай ук күңелләргә сары май булып ятты:

—Минем Роберт турында ныклы уй-фикерем булганга, иҗатын яхшы белгәнгә күрә түбәндәгеләрне әйтәсем килә. Хәер, Әхсән абый да үз фикерен яхшы итеп аңлатты. Төпле һәм ышандырырлык итеп. Робертның китабы турында фикерем тулаем әйбәт. Ә инде аның редакторы булсам, мин кайбер әсәрләрен кертмәс идем.

Шагыйрьне мин бер урында таптана димәс идем. Моны аның соңгы вакытта язылган шигырьләре раслый. Роберт үсештә, әйтергә кирәк, иҗатында тагын бер баскычка югары күтәрелгән.

Характеры белән тыйнак булса да, иҗатында битарафлык күренми. Тормышка фәлсәфи күзлектән карый белә, уйлап, җентекләп яза. Киләчәктә уңай сыйфатлары тагын да үсәр, дип ышанам.

Рөстәм: «Робертта да, Фәннурда да яңалык күрмим, башкаларны кабатлыйлар», —диде. Гомумән, без үзебез һәрвакыт оригиналь әсәрләр генә иҗат итәбезме? Ныклап уйлап карасаң, аларның күбесе һәм, Рөстәм, синең әсәрләр дә—дөнья әдәбиятында яңалык түгел, күптән билгеле әйберләр. Бүген аларның иҗат отчетлары куелган икән, бу үзе егетләрнең күп нәрсәгә лаек булуы турында сөйли.

Фәннур турында. Мин үзем аның иҗатын якын күрәм. Ә инде «Ак канатлы егет» поэмасын һич кенә ыргытып ташлый торган әсәр дип уйламыйм. Бу поэманы Сибгат абый да бик яратып кабул итте. Һәм Фәннурны да Союзга кабул итәргә кирәк дип уйлыйм. Чөнки ике китап әзерләп бирү үзе күп нәрсә аңлата. Мин аларны безнең сафка алуга шатланып риза.

Аксакаллардан соң яшьрәкләр дә берәм-берәм сүз ала башлады. Поэзия секциясе утырышларының берсен дә калдырмаган, һәрберсендә үз фикерен әйтә килгән, безнең өчен ул чакта ук инде классик булган Мөдәррис Әгъләмов та үз фикерен әйтми булдыра алмады. Шактый буталчык итеп сөйләсә дә, ахырдан, барыбер, икебезне дә яклап чыкты:

—Роберт иҗатын кабул итәргә дә, итмәскә дә мөмкин. Чөнки ул зәвыкка бәйле. Аның китабын укып чыккач, үз бүрегенә карап акыллы гына сөйләп утыручы карт күз алдына килеп баса. Ул бер дә ялгышмый, гел дөресен сөйли.

Лоркага багышланган шигыре турында сүз булды. Роберт шагыйрь тормышының асылына үтеп керсә, аны халык язмышы белән бәйләсә, үзебезнең җирлек белән үреп бирсә, без анда Робертны күрер идек.

Фәннур турында. Мин аны электән үк белеп, иҗаты белән кызыксына киләм. Биредә поэманы аңламаучылар булды. Ә бит автор бу әсәрендә бүгенге геройның рухи халәтен ачып бирә. Әсәрнең эчтәлеге әнә шунда.

Бу егетләр эшләрен яхшы эшлиләр. Җәмәгать эшендә актив катнашалар. Икесен дә Язучылар союзына тәкъдим итәргә кирәк.

Яшь тәнкыйтьче, безнең яшьтәш Мансур Вәлиев исә: «Безнең шагыйрьләр хәзер шома язарга өйрәнделәр. Ләкин шигърияткә шома гына килү күнелсезлеккә китерергә мөмкин. Мин моны Роберт белән Фәннурга карата гына әйтмим. Бу сүз, гомумән, үземнең яшьтәшләремә кагыла»,—дип безгә сабак өйрәтеп алды. Әмма беребезнең иҗаты турында да конкрет бер фикер әйтмәде. Гомумән, утырышта катнашкан калган чордашлар дәшми генә тамашачы ролендә утырдылар, һәрберсе үзен уйлап, гыйбрәт алып утыргандыр инде. Аларның да киләчәктә без кичергәннәрне кичерәселәре, без күргәнне күрәселәре булачак бит әле. Ә менә Хәкимҗан абый Халиковны әле күптән түгел генә Союзга алдылар. Без аның белән бер редакциядә, бер бүлмәдә утырып эшлибез. Бер-беребезнең иҗатын яхшы беләбез. Минем өчен бик борчылып, чыгыш ясарга әзер булып килде. Тулы хокуклы Союз әгъзасы буларак та, минем хезмәттәшем буларак та, бик җентекләп чыгыш ясады ул:

—Роберт Миңнуллинның китабын мин дә яратып, яшь шагыйрьнең шигырьдән шигырьгә үсә баруын күреп, сөенеп укыдым. Автор тырышып эзләнә, шигъри фикерне кыска, җыйнак формада бирергә омтыла. Шигырьләрнең тематикасы да шактый киң. Бу турыда Әхсән дә, чыгыш ясаган кайбер иптәшләр дә әйттеләр. Шунлыктан минем Роберт Миннуллин иҗатының икенче ягына, аның да балалар поэзиясенә караган өлешенә тукталасым килә.

Роберт университетны тәмамлаганнан бирле «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли. Балалар газетасында эшләү, балалар белән аралашып яшәү аны балалар өчен дә язарга мәҗбүр итте. Робертның урта яшьтәге балалар өчен язган иң унышлы шигырьләре «Безнең бәйрәмнәр» дигән җыентыкка кертелде. Бу шигырьләр әлеге җыентыкны бизәп торалар, дияр идем мин. Поэзиябездәге политик шигырьләрнең шактые әле дә риторикадан котыла алганы юк. Роберт исә андый шигырьләрне дә образлы итеп, поэтик детальләр белән язарга омтыла. Яшь шагыйрь хәзерге укучының зәвыгын яхшы белә: аны инде риторик шигырьләр канәгатьләндерми. Ул нәниләр өчен дә иҗат итә. Аның мондый шигырьләре «Ялкын» һәм «Яшь ленинчы»да да урын алды. Нәшриятка тапшырган «Акбай цирк карый» китабындагы күп шигырьләр миндә унай тәэсир калдырды. Шуларның кайберләре: «Кеше карап тормагач», «Кычыткан» һ. б. күп кенә әсәрләре.

Яшь иптәшкә киңәшем шул: балалар өчен язуын дәвам итсен иде, алар өчен дә өлкәннәр өчен язган шигырьләре кебек кыска, конкрет, тагын да образлырак һәм җылырак итеп язсын иде. Ә язган кадәресенең иң яхшыларын туплап (кайбер шигырьләрне төзәтеп) кечкенә генә бер җыентык чыгарганда балаларыбызга зур бүләк булыр иде.

Сүз уңаенда Робертның марксизм-ленинизм университетында укуын, «Яшь ленинчы» газетасы хезмәткәре буларак, яшь сәләтләргә зур ярдәм күрсәтүен дә әйтеп үтәсе килә.

Ф. Сафин турында ике сүз. Аның хакында бүген төрле фикерләр әйтелде. Ә бит

Фәннур сәләтле, эзләнүчән шагыйрь, шигырьдән шигырьгә үсә бара. Җыентыгы никадәр тизрәк чыкса, шул кадәр яхшы булачак. Бу китап аны тагын да дәртләндерер һәм канатландырыр иде. Очу өчен, күккә күтәрелү өчен кошка канат кирәк. Ә шагыйрьнең канаты—яхшы шигырь, яхшы китап.

Сүземне йомгаклап шуны гына әйтәм, мин шагыйрь егетләрнең икесен дә СССР Язучылар союзына член итеп алу ягында.

Әмир Мәхмүдовның сүзләре дә истә калган:

—Сөйләшү күп булды. Мөдәррис Әгъләмов хәтта Роберт иҗатын үз бүрегенә карап сөйләнеп утыручы карт фәлсәфәсе дип атады. Ләкин мин алай димәс идем. Робертның үз алымы бар. Ил язмышы, җир язмышы турында уйлана. Тирән мәгънәле, эчтәлекле шигырьләр язып килә. Унай якны да күрә белергә кирәк. Х. Туфан Фәннурның поэмасын иректе формада язылган, диде. Ә бит хәзерге поэзиядә һәр ике стиль яши. Шагыйрь нинди формада язса да, таләп бер генә: яхшы әсәрләр иҗат итсен. Әгәр Тукай бүген исән булса, ул, әлбәттә, поэманы болай язмас иде. Башка ысул, алым табар иде. Әмма Тукай, барыбер да Тукай булып калыр иде.

Минемчә, ике иптәшне дә Союзга тәкъдим итәргә кирәк.

Равил Фәйзуллин ул чорда Язучылар союзы секретаре булып эшли иде. Аның чыгышын мин бик аңлап бетермәдем. Ул чын җитәкчеләр тавышы белән, ни өчендер ризасызлык кыяфәте чыгарып, кискен тонда сөйли башлады:

—Капма-каршы кискен фикерләр әйтелсә дә, сөйләшү матур бара. Эшлекле сөйләшү бу. 72 нче елда дөнья күргән «Зәңгәр кабырчыклар» китабы белән «Бәхетле булыгыз»ны чагыштырып карыйм. Кайсы өстен? Һәрхәлдә, Разилнең китабы Робертныкыннан ким түгел. Ә әдәбиятка шаулап килеп кергән Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмов белән чагыштырганда, Роберт алардан бер баш түбән, күпкә кайтыш. Разил Вәлиевнең монарчы Союзга тәкъдим ителмәве гаҗәпләндерә.

Бу сүзләргә Илдар Юзеев та аптырашта калды һәм тиз генә аңлатма бирүне кирәк тапты:

—Мин аңа моннан өч ел элек рекомендация биргән идем. Эш Язучылар союзы идарәсенә кайтып кала. Союз секретаре буларак, бәлки, үзегез аңлатып бирерсез?

Ләкин Р. Фәйзуллин җавап биреп тормады, мине тәнкыйтьләвен дәвам итте:

—Роберт поэзиягә үз юлы белән килде дигәнгә ышанып җитә алмыйм. Шактый шигырьләре шома, гамьсез. Тема берлеге: әнисе, Сөн, Базы елгалары. Алар хакында китапта күпме шигырь табып була!

Робертны монда күпләр тыйнак диделәр. Фәннур аңа караганда тыйнаксызлыр, шуңа китабы чыкмый ята торгандыр.

Гражданлык поэзиясен дөрес аңлыйбызмы? Газетада бәйрәм унае, нинди дә булса политик вакыйга унае белән чыккан шигырьләр генә гражданлык поэзиясе була алмый. Бу яктан Роберт өлгер: бәйрәм саен шигырьләре чыгып кына тора, рәсем астына да шигырь язудан баш тартмый. В. Хара турында йөзләгән кеше язды. Роберт шуңа өстәп нәрсә әйтте соң? Шул ук гитара, канлы стадион... Башка берни юк. Чит җирләргә барып кайтып кына да шигърияткә күп нәрсә өстәп булмый. Робертта зур бер сыйфат бар, билгеле: ул соклана белә. Әнә шулай гел шома гына барса, белмим, киләчәге ничек булыр? Хәзер фәндә «тизләтелгән метод» дигән термин кин кулланыла. Без иптәшне Союзга алсак, әлбәттә, ул аның үсешен тизләтер. Чөнки соңгы елларда Союзга алынучылар саны нык кимеде.

Союзга Разилне, Фәннур белән Робертны тәкъдим итәргә кирәк!

Равил Фәйзуллиннан соң Әхмәт Исхак тагын сүз сорады:

—Союзга алу мәсьәләсе читен һәм ул озак вакыт хәл ителә. Комиссия дә китапның чыккан булуын таләп итә. Документларны әзерләгән арада Фәннурның китабы чыгып җиткән булыр. Шуңа күрә бу эшне сузмаска кирәк.—диде ул.— Мондый бәхәсле, капма-каршы фикерле секция булганы юк иде. Татар поэзиясендә бер чорда яшәгән төрле шагыйрьләр бар: Тукай, Дәрдмәнд, Бабич, С. Рәмиев һ. б. һәркайсы үзенчә язган, һәркайсының әдәбиятта үз урыны. Шуңа күрә һәркем хәленнән килгән кадәр иҗат итсен. Кемнең нәрсәгә сәләтле булуын тормыш үзе күрсәтер. Шуңа күрә, әйдәгез, беркемгә дә үз фикеребезне көчләп такмыйк.

Хәсән ага Туфан әлеге сүзләрне үз адресына алды бугай—шунда ук реплика ташлады:

—Һәр поэзиядә бер генә система булырга тиеш. Бер әдәбиятта әллә ничә система яши алмый. Бу система бездә—традицион, ритмлы шигырь системасы.

Яшь иптәшләргә кискен әйтүемнең сәбәбе—мин битараф, читтән күзәтүче түгел. Шунлыктан фикерләрем изге нияттән чыгып әйтелде.

Шушының белән фикер алышулар тәмамланды. Мин килгән иптәшләргә аксакалларга, урта буын шагыйрьләргә, үз фикерләрен әйтүчеләргә рәхмәтемне житкердем. Чыннан да, тәнкыйть сүзләре дә, мактаулары да урынлы булды. Бу сөйләшү безнең икебез өчен дә бик кирәкле, бик вакытлы иде. Миңа кушылып, Фәннур да рәхмәт сүзләрен ирештерде.

Соңгы сүзне Илдар абый әйтте:

—Дөресен әйтик, бик файдалы сөйләшү булды бу. Күпләр өчен гыйбрәтле сөйләшү. Классикларга гына куела торган таләпләр куелды.

Әйе, Роберт китабына кереш сүзне мин яздым. Мин анда аны зур шагыйрь дип атамадым, бәлки өметле, язган кадәрлесе өметле дип телгә алдым. Хәзер дә шулай уйлыйм. Киләчәктә нинди юнәлеш белән үсәр, бусы бары тик Робертның үзенә генә бәйле. Язучылар союзына беркайчан да зур шагыйрьләр булып килмәделәр. Мондый хәл булса да, сирәк күренеш... Егетләрне Союзга алу кирәк, иҗатчы тик Союзда гына тәрбияләнә, язучы булып формалаша.

Фәннур турында. Аның китабы күптән чыгарга тиеш иде инде. Бүгенге сөйләшүне дә истә тотып, шагыйрь җыентыгын тагын да сыйфатлырак итеп чыгарыр дип уйлыйм. Поэмасына килгәндә, мин Фәннурның талантлы булуына тагын бер тапкыр ышандым. Өметемне аклады. Нигездә, әйбәт поэма ул. Кимчелеге шунда—әсәрнең башы бераз буталчык. Конкрет тормыш детале кирәк. Поэманың ритмикасы турында бәхәс булды. Мин, мәсәлән, үзем мондый ритмиканы кабул итәм.

Кыскасы, ике егет тә сәләтле. Мондый егетләрдән башка Союз үсә алмый. Шуңа күрә, минемчә, сәләтле яшьләрне язучылар сафына алуны җайга салырга кирәк.

Утырыш ахырында икебезне дә СССР Язучылар союзына тәкъдим итү тавышка куелды. Тәкъдим бер тавыштан расланды. Яшь шагыйрь Разил Вәлиевнең иҗат отчетын секция утырышына кую турында да карар кабул ителде...

Менә шулай шаулап-гөрләп узды ике яшь шагыйрьне Союзга тәкъдим итү җыелышы. Ул чакта безнең икебезгә дә егерме сигез яшь булган. Аннан соң инде бик күп сулар акты, бик күп шигырьләр язылды. Хәзер инде аксакалларыбыз да, Фәннур яшьтәш тә күптән гүр иясе. Ә мин Язучылар берлегенең поэзия секциясе биргән фатыйха белән әле һаман шагыйрь булып йөрим. Менә ничә еллар инде безне яклаучылар белән дә, тәнкыйтьләүчеләр белән дә бер Казанда кайныйм. Шигырь дип янып яшәгән булам. Секция утырышы минем өчен, әлбәттә, олы сынау, олы бер мәктәп, шул ук вакытта олы бер сабак та булды. Беренче чорда язган шигырьләрем арасында шактый йомшак, шактый наивлары да булуын мин ул чакта ук чамалый идем. Шуңа күрә минем адреска әйтелгән тәнкыйть сүзләрен, күпме генә авыр булса да, дөрес кабул итәргә тырыштым, һәрчак шигъри камиллеккә омтылдым. Әле дә иманым камил: тәнкыйть ул яшь шагыйрьгә генә түгел, кирәк чакта өлкән шагыйрьләргә дә әйтелергә тиеш. Әлеге секция эшендә катнашкан, минем иҗатыма битараф булмаган, үз фикерләрен ихластан әйткән һәммә каләмдәшләремә (олысына да, кечесенә дә) мин гомерем буена рәхмәтле булдым, һәм әле дә аларның сүзенә колак салып иҗат итәм.

Билгеле инде, һәркем үзенчә тырыша, үзенең кулыннан килгәнне яза. Ákладым микән мин үзебезнең аксакалларыбызның, каләмдәшләребезнең ышанычын? Бер дә әйтә алмыйм. Ә менә шагыйрь булуның Язучылар берлеге әгъзасы булуга караганда бик-бик күпкә авыр икәнлеген хәзер инде төгәл беләм. Шагыйрь булулары, чыннан да, җиңел түгел икән!

Тәфкил Вафин

# МӘКРУҺЛАР

## Таушалган Коръәннәр

Мин үземне белгәннән бирле хәтерлим: безнең өйдә, шкафның иң югары шүрлегендә ике бик тә искергән Коръән саклана иде. Алар белән бергә таушалган тышлы берничә дини китап та әбиемнең ак яулыгына төрелеп куелган иде. Җомга көн саен Әмәйгел әби Бибикамал әби белән бергәләп аларны кычкырып укыйлар иде.

Ә Коръәннәр шулкадәр таушалганнар иде ки, аларның кулга тотар җирләре дә калмаган кебек иде. Әбием аларны күз карасы кебек саклады, "Әгүзе бисмилла"сын әйтеп, безгә дә кабатлатып, Коръәннәр төрелгән яулыкны чишә иде. Битләрен дә үзе генә ача иде.

Коръәннәрнең берсе басмаханәдә басылган булса, икенчесе кул белән язылган иде. Анысының таушалуы соң чиккә җиткән. Китапның битләре уртасында гына калган хәрефләрне хәтта әбием дә таный алмый иде. Ул: "Балалар, бу коръән китапларының басмаханәдә бастырылганы Ләйли әбиегездән (әнисеннән) калган. Ләйли әбиегезгә аны әнисе биргән булган. Коръәннәрнең кулдан язылганы Мөхәммәтсабит бабагызның бабасы Мөхәммәтсафадан калган. Ул аны, Татар Әҗәлесе авылында яшәгәндә, күрше Югары Шырдан авылында көн күргән Хөсәен мулладан биш пот бодай биреп күчертеп алдырган булырга тиеш",—дип сөйли иде.

Әмәйгел әби әйтүенчә[1], ул үзе дә дин сабакларын шул Коръәннәр аша өйрәнгән. Моны әбинең 100 яшендә вафат булган Хәбирә исемле кызы һәм 93нче яшендә дәрел бакыяга күчкән өченче кызы Бибисара (әтиемнең кыз туганнары) да раславылар.

Кульязма Коръәнне Мөхәммәтсафа хәзрәт (1771-1846) улы Шәрәфетдингә, Шәрәфетдин баба исә үзе үләр алдыннан улы Мөхәммәтсабитка калдыра. 1867 елда Мөхәммәтсабит бине Шәрәфетдин мәкруһларны исламга күпләп кайтаруда гаепләнеп Турухан краена сөрелгәннән соң, кулдан язылган Коръән аның өлкән улы Мөхәммәтсадыйкка күчә. Ул вакытта аңа 16 яшь була. Садыйкның энесе Мөхәммәтвафа (әтиемнең әтисе) 16 яшенә җиткәч, Садыйк Коръәнне энесенә тапшыра. Таушалган, тузган хәрефләре дымланып, җәелеп, инде укырлыгы калмаган изге Коръән китабы Мөхәммәтвафа бабамнан Әмәйгел әбием кулына килеп кергән. Шулай итеп, ул, буыннан-буынга күчеп, гаилә мирасына әверелгән.

Тузган, гасырлар кичергән Коръәннең язмышын мин дә хәтерлим. Ул әби кулында 30-40 ел сакланганнан соң, әби: " Үзем исән чагымда, таралып беткәнче берәр хәл кыласы иде",—дип, дусты Бибикамал белән киңәшләшә. Бибикамал әби: " Әмәйгел, бу—изге китап. Аның укырлык җире калмаган, без үлгәннән соң бөтенләй таралачак. Үзебез исән чакта бу изге китапка тулы Коръән чыгып, адәм һәм хайваннар аяк басмаган җиргә күмәргә кирәк",—диде. Алар икәүләп, мин

[1] Укучыларыбызга бу исем таныштыр. "Тормыш язган хикәяләр" дигән яңа сәхифәбезне шушы ук авторыбызның "Әмәйгел әби" дигән язмасы белән ачып җибәргән идек (2006,№ 4).

*Дәвамы. Башы 11 санда.*

мәктәптә булган вакытта тәрәзә каршысында үсеп утырган өянке төбенә чокыр казып, Коръәнне шунда күмгәннәр.

Басмаханәдә сыйфатлы кәгазьдә бастырылган, Ләйли әбидән калган Коръән һәм тагын берничә дини китап бүгенге көндә минем гаилә музеенда саклана...

## Мөхәммәтсафа мәкруһ

Бүлекне К. Насыйри хезмәтеннән өзек китерүдән башлыйм: "Казан ханлыгын урыслар яулап алгач, Татар Әҗәлесе халкын урыслар килеп, җәфа кылалар икән. Анда-монда узсалар, олау сорап, ат сорап, бирмәсәләр, көчләп алып талап китәләр икән. Урысның бу җәфасына чыдый алмый әҗәлеләр төрле авылларга таралып беткәннәр" (Насыйри К., Сайланма әсәрләр.—Т.2.—9 б.).

Мөхәммәтсафаның да башка чыдар чамасы калмый. Ул да кая булса да күчеп китү ягын уйлый. 16 яшьлек улы Шәрәфетдин (1797 елда туа) иптәш малае Вәлиәхмәттән ишетеп кайткан: Зөя өязендә үк Татар Әҗәлесеннән 30-40 чакрым ераклыкта бер кечкенә генә авыл бар икән. Анда урысы-татары тату гына бергә яши икән. Якын авылларның барысында да татарлар яши икән. Авылның исеме Янгилде икән.

Явыз Иван Казанны яулаганнан соң, басып алынган уңдырышлы җирләргә гаскәр һәм чукындыручылар артыннан гади урыслар агыла башлый. Яңа урыс авыллары барлыкка килә. Зөя буенда Кобы-Копр (кабык күпер), Шонгаты авыллары калкып чыга. Җиде Кизләү авылына урыс алпавыты килеп урнаша. Зөя үзәнлегендәге уңдырышлы җирләр аның кулына күчәләр.

Янгилде—борынгы авыл. Егермеләп урыс гаиләсенә шунда урын бирелә. Урыслар Янгилденең өске өлешенә урнашалар, өченче урам барлыкка килә. Татарлар яшәгән аскы өлештә буш урын табылмагач, Мөхәммәтсафа баба, керәшен татары исемен алып, урыслар арасында мөселманча яшәргә ниятли. Татарларның өйләре салам түбәле, 4 тәрәзәле булса, хакимият көче белән күчеп утырган урыслар өчен нарат бүрәнәдән салынган, кызыл буяуга буялган калай түбәле йортлар җиткерелә. Татар өйләре мескен кыяфәттә утырып калалар. Кыш көннәрендә алар кар көртенә күмелә. Бала-чагалар, утын яркасыннан ясалган чаңгыларын өй түбәсенә алып менәләр дә, шуннан шуып төшәләр.

Мөхәммәтсафа баба, улы Шәрәфетдин һәм Әҗәледәге дуслары, Янгилдедәге яңа танышлары ярдәмендә йортын күчереп, иң кырыйга, сары сакаллы Федор күршесенә сала. Түбәсен яңа салам белән ябалар. Аңа урыслар да булыша. Берничә ел тыныч гомер кичерәләр. Шул арада Бурышлы тавы өстендәге урманны кисеп, төпләрдән арындырып, шактый зур мәйданда чәчүлек җир булдыра. Яңа җирдә яхшы гына уңыш үстерә. 1819 елда 22 яшьлек улы Шәрәфетдинне Янгилде авылы кызы Миңлекамалга өйләндерә. Бер елдан соң Мөхәммәтсафаның оныгы -Шәрәфетдиннең кызы Нәсимә дөньяга килә.

Кышкы озын кичләрдә яшьләр, мунчаларда җыелышып, уен-көлке сөйләшергә яраталар. Шундый кичәләрнең берсендә буй җиткән бер егет Чабаксар өязендә яшәүче татарларны, мәҗүси чуашларны чукындыру башланган икән дип сөйли. Авылы-авылы белән якындагы чиркәүләргә куып алып баралар, чукындырып, муеннарына тәре асып, урыс исеме кушалар, каршы килүчеләрне кыйнап җәзалыйлар икән, дигән сүзләргә авыл кешеләре ышанмый, "булмас" дип кенә куялар. Бу хәбәрне Шәрәфетдин дә ишетеп кайта һәм ул әтисе Мөхәммәтсафага сөйли. Мөхәммәтсафа, улын тыңлагач, уйга чума. Ирексездән яшь чагы исенә төшә. Яңа өйләнгән чагы. Әҗәле авылында яшиләр. Поплар, Мөхәммәтсафа өенә килен төшкәнен белгәч, ике атлы казак, бер унтер җибәреп, икесен дә чиркәүгә алып китәләр. Хәдичәсенә (1780-1854), Янгилде авылында вафат Пелагея исеме кушып кайтаралар. Мөхәммәтсафа Иван Ивановка "әйләнә".

Екатерина II вакытында беркадәр йомшарган дини изү Александр I патшалык иткән чорда янә котырынып кабына, татарларны чукындыру яңадан башлана. Төбәкләрдәге чиркәү руханилары һәм миссионерларны матди кызыксындыру күздә тотыла. Үзе теләп христиан диненә күчкәннәргә өстәмә рәвештә чәчүлек җирләре, акча, кием-салым бирү, солдат хезмәтеннән, салымнардан азат итү карала.

Янгилде авылы, Тау ягының Мәскәү-Казан юлы өстендә урнашкан авылларның берсе буларак, Казан ханлыгы һәлак ителгәч тә, чукындыру гарасатына беренчеләрдән булып дучар ителә. Башта 1557 елда, аннан соң 1742, 1762 елларда чукындыралар.

XIX гасырның беренче чирегендә Янгилде кечкенә авылларның берсе була. 1818 елгы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча бу вакытта 19 гаиләдә 53 ир-ат, 72 хатын-кыз заты яши. Православие руханилары, эшне җиңеләйтү өчен, башта кечкенә авылларны чукындырырга ниятлиләр. Алар араларында Имәлле елгасы агып яткан Янгилде һәм Чүкри-Алан кебек ике кечкенә авыл мисалында әлеге ике сала халкын тулысынча чукындырып 100 процентлы күрсәткечкә ирешергә өметләнәләр. Соңгы елларда Янгилде авылына ундүрт урыс гаиләсе килеп урнашу чукындыручылар өчен уңайлы шартлар тудыра.

Башта берничә мәртәбә җыен җыеп, авыл халкын үгетләп карыйлар. Ягъни теләгән кешеләр, үз ирекләре белән гаиләләрен алып барып, Колангы чиркәвендә православиегә күчеп кайтырга тиешләр. Ләкин моны бер генә кеше дә эшләми, берни булмаган кебек яши бирәләр. Казан архиепископы Антоний, кечкенә генә авыл халкын "яхшылык" белән тыңлата алмагач, бу халыкны чиркәүгә куып алып барырга уйлый. Ул Колангы побы карамагына бер дистә кораллы жандарм җибәрүләрен сорый. Аның гозере үтәлә. Берничә кешене, аяк-кулларын богаулап, ат арбаларына бәйлиләр. Калганнарны көтү куган кебек, камчылап, урман аркылы чиркәүгә алып китәләр. Ләкин бу юлы да эшләре барып чыкмый. Каршылык күрсәткән өчен богауланган алты кешедән башкалар урманны чыкканчы качып бетәләр.

## Авыл халкын көчләп чукындыру

1834 ел. Халык санын алуга санаулы айлар гына калып бара. Шуңа күрә югарыдагылар эшне тизләтергә кушалар. Беренче чиратта кечкенә Янгилде һәм Чүкри-Алан авыллары халкын чукындырып бетерергә, аннан зуррак авылларга— Шыгай һәм Сатмышка күчәргә. Янгилде халкын тулысынча православиегә көчләп күчерергә кирәклеге ачыклана, башка чара калмый. Чукындыруны бәйрәм төсендә уздырырга кирәк булачак...

Мөхәммәтсафа үзенең биш яшьлек оныгы Мөхәммәтсабит белән урамга чыгуга, сәер күренешкә тап булалар. Урман ягыннан халык төялгән 5-6 атлы арба килеп, аның өе каршысына туктый. Арбадан сакаллы ят кешеләр төшә. Алар утызлап. Араларында берничә поп та бар. Өч балаклы байраклар күтәреп, чиркәү җырларын җырлап болар урамга юнәләләр. Авылны егермеләп атлы жандарм чолгап ала—чыгып качарлык түгел. Авылдаш урысларны—ирләрне, хатын-кызларны, хәтта бала-чагаларны өйләреннән чыгарып, Колангы чиркәвеннән килгән төркемгә кушалар. Авыл урамы төрле ямьсез авазларга күмелә. Татарлар, ахырзаман килә дип куркышып, идән асларына, нәүрәпләргә (бәрәңге базы) төшеп качалар. Ләкин аларны берәмләп сөйрәп чыгаралар, бер җиргә туплыйлар. Атлы жандармнар авылдан чыгып качарга ниятләгән берничә малайны тотып китерәләр. Шулай итеп, авылның барлык татарларын җыеп, Имәлле елгасы буена куалап төшерәләр. Чукындыру белән Зөя өязе исправнигы һәм приставы җитәкчелек итә, аларга берничә чиркәүнең поплары булыша.

Поплар башта елга суын "изгеләштерәләр" (ягъни араларындагы иң олы поп시 себерке белән елгага су бөрки). Аннан ике жандарм киенгән килеш суга керә. Алар елганың тирәнрәк җирендә туктап калалар. Чукынмас өчен батып үләргә теләүчеләрне тотып калачаклар, янәсе.

Жандармнар яшь дьяклар булышлыгы белән татар картларын, хатын-кызларын һәм бала-чагаларны суга кысрыклап төшерә башлыйлар. Андагы елаулар, бала-чагаларның кычкыру-чинаулары акылга сыймаслык күренеш булган— Әмәйгел әбиемә аның әнисе Ләйли әби (1830-1921) әнә шулай дип сөйләгән. Поплар исә тыныч кына яр өстеннән карап торган. Чөнки алар өчен мондый күренешләр инде гадәти хәлгә әйләнгән була. Олы яшьтәге ак сакаллы поп су эчендәге татарларның башларына себерке белән су бөркеп чыккач, чукындыру церемониясе башлана.

Яр буена иконалар тезеп куела. Ерактан кайтарылган, Колангы чиркәвенең горурлыгы булган зур иконаны өч дьяк күтәреп тора. Судан кешеләрне берәмләп сөйрәп чыгара башлыйлар. Ирләрнең түбәтәйләрен салдырып ташлап, хатын-кызларны елатып, бала-чагаларны кычкыртып чукындыралар. Муеннарына калайдан ясалган тәре тагалар. Баулары сүс талкышыннан үреп ясалган була. Аны тиз генә чишә алмаслык итеп юешләп чиyләп бәйләп тә куялар. Әбием сөйләгәннәрдән: "Әни әйтә иде, шул тәреле бауны муенга көчләп такканчы, пычак салсалар җиңелрәк булыр иде",—дия иде. Бу чиркангыч чукындыру церемониясе берничә сәгать дәвам итә.

Янгилде авылы халкын чукындыруны тәмамлагач, Зөя өязе исправнигы, поплар һәм жандармнар, тере божра ясап, халыкны бер урынга кысалар. Башта исправник сүз ала. Ул авылның бөтен халкын "үз теләге" белән православиегә чыгуы белән котлый. Колангы чиркәве побы Виктор Охотин да авылның тулысынча христиан динен "кабул итүе" белән тәбрикли. Аларның сүзләрен үз теләкләре белән ияреп килүче сатлык җаннар (хәзер инде "крешенный татар"лар) тәрҗемә итеп, авыл халкына җиткерәләр, котлау сүзләре әйтәләр, сез дә хәзер безнең (Мәлки, Яншура, Тәрбит авыллары халкы) кебек керәшен татарлары булдыгыз, диләр. Колангы побы Виктор Охотин яңа чукындырылганнар белән беренче служба үткәрергә ниятли. Халыкны аның кыланганнарын кабатлатып азаплыйлар. Ләкин беркем дә бернәрсә эшләми, тик басып тора бирәләр. "Арыгансыз, гыйбадәтне чиркәүдә, Колангыда кылырбыз",—ди Охотин. Аннан соң ул христиан динендәге кешеләр нәрсә эшләргә тиешлеге турында сөйли: атнага бер мәртәбә чиркәүгә барырга, яңа туган балаларны чиркәүгә алып килергә, яңа өйләнешүчеләрне чиркәү йолалары нигезендә никахларга, мәетләрне татар зиратларына күммәскә һ. б. Попның халыкка җиткерәсе "шатлыклы" хәбәрләре дә була: олы яшьтәгеләр, авырулар, балалы хатыннар өчен "Келәү елгасы" чишмәсе янына бер атна эчендә часовня куелачак. Янәсе, гыйбадәтне шунда гына кылырлар.

Шуннан соң һәр 19 йортны су бөркеп "изгеләштерәләр". Тәреләр, иконалар, православие байраклары күтәргән авылдаш урыслар катнашкан төркем Янгилде урамнарын, татарның күңеленә ят булган тавышлар белән чиркәү җырларын җырлап, бер мәртәбә әйләнәләр дә, тәре куеласы алгы урам чишмәсенә юнәләләр. Алдан әзерләнгән чокырларга юкә агачыннан ясалган ике метр биеклектәге тәрене утыртып куялар. Шундый ук тәрене арттагы урам чишмәсе янына да утырталар. Авылның дүрт басу капкасы янына өчәр метр биеклектәге дүрт тәре бастыралар. Черемәсеннәр дип аларга кара дегет сылыйлар.

Шулай итеп, бер көн эчендә кечкенә генә Янгилде авылы тәреләргә күмелә. "Келәү елгасы" чишмәсе янына куелачак часовня дигәннәрен кичкә таба пар ат белән Җидекизләү авылында ясатып алып киләләр.

Часовня дигәннәре шундый ук агачтан ясалган тәре. Аермасы—тәренең өске өлешенә иконаларны яңгырдан саклар өчен такта ябылган була. Часовняны урнаштыралар, аннан соң "освящать" итәләр. Охотин авыл уртасына чаң (колокол) куелачагын әйтә. "Ул авылыгызның яме булып торыр, "Малиновый звон" белән сез, крещенный татарларны гыйбадәт кылырга чакырыр",—ди.

Авыл халкы бу мәхшәр көне тәэсиреннән айның алмый интегә, балалар көнозын ашамый, көтүләр куылмый, сыерлар савылмый, чишмә янындагы тәреләрдән куркып, хатын-кыз суга бармый. Көянтә-чиләк күтәреп ирләр үзләре су алып кайтырга мәҗбүр була. Ирләр дә су алганда аска гына карарга тырышалар.

Зөя өязендәге кечкенә авыллардан Чүкри-Алан халкын да шундый язмыш көтә. 1834 елда бу авылда 16 гаилә—106 кеше яши, шуларның 50се ир-ат, 56сы хатын-кыз. Янгилдедәге хәлләр турында ишеткәч, авыл халкының яртысы кайсы кая чыгып кача. Ләкин күпме генә качып йөрсәң дә, йорт эшен эшләргә, хайваннарны ашатырга, сыерларны саварга, балаларны карарга кирәк. Колангы побы әлегә ашыкмый, халык тынычланганны көтә. Киткәннәр әкренләп өйләренә кайта.

Чүкри-Аланнар Колангы побы янына делегация җибәрә. Бу—отставной солдатлар Исхак Хәлилов белән Назыйр Халитов һәм староста Тимербулат Бадамшин. Алар чукындырмауларын үтенеп бөтен авыл кул куйган "отношение"не тапшыралар. Ләкин Колангы чиркәве рухание: "Бернәрсә дә әйтә алмыйм, мин боерык үтәүче генә",—дип җавап бирә.

Өч көн узгач, иртә белән көтү чыгып киткәнче, атлы жандармнар авылны чолгап алалар, бер генә кеше дә чыгып качарлык булмый. Жандарм башлыгы чыгарган сыерларны кире абзарга ябарга боера. Озак та үтми, Янгилде авылындагыча ук, атлар белән утызлап кеше килеп төшә. Тиз арада күрше Янгилдедән урыс милләтеннән булганнарны, аларның балаларын алып киләләр. Алар рәхәтләнеп Колангыдан килгән төркемгә кушылалар. Төрле тавышлар белән җырланган чиркәү җырларын ишетмәс өчен авыл кешеләре колакларына бармакларын тыгалар, ә жандармнар, кысрыклап, халыкны буага таба куалар.

Барысы да Янгилдедәгечә була: тәре асалар, чукындыралар. Аерма шунда гына: Янгилде авылын элегрәк заманда инде чукындырган булганнар. Халык, әби-бабаларыннан ишетеп, аз булса да бу турыда белгән. Монда исә барысы да өр-яңа эш, күңелләре ышанмый. Алай да халыкның күбесе моны котылгысыз хәл дип кабул итә: тарткалашмыйлар, хәтта елашмыйлар да.

Муеннарына тәре такканда, попларның әйтеп торуы буенча, чиркәү писаре һәркемнең яңа исемен теркәп бара. Исемнәре дә шул ук, күбесе Иван, Фёдор, Петр яки Василий була.

Чукындыру эшләре тәмамлангач, поп Охотин "новокрешенныйлар" белән служба үткәрмәкче була. Ләкин попның кыланмышларын бер кеше дә кабатламый, кайберләре арт белән басалар. Авылның өч басу капкасы янына, шулай ук чәй кайнату өчен су ала торган кизләү янына тәреләр куялар, чукынырга Колангы чиркәвенә барырга кушалар. Бара алмаганнар кизләү янындагы тәрегә табынырга тиеш булалар.

Чүкри-Алан авылы халкы бу көннәрне бик авырлык белән үткәрә. Шулай да авылда иманны саклап калырлык кеше—мулла була. Бу—Вәлиулла хәзрәт Әхмәдиев. Аны чукындыра алмыйлар—качып котыла. Чүкри-Алан авылы кечкенә булса да, аны тулысынча чукындыра алмыйлар. Басу капкасы янындагы тәреләр беркадәр вакыттан соң бөтенләй юкка чыга. Аларны авыл яшьләре төнлә урманга алып китеп яндыра.

Миссионерлар, поплар чукындыруларын дәвам итәләр. Чүкри-Алан авылыннан соң Шыгай авылы халкын православиегә күчерәләр. Авылдагы 33 гаиләдән берсе мөселманлыкта кала. 8 ир-аттан һәм 10 хатын-кыздан торган бу гаилә өлкәннәренең исемнәре билгеле: Мөхәммәткулов Мөхтәр, аның хатыны Миңлегөл, әнкәсе Хәбибә. Сатмыш авылында хәл киресенчә була: 63 гаиләдән берсен генә чукындыра алалар, 62се мөселманлыкта кала. Чукынган гаилә башлыгын Михайлов Иван дип язып куялар. Үз исеме мәгълүм түгел.

Карамасарда 67 гаилә, 540 кеше яши, шуларның 269се ир-ат. 271е хатын-кыз. Поплар 17 гаиләне православие диненә күчерүгә ирешәләр.

Зур Урсак авылы—төбәгебездәге татар авылларының иң зурысы, анда 94 гаилә исәпләнә, 1158 кеше (608 ир-ат һәм 550 хатын-кыз) яши. (Болар 1834 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча.) Авыл тулысынча мөселманлыкта кала *(Татарстан Республикасы Милли архивы.[2]—Ф.3.—Тасв. 2.—Сакл. бер. 353)*.

1834 елда халык саны алганда кемнең нинди диндә торуы иң мөһим күрсәткечләрнең берсе була. Соңгы елларда күпме татарның православиегә күчүе билгеле булачак—шуны истә тотып, чукындырылган татарлар арасында көчле аңлату эшләре алып барыла. Көне килеп җиткәч, авылдан беркемгә дә беркая да барырга рөхсәт ителми.

1834 елның 6 апрелендә Федоровск волосте идарәсе старшинасы ярдәмчесе Туктар Миннебаев, Колангы чиркәве писаре һәм Янгилде авылы старостасы Алексей Иванов Мөхәммәтсафа өенә килеп керәләр. Алар авылда халык санын алучылар икән. Гаилә әгъзаларының урысча исемнәрен, шулай ук башка сорауларга да җаваплар алып теркәп куйгач, балаларны язарга керешәләр, үндүрт яшьлек Нәсимәне—Настасья, сигез яшьлек Мәрьямны—Мария, җиде яшьлек Миңлеҗамалны Матрена дип язалар. Биш яшьлек Мөхәммәтсабитны бабасы Мөхәммәтсафа һәм әтисе Шәрәфетдин исемлеккә үз исеме белән кертергә тырышып карыйлар. Ләкин писарьга исемлеккә татар исеме кертү тыелган була. Тулысынча чукындырылган авылда татар фамилиясе булырга тиеш түгел, дигәннәр. Биш яшьлек Мөхәммәтсабитка Василий кушаматы тагалар, шулай итеп

[2] Алга таба – ТР МА.

ул Василий Иванов була...

"Высочайщий" исеменә "сотвори суд и милосердие и повели нас... остаться в могаметанской вере" дип тәмамланган хатны язуны оештыруда гаепләнеп 30 камчы алучылар исемлегендә Василий Иванов та бар. Янгилде авылы мәкруһларының күпләп Мөхәммәд диненә кайтуларын оештыруда да Василий Иванов гаепләнә. Ул күрше Сатмыш, Зур Урсак, Кече Урсак, Карамасар авыллары мөселманнарын миссионерларга каршы тору чараларына өйрәтә, аларның киләчәген алдан әйтеп, кисәтеп куя. Бу исә мөселманнарга каршылык күрсәтүне оештырырга мөмкинлек бирә. Боларның барысын да Мөхәммәтсабит (Василий Иванов) эшли. 1867 елның апрелендә Зөя каласында кулга алып, шул елның июль аенда аны Көнчыгыш Себердәге Турухан краена (Енисей губернасына) сөрәләр. Бабабыз 36 ел гомерен Себердә сарыф иткәннән соң, 1903 елда шунда вафат була. Аның оныклары Хәбирә һәм Бибисара Свердловск өлкәсендә һәм Төрекмәнстанда гомер кичереп олыгайдылар, соңгы сулышларына кадәр (100 һәм 92 яшьтә вафат булдылар) бабаларының изге рухына дога кылып яшәделәр. Алар икесе дә—әтиемнең кыз туганнары. Бу апаларым ярдәме белән (аларның хатирәләрен язып алып калдым) бабабыз тормышының кайбер якларын ачыклап китмәкче булам.

## Белемгә омтылыш

1834 елгы халык санын алуга бәйле рәвештә чукындырылган Янгилде һәм күрше Чүкри-Алан авылы татарлары шок хәлендә калалар. Берничә ел буе алар үзләренең кем икәнлекләренә төшенә алмыйлар. Патша хөкүмәте, чиркәү һәм миссионерлар аларны "крещенные татары" дип атыйлар. Авыл халкы үзен: "Без мөселман" дип юата. Поплар һәр якшәмбедә Колангы чиркәвенә барып христиан гыйбадәтен кылырга мәҗбүр итәләр. Берничә мәртәбә жандармнар чакыртып Петропавел чиркәвенә алып бармакчы булалар. Ләкин авыл халкы юлда качып бетә.

Вакыт үтү белән үз диннәренә кайтучылар күбәя башлый. Күрше-тирә мөселман авылларында мәчетләр төзелә, искеләре төзәтелә. Янгилде һәм Чүкри-Алан авылы "керәшеннәре" бу авыллар халкы белән аралашу нәтиҗәсендә үзләренең мәкруһлыкларын нгытлар.

Кайбер мәкруһлар, биш-алты бабадан бирле христианлыкта саналсалар да, аларның күңелләрендә ислам дине саклана. Алар арасында хәтта үзләренең христиан динендә дип исәпләүләрен белмәүчеләр дә була. Алар моны һәр 7-8 ел саен уздырылган халык санын алу (элегрәк—ревизия) вакытында гына белгәннәр.

Янгилде авылы мәкруһларына килгәндә, алар мөселман диненә кайту нияте белән яшиләр. Аларны моңа өндәүчеләр, өйрәтүчеләр дә була. Әйтелгәнчә, мәкруһлар, мөселман диненә кайтырга сорап, патша исеменә үтенечләр юллый башлыйлар. Мәкруһларның үзләре арасында да белемле кешеләр пәйда була. Аларның исемнәрен Зөя өязе халкы бик яхшы белә. Гыйлем ияләре белән аралашу башлана.

Мөхәммәтсабитның апалары Нәсимә, Мәрьям һәм Миңлежамал 1840-50 нче еллар арасында дин сабакларын үзләренең бабалары Мөхәммәтсафадан алалар. Аларның өчесе дә гарәп хәрефләре белән язылган язмаларны, догаларны укый ала. Сабит энеләре, әлегә кечкенә булса да, хәрефләрне өйрәнеп, кайбер догаларны укый башлый. Тәкъдире юлын тәгаенләп, Мөхәммәтсафа баба оныгы Сабитны укытуны аның әтисе Шәрәфетдингә йөкли. Мөхәммәтсафа баба, кызларның әтиләре, ягъни улы Шәрәфетдин белән киңәшеп, кызларга белем бирүне тизләтергә кирәк дип таба. Чөнки аларны сорап килүче яучылар күбәя бара.

Кызларга, дин сабагыннан башка, киндер туку, сугу, чигү, оек бәйләү, ипи салу, аш пешерү кебек һөнәрләрне дә үзләштерү кирәк була. Шуның өчен сабак бирү эше Хәдичә әбигә күчә. Ул аларны мөстәкыйль тормышка өйрәтә. Әлеге тәрбия эшләре кызларның әниләре белән бергәләп башкарыла.

Бабасы Сабитка ирләр генә башкара алган эшләрне тапшыра башлый.

Сабитның апаларын, ерак булмаган авыллардан килеп, никахлап алып китәләр. Бер Сабитның өч җизнәсе була. Ул 11-12 яшьләренә җиткәч, аларның өчесе янына да, ягъни Татар Әҗәлесе, Карашәм һәм Ташкичү (Тәтеш өязе) авылларына атка атланып барып килүне бернигә дә санамый.

Мөхәммәтсабит бабасы Мөхәммәтсафа һәм этисе Шәрәфетдин туып-үскән Татар Әҗәлесендә ешрак булырга ярата. Нәсимә апасы белән Хөсәен җизнәсе янында булуны кулайрак күрә.

Мөхәммәтсабит ислам дине сабакларын өендә алуны дәвам итә. Янгилде, патша хөкүмәтенең рәсми билгеләвенчә "керәшен" авылы булу сәбәпле, анда мәчет тә, мәдрәсә дә булмады. Берничә гасыр буена Янгилдедә татар-мөселман исем-фамилияле кеше бөтенләй теркәлмәгән. Башка мөселман авылларындагы мәчеткә бару, мәдрәсәдә уку хөкүмәт тарафыннан тыелган. Керәшеннәрне мәчеткә, мәдрәсәгә керткән өчен муллаларны Себер көткән, йә булмаса указларын алганнар. Шуңа карамастан, Мөхәммәтсафа, Сатмыш мәхәлләсе имам-хатибы Садретдин Ибраһимов белән сөйләшеп килешенгәнчә, шәкертләр кичләрен өйләренә таралгач, Мөхәммәтсабит Садретдин хәзрәттән сабак алырга да йөри. Сабитның мәчеткә килеп-китү юлы Бәхтияр чокыры аша була.

Чүкри-Алан авылы халкы чукындырылгач, мулла Вәлиулла Әхмәдиев урыслардан качып йөреп, күп вакытын Янгилдедә, Мөхәммәтсафа гаиләсендә үткәрергә мәҗбүр була. Вәлиулла хәзрәт урманнарда качып ятмый, ул, һөнәрчеләрчә киенеп, сакал-мыегын үзгәртеп, иләк, чиләк, комган төзәтүче кыяфәтенә кереп көн күрә. Вәлиулла хәзрәт күп вакытын Мөхәммәтсафаның онын Мөхәммәтсабитка сарыф итә. Вәлиулла хәзрәтнең тәфсилләп биргән дин сабагы, вәгазе, фикерләре Мөхәммәтсабитның ислам фидакаре булып үсүенә зур өлеш кертә. Мөхәммәтсабит Вәлиулла хәзрәттән мәдрәсә программасында каралган күләмдә төпле дини белем ала.

Зөя өязендәге Татар Әҗәлесе, Югары Шырдан, Карашәм авыллары күрше мөселман авыллары булганнар, аралары 5 чакрымнан артмаган. Аларда мәчетләр, мәдрәсәләр, укымышлы кешеләр булган. Аларны тирә-як өяз мөселманнары яхшы белгәннәр. Мөхәммәтсабит Югары Шырдан, Карашәм авылы мәчетләре белән аеруча кызыксынган.

Карашәм авылында булганда Хәсән җизнәсе аны күрше авыл мәчетләренә җомга намазына йөртә. Ул анда намаз укый, азан моңын тыңлый. Күргән, ишеткәннәрен урыслар тарафыннан рәнҗетелгән Янгилдегә кайтып яшьтәшләренә сөйли, Чүкри-Алан авылы яшьләренә дә җиткерә. Аларга атна саен Колангының Петропавел чиркәвеннән килгән яшь дьякларга ничек җавап бирергә кирәклеген өйрәтә.

Мөхәммәтсабит (Сабит) кыска гына вакыт эчендә Чүкри малайлары үсмерләре алдында ихтирамга лаек затка әверелә. Ул, 12 яшьлек малай булса да, мәкруһларны керәшеннәрдән аера белә, урысларның мәкруһларны "крещенный из татар", ягъни "керәшен" калыбына ни өчен кертергә тырышуларын да бик яхшы аңлый. Казан губернасы, бигрәк тә үзләренең Зөя өязе мәкруһларының хәлләрен, Татар Әҗәлесе, Тәтеш өязенең Ташкичү авылында ишетеп, үз авылдашларына, яшьләренә җиткерә.

XIX гасыр урталарында Зөя өязенең "керәшен", мәкруһ авылларында миссионер Н. Ильминский тәкъдиме белән "инородческая школа"лар ачыла. Бу мәктәпләрдә укыту кириллица алфавитында татар телендә басылган дини китаплар нигезендә алып барыла. Андый школалар Янгилде авылында урыслар яшәгән ике йортта оештырыла. Берсе авыл уртасындагы Чернова Зиновья өендә, икенчесе аскы урамда, Ивановск волосте старшинасы хезмәткәре Лука-сакау өендә урнашкан була. Соңынан бу ике катлы йортны Чернов Алексей бабай сатып алып, өстәге урамга күчерә. (Ул йортны мин яхшы беләм, заманында авылда берд әнбер ике катлы агач йорт иде.) Урыс милләтеннән булган балалар өчен ике мәктәп эшли, алары да шәхси йортларда урнашкан була.

Христиан дине китаплары татар телендә шулкадәр дә саклык белән тәрҗемә ителгән ки, татар укучы, китапның бер өлешен укып чыкмыйча, сүзнең кайсы дин турында барганлыгын да төшенми. Чөнки китапта "тәре", "Бог", "Библия" сүзләре башка сүзләр белән алмаштырыла (хач, Аллаһ, Инҗил һ. б.). Татар телендә

басылган христиан китабында тәренең үзе түгел, хәтта күләгәсе дә күрсәтелми. Бу китапларның бизәлешендә дә мәкерле уй салынганлыгы шәйләнә.

Кызганычка каршы, мондый мәкерле эш хәзер дә дәвам итә. Безнең Казанда "Изге китапны (Библияне) тәрҗемә итү институты", Библияне бастырып чыгаруны әзерләүче "Изге китап" җәмгыяте бар икән. Минә кулымда "Инжил" китабы, ягъни "Библия". Ләкин аның "Библия" икәнен аеру кыен. Вак шрифт белән басылган кереш сүздә "Библия" сүзе нибары бер тапкыр гына очрый. Китапны сул ягыннан ачсаң, "инжил" икәнен чамалыйсың, уң ягыннан ача башласаң, "Инжил шәриф" дигәнне гарәп имласын белсәң генә укый аласың. Ә бит "Инжил"нең "Библия" икәнлеген белмәүчеләр дә күп әле.

"Инжил" китабы югары сыйфатлы кәгазьгә басылган. Бизәлүе дә югары дәрәҗәдә. Китапта чукыну, чукындыру сүзен таба алмыйсың. Болар барысы да дин белән яңа таныша башлаган татар балаларының һәм аларның ата-аналарының дингә карашларын христиан диненә юнәлдерү өчен кирәк, әлбәттә. Яки менә "Изге инжил", "Раббыбыз Гайса турындагы яхшы хәбәр" "Тәүрат", "Илчеләрнең эшләре", "Изге язманың уникальлеге" кебек китаплар. Бусы менә—"Коръәннең барлыкка килүе". Кечкенә форматта эшләнгән, "Намазда укыла торган догалар, сүрәләр һәм тәһарәтнең тәртибе" китапчыгыннан аерып алуы кыен. Аерма шунда, беренчесе хәзерге заман миссионерлары тарафыннан бушлай таратыла. Аны бөтен җирдә—вокзалларда, базарларда сорамасаң да кулыңа китереп тоттыралар. Максат ни? Коръәнне Библиягә караганда түбәнрәк итеп күрсәтү...

Сүзне үткәнгә кайтып дәвам итик әле. Н. И. Ильминский ачкан школаларда формаль яктан христиан динен өйрәнү булмаса да, рус теле дәресләрендә христиан диненең һәм урыс халкының бөеклеге турында сөйләнелә, аларның башка диннәрдән һәм халыклардан өстенлеге күрсәтелә...

Татарлар арасында укый-яза белүнең югары кимәлдә булуын миссионерлар да таный. "Сильно же магометанство,—дип күрсәтелә алар чыгарган журналда,—прежде всего очень распространённой в магометанском населении грамотностью. Казанские татары-магометане, почти все за редкими исключениями, грамотные и очень ценят образование и заботятся о нём". Татарларны христианлаштырудагы уңышсызлыкларның төп сәбәбен миссионерлар нәкъ менә шунда күрәләр.

Мөхәммәтсафа һәм Шәрәфетдин Сабитны яңа оештырылган инородческая школада укытуга шикләнеп карыйлар, Вәлиулла һәм Садретдин хәзрәтләр белән киңәшәләр. Алар баланың күңеленә ныклы ислам оеткысы салынганлыгын, шикләнергә урын юклыгын аңлыйлар. Аның урам теле дәрәҗәсендәге урысчасын камилләштерергә кирәклеге белән дә ризалашалар.

Татар белән урыс катнаш Янгилде авылында туып үскән Сабитка урысча акцентсыз сөйләшүгә ирешү өчен берничә ел уку җитә. Ул тарих, география, математиканы һәм башка дөньяви фәннәрне бирелеп өйрәнә. Соңрак мәкруһларга кагылышлы рәсми документлар белән ныгытып таныша, миссионерлар, христиан дине руханилары белән сөйләшүләрдә катнаша, мәкруһларны яклап император исеменә хат язуны оештыруны, кыскача әйткәндә, гади мәкруһлар эшли алмаган эшләрне башкаруны үз өстенә ала.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Булат
Солтанбәков

# ТАТАРЛАР ҺӘМ ИГНАТЬЕВ

**Бу мәкаләдә Татарстан Республикасы тарихындагы гаҗәеп бер дәвер—Игнатьев дәвере турында сөйләнер. Ләкин әүвәл Татарстанда җете эз калдырган бу шәхеснең алдагы тормыш сәхифәләренә дә сүз салыйк.**

1951 елның июлендә Семен Денисович Игнатьевны СССР дәүләт иминлеге министры итеп куялар. Аның карьерасындагы иң югары биеклек ноктасы 1952 ел ахыры белән 1953 ел башына туры киләдер. Атап әйткәндә, "врачлар эшен" тәгәлләве, дәүләт иминлегендә тамыр җәйгән "абакумовчыларны" фаш итүе һәм кулга алуы, Политбюро әгъзаларыннан берсенең секретариатыннан чит илгә мәгълүмат китеп тору каналын ачыклавы белән ул Сталинның мәхәббәтен яулый, шул ук вакытта Бериянең сагаюын да көчәйтә. Ләкин үзе күтәргән Игнатьевны бәла-казадан Маленков аралап килә. Партиянең XIX съездында Игнатьев Үзәк Комитет әгъзасы итеп сайлана һәм киңәйтелгән Президиумга керә. Бу Президиум, Сталин фикеренчә, элеккеге Политбюро әгъзаларының йогынтысын киметергә һәм аларны сәяси аренадан читләштерүдә ярдәм итәргә тиеш була.

Менә бу мисаллар гына да Игнатьевның абруе нинди зур икәнлеге турында сөйли: юлбашчы даирәсендәге иң якын кешеләрне—"халыклар атасының" 30нчы еллар башыннан бирле алыштыргысыз ярдәмчесе һәм шәхси секретаре булган А. Поскребышевны, 1919 елдан бирле тугры хезмәт итеп килгән шәхси сак башлыгы генерал Н. Власикны кулга алуны нәкъ менә Семен Денисовичка тапшыралар. 1953 ел гыйнварында Сталин даирәсеннән янә 5 кеше кулга алына. Игнатьевка өстәмә рәвештә шәхси сак башлыгы вазифасы да йөкләнә. Ана чаклы махсус хезмәт башлыкларының берсе дә мондый зур ышанычка ирешә алмаган.

Әгәр дә Сталин тагын берничә ел яшәсә, бәхәссез ки, язмабыз каһарманы тагын да зуррак биеклеккә күтәрелгән булыр иде... 5 мартта, Сталин үлем газабы белән тартышканда, аның бүлмәсенә керүчеләр журналындагы исемлеккә Игнатьев фамилиясе иң соңгылардан берсе булып теркәлгән... Хәлбуки, бу хәл һәм без белеп бетермәгән башка сәбәпләр юлбашчы үлеме хакында төрле фаразлар тудыра. Мәсәлән, "Сталинны үтерү һәм Берия" дигән китап авторы Ю. Мухин фикеренчә, юлбашчыны юк итү турында Политбюроның өч әгъзасы карарын турыдан-туры Игнатьев гамәлгә ашырган...

Җитәкче лидерлар үлеп баручы юлбашчы янында ашыгыч рәвештә, кабалана-кабалана, партия уставы таләпләрен үтәмичә, кайбер карарлар кабул итәләр. ҮК Президиумының тар даирәсе хакимиятне бүлешү эшенә керешә. Әлеге органның яңа составында инде Игнатьевка урын табылмый. Ана ҮК секретарьларыннан берсенең вазифасын йөклиләр. Ул Поспелев һәм Шаталин кебек икенче дәрәҗәдәге фигура булып кала. Ул гына да түгел, ҮК Президиумының 3 апрельдә узган утырышында

Берия тәкъдиме белән байтак сәяси эшләрне туктату, "җәмгыятькә зыян китергән врачлар" эше буенча җавапка тартылган 37 кешене тулысынча аклау һәм иреккә чыгару турында мәсьәлә карала. Шулай итеп, Игнатьевка сәяси һәлакәт сәгате якынлаша.

Президиум элеккеге дәүләт иминлеге министрыннан совет законнарын һәм тикшерү материалларын тупас бозганы өчен аңлатма бирүен таләп итүче карар чыгара. Экс-министрның ачы язмышы шул документтагы менә бу юлларда ачык чагыла: министрлык итү дәверендә җитди хаталары өчен С. Д. Игнатьевны ҮК секретаре вазифасыннан азат итү турындагы тәкъдимне пленум каравына куярга. Тиздән ул әлеге вазифадан колак кагу белән беррәттән ҮК составыннан да чыгарыла.

СССРда сәяси хакимият системасы турындагы китап авторы Р. Пихоя әлеге карарга аңлатма биреп, "врачлар эшендә" Игнатьевның һич тә катнашы булмавы турында яза. Ул эшне Политбюро үзе башлаган, аңа Сталин белән Маленков контрольлек иткән. Бериянең соңыннан яклавына өметләнеп, Игнатьевны чынлыкта Маленков саткан. Фаразан, монда искитәрлек нәрсә юк, элек ничек булса, бүген дә шулай "саталар"...



Игнатьевның шуннан соңгы язмышы ничегрәк язылган? Аның ТР Үзәк архивында саклаучы шәхси эшендә үз култамгасы куелган серле бер язу бар: "1953 елның апреленнән декабрьгәчә авырдым". Ничектер бер очрашып сөйләшкәндә ул әлеге хасталык чорында үз ведомстволарының "санитарлары" карамагында булганлыгы хакында әйткән иде. Гәрчә К. Фасеев истәлекләренә караганда, ул үз кешеләренең холык-фигылен әйбәт белгәнгә күрә, төннәрен мендәр астына пистолет куеп йоклый торган булган. Исән килеш бирелергә җыенмаган, янәмәсе. Хәер, бусы әтәчләнү галәмәте генә инде.

Хәер, Хрущев үзенең шактый керле истәлекләрендә, ул үз-үзен өй шартларында кулга алды, дип яза эчке бер каһкаһә белән. Әмма шунысы хак—Игнатьев рәсми рәвештә кулга алынмаган һәм Мәскәүдә яшәгән. Минем гыйльми остазым И. М. Ионенко Казанда берничә мәртәбә аның белән очрашып сөйләшкән. Ул беркайчан да үткәнне искә төшерергә яратмаган. Шулай да бер мәртәбә: "Мин могҗиза белән генә исән калдым. Мине кулга алу турындагы ордер күптән прокурор өстәлендә ята иде",—дип әйтеп куйды.

Документлар моны раслый. Язмышы кыл өстендә торган, аны көннәр түгел, сәгатьләр хәл иткән. Болай була бу. 25 июньдә, үзе кулга алынуга бер көн кала, Берия "врачлар эше" буенча күптән түгел генә тикшерү үткәргән элеккеге министр урынбасары Рюминнан сорау алу материалларын Маленковка юллый. Шул материаллардан күренгәнчә, Игнатьев ҮК фикеренә таянып, тикшерүгә тартылганнарны кыйнарга кушкан, имештер лә ул шулай ук "врачлар эшен" генә түгел, ә "ленинградлылар эшен" дә әвеш-тәвеш китергән, яһүдиләрнең антифашистик комитеты әгъзаларын юк итүне оештырган. Берия телдән кичекмәстән Игнатьевны кулга алуны таләп итә. Минемчә, ул шулай итеп хәтәр бер хата ясый. Игнатьевны кулга алу үзеннән-үзе Маленковның бик күп зобани гамәлләрен, явыз гөнаһларын ачуга китерер иде. Бу җәһәттән ҮК секретаре Кузнецовның "ленинградлылар эше" буенча кулга алынуын һәм Маленков бүлмәсеннән чыкканда атып үтерелүен искә төшерик. Әгәр кулга алсалар, Игнатьевның да авызын бик тиз ачтырырлар иде.

Маленков җилнең кайсы якка искәнен бик тиз тоеп ала, ул һичбер икеләнүсез Берияне сәяси яктан, ә аннары физик рәвештә дә юк итү эшенә керешә. Бик хәтәр детектив әсәрне хәтерләтүче әлеге драматик хәлләр инде күп тапкырлар язылган. Алай гына да түгел, бу уенда катнашкан һәркем үзен хәлиткеч рольне уйнаучы дип исәпли. Ә бер атаклы генерал гомеренең ахырынача Берияне үз кулы белән атып үтерүе белән горурланып йөрде... Гәрчә ул елларда җәмәгатьчелек алдында бу зобани

затны юк итүдә Маленков башлап йөрде дигән фикер өстенлек итте.

Мин ул чакта армия хезмәтендә идем. Әлеге вакыйгаларга күпмедер кимәлдә безнең батареяның да катнашы бар. Безне төн уртасында хәрби тревога белән уятып, Мәскәүнең Бескудниково районына күчерделәр. Без сугыш башлана дип уйладык. Комбатыбыз вәзгыятьне бик тиз чамалады, сугыш булырмы-юкмы—билгесез, әмма безгә агитмасса эшенең торышын тикшерергә дивизиянең сәяси бүлегеннән комиссия килүе бәхәссез, диде ул миңа. Шуңа күрә хәзер үк Ленин бүлмәсен—кызыл почмакны бизәү эшенә тотын (замполит ялда булганлыктан, аның вазифасын, партоешма секретаре буларак, мин башкара идем), Политбюро әгъзалары портретлары, сугышчан листоклар, социалистик йөкләмәләр, стена газетасы эленгән булсын, дип боерды... Без шушы эшләрне тәгәлләүгә полк замполиты шалтыратты. Иң әүвәл ул: "Берия портреты бармы?"—дип сорады. Мин, шатланып, әлбәттә, бар, дип җавап биргән сүземне кырт кисте: "Ал да, чыгарып ыргыт!" Хәер, соңыннан бу хакта комбатка әйткәч, ул: "Алуын ал син аны, әмма чыгарып ыргытырга ашыкмый тор, дөнья хәлен кем белгән?!"—дип кинәш бирде. Әнә шулай итеп тревоганың төп сәбәбен ачыкладык без.

Сүз уңаеннан язып үтим әле, мин хезмәт иткән 1нче гвардия зенит-артиллерия дивизиясенең сәяси бүлеге башлыгы полковник Зуб Лубянкадан Булганин лимузинында, аның аяк очында яшерен рәвештә Кремльгә килеп, Берияне кулга алучыларның берсе булган. Әйе, ул вакытта без хезмәт иткән ПВО гаскәрләре әлеге мажаралы вәзгыятьтә зур роль уйнаганнар. Ә инде үзгәртеп кору дәверенә кергәч, Берияне кулга алучылар, шул җөмләдән генерал Зуб та, батырлыклары өчен үзләренә Советлар Союзы Герое исемен бирүләрен сорап, М. Горбачевка мөрәҗәгать итәләр. Ләкин 1953 елда аларга орденнар бирелгәнлектән, бу үтенеч үтәлмичә кала.

Берияне кулга алу халыкның бөтен катламнарына да көчле тәэсир ясый. Без ул вакытта "Берия, Берия, нет тебе доверия, а товарищ Маленков надавал ему пинков" дип җырлап йөрдек. Ач күзеңне, дөнья бу. Соңыннан Маленковның да, Хрущевның да, Жуковның да арт санына типтеләр. Дөресе, үз кармакларына үзләре каптылар. Ә Игнатьевка килгәндә, бу юлы да язмыш аны аяп кала—җил-давыл читләп уза. Ул Бериягә соңгы нокта куйган ҮК Пленумында катнаша. Чыгыш ясамый. Гәрчә Хрущев аны "катлаулы чекистлык хезмәтен тиешенчә башкарып җиткерә алмаган намуслы партия кешесе" дип телгә алса да. Бу инде үзенә күрә бер төрле амнистия чарасы булгандыр. Вәләкин элеккеге үрләрен аңа кире кайтарып бирмиләр инде. Ни дисәң дә, 51-52 нче еллардагы золымнарны әле берәү дә онытмаган лабаса...

Үзәк Комитет әгъзалары арасында Игнатьев үзе күтәрешкән затлар да була. Шулардан берсе—50нче еллар ахырында Хрущевнең чынлыкта РСФСР эшләре буенча урынбасарына әйләнгән ҮК секретаре А. Б. Аристов белән мөнәсәбәтләре аеруча җылы була. 1953 елның декабрендә С. Д. Игнатьевның Мәскәү эпопеясы тәгәлләнә. Хрущев һәм Аристов тәкъдиме белән аны Башкортстанга партия өлкә комитетының беренче секретаре итеп җибәрәләр. Әмма аның язмышында тагын бер борылыш була. Бу хакта тәфсилләбрәк бәян кылыйк.

* * *

Монысы безнең Татарстан белән бәйләнгән. Без, гади партия әгъзалары, партия өлкә комитетының беренче секретаре З. И. Моратовның эштән алынуын авыр кичердек. Ул гадилеге, кешеләрне тыңлый белүе, эчкерсезлеге белән хәтердә уелып калды. Югары түрәләр алдында бик бил бөгәргә дә яратмый иде. Аңа алмашка Семен Денисович Игнатьев килде. Татарстан тарихында гаять тирән эз калдырып киткән олуг шәхес ул.

Мин әлеге хикәятемне Камил Фасеев истәлекләренә, үз истәлекләремә һәм иң мөһиме—документларга таянып бәян кылам.

Без Моратовны ни өчен эштән алганнарын тәгаен генә белмибез. Фаразларның берсе кукуруз кампаниясенә килеп терәлә, Моратов аңа тиешле кимәлдә игътибар биреп җиткермәгән, хәтта шуның өчен шелтә дә алган, янәсе. Аның эштән китүе ул тиклем хурлыклы булмады—ҮК инспекторы итеп билгеләделәр.

1957 елның июнендә үткән өлкә комитеты пленумында А. Б. Аристов ҮК

исеменнән С. Д. Игнатьевны беренче секретарь вазифасына тәкъдим итә һәм, гадәткә кергәнчә, ул бертавыштан раслана. Хәер, пленумда элеккеге секретарьның эшендә гаеп табучылар да булмый түгел, була. Ләкин Игнатьев моңа әлләни игътибар итми. Кем-кем, нәкъ менә ул арттан "чагуларның" бәһасен яхшы белә.

Пленумда шулай ук Татарстан совнархозы төзү мәсьәләсе дә карала. Аңа елына 10 миллиард сумлык продукция житештерүче 225 предприятие кертелә. Шул рәвешле, икътисадны һәм дәүләтне идарә итүнең Ленин заманындагы алымнарын тергезүнең чираттагы омтылышы ясала. Хрущев моңа үтә зур әһәмият бирә. Ул гомумән дә "сәяси археология" белән бик яратып шөгыльләнә.

Тәҗрибәле оештыручы һәм инженер буларак, Игнатьев республика икътисадының ике төп юнәлешен—нефть һәм химия тармагын үстерүгә зур өлеш кертә. 1959 елның июлендә Татарстан нефтьчеләре илдә беренче тапкыр тәүлеккә 100 мең тонна "кара алтын" чыгаруга ирешәләр. Сугыштан соңгы чорда Татарстан белән Башкортстанның нефть сәнәгатен үстерүдә Л. П. Берия зур роль уйнаган. Бу хакта КПСС ҮКының ГУЛАГ башлыгын фаш итүгә багышланган 1953 елгы пленумында нефть сәнәгате министры И. Байбаков төпле итеп сөйләде. Нәкъ менә Берия әлеге ике төбәктә сугыштан соңгы бишьеллыкта нефть чыгаруны ике тапкыр арттыру бурычын куйган. Ләкин илнең төп нефтьчесе боларның берсен дә Берия ил мәнфәгате өчен түгел, ә үз карьерасы өчен эшләгән дип мөһер суга.

Казанда Органик синтез заводын кору исә Игнатьев исеме белән бәйле. Хәзер дә бу предприятие республикабыз бюджетын хасил итүче төп чыганакларның берсе. Игнатьев оборона һәм, беренче чиратта, авиация сәнәгатен үстерүгә зур игътибар бирә. Аерым алганда, стратегик авиациябезнең яшерен сере булып саналган, тавыш тизлегеннән тизрәк очучы, Көнбатышта "Бэкфайр" дип аталган ТУ—22 бомбардировщигының Казанда житештерелә башлавына ирешә.

Ул шактый вакытын авыл хуҗалыгын чәчәк аттыру юнәлешендә Мәскәүдән әледән-әле килеп торучы рецептларга багышлый. Хәер, сак эш итә, үз башына азынган Рязань секретаре Ларионов кебек ит һәм сөт сатуда 2-3 план үтәү авантюрасына бармый. Бу унайдан ул ҮКның РСФСР буенча эш итүче секретаре, заманында үзе үстергән Аверкия Аристовтан шелтә дә ала. Ләкин ҮК белән мөнәсәбәте барыбер әйбәт булып кала. Ни дисәң дә, Татарстан тимер-томыр тапшыру буенча... өч план үти. Хәер, монда бик күп яраклы техниканың да тимер ватыгына әйләндерелүен онытмаска кирәк.

ҮК һәм Министрлар Советы аппаратында заманында Игнатьев үзе жаваплы урынга күтәргән, сүзе үтүчән кешеләрнең күп булуын да онытмыйк. Шуна күрә сәнәгать һәм бигрәк тә халык куллануы товарлары өчен Татарстанга фондлар алу әлләни кыенлык тудырмый. Шул чор күзлегеннән караганда, азык-төлек белән тәэмин итү дә бик үк начар булмаган. Игнатьев ил башкаласында үзенә кирәкле ишекләрне тибеп кенә ачып кергән диләр. Ә бу инде аның югарыда абруе зур булу турында сөйли. 1959 ел ахырында авыл хуҗалыгы йомгаклары буенча республика һәм өлкәләргә бүләкләр ява. Игнатьевка "Хезмәттәге батырлыгы өчен" медале бирәләр. Мондый түрәгә бирелә торган бүләк түгел түгелен, әмма Хрущев үзе дә шундый медаль ала.

Хакимияткә Игнатьев килгәннән соң кадрлар белән эшләүнең яңа, таләпчән тәртибе урнаша. Министрлар Советы рәисе вазифасын ул чакта Сәет Минһаж улы Шәрәфиев башкара. Ул республика тарихында шушы вазифага ике тапкыр куелган бердәнбер, легендар шәхес. Хәер, теориягә әлләни теше үтмәгән. Югары партия мәктәбендә ничә ел читтән торып укыса да, диплом ала алмаган. Әмма финанс эшләренә сәләтне Ходай аңа жәлләми биргән, ул авыл хуҗалыгын да биш бармагыдай белгән.

Берничә елдан соң миңа Шәрәфиев белән хастаханәдә бер палатада ятарга туры килде. Без китаплардан гына укып белгән нәрсәләрне абзый үз күзе белән күргән икән бит. Шулар хакында ачылып сөйләде ул миңа. Мәсәлән, 1937 елның көзендә финанс халык комиссары Шәрәфиев хөкүмәттә берүзе торып кала—барлык халык комиссарларын һәм аларның урынбасарларын кулга алып бетерәләр. Бөтен документларга да аңа кул куярга туры килә. Иртән хатыны эшкә алмаш кием һәм

азык-төлек салынган төргәк биреп озата торган була: кулга ала калсалар дип инде. Шөкер, афәт аны читләтеп уза.

Игнатьев кайбер кадрларны алмаштыра. Ләкин моны нинди мантыйкка таянып башкаруын аңлавы кыен. Мәсәлән, Моратов тарафыннан әхлаксызлыкта гаепләнеп куылган Бушневны ул кабат өлкә комитетына, партия-хуҗалык эшенә кайтарта. Өлкә комитетына һәм башка хакимият структураларына яшьләрне күпләп тарта. Бер үк вакытта аларның тышкы кыяфәтенә дә зур игътибар бирә. Тиз арада күтәрелгән яшьләрнең берсе университетның яшь доценты Ф. Табиев була. Ул өлкә комитетында фән һәм мәктәпләр бүлеге мөдире итеп куела.

Игнатьев үзен тәкәббер тотмый. Ул, мәсәлән, бүлек мөдиренә әйтеп тормыйча, турыдан-туры инструкторны чакыртып, аңа эш кушарга мөмкин. Үземне дә чакыртканы булды. Ләкин әгәр арадагы тиешле чикне бозасын икән, кемнең кем булуына карамастан, шундук шып итеп урынына утырта. Шулай бервакыт район башкарма комитеты рәисләреннән берсе бюрода урынсызга шаяртмакчы була. А. Лебедьныкыдай калын тавышы белән Игнатьев болай ди: "Эшеннең рәте юк, ә менә кәҗә "шомыртыдай" сүз сибәргә остасың". Тегенең авызы шундук ябыла.



*Татарстанга күчмә Кызыл байрак тапшыру. Сулдан уңга: КПСС Үзәк Комитеты секретаре академик П. Поспелов, С. Игнатьев, Татарстан Министрлар Советы рәисе А. Абдерәзаков, К. Фасеев.*

Игнатьевның интеллигенция вәкилләренә, ягъни зыялы затларга һәм гомумән мәдәнияткә булган мөнәсәбәте турында сокланмыйча язу мөмкин түгел. Ул каләм әһелләрен һәм галимнәрне теләп кабул итә. Күпләргә бу заманда бик интектергән торак мәсьәләсен хәл итешә. Күренекле мәдәният эшлеклеләренең Тукай премиясен булдыру турындагы тәкъдимен бик теләп яклап чыга. Ә менә Игнатьев эшеннән киткәч, финанс кытлыгы сылтавы белән, ошбу бүләк берничә ел бирелмичә торды. Фасеев истәлекләренә караганда, ул Гражданнар сугышында катнашкан талантлы әдип Гомәр Бәшировны республика Югары Советы Президиумы рәисе итеп куярга тели. Моның өчен иң әүвәле аны КПСС өлкә комитеты бюросына сайларга кирәк була. Ләкин нindидер сәбәп белән бу кыю адым ясалмыйча кала.

* * *

Язмабыз каһарманының мәктәпләрдә татар теле статусын яңадан торгызуга уңай карашын онытасыбыз юк. Ул вакытта мин өлкә комитетында фән һәм мәктәпләр бүлеге инструкторы булып эшли идем. Әлеге олуг мәсьәләне хәл итүдә миңа да беркадәр катнашырга туры килде. Чөнки киеренкелек тулы бу хәлләр документларда тулы килеш теркәлмәгән, өстәвенә, матбугатта чынбарлыктан ерак торган мәгълүматлар да басылгалый.

Ул чактагы вәзгыятьне кыскача болай дип аңлатырга мөмкин. Татар халкының рухи тормышын мәҗбүриләп дигәндәй "интернациональләштерү" теленең йотылуына китерде. Ул укыту, фән һәм эшлекле аралашу даирәсеннән ерагайды. 20нче—30нчы еллар башындагы татар теленә жентекләп өйрәтүче байтак кына милли сәясәт казанышлары юкка чыкты. Ул чакта бит югары уку йортларында татар телендә укыту группалары бар иде. Кайбер структураларның җитәкчеләре тикшерелгән нәрсәләрне аңлау кимәлендә булса да татар телен белергә тиеш иде. 30нчы еллар ахырында да әле өлкә партия конференциясендә отчет докладлары ике телдә ясала иде.

Бу хәл җәмәгатьчелекне тирән борчуга салды. Шул уңай белән өлкә комитетына

һәм ҮКка хатлар агылды, жыелышларда чыгышлар ясалды. Фаразан, мондый жанлылыкка КПССнын XX съездыннан соң башкачарак уйлаган өчен физик юк итү, репрессияләү мөмкинлеге бетерелү дә китергәндер. Шулай ук 30нчы елларда зобанилыклар өчен бар гаепне НКВД хезмәткәрләренә аударып, үзләре кулэгэдә калган сәяси заказчылар, махсус хезмәтләр дә артык активлык күрсәтмиләр иде.

1954 ел ахырында республика мәгариф министры Әминә Вәлиуллина татар мәктәпләрендәге хәлне пленумда карыйк дигән үтенеч белән Игнатьевка мөрәжәгать итә. Бу унайдан Игнатьевнын үзен ничек тотуы хакында хәзер тәгаен нидер әйтү кыен. Ләкин өлкә комитетынын ул чакта татар теленен элекке статусын кайтарунын анардан да активрак пропагандисты булмый. Игнатьевны КПСС ҮКнын бүлек мөдире урынбасары В. Н. Дербинов та яклап чыга, Казанга килгәч, өлкә комитетынын бу җәһәттән тырышлыгын ленинчыл милли сәясәтне гамәлгә ашырунын тарихи үрнәге дип бәяли.

* * *

Партия өлкә комитетынын 1958 елнын 21 маенда үткән пленумы бу эшнен ин югары ноктасы була. Анын көн тәртибенә "татар гомуми белем бирү мәктәпләрендә эшнен торышы һәм аны яхшырту чаралары турында"гы мәсьәлә куела.

Доклад белән өлкә комитеты секретаре К. Ф. Фасеев чыгыш ясый. Шуна хәзер бу хәлләргә Камил Фасеев күзе белән дә карарбыз.



*С. Игнатьев һәм К. Фасеев (уңда).*

Фасеев әйтүенчә, Игнатьев, үзенен элгәре Моратовтан аермалы буларак, милли проблемаларга да битараф булып калмый, аларны хәл итү юлында кыюлык күрсәтә. Башкортстан өлкә комитетынын идеология буенча секретаре, партия мәктәбендә бергә укыган сабакташы Сәйранов та Фасеевка шулай дип сөйләгән. Бу, минемчә, дөреслекнен бер өлеше генә. Фасеев үзе дә Мәскәү архивларындагы мона кагылышлы бөтен документларны да күрмәгәндер. Монда шуны анларга кирәк: милли мәсьәләләрне татар кешесе Моратовка караганда рус кешесе Игнатьевка хәл итү күпкә җиңелрәк булгандыр. Болай дип әйтеп мин һич кенә дә Игнатьевнын хезмәтен киметеп күрсәтергә җыенмыйм. Чөнки югарыда, ҮКта үзе күтәргән егетләр аны читкә какмагандыр. Бу җәһәттән, Хрущевнын ун кулы саналган А. Б. Аристовны искә төшерү дә житә торгандыр...

1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы искитмәле зур уныш

белән уза. Республикабызның иҗат әһелләре бүләкләр "яңгырында" коена. Башка очракта андый кадер-хөрмәтне дистә ел буе күтәргә туры килер иде... Партия-совет әһелләренә дә өлеш чыга. Фасеевка "Почет билгесе" ордены бирәләр. Өлкә комитеты бюросы әгъзаларының һәм кайбер бүлек мөдирләренең тар даирәсендә Декада йомгаклары турында сөйләшү, дип яза Фасеев, телне чишә, тыелган темаларга да кагылалар. Менә Игнатьевның әлеге темаларга унай мөнәсәбәте дә тәэсир итми калмагандыр. Шунысы кызык, берләштерелгән ике бүлек—фән, мәдәният һәм уку йортлары бүлекләре мөдире Фасеевка ике тапкыр сүз бирәләр. Монарчы сүз күтәренке рухта барса (җырлау-бию дигәндә татар булдыра ул, инде менә милли операга да тиеңдәк!) Фасеевның хәзерге мәдәниятебезнең төп нигезе булган милли мәктәпнең үлемгә йөз тотуы турында әйтүе аяз көнне күк күкрәү кебегрәк кабул ителә. Милли мәктәбең, телең булмаса, бик җырлый алмассың.

Бу сүзләр рәсми рәвештә әйтелмәсә һәм беркетмәгә теркәлмәсә дә, югары түрәләр битараф калмый. Сүзенең кемгә ничек тәэсир иткәнлеге турында Фасеев җентекләп, хәтта исемләп-фамилияләп искә ала. Бигрәк тә Татарстанның төп идеологы С. Батыевның "авызына су кабып утыруына" гаҗәпләнүен белдерә. Бу очракта ул ихлас ук түгелдер. Камил Фатыйх улы бу түрәнең ни өчен тын утыруын белгән, әлбәттә. Белмәгән булса, үзем әйтә алам. Салих Гыйлемханович белән минә күп тапкырлар гәпләшергә туры килгәне бар, беләм: тәҗрибәле сәясәтче буларак, Игнатьев Фасеев тасвирлаган авыр хәл өчен гаепле кешене тиз билгели: Батыев. Икәүдән-икәү калганда Игнатьевтан ул кискен-кискен шелтә сүзләре ишетә, беренче секретарь аларны соңыннан бюро утырышында да кабатлый.

Элек тыелган күп документлар ачылганлыктан, миңа—тарихчы кешегә, хәзер "Игнатьев феномены" турында уйлау кызык. Минемчә, Игнатьевның татар мәдәниятенең түбән тәгәрәвен туктату ниятендә азмы-күпме ихласлык та булгандыр. Шулай ук милли азчылыкка ярдәм кулы сузган рус кешесенең менә без нинди киң күңелле дигәндәй амбициясен дә онытырга ярамый. Моның алдан уйланган, сәяси адым булуы да ихтимал. Чөнки куәтле нефтькә һәм зур биеклеккә ирешкән милли мәдәнияткә ия Татарстан аны кабат Мәскәүдә абруйлы кәнәфигә күтәрәчәк трамплин була ала дип уйласа да гаҗәп түгел. Татарстанда озак торырга җыенмавын ул үзе дә яшермәгән.

Киңәшмәдә дә Игнатьев Фасеевны яклап чыга, асылда аның кулына "козырь картасын" тоттыра. Һәммәсен дә уйлап эш йөрткән сәясәтче Игнатьев Мәскәүдәге кайбер абруйлы затларның яклап чыгуына өмет иткәндер. Минемчә, аның Аристов хатынына Казан мәктәпләре нигезендә диссертация язарга тәкъдим итүе дә шул җәһәттән булгандыр. Миңа баштагы дәвердә бу эшнең кураторы булырга туры килде. Семен Денисовичның Аристов хатыны янында үземне ничек тотарга өйрәткәнен дә яхшы хәтерлим. Хәер, Людмила Павловна үзе дә шактый гыйлем кеше иде, кайчандыр мәктәп директоры булып эшләгән. Үз диссертациясен язганда ул Казанның күп кенә укытучыларын һәм мәгариф хезмәткәрләрен фән дөньясына алып керешә әле.

Татар теле һәм мәдәнияте язмышын хәл итәргә тиешле пленум алдыннан алып барылган әзерлек чараларының исемлегенә күз төшерү генә дә Игнатьев белән Фасеев ниятенең никадәр җитди булуын чамаларга мөмкинлек бирә. Мондый да саллы, төпле пленум өлкә комитеты тарихында беренче тапкыр үткәрелә! Аңарчы исә укытучылар, роно мөдирләре, язучылар һәм партия хезмәткәрләренең киңәшмәләре булып уза. 1957 елның ноябрендә Мәскәүнең күренекле язучылары катнашында балалар әдәбиятына багышланган конференция үткәрелә. Гәрчә докладны мәдәният министры Х. Рәхмәтуллин ясаса да, анда катнашучыларның төп игътибарын Игнатьев чыгышы җәлеп итә. Ул татар мәдәнияте белән озаклап һәм җитди рәвештә шөгыльләнәчәкбез дип белдерә, аның матди базасын ныгыту җәһәтеннән байтак вәгъдәләр бирә.

Шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә татар мәктәпләренең стихияле рәвештә руслаша баруы аеруча хәвефләндерә.

Өлкә комитетында кадрларны алмаштыру дәвам итә—декабрьдә Фасеев идеология секретаре итеп куела, ә фән, уку йортлары бүлеге мөдире итеп кө тмәгәндә доцент-политэконом Табиев билгеләнә. Мин тиешле тәҗрибәсе булмаган, әмма бик

тә тәкәббер һәм елгыр, өйрәнергә һәм сабаклар алырга сәләтле бу кешенең өлкә комитетына шактый очраклы рәвештә урнашуы хакында язган идем инде. Аның бүлек мөдире, аннары тиз арала идеология секретаре булуына унай карыйм үзе.

* * *

Менә вакыйгаларның иң биек ноктасы булган көн дә житте. Аның хакында хәзер ялган белән буталган төрле риваятьләр йөри. Татар мәктәпләре турындагы мәсьәләне пленум тикшерүенә куйганда Фасеев "татарлаштыру" процессын—аның иң тыйнак вариантында—элекке хәлгә кире кайтып булмаслык итәргә омтылды. Баштарак хәтта Игнатьев үзе дә моны әүвәлге милләтчелек шаукымы димәсләрме дип шикләнеп калды. Чөнки "милли мәдәният" төшенчәсен реаль эчтәлек белән баетырырга омтылганнары өчен система тарафыннан юк ителгән Солтангалиев, Мохтаров, Брундуков, Мансуров һәм Галимҗан Ибраһимов кебек каһарманнарның күзгә күренмәс сыннары 40 елдан соң янә шушы эшкә тотынучыларның аңында янарды. Ләкин сәяси "жепшеклек" рухы өметкә дә урын калдыра иде...

Мәскәү моңа рөхсәтне ҮК бүлекләре һәм РСФСР мәгариф министры аша бирә, КПСС Үзәк Комитеты секретаре Аристов та телдән ризалыгын белдерә. Мәңгелек дус-көндәш башкортларга хәбәр ителә. Аларда милли мәктәп проблемасы, мөгаен, тагын да кискенрәк торгандыр. Чөнки гомерлек четерекле мәсьәлә—белем бирүдә татар һәм башкорт компонентларының нисбәте гел өскә калкып чыга.

Пленум 1958 елның 21 маенда ачыла. Анда партия Үзәк Комитетының мәктәпләр бүлеге мөдире В. Н. Дербинов һәм бер атна дәвамында Татарстан районнары мәктәпләрендәге хәлнең торышын өйрәнеп кайткан ике инструктор катнаша. Язмышның усал шаяруыдыр бу, 35 ел элек нәкъ менә шул көндә Политбюрода Лубянка төрмәсендә утырган Солтангалиевнең тәүбәгә килү хаты тикшерелә. Ул чакта шулай ук милли мәдәният белән мәктәпнең кискен проблемалары да карала. Солтангалиевне төрмәдән азат итәргә, әмма партиядән чыгарырга дигән фикергә киләләр: атып үтерергә беркайчан да соң түгел, хәзергә аның язмышы республикаларның партия документларында язылган хокукларын тормышка ашыру артыннан йөрүче милли эшлеклеләрнең йөрәгенә шом вә өркү салсын әле. Яки, яшерен бер киңәшмәдә Сталин мыскыллап әйткәнчә, "исән икәнлекләрен белдереп, әтәчтәй кычкырып йөри бересеннәр шунда". Ул моны Татарстан Совнаркомы рәисе Мохтаровка карап әйтә, ләкин бу барысына да кагыла.

Фасеевның татар мәктәпләрендәге хәлнең торышы, киңрәк мәгънәдә тел һәм мәдәният язмышы турындагы докладын бүген дә кызыксынып укыла. Аны Ленинннан күпләп китерелгән өземтәләргә таянып, татар мәктәбенең үлеменә китерүче вәзгыятьнең түзеп тормаслык булуын виртуозларча осталык белән исбатларга тырышу дип әйтергә кирәк. Фасеев тарафыннан китерелгән мәгълүматлар чәчләрне үрә торгызырлык... Әгәр 1947-1948 елларда татар балаларының 95 проценты туган телендә укыса, 1958 елда бу—70 процентка, Казанда исә 16 процентка кала. Шәһәрдә 16 татар мәктәбенең нибары икесе исән, алары да соңгы көннәрен яши.

Докладта татар мәктәпләренең чынлыкта "дискриминацияләнүе" турында, гәрчә бу термин үзе әйтелмәсә дә, башка төрле мәгълүматлар да китерелә. Татар мәктәбен тәмамлаучыларга югары уку йортына керү мөмкин түгел диярлек. Мәсәлән, КАИның 1нче курсына алынган 750 студентның 113е генә татар, шуларның фәкать 11е генә ана телендә укыган. Башка вузларда да хәл шул чама.

Доклад беркемне дә битараф калдырмый, әмма аңа мөнәсәбәт төрлечә була. Тәнәфес вакытында бер активист минем янга килеп: "Моның өчен хәтта Игнатьевның да башыннан сыйпамаслар",—диде. Докладтан соң тагын 8 кеше чыгыш ясады. Шулардан иң кызыклыларына тукталыйк. Мәсәлән, пединститут ректоры Йосыф Туишев вуз житәкчеләре арасында иң зыялы, иң акыллы һәм иң тыйнаклардан булгандыр (кызганыч ки, алмашка килгән әрсез затлар аның хезмәтләрен бик тиз оныттылар). Ул әле 1955 елда ук, жаваплылыкны үз өстенә алып, барлык факультетларда да татар телендә укытуны кертканлеген әйтә. 1957 елда исә физика-математика факультетында милли мәктәпне тәмамлаучылар өчен бүлек ачканнар.

Язучы Гомәр Бәширов шактый кискен чыгыш ясый. Хакимият кияләренә һәм татар зыялыларының үзләренә шелтә белдерә. Туган телебезгә югарыдан түбәнсетеп караудан туктарга вакыт, дип кисәтә. Олпат композитор һәм консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов югарыдагылар алдында тәлинкә тотмыйча, һәрвакыттагыча бик кыю-кискен чыгыш ясый. Ул мондый фикер ирештерә: тел һәм музыка—милли рух белән мәдәниятнең аерылгысыз нигезе ул, иң беренче чиратта шулар хакында кайгыртырга кирәк. Хәер, опера театрында Европа һәм рус композиторларының татар теленә тәрҗемә ителгән классик әсәрләрен куярга кирәк дигән тәкъдиме әлләни яклау тапмады. Чыннан да, монда уйланасы бар. Ленский ариясе хәтта украин телендә дә сәер яңгырый.

Иң мөһиме, башка ораторлар да тәнкыйть күзлегеннән чыгыш ясадылар. Әмма барысы да Дербинов белән Игнатьевның чыгыш ясауларын көтә иде. КПСС Үзәк Комитетының бүлек мөдире докладның тәнкыйди рухын саклап, хәтеремә уелып калган мондый мисал китерде—татар мәктәпләрендә укучыларның нибары 12 проценты гына 10 класска хәтле барып житә икән, бу рус мәктәпләрендәгедән ике тапкыр кимрәк. Әмма иң үткен, иң аяусыз чыгыш Игнатьевның кыскача йомгаклау сүзе булды: "Эшләр түзеп тормас дәрәҗәдә начар бара. Без чынлыкта татар мәктәпләренең бетү куркынычы алдында торабыз... Мин Фасеев докладындагы һәм карар проектындагы фикерләр һәм нәтиҗәләрне тулысынча хуплыйм". Игнатьев үзенә маневр өчен урын калдырмый, ул киләчәктәге карьерасы язмышын кузнага куя... Мөгаен, Г. Бәширов аның хакында: "Шушы рус житәкчесе теләсә кайсы татарга караганда безгә күбрәк эшләде",—дип әйтүе белән хаклыдыр да. Игнатьевның татар иҗат әһелләре белән очрашуыннан соң Нәкый Исәнбәт тә шундыйрак фикер әйтте. Игнатьев бик кыю адымга барды. Г. Тукай исемендәге премия булдыруга рөхсәт бирде. Бу исә Мәскәүгә бер дә ошамады. Чөнки үзәктәге кайбер идеологлар фикеренчә һәм Мәскәүнең жирле куштаннары әйтүенчә, шагыйрь әсәрләреннән милләтчелек рухы бөркелеп тора икән.

Йомгаклау сүзендә Игнатьев милли үсеш һәм тел проблемалары аны күптәннән борчуын, ләкин бүген бу хакта инде барысы да ишетерлек итеп әйтергә мөмкинлек тууын бәян итте һәм бик ачынып болай дип өстәде. "Мин шундый нәтиҗәгә килдем, эшләр чынлап та бик мөшкел. Без татар мәктәбенең асылда юкка чыгарылу куркынычы алдында торабыз." Кайдадыр кухняда яисә дус-ишләр арасында түгел, ә өлкә комитеты пленумы төрбәсеннән әйтелгән шушы сүз өчен генә дә С. Д. Игнатьев исеме татар мәдәнияте тарихында калырга тиеш. Бәлкем, бер төбәктәге милли сәясәт хакында рус кешесе, югары даирәдәге эшлекле, ҮК әгъзасы тарафыннан мондый сүзнең әйтелүе сугыштан соңгы чорда иллә дә беренче тапкыр булгандыр әле. Бу хәл, әлбәттә, Мәскәүгә ошамагандыр...

Пленум карарында соңгы елларда ана телендә укучы балалар саны 95тән 70 процентка, Казанда исә 16 процентка гына калуы, татар мәктәпләренең матди хәле начараюы, аларның саны кимүен, кадрларның сыйфат ягыннан зәгыйфьләнүен күрсәткән бик күп дәлилләр китерелә. "...Рус мәктәбендә белем алучы татар балаларының күпчелек өлеше ана телен һәм әдәбиятын өйрәнми һәм белми, шунлыктан туган телен начар беләләр яки бөтенләй белмиләр, татар халкы гасырлар буена тудырган мәдәнияттән читләшәләр" дигән нәтиҗә дә актуальлеген жуеп бетермәде әле. Шундый да кискен итеп әйтелгән ки бу, "Игнатьев чорыннан" соң 10-15 ел үткәч, мондый сүз әйтүчене диссидент дип санарлар иде. Карарда кимчелекләрне бетерүнең киң программасы да бирелә. Анда махсус уку йортларында татар группалары ("коренизированные группы" диелгән) булдыру, өлгергәнлек аттестатында яңадан татар әдәбияты буенча билге куя башлауларга кадәр күрсәтелгән. Әмма шунысын да әйтик, ул вакытта күтәрелгән, йөрәкне әрнеткән мәсьәләләр, пленумның байтак тәкъдимнәре, өлешчә генә булса да, фәкать безнең көннәрдә чынга ашты...

Шунысын да әйтик, Игнатьевның һәм аның тарафдарларының (шул җөмләдән, К. Фасеевның) изге эш-гамәлләре башка төрле сәясәткә күнеккән, үз мәнфәгатьләре хакына теләсә кемгә тәлинкә тотучы тел белгечләрендә, телләрнең якынаюына һәм хәтта кушылуына китерүче якты киләчәккә дан жырлаучы, фән тирәсендә чуалучы бәгъзе затларда тискәре хис-тойгылар уяткан.

* * *

Пленум карары нигезендә тиешле документлар һәм инструкцияләр кабул ителде. Кайбер оештыру эшләре башкарылды. (Аяк чалу, саботаж очраклары да булгалады.) Ләкин сәяси офыкта инде беренче "болытлар"да пәйда булды. Милли мәктәпнең һәм ана теленең абруен күтәрүдәге бу унай үзгәрешләр Мәскәүне борчуга сала. РСФСРдагы бер генә милли республика да безгә ияреп мондый карар кабул итмәде, "кузгалырга" җыенган башкортлар да гадәттәгечә татарларны "куып житәргә" ашыкмадылар. Күрәсең, "югарыдан" әйткәннәрдер.

1953 елның мартында К. Фасеев ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе итеп куела. Горур вә матур яңгыраучы вазифа, ләкин тыштан гына шулай бу, чөнки парламент башлыгының барлык Указлары да башта өлкә комитетында раслана иде. Мин өлкә комитетында эшли башлаганда раслау сүзләре мондый иде: "ПВС (ягъни Югары Совет Президиумына) фәлән Указны менә мондый редакциядә басуны рөхсәт итәргә". Сонрак гыйбарә бераз йомшартылды: "Указ текстына ризалык бирергә"...

1959 ел ахырына якынлаша. Өлкә комитетының икенче секретарь итеп куелган С. Г. Батыев отыры зуррак көч туплый бара. Ул чорда 2нче секретарь инде ул Мәскәүнең күзе дә, колагы да. Игнатьев белән Батыевнын үзара мөнәсәбәтләре гел киеренкеләнә барды, чөнки татар мәктәбе кичергән барлык кыенлыклар өчен гаепле итеп әле сугыш елларында ук төрле югары урыннарда идеология эшенә житәкчелек иткән шушы кешене күрсәтмәкче иделәр. Аларның бер-берсе белән бюрода чәкәшкәне хәтеремдә калган. Беренче секретарьның ярым шаяртып: "Монда синең дә гаебең бар, Салих",—дип әйтүенә каршы Батыев бик кырыс итеп җавап кайтарды: "Мин барысын да ҮК күрсәтмәсе белән эшләдем, җавабын да анын алдында бирермен..."

Ул вакытта Моратов Мәскәүдә Үзәк Комитетта инспектор булып эшли. Әлләни зур йогынтылы вазифа түгел бу, ләкин тагын да югарырак утырган эшлекләләр белән аралашырга мөмкинлек бирә. Өлкә комитетының идеология буенча секретаре итеп Табиев куела. Ул "келәм асты уены" кагыйдәләрен тиз үзләштереп ала һәм үзенең беренчегә тугрылыклы икәнен туктаусыз сиздереп тора. Шунысын да әйтим әле, Игнатьев тар даирәдәге житәкчеләр белән беренче тапкыр очрашканда үзенә алмаш итеп Батыевны күрүен әйткән иде. Казанда озакка калырга җыенмавын да әйтте. Вәләкин үзара тартыш башлангач, ул ҮКның оештыру эшләре бүлеген Табиев кандидатурасына күндерә алган.

* * *

"Татарлаштыру" тарихы күнелсез тәмамланды. Мәскәүгә Игнатьевны милләтчелеккә юл ачуда гаепләп язылган хатлар агылды. Үзәк Комитетка шундый ук фикердә торган Моратов та мөрәҗәгать итә (бәлкем, ана югарыдан шулай кушканнардыр).

Игнатьев, күрәсең, үзен ни көткәнен чамалагандыр. Ләкин Батыев аның өчен хакимиятне һич тә үз кулына алырга тиеш булмаган "Карфаген"га әверелә.

Пәрдә артында, хәтта ки Кремль табибларын да катнаштырып уйналган күп йөрешле уеннан соң ул ниятенә ирешә. Өлкә комитетның беренче секретаре итеп Табиев сайлана. "Дару ачысын" тәмләү өчен Батыевка мактаулы, әмма декоратив вазифа йөклиләр—ТАССР Югары Советы Президиумы рәисе итеп куялар. Моның өчен гомер буе башкорт булып йөргән Батыевка тиз арада татарга әйләнергә туры килә. Ул бер дәүләт-сәясәт урынында эшләү вакыты буенча абсолют рекорд куйды, хәтта үзенең күп бәхетлерәк көндәше Табиевны да уздырып, 23 ел Президиумны җитәкләде. Аңарчы шушы урынны биләгән Фасеев исә Тел, әдәбият, тарих институтына директор итеп эшкә урнаштырылды.

Мәскәүдә бик тә югары кимәлдә, уйлавымча, Сусловтан түбәндәрәк булмас, "татар экспериментын" туктатырга дигән карар кабул ителә. Моның сәбәпләре күп төрле булгандыр. Беренчесе, әлбәттә, башка автономияле республикаларда "милләтчелек" рухы уянуга юл куймау. Чөнки "милли мәктәп" һәм "тел" төшенчәләре, үзәктәге кайбер идеологлар фикеренчә, тагын да куркынычрак бүкигә—"буржуаз милләтчелеккә" китереп житкерергә мөмкин. Татарстанда әле

янарак кына булган Венгрия вакыйгаларының "кайтавазын" ишетүчеләр дә табыла. Бу илдә дә бит барысы да әдәбият белән телдән башланган... Боларны, күрәсең, Игнатьевка әйбәтләп төшендергәннәрдер һәм ул Мәскәүгә зур урынга әйләнеп кайту турындагы хыялының чәлпәрәмә килүен аңлагандыр.

Фасеевның фаразына караганда, барысы да Моратовның өлкә комитетына юллаган вәрәкасеннән (записка) башланган. Ул анда Фасеевны милләтчелектә, өлкә комитеты бюросын исә аның кубызына биюдә гаепли. Хәлбуки, бу кәгазьнең һәм шуна ияртеп җибәрелгән, өлкә комитеты карарын янадан тикшерергә тәкъдим иткән хатның һаман табылганы юк әле. Юкса Фасеев аларны үз күзем белән күрдем дип раслый. Тәҗрибәле аппаратчы (һич кимсетеп әйтүем түгел) Фасеев Үзәк Комитет инспекторының башында Игнатьев кебек зур фигура торган өлкә комитетын милләтчелектә гаепләве бер Моратовка гына бәйле булмавын чамаларга тиеш иде ләбаса.

Гомумән, һәммәсе дә бөртекләп алдан язып куелган монда. Әлеге мәсьәлә буенча үткәрелгән бюро утырышында Фасеевның дөрес эшләдек дип исбатларга тырышуы донкихотлык үрнәге буларак мактауга лаек, әлбәттә. Әмма мәсьәлә хәл ителгән инде. Игнатьев хәзер бик түбәнсетмәслек чигенүне, тәүбәгә килүне оештырырга тиеш була.

Фасеев үзе бу манзараны менә ничек сурәтли. Батыев һәм Министрлар Советы рәисе Габдерәзәков Моратовның кайбер гаепләүләрен хуплап чыгыш ясыйлар. Бюроның башка әгъзалары, шул җөмләдән Табиев та, дәшми калалар. Бу үзе үк хәлнең ни дәрәҗәдә киеренке булуы турында сөйли. Табиевның ул беренче чордагы уңышы күпмедер дәрәҗәдә әнә шулай дәшмичә кала алуы, пауза ясый белүенә бәйле.

Сөйләүчеләрне тыңлаганнан соң Игнатьев кара көеп, Пленум карарын гамәлдән чыгарабыз, диде. "Гамәлдән чыгару" 1960 елның гыйнварында булды. Май пленумы карары бернинди дә фикер алышуларсыз гына юкка чыгарылды. Бу чигенү генә түгел, җиңелү—капитуляция иде. Ул бихисап татар кешеләре аңында вә җанында тирән эз калдырды...

Игнатьевның сәяси карьерасы ахырына якынлашты. Монда инде Аристов та ярдәм итә алмый иде, бәлкем, теләмәгәндер дә... Актив сәяси тормыш алып барудан һәм дөнья куу мәшәкатьләреннән суынгач, Салих Гыйлемханович тирәнтен ачыну белән миңа әлеге "детектив"ның кайбер нечкәлекләрен ачкан иде. Игнатьевка кешечәрәк китү, әйтик, Монголиягә илче булып бару вариантын тәкъдим итәләр. Ләкин ул сәламәтлеге аркасында отставкага чыгуны артыграк күрә. Юкса ана 56 гына була әле. "Геронтократия" девере бит бу. ҮК секретаре Кириленконың халык каршында телен көч-хәл белән әйләндереп: "70 яшь бездә уртача яшь ул",—дип әйткәне хәтердә калган.

Мәскәүгә киткәндә, инде кузгалган поезд тамбурыннан Игнатьев үзенең яшь алмашына: "Фикрәт, кара аны, халыкны ашатырга онытма",—дип кычкырган имеш. Шәп киңәш. Ләкин ул Мәскәүнең республикага байтак ташламаларны һәм икътисади булышлыкны фәкать бирелә үзе булганга гына биргәнен белгән, әлбәттә.

Ни генә булмасын, ни генә сөйләмәсеннәр, Игнатьевны халкыбыз күбрәк уңай яктан хәтерли.

Семен Денисович көтелмәгәнчә адым ясарга, халык теленә кирәклек гамәлләр кылырга һәвәс иде. Мәсәлән, Казанга килүенең тәүге көннәренең берсендә кибеткә кереп, бер кило вермишель үлчәп бирүләрен үтенә ул. Сатучы хатын исә пакет ясарга кәгазь юклыгын әйтә. Бу ир-ат, миңа нишләргә соң инде, дигәч, сатучы: "Әнә эшләпәгезгә салыйк",—ди. Һәм Игнатьев бернинди карышусыз баш киемен сатучы алдына куя... Бер сәгать тә үтми, өлкә комитетында сәүдә министры һәм башка җаваплы түрәләр үрә катып эшләпәгә текәлеп карап торалар (монда ниләр әйтелгәнен язып тормыйм инде. Моратовтан аермалы буларак, Семен Денисович аты-юлы белән сүгенүдән дә тайчанып тормый иде. Хәер, лексика мәсьәләсендә алмашы анардан да уздырып җибәрде. Заманасы башка иде шул, һәм бу гадәти хәлгә әйләнде. Хәер, бүгенгеләр тагын да "югарырак" үрнәкләр күрсәткәлиләр). Кәгазьгә килгәндә исә, тиздән ул кибетләрдә пәйда була. Күпмедер вакытка...

...С. Д. Игнатьев гомеренең өч елын (1957-60) Казанда үткәрде. Шуннан соң

23 елын Мәскәүдә яши ул. Отставкага чыккан лидерлар гадәттә кайнап торган тормыш алып баралар, күз уңында булырга яраталар. Игнатьев исә үз бәясен белеп, тыныч тормыш кичерә, персональ пенсионерларның тусовкаларына йөрми, пионерларны үзеннән үрнәк алырга өндәми. 70нче елларда, юбилей уңае белән, аңа орден тапшырдылар. Ул 1983нең ноябрендә дөнья куйды һәм Ново-Девичье зиратында җирләнде...

* * *

Шул рәвешчә, татар телен һәм татар мәктәбен җәмгыять тормышының тулы хокуклы компоненты итәргә тырышудагы икенче омтылыш та (беренчесе 20нче еллар башында ясалды) һәлакәткә дучар булды. Фасеев "татарлаштыруның" күп кенә фактларын дөрес бәян кылса да, Игнатьевка кирәгеннән артык кырыс бәя бирә, "ул татар мәктәпләрен торгызу һәм ныгыту мәсьәләсен җиңел генә сызып атты", дип ассызыклый. Ләкин Игнатьевны академик Сахаров белән дә, генерал Григоренко белән дә бутарга ярамый. Ул Сталин чорында тәрбия алган зур сәяси эшлекле иде. Күп нәрсәдән мәхрүм каласын тойган тәкъдирдә дә тәвәккәләп татар халкы өчен игелек кылырга омтылуы үзе үк олы рәхмәткә лаек. Аңардан соң хакимияткә килгән кайбер татарлардан шуның белән аерылып тора да инде ул.

Тормыш исә ага бирә: өлкә комитетның яңа җитәкчелеге Тукай бүләге тапшыруны туктата һәм "тугрылыклы хезмәт итүнең" башка төрле адымнарын да ясый. Фасеев әнә Табиевның әхлак кагыйдәләрен бозуы турында яза. Нәрсәгә ишарәләвен әйтә алмыйм, әмма беренче секретарь Мәскәү алдында тәлинкә тотуда ай-һай оста һәм елгыр булды. Республиканың Игнатьев чорында тапланган абруен "аруларга" кирәк була бит. Шул җәһәттән өлкә комитетының 1960 елның октябрендә үткәрелгән пленумында Табиев, "Татар теленең ролен һәм әһәмиятен күпертеп күрсәтүнең мәгънәсе юк, шулай эшләргә маташучыларны гаепләргә кирәк",—дип искәртте. Фасеев язуынча, Табиев тагын 15-20 елдан татар теле бетәчәк дип фараз кылган, моны ул тар даирәдә түгел, өлкә комитеты пленумнарының берсендә әйткән. Хәер, ул чорда шулай дип уйлаучы "интернационалистларның" исәбе-хисабы юк иде.

**Редакциядән:**

***Тарихчы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, профессор Булат Фәйзрахман улы Солтанбәковка 80 яшь тулды. Булат ага—журналның күптәнге авторы. Ул әзерләгән, "Солтангалиев эше" дигән мөһим документ (үзенең кереш мәкаләсе белән) һәм гарәп графикасындагы язу машинкасын эшләгән Әскәр Шәех-Али турындагы зур очеркы "Сүнмәс утлар балкышы" дигән китабыбызга да кертелде.***

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Миркасыйм
Госманов

### РЕЖИССЕР ХЫЯЛЫ ҺӘМ КЫРЫС ЧЫНБАРЛЫК

"Әгәр бик яшерен сер, яки тегендирәк, ягъни интимрак ният булмаса, миңа да әйтерсең. Белеп кенә торырмын, башкаларга сөйләмәм серенне... Бәлкем киңәшүнәш та кирәк булуы мөмкин. Һич югы, комачауламам",—дидем.

Дамир беравык сүзсез утырды. Аннары яртылаш тартылган челемен сүндереп тормыйча савытына ыргытты да, миңа күтәрелеп карады:

—Бар андый хыялым,—диде.—Монарчы ачык итеп әйтеп йөрмәгән серем бар, Миркасыйм абый. Ярар, әйтим инде, сез сорагач..."

Истәлек героеның тулы исеме—Дамир Сиражиев.

Рәфикъ
Юныс

# КАРАБЫБЫЗ БАТЫП БАРГАНДА...

## "Мин калырмын җирдә соңгы татар булып"

*Кайсы юллар,*
*Нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?!.*
(Дәрдемәнд. "Караб")

Татар карабы[1] революциядән соңгы болгавыр елларны кичә алды ул. "Диңгез" безне бихисап асыл затларыбыздан, рухи һәм матди байлыкларыбыздан мәхрүм итсә дә. Безне тулаем йотачак упкын XXI гасырда көткән икән ул. Бәйсезлек дип шашынулар, гимн, герб, флаг, Конституциягә тиенүләрдән соң...

Юк, бернинди ярсу дулкыннар, давыл-өермәләр дә булмаячак, чоңгыл безне тып-тын гына суырып алачак. Көндәлек мәшәкатьләр белән мәшгуль милләттәшләребезнең күбесе моны, мөгаен, сизми дә калыр.

Менә мин дә Фәннүр Сафинның юбилей кичәсенә бернинди борчылу-фәлән тоймый гына барган идем. Кичә үзе бик әйбәт үтте ул. Әмма буш урыннар күп иде. Юкса 44 яшендә фаҗигале төстә дөнья куйган кордашымның шәхесе дә, шигърияте дә үзенә бер төрле инде, җитмәсә әле шәп-шәп җырлары да күп бит... Кинәт күңелне шомлы бер ачыш биләп алды. Актерлар йорты залындагы бу бөтенесе дә диярлек өлкән яшьтәге тамашачыларның мин барысын да диярлек күреп беләм икән бит! Дикъкать кенә итмәгәнмен: ничәнче кат рәттән кабатлана инде мондый хәл. Камал театры кебек заллар, Илдар Юзеев, Нурихан Фәттах кебек исемнәр халыкны күбрәк җыя анысы. Әмма махсус оештыру булмаганда, студентлар китерелмәгәндә барыбер тулаем шул тенденция саклана лабаса. Куркыныч фал түгелме бу? Татарның туксанынчы еллар бүлеп торган бетү процессы янә тулы көчкә бара дигән сүз түгелме?

Суверенитет чорының олы казанышы итеп дәүләт җитәкчеләребез трамвай-троллейбуста кыенсынмыйча үз телебездә сөйләшә башлауны һәм Казанда күпләп татар мәктәпләре ачылуны әйтәләр. Олуг түрәләребез соңгы елларда шәһәр транспортына утырмый, күрәсең. Юкса сизәрләр иде: янә элекке хәлгә калып барабыз. Бу җәһәттән без урыс шәһәрдәшләребездән генә түгел, башкаларыннан да нык калышабыз икән әле. Фирганәдән килгән шофер автобуста бер тапкыр юл буе үзбәк җырларын тыңлатты (һәм аңа кырын сүз әйтүче дә булмады). Татар шоферы шулай татар җырларын "акыртсамы?" Автобустагы бөтен татар бу "әдәпсез" өчен оялып, ут йотып барыр иде.

Җитәкчеләребез (бераз кечерәкләредер) әнә Казанның меңьеллыгында төп бәйрәмне алып барырга да Мәскәү артистларын чакыртып, аны "татар оялмаслык итеп" үткәрттеләр бит. Әнә шулай иң югары кимәлдә тел сабаклары алып, татар теленең дәүләт теллеге җитәкчеләребезнең чыгыш ясаганда үзебезчә бер-ике җөмлә кыстырып куюыннан узмавын күреп торган шәһәр татарларыбызның "транспорт теле" генә түгел, инде "кухня теле" дә үзгәреп ятуы (сөйләшү—урысча, яшь буын ишетмәгәндә аз-маз такылдап куйгалау—татарча) гаҗәп микән?

Казандагы (һәм республикадагы) чын татар мәктәпләре саны да инде кими бара, әлегә исәннәре дә начаррак биналарга кысрыклана тора икән.

[1] "Караб"—татар сүзе буларак (русча варианты "корабль") ике хәрефе «а» белән язылырга тиеш. "Кораб" дип язганда бу сүз татарча "кыраб" рәвешендәрәк укыла.

"Милли компонент" мәктәпләребездән бөтенләй дә куылгач, татарның инкыйразы инде нык кына түгел, бик нык, үтә нык тизләнәчәк бит! (Татар тарихында мәгарифсез чорның булганы юк дип беләм.) Күпмедер вакыттан газет-журналларга язылучы да, китапханәләргә йөрүче дә, китап сатып алучы да калмаячак. Аларның саны болай да ажгырып кими. Электән чыгып килгән төп газетларыбыз ("Ватаным Татарстан", "Татарстан яшьләре" һәм "Сабантуй"), мәсәлән, 1990 елгы тиражларының уртача 86,3 процентын җуйдылар инде. Тамаша залларыбыз озынрак гомерле булыр, ләкин тора-бара алар да татар сүзе, татар моңыннан арыныр—берничә дистә кеше өчен спектакль дә, концерт та куеп тормаслар... Эшләр шул рәвешле бара бирсә, тагын иллеме, алтмышмы, җитмешме елдан татар халкы, үзенең данлы тарихы, әдәбияты-сәнгате белән төпкә китеп, үле халыклар, үткәндә, тарихта гына бар халыклар рәтенә күчәр...

Бу хәлне бәгырьләрендә фаҗига итеп йөрткән аерым затлар калыр әле калуын. Шуларның берсе соңгы чын татар булыр...

*Миң ел җыйган хәзинәбез аман торыр.*
*Тукай яшәр миндә, моңлы Сәйдәш яшәр.*
*Миндә кавышыр Зөләйха белән Йосыф,*
*Миңа, бары миңа гына Такташ дәшәр...*

## Хикмәтледер татар көрәше

Нигә мондый хәлгә тарыдык соң әле без? Юкса тарих безгә шәп бер шанс һәм ун еллап вакыт биргән иде бит. Мондый шанс һәм шулкадәр вакыт яһүдләр кулында булсамы? Алар әнә күп тапкыр катлаулырак эшне дә эшләп күрсәттеләр инде: телсездән телле булдылар, җирсез килеш илле булдылар.

Югыйсә татар да төшеп калганнардан түгел инде. Батырлык һәм тырышлык җәһәтеннән ул болардан калышмый кебек. Башның йомрылыгы, хәйләкәрлек дигәндә кемнәрдер, урыслар микән, әллә яһүдләр үзләре үкме, татарны өстенрәк тә куйган әле. ("Где есть татарин, там еврею делать нечего", "Один татарин двух евреев стоит" дигән мәгълүм гыйбарәләрне күздә тотам.)

Кызганыч ки, бүтән төрле математика да бар әле. Бер яһүдкә бер яһүдне кушсаң, ким дигәндә ике ярым яһүд килеп чыгар. Иҗатта булсын, сәясәттә булсын—шулай бу. Бер татарга тагын берне өстәдең исә, нәтиҗә һәрвакыт диярлек икедән ким булыр. Ә еш кына болар плюс белән минус кебек бетерешә дә, шәп-шәрә ноль торып кала! Алай гына булса. Моның бетмәс җәнҗаллары, таркаткыч тәэсире тискәре нәтиҗә дә бирә ала әле.

*Җитмәде безгә һич бердәмлек.*
*Баш булды безгә гел таркаулык.*
*Мең җирдә мең учак пыскыды,*
*Мең дулкын булып без вакландык...*

Безнең ул Иҗтимагый үзәк кебек милли оешмаларыбыз Казанда да, Чаллыда да, Мәскәүдә дә гел икешәр булды кебек. Утны да шулай каршы ут җибәреп сүндерәләр бит!

Хәзер менә карабыбызга ургылып су керә. Ә без нишлибез? Бер-беребезгә ярсып йодрык изибез, "Ай, шәп тә әйттем соң, издем-сыттым тегене!"—дип куанабыз.

Яһүд өчен нинди яһүд әйбәт? Үз кавеменә игелек кылган яһүд. Татар өчен нинди татар әйбәт?

Исмәгыйль Рәми атлы күренекле кешебезнең истәлекләрен укып утырам. Бер шәхесне тасвирлау рәвеше уйга салды. "Оренбург миллионеры Мәхмүт бай Хөсәенов Казанга килгән чагында, ничектер ялгышып, "Шәрык клубы"нда күренеп китте... Кәләпүшенең түбәсендә, кырпусында чын энҗедән чигелгән роза чәчкәсе бизәкләре. Чәчкә саен бриллиант. Алар электр яктысында елык-елык килеп уйный. Бай абзый спектакль карамады, түбәтәен күрсәтте дә китте". Шулай мыскыллап кем турында язган соң Исмәгыйль агай? Бертуган өч Хөсәеновның берсе турында. Мәчетләр төзү, дәреслекләр нәшер итүгә, мөгаллимнәргә чутсыз акча тоткан, шәкертләр белем алуны Россиянең һәм чит илләрнең махсус уку йортларында дәвам итә алсын өчен 20 стипендия билгеләгән, үз акчаларына 60тан артык мәдрәсә һәм мәктәп ачкан кешеләр ләбаса бу! Оренбургтагы "Хөсәения" мәдрәсәсенең алар төзеткән өч катлы бинасына (рәсемен "КУ"ның 11нче санында яки "Сүнмәс утлар балкышы" китабының 58нче битендә күрә аласыз) хәзерге кайбер университет ректорлары да кызыгырлык.

Күптән түгел милли хәрәкәтнең күренекле бер әһеле 1991 елның маенда Азатлык мәйданында үткән сәяси ачлык турында китап чыгарды. Бүләк китапны кулга алгач, ул сөенүләрем! Бу олы вакыйга да тарихка теркәлгән, димәк. Тик

бераздан укуым газапка әйләнде. Анда автор иң әүвәл милли хәрәкәтнең беренче оештыручыларыннан булган мәрхүм Марат Мөлековны ямьсез яктанрак күрсәтеп үтә. Аннары инде Фәүзия Бәйрәмова да түбәнәйтелә. "Безнеңчә, татарча булган бу",—дигәч, автор, горур кыяфәттә, "Юк, татарча түгел, көрәшчә!"—диде. Йә, тикшереп карыйк әле, нинди көрәш була икән бу?

Ачлыкны Татарстан Югары Советы депутаты Фәүзия Бәйрәмова игълан итте. Максаты—Россия президентын сайлауны Татарстанда үткәртмәү иде. Ничәдер көннән бу сәяси акциягә Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар, Газинур Морат кебек халык шактый белгән кешеләр дә, шул җөмләдән, әлеге китап авторы да кушылды. Ул ошбу күмәк акциянең коменданты кебек иде, әйбәт үтүендә аның да өлеше бар. Асфальт эретерлек эсседә болар барысы да каһарманлык күрсәттеләр. Иң озын ачлык (14 көн) кичергән Фәүзиягә, хатын-кызга, аеруча авыр булгандыр. Һәм бу акция хакимият өчен дә, халык өчен дә иң әүвәл ул чакта үтә популяр булган (депутатлыкка да Саба райкомының беренче секретарен үз биләмәсендә җиңеп үтте!) Фәүзия акциясе иде. Җиңү дә (Югары Совет Россия президентын сайлау Татарстанда рәсми төстә үткәрелми дигән карар кабул итте) төп аның җиңүе иде. Кыйммәтле, кадерле җиңү, ул яуланмаса, Татарстан үзеннән-үзе Россия составында булып килеп чыгасы иде.

Милли көрәшнең матур бер сәхифәсе иде бу (кызганыч ки, алар күп түгел). Алдагы көрәшебездә рухи таяныч булырлык сәхифә. Фәүзия аша аны хаксыз түбәнәйткәннән, йә, кем отты соң? Бәлки, автор үзе күтәрелә төшкәндер, китапта ул ошбу вакыйганың үзәге, төше кебегрәк тасвирланган. Ай-һай. Минем үземнең аңа булган ихтирамым (зур иде!) кимеде генә. Татарның үз-үзен ашавының мең дә беренче мисалы булмыйча, йә, ни булсын ди бу "көрәш"?

Татарның ошбу үзенчәлеген инде һәркайсыбыз белә. Белү—кимчелектән арына башлау дигән сүз. Арынып җитә алмыйбыз, чөнки бу "белү"не без башкаларга карата, кемнедер төкерек чәчеп фаш иткәндә генә кулланабыз, үзебезнең дә шул "көрәшче татар" булуыбызны онытабыз.

Күптән түгел (25 августта) милли хәрәкәт әйдәрләренең тагын берсе, галим, шагыйрь Рәшит Ягъфәров дөнья куйды. Аның белән дә озак еллар көрәштек әнә. Судларга кадәр барып җитеп.

Үләренә дүрт айлап кала Рәшит минем янга килде, иркенләп сөйләшеп утырдык. Милләтнең хәзерге хәле, ошбу таркаулык-тетkәләнгәнлек, бер-беребез белән көрәштә генә калган активлык аны бик тә, бик тә борчый иде. Күп тә үтмәде, Рәшит "Ватаным Татарстан"да (1 май) "Рухы көчле халык мәңгелек" дигән мәкалә бастырып чыгарды.

Белмәгәнбез, йомшак күңелле бу нәфис, самими зат озак вакытлар теге дөнья чигендә булган, көн аралаш канын чистарттырып кына яши алган икән. Шул килеш тә милләт дип җан атты, эшләде-тырмашты бит әле. Үләсен белгән инде ул, шуңа да фикерләрен туплап-теркәп калдырасы иткән...

Җиңүнең дуслары күп, җиңелүнең—аз. Милләт өчен ихластан нәрсәдер эшләүче затларны инде берәмтекләп санап була торгандыр. Бер-беребезне белеп-белешеп яшәү фарыздыр безгә. Бу авыр вәзгыятьтә сафташларыбызны кабергә ашыктыра-ашыктыра үзара көрәшмик, һәркайсыбызның кадерен белик, кәефен күтәрергә тырышыйк. Беребез дә фәрештә түгел, холык-фигыль дигәне дә бер станокта штампланмаган—бәхәсләр булыр инде ул. Синеңчә уйламаганны дошман күрмик. Кайвакытны ишекне шапылдатып дулап чыгып китсәк тә, биш минуттан елмаеп килеп кереп, сүзне дәвам итик. Җиңсәк тә шәхесне түгел, фикерне җиңик, җиңелгән хәлдә сөенә белик: адашканда юлны кем табуы түгел, юлның табылуы кыйммәт. Шундый булмасак, безгә бер карабта батып, "теге (тегеләр) тәки бата бит!" дигән исәр сөенеч кенә тәтер.

## Кем килмешәк, кем китмешәк

Бер шагыйребез матбугатта Казанга Башкортстаннан килгән татарларны—әдәбият-мәдәният әһелләрен "мафия" кебек сүзләр кулланып хурлап язып чыкты. Бер-берсен үз итәләр, яклыйлар икән бит. Татар мондый "фаш итүләрне" ярата инде, хуплаучылар булды, автор үзен каһарман санап та йөргәндер әле...

Бу "мафиозникларны" беләм мин, кайсылары белән бергә, кайсылары белән янәшә эшләдем. Берсенең, чамалавымча, автор иң нык өнәмәгәненең, мин четерекле хәлгә тарыгач, костюмын да салып биргәне булды әле. Юкса танышлык та чамалы гына. Бөтен уңай һәм кимчелекле сыйфатлары белән бу шул "без татарлар" инде. Күпме еллар җигелеп татар мәдәниятенә хезмәт итәләр. Ләкин алар Казанга без үтмәгән бер сынауны үтеп килделәр.

Беренче секретарь Шакиров заманнарыннан ук Башкортстанда татарларга

татар булып яшәү—авыр, башкорт булып яшәү рәхәт була башлый. Күпме "татар башкорты" шәп карьера ясый, балда-майда йөзә. Теге шагыйрь күздә тоткан затлар да бүген анда зур-зур постларда утыра алган булырлар иде. Ләкин алар, милләтләренә тугры калып, туган җирләреннән читкә юл тотканнар. Безнең, "чын", ягъни Татарстан татарларының бөтенесе дә мондый имтиханны үтә алыр иде микән әле? Нурихан Фәттах әйтмешли, "Ай-һай" дигән фикер бар!" Кайсыбер мөхтәрәм язучыларыбыз әнә, башкорт теләндә сыңар китап чыгарып та (гонорары акча теләндә, ару гына), ике халык арасын бозалар дигән булып, андагы татарларны яклап сүз әйткәләгән каләм ияләренә (ни кызганыч, мондыйлар бер-ике генә бөртек) ябырылдылар.

"Моңа кадәр әле без, бербөтен татар халкының зур гына өлеше буларак, күзебезне рухи мәркәзебез Казанга төби идек. Әмма өметләр акланмады һәм акланмас та кебек",—журналда алдагы саннарның берсендә чыгачак язмадан бу сүзләр. Әйе, Татарстан җитәкчеләренең "нинди дер халык кисәге" аркасында гына Башкортстан хакимнәре белән тәмсезләнеп торасы килми бугай. Зыялыларыбызның да бу хәлнең эченә керәселәре килгәне сизелми, бер өлешенә әнә алдарак әйткән "фаш итү" уеннары кызыграк булса кирәк. Алай гынамы әле? Башкортстан татарлары ел саен Казан аша Болгарга барып, милли хаҗ кылу кебек бер сәяхәт ясыйлар. Шулар Казанга килеп җиткәч, "үз татарларымыздан" ничә тапкыр инде "башкортлар килгән" дигәнне ишеткән булды. Башкортстандагы 1 миллион 120 мең татарны тулаем башкортларга биреп тә тәмле төшләр күреп йоклый алачак кавем бугай шул без, әйе.

Урыс үзенә тарта. Күпме татарны, башка милләт кешеләрен үзенеке итте инде ул. Татар этә. Ике учын тырпайтып, төрле сылтаулар табып—йә килмешәк, йә китмешәк (туган җирен, илен ташлап киткән кеше), йә чын татар ук түгел дип гел читкә тибәрергә генә тора. Татар кешесенә кавеме никадәр бәләкәй булса, байлык та, хөрмәт тә үзенә шулкадәр күбрәк тамар кебек тоела булса кирәк.

Урыс, сайлап-сайлап, хәтта үзе куралмаган яһүдләрне дә сеңдерә. ("Простой еврей—жид, а талантливый—великий русский писатель".) Татарга, бигрәк тә үзен талантлы санаганына, мондый милләттәшләре дә бик тансык түгел шул. Казанга сыймыйча Урта Азия республикаларына, башка тарафларга китәргә мәҗбүр булган галимнәр, әдәбият-мәдәният әһелләребезнең зур бер исемлеген төзү мөмкиндер. Олуг галимебез, ерак Шәркый Төркестаннан тарихи ватанын тансыклап, туган халкыма хезмәт итим дип кайткан Миркасыйм Госмановка да башта бер дә җиңел булмаган әнә, "килмешәк" дигән сүзне ул да ишеткәләгән.

Әйе, шагыйрь хаклы. Әллә кайлардан килеп түр башына узучылар күп әле ул безнең арада. Нишләргә соң? Бәлки, "бөек чистарту" үткәрергәдер? Әллә, мәйтәм, хакимият, байлык, абруй "чып-чыннарга", "тач лаеклы затларга" гына күчсен өчен татарара гражданнар сугышы башлап җибәрик микән?

## Күзне кайсы Кремльгә төбик?

Сахаров һәм Ельцин белән бергәләп СССР Югары Советының мәшһүр төбәгара депутатлар төркеменә җитәкчелек иткән академик Юрий Афанасьев үзенең "Опасная Россия" дигән китабында (М., 2001), бүтән чыганаклар буенча, мондый мәгълүмат китерә (234 бит): Халыкара валюта фонды 1998 елның августында Россиягә бурычка биргән акчаның 235 миллион доллары—Ельцин кызы Т. Дьяченконың, 1 миллиард 400 миллион доллары—ул чактагы премьер В. Черномырдинның, 2 миллиард 415 миллион доллары—Б. Ельцинның чит ил банкларындагы исәпләренә күчкән.

Без, шушы саннарны белгән аркылы, Рәсәй хакимнәренең баш миендә нинди дер татарларны милләт итеп исән-имин яшәтү гаменә дә урын калгандыр дип өметләнсәк, шыр чыккан җүләрләр булыр идек. Аннан, мондый өмет өчен тарихи җирлек тә юк икән бит әле. Шул ук Юрий Николаевич, әңгәмәбез вакытында *(Ю. Афанасьев: Рәсәйне коткаруның төп юлы—төбәкләргә бәйсезлекне күбрәк бирү!—Идел, 1995, № 1)* болай дигән иде: "Рәсәйнең тарихына күз салыгыз, азмы-күпме мөһим барча концепцияләрне күздән кичерегез—фәлсәфи, тарихи һ.б.—сез анда эзлекле демократик традицияләрне күрмәссез. Урыс булмаган халыкларга өстән торып карау исә Рәсәйнең бөтен зур әдипләренә, философларына, мәдәният әһелләренә дә диярлек хас булган... Күпләргә исә иң шәп дигәндә баягы "без барыбыз да урыслар инде!" дигән караш хас булган. Ә үзләрен бүтән төрле исем белән атап йөртүчеләр алар, янәмәсе... урысның балалары, ягъни җитлегеп җитмәгән урыслар. Бетте-китте, вәссәлам!"

Без, шул "бишенче сортлы урыслар", татарның милләт булып яшәвен тәэмин итәрлек хокукларны Мәскәүдән бары буып, мәҗбүр итеп кенә ала алабыз. Моны иң

әүвәл, әлбәттә, Казан Кремле эшләргә тиеш. Ләкин соңгы 4-5 елда ул гел киресен майтарып килде, хокукларыбызны талауга ("кычкыртып талауга" дип язган идем дә, беренче сүзне сызып ташладым—кычкыру дигәне генә дә булмады бит хәтта!) Татарстан хакимияте гел күнә килде. Гимн, герб, флагыбызның инде асылда футбол-хоккей атрибутларына гына әйләнеп калуына дәүләт җитәкчеләребез гаепле. Татарның хәзерге хәлдә булуына да иң әүвәл алар гаепле... Татарстан Автономияле Республикасының беренче елларында җитәкчеләребез арасында милләтҗанлылар да шактый булган бит, һәм алар ул күп хәтәррәк чорда да үзләрен тәвәккәлрәк тотканнар әнә. (Татарстанның беренче президенты да 90нчы еллар башында (бигрәк тә референдум чорында) зур тәвәккәллек күрсәткән, үзен егетләрчә тоткан иде юкса.)

Күзне бер Кремльдән икенчесенә күчерә-күчерә, "Уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк" дип җырларга яки үкереп еларга гына калдымени инде безгә?

Биредә татарга хас тагын бер үзенчәлекне искәртмичә булмый. Түрәләр алдында үрә кату осталыгыбызны. Хәер, монысы аның урысның да канына сеңгән нәрсә инде. ("Ты начальник—я дурак, я начальник—ты дурак!") Эш бүлмәмә кергән авторларның инде ничәнчесе миңа "Хуҗаң мондамы?" кебек "хуҗалы" сорау бирә. "Ходайдан гайре хуҗам юк минем", дигән җавап ишеткәч, артык тәвәккәл кыланганын чамалап җиткерә микән бу исәр дигәндәй, күзгә текәлеп озак кына дәшми торалар. Иң югары кабинетлардагы түрәләрне инде әйткән дә юк, күпләр өчен алар—Алла дәрәҗәсендә.

Исән калыйк дисәк, безгә хәзер менә шул галиҗәнаплардан эш таләп итәргә, эшләнмәгән яки ялгыш гамәл өчен җавап сорарга кирәк булачак. Татарстан халкы үзе сайлаган Дәүләт Советыннан да, соңгы тапкырында Мәскәү куйган президенттан да суверенитетыбызны яклауны, җуйганны кире кайтарып алуны таләп итәргә хаклы. Референдум карарын бернинди "хакимият вертикале" дә юкка чыгара алмый. Аннан, татар халкының милләт булып яшәвен тәэмин итә алмаса, "Татарстан" дигән бу республиканың ни пычагыма кирәге бар соң?

Татарстан җитәкчеләренең хәзер дер калтырап күзәткәне шул бугай: татарга берүк урыстан артыграк тама күрмәсен! Таммый. Казанда, әйтик, татар балалар бакчалары, татар мәктәпләре, татар училище-техникумнары, татар югары уку йортлары саны рус телләләр белән тигезме?

Тигезлек дигәннән, уйлыйк әле. Әгәр дә табиблар яман чир белән кыл өстендә яткан хастаны томау төшергән берәү белән тигез күрсәләр, бу дөрес эш булыр иде микән?

Кытайдан кайткан Зифа Табиева истәлегендәге (2007, № 5) ошбу сүзләр һич истән чыкмый: "Менә без, Голҗадагы татарлар, чит илдә яшәсәк тә, шулай тату, халкыбызны, туган телебезне яратып, бердәмлек аңы белән тырышып-тырмашып яшәгән, һаман алга омтылган идек... Казанга кайтырга кирәк, үз җиребездә үзебез булып яшик дип Казанга кайттык. Тик монда үз телендә сөйләшкән, үз тарихы белән якыннан кызыксынган, халкының киләчәген төптән уйлап кайгырган татар яшьләрен эзләп табарга кирәк икән. Әллә татар булып калыр өчен чит илләрдә яшәргә кирәк микән ул?"

## Ике әби онык бага

Революциядән соң балаларны әти-әни, әби-бабайларыннан аердылар. Яшьләр—матур киләчәкне төзүче прогрессив буын, өлкәннәр исә аяк астында буталучы, тоткарлаучы искелек калдыгы дигән аң сеңдерелде. Әти-әни сүзенең абруе төште. Ләкин, традиция көчле булгангамы, татарда өлкәннәргә ихтирамны корытып ук бетерә алмадылар. Әниләр турындагы җырлар гына да күпме әнә.

Җырлар җырлана, әмма татар әниләренең барысы да үзләренең әнилек вазифаларын үтәп җиткерәләрме икән соң? Мәче әни әнә балаларын мәче итеп тәрбияли, мәчечә яшәргә өйрәтә, тыңламасалар, кундырып алырга да күп сорамый. Каз әни балаларын каз итеп, аю әни аю итеп үстерә. Бу җан ияләренең аерым бер төрләре дә балаларын шул төр мәче, шул төр каз, шул төр аю итеп тәрбияли. Күпме татар әни исә үз баласын татар кешесе итеп тәрбияләү тиеш икәнен, шулай эшләмәсә, туган халкына гына түгел, балага да, үзенә дә яманлык кылуын уйлап та карамый булса кирәк.

*Имезгәндә туган балаңны син*
*Туган түгел көйләр көйлисең.*
*Белдекләнеп, телне вата-вата*
*"Скаскалар" аңа сөйлисең.*

*Ана күңеле диләр балада да,*
*Бала күңеле әмма далада.*
*Чүл-далалар кичеп кайта бала*
*Туган моңлы газиз анага.*

*Ә син мена нәрсә көтәсең?*
*Чит-ятлыкны аңа үзең ук бит,*
*Ана сөте белән кертәсең!*

Үз кавеме аша гасырлар түреннән килүче рухи иммунитеты имгәтелгән, тамырыннан аерылган бала заманның наркомания кебек кабахәт чирләренә тизрәк бирешә, тулы рух көчен, күңел көчен тоеп яши алмый. Америкада, Финляндиядә, Австралиядә гомер кичергән, икешәр, өчәр дөнья телен камил белгән милләттәшләребезнең туган телне кадерләүләре, аны һәр яңа буынга тапшыра барулары тикмәгә мәллә?

Казанда яшәүче әти-әниләр телне онытa башлаган балаларын элек авылга алып кайтып ыргыталар иде дә, алар аннан чын татар балалары булып килә торганнар иде. Хәзер җәен авыл урамы урысча сөйләшә. Урам гына булса бер хәер әле. Әби-бабайларыбыз, фанилыктан өстенрәк калып, онықларының аңына һәм күңеленә нәселләренең асыл үзенчәлекләрен, татар рухын, аның әхлак кагыйдәләрен сеңдерергә—рухүткәргеч булырга тиешлекләрен аңлап җиткерәләр микән?

Миңа бер тапкыр ике әбинең алты яшьләрдәге малай белән гәпләшкәнен шаккатып тыңларга туры килде. Авыл түгел иде бу түгелен, Казан тирәсендәге бер бакча иде. Әмма әбиләр чын авыл әбиләре инде. Берсе—ана, икенчесе ата ягыннан иде, күрәсең. Малай урысча гына сиптерә. Әбиләрнең берсе моңа "теттереп", ягъни бөтен сүзләрне дә "тетеп", шулай ук урысча җавап кайтара. Икенче әби, син бит урысча җиде сүз генә беләсең, мин мена унҗиде сүз беләм дигәндәй, тавышына масаю галәмәте чыгарып, беренче әби әйткәннәрне "редакцияләп" сөйли! Ат азгыны тайга иярер дигән нәрсә шул буладыр инде!

Хәер, үзебез дә шул әбиләр ише. Элек эшләгән редакцияләремнең берсендә читтән килгән бер ханым бар иде. Исемен Сания диик. Сөйләвен урысча сөйләшә, ләкин татарча сүзләр дә кыстыргалый, телне белә—тәрҗемәче. Ул килеп керде исә, булмәдәгеләр, шул җөмләдән "туган тел!" дип өзгәләнеп шигырь язган егетләр дә, шундук теге телгә күчә! Мондый "Сания"ләр һәр татар редакциясендә дә диярлек бар ул, һәм һәркайда диярлек шул "Сания эффекты"н ишетәсең. Урысның үзеннән генә түгел, хәтта ки күләгәсеннән дә курку-оялу булып чыга түгелме соң инде бу?

Мунчада татарча сөйләшкән ике татар янына килүгә, сүз катарга ашыгам. Чөнки белеп торам (мисаллары күп булды), алар миннән—"нинди телдә сөйләшкәне мәгълүм булмаган кешедән" (татарлыгым анисы йөземә чыккан) оялып, урысчага күчәчәкләр!

Сирәк-мирәк кенә баласы белән татарча сөйләшкән әтиләр дә очрый. Чын татарча, бигрәк тә кайсыдыр төбәк үзенчәлекләрен кушып кызып-кызып сөйләшкән баланы тыңлау (андыйлар да очраштыргалый)—җан рәхәте инде. Татар баласының татар телендә сөйләшүе ул—һавада ак болытлар йөзүе, талгын җилдә яфраклар шыбырдашуы, кошлар сайравы кебек табигый, саф һәм матур бер эштер. Сөйләшә алмавы—гайре табигый хәлдер, фаҗигадер.

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*

Тукайның шушы бер шигырь юлы гына да совет чорында безгә рухи таяныч булды, телебезне саклап калырга ярдәм итте. Россиядә милләтләргә дуст сиптерелә торган бу тарихи мәлдә исә аны лозунг итеп барча татар күрерлек биеклеккә күтәрергә кирәк. Ләкин, исән калыйк дисәк, аны бераз киңәйтә төшү мәгъкульдер. Гаилә корганнар өчен бу—"әткәм-әнкәм һәм балаларымның теле", өлкәннәр өчен исә "әткәм-әнкәм, балаларым-оныкларымның теле" булырга тиештер.

## "Рәхәт бит ул сарык булу!.."

90нчы елгы вакыйгалар Казанда Кремльдән башландымы? Һич юк. "Союздаш!", "Суверен дәүләт!" "БДБ!" дигән ораннар әүвәл митингларда яңгырады, ул чорның күп кенә мөһим мәсьәләләре Югары Советның көн тәртибенә мәйданнан керде. Милли хәрәкәт аннары үз "көрәшебез" һәм дә тагын кемнәрнеңдер тырышлыгы белән "зарарсызландырылды". Бу мәсьәләдә ике Кремльнең фикере тәңгәл килгән булуы да бар. Казанныкына ул чакта хакимлек үз кулына инде ныклап күчте, аны беркем дә какшата алмас, тавыш-шау-шулы ул аркадашларга ихтыяҗ бетте кебек тоела башлаган иде бугай.

Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең (үзәкләренең?) хәзер үз хәле хәл. Ярый әле Бөтендөнья татар конгрессы, аның структуралары бар (көчсез ягы—Кремльгә басым ясый алмау). Ләкин милләт карабына ыргылып су кергән бу хәтәр мәлдә тырышлыкның колачы да, егәре дә нык артырга тиеш бит!

Рәшит Ягъфәров исәннәргә васыяте кебек калдырган мәкаләнең соңгы сүзләренә багыйк. "Хәзер халкыбыз үз зыялыларыбызның рух өрүенә мохтаҗ",—дигән ул. Әйе, зыялылар халкыбызны уятырга тиеш һәм үзләре көрәшнең алгы сафына басарга тиеш.

Рәшит болай дип тә өсти әле: "Ә без ("сез" дип укыйк) моңа әзерме, зыялылар?" Сорау куелу бик урынлы. 90нчы елларда Татарстан язмышы, шуңа бәйле рәвештә шактый дәрәҗәдә татар халкы язмышы хәл ителеп яткан киеренке мәлләрдә интеллигенция, ничәдер дистә кешене исәпләмәгәндә, сүлпәнлек күрсәтте. Аклану рәвешендә, без болай да татарга эшлибез бит, диючеләр булды. Түләүле вазифаңны биш ел элек тә, унбиш ел элек тә үтәгәнчә үти бирү турында инде бу. Ләкин бата башлаган карабта минем вахта тәгәлләнде дип йокларга ятмыйлар, башкарган эшнең күләмен исәпләп тормыйлар.

Шөкер, милләт өчен иң кирәкле эшләрне көн дими, төн дими башкаручылар да булды. Бу, мәсәлән, Казанның югары уку йортларында татар группалары ачуны тәэмин итүчеләр. Кемнәрнедер күндерү, ризалык алудан тыш, терминологияне эшләү, сүзлекләр булдыру, татар телендә дәреслекләр язу да бит әле бу! Кайберәүләрнең исемнәрен дә атап китик инде: Алмаз Юлдашев, Әнәс Җомагулов (Авыл хуҗалыгы академиясе—бу игелекле эш шушы уку йортында башланып киткән икән), Вәгыйз Фәтхуллин (инде мәрхүм), Рәшит Шакир, Садрислам Миңнуллин (Архитектура-төзелеш университеты), Борис Тимеркаев, Гали Даутов, Дамир Галимов (Техник университет), Николай Максимов (Технология университеты)... Сөембикә манарасына ай куйган затның да исемен онытырга тиеш түгелбез—Габбас Мөхәммәдшин. Академик Миркасыйм Госманов "Шәхесләребез" дигән серия ачып, милләтебезнең олуг затлары турында китаплар нәшер итүне оештырды. Мәрхүм Тәүфикъ Әйди элекке Союзның төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче зыялыларыбызны барлау һәм туплау буенча зур эш башкарды. Адлер Тимергалин да әнә мыштым-тыйнак кына халкыбызга милли аң сеңдереп ята... Мондый кешеләр тагын да бар инде ул. (Бу җыйнак исемлеккә эләкмәүчеләр мине үзләренең кара исемлекләренә кертмәсләр дип өметләнәм!) Оныта язганмын. Татар хәзер җир астында булса да кимсенмичә яши ала: Казан метросы ике телле. Моңа кемнеңдер саллы шәхси өлеше кергән бит инде, рәхмәт аңарга! Сабый метробыз татарчаны зур үскәч тә онытмасын иде.

Татар язмышына азмы-күпме тәэсир итәрлек гамәлләрне үз эш урыныңда да кылырга мөмкин, әйе. Ләкин—эшеңне бүтәнчәрәк корып. Мине журналистлар корпусыбыз гаҗәпләндерә. 1992 елны, референдум алдыннан бер ай дәвамында суверенитет тарафдарлары һәм аңа каршылар арасында матбугат көрәше барды. Безнең журналистлар шунда үшәнлекләре, бәхәсләшә белмәүләре белән шаккатырган иде. Суверенитет ягы сынатмады анысы, әмма бу инде—башлыча язучылар, галимнәр, юристлар казанышы... Ошбу четерекле чорда төп тема—миллият, төп максат татарны исән калдыру, яклау һәм, Р. Ягъфәров әйткәнчә, халыкка рух өрү булырга тиеш. Хәзерге вакытлы матбугатыбызның әйбәт-әйбәт талпынышлары бар. Ләкин милләт темасы барча жанрлар аша ачыла торган үзәк, магистраль темага әйләнде дип әйтеп булмый әле... Хәбәрдарлык, ушлылык җитми. Укылышлы итеп, үткәзеп язу да җитеп бетми... Арада үзләрен киләчәк язмышлары халкыбыз язмышына, тел язмышына һич бәйләнмәгән кебегрәк тотучы басмалар да бар әле.

"Звезда Поволжья" атналыгын чыгаручы Рәшит Әхмәтов (заманында, ДПРның Татарстан бүлекчәсе рәисе буларак, республикабыз суверенитет алмасын өчен көрәшкән кеше!), тирәнлек, төплелек гел җитеп бетмәсә дә, татарны әзлекле һәм кыю рәвештә яклый, Татарстанга, татарга кагылышлы яңалык-үзгәрешләрне һәм аларга үз мөнәсәбәтен атнага 3—4 тапкыр чыга торган татар газетларын узгалап (еш кына алар бу хәлләрне бөтенләй дә күрми кала) биреп бара. Үрнәк алыйк!

Газет-журналлар кулда чакта, радио-телевидениегә үтеп булган, укучылар һәм тыңлаучылар бар чакта эшләп, әйтәсен әйтеп өлгерәсе иде бит, җәмәгать!

Казан университетының журналистика факультеты нигә миллият һәм милли сәясәтне үз иткән журналистлар да әзерләми? Нигә татар мәктәпләрендә татар балалары күңеленә милли иман салынмый? Нигә мәктәпләргә укытучылар булып киләчәк кешеләр—студентларга милли аң җитәрлек сеңдерелми? Нигә концерт бригадаларыбыз, әхлак ягы чамалы булган мәзәкләрне телдән төшермәсәләр дә, татар теле, татар халкы турындагы шигырьләрне (андыйларны сәхнәдән

совет чорында да укыйлар иде бит!) программага кертмиләр, балаларны, оныкларны татар итеп тәрбияләү фарызлыгы турында үтемле-ягымлы бер-ике сүз кыстырмыйлар? Киләчәктә тамашачысыз торып калмау җәһәтеннән үзләренә үк кирәкле эш бит инде бу юкса.

Татар тормышының һәр тармагына, һәрбер эш урынына әнә шулай исән калу ихтыяҗыннан чыгып багарга кирәк хәзер.

Бу сүзләрне укыганда кемнәрдер куркынып Мәскәү тарафына карап-карап куяр. (Шунда бер очтан чукынып та җибәрә күрмәгез тагын!) Мәскәүләр алар, абзыкайлар, безнең үз-үзебезне яклауга, исән калырга омтылуыбызга әлләни гаҗәпләнмәсләр, ә менә әле кайчан гына тавышлары бөердән чыккан хакимнәребезнең, мәйданнарны тутырган халыкның шулай мөлҗерәп төшүе аларны шаккатыра, әлбәттә.

"Мәйданга чыгып кычкыру җиңел ул",—сүлпәнлекләрен аклап шулай дип әйтүче зыялыларыбыз да бар. Алай бик җиңел дә булгач, чыгарга, кычкырырга иде соң. Балтыйк буе республикаларында әнә мондый күмәк акцияләрдә интеллигенциянең каймагы катнашкан. Шуңа күрә алар югары кимәлдә үткән дә. Хакимияткә тәэсире, нәтиҗәлелек җәһәтеннән шәп оештырылган митинг-демонстрация газет-журналлардагы олы-олы мәкаләләрне орып бирә бугай ул.

Кызганыч ки, татар интеллигенциясенең төп массасы татар язмышының үзәгенә төбәлгән мәсьәләләрдән дә, аның үзенә бөтенләй кагылмагандай, читтә, ышыкта кала бирә. Гамьсез, ваемсыз бер сабырлык белән үзебез утырган агачны кисеп бетергәннәрен көтәбез.

*Сабыр төбе алтын булса,*
*Безнең алтын сандык тулы.*
*Дәштеләр—бар, кудылар—кайт,*
*Рәхәт бит ул сарык булу!*

*Бер гамь дә юк. Уңайсызрак*
*Фидакарьләр каршында тик.*
*Юанабыз аларның да*
*Сугарлар бер башына дип.*

Хәтта ки халкыбызның киләчәге кебек югары гамьгә саңгырау булганда да, үз хәлебезне, фани якны булса да кайгырта белик инде. Татар теле гамәлдән чыкса, күпмебез эшсез торып калачак бит. Язучылар (язучы буларак). Радио-телевидение, газет-журнал, нәшрият хезмәткәрләре. Театр һәм эстрада артистлары. Галимнәр. Китапханәчеләр. Укытучылар. Шул урыннарга киләбез дип укып яткан студентлар...

Сүлпәнлегебезнең тагын бер сәбәбе бар анысы. Күңел кайту, ышанычны җую. Дәүләт җитәкчеләребезнең үзләре күпме мактаган мөстәкыйльлекне тәлинкәгә салып диярлек кире илтеп бирүләренә үпкәләү яки рәнҗү. Беткә уч итеп тунны якмыйлар. Хакимнәрнең үз гамедер, күрәсең, безнең—үз гамебез.

"Татар акылы төштән соң"—бабаларыбыз моны үзләре турында әйткән. Безнең акыл исә еш кына эштән соң килә. Эш эшләнгәннән соң. "Болгар" бинасы турында газетларда күпме аһлар булды әнә. Кайчан булды? Һавада ачы тузаны гына торып калгач. Ярый, монысын, белмәдек бит, дип акланган була алабыз әле. Хәзер безнең күз алдыбызда бабаларыбыз гасырлар буе корган Татар бинасын җимереп яталар әнә. Бу юлы җимереп бетергәч аһларыбызны ишеттерерлек матбугатыбыз да булмас шул. Берәрсе "Юк ителгән татар бәете" чыгарып, урамнарда җырлап йөрсә генә инде...

Төшенкелеккә бирелмик. Милләт тәнендә көч бар әле. Алтмышынчы еллар җепшеге эзсез үтмәгән кебек ("үзгәртеп кору" каһарманнарының күбесе шуннан үсеп чыкты), безнең бу ун ел да эзсез-нисез генә эреп юкка чыкмас. Яшьләргә дә тәэсире булды аның. Күпме кешенең бәгъренда ут булмаса утлы күмер бар. Татарга сыйфатларның начарлары гына түгел, әйбәтләре дә хас. Кыен хәлгә тарыгач әллә нинди төпкелләрдән бәреп чыга торган дәрт, көч-гайрәт тә бар әле безнең канда. *"Без батырган саен калыккан!"*—Нури Арсланов шулай дигән әнә. Бер карабта икәнебезне, язмышташлар булуыбызны онытмыйк та, иң мөһим, иң ашыгыч эшләрне вакытында эшләп өлгерик.

Гомәр
Бәширов

# КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕ

## ИКЕНЧЕ ДӘФТӘР

## (1956 ел)

Нинди фаҗига! Нинди аяныч хәл, коточкыч хәбәр! Әле генә Мәскәүдән Александр Фадеевның үзен-үзе атып үтерүен әйттеләр. Нәрсәдер язып та калдырган дип сөйлиләр. Нәрсә генә язган булса да, әдәбият өчен аны югалту—бик зур югалту бит ул. Максим Горькийдан соң ул совет әдәбиятын алга җибәрү, төрле милләт язучыларын зур әдәбият дөньясына чыгару өчен бик күп нәрсә эшләгән иде. Ни булган? Бәлки съездда Шолоховның, аңа кадәр башкаларның аны нахакка рәнҗетүләре башына җиткәндер? Бәлки каты авыруына түзә алмагандыр, бәлки шуның аркасында нервлары какшап үзен-үзе тота алмагандыр?

Белмим, ни генә булса да, бу яхшы фал түгел. Безгә, күрәсең, нидер җитми, нәрсәнедер без Ленин өйрәткәнчә дөрес итеп уздыра алмыйбыз.

Күпмилләтле барлык әдәбият өчен зур кайгы, зур фаҗига бу.

**14 май, 1956.**

* * *

Фадеев үлеменнән соң һаман да тынычланып булмый әле. Күңел шундый тирән акыллы, шундый талантлы кешенең алай көчсез кешеләр үлеме белән кинәт кенә, көрәшсез генә үлеп китүенә ышанмый. Нindидер, аны бик тирәнтен рәнҗеткән берәр хәл булган, күрәсең. Аның башка юл таба алмавы бик аяныч хәл. Бик, бик! Ул бит бик көчле кеше иде.

**24 май, 1956.**

* * *



*Язучы Гомәр Бәширов Аккош күле урманында. 22 июль, 1973 ел.*

Бу көннәрдә М.да[1] булдым. "Яшьләр журналын оештырырга кирәк, башка өлкәләрдәге татарларга газетә-журнал җибәрергә кирәк, аларны үз милли телләрендә тәрбияләргә, социалистик аңнарын үстерергә кирәк",—дигәч, коты чыгып миңа:

—Бу безнең эш түгел, ташла-ташла! Монда татар шовинистлыгы бар,—дип әйтте.

Йа Алла! Әгәр дә безнең заманда, менә хәзер нинди дә булса милләтче килеп

[1] Партия эшлеклесе Мусин Мөдәррис Муса улы булуы мөмкин.

*Дәвамы. Башы 11нче санда.*

чыга икән, ул чын-чыннан ахмак кеше булырга тиеш! Без башка халыклар белән шундый дус яшәгән бер вакытта берәр кеше үзенең татары турында, аны башка халыклардан аерып алып уйлый икән—ул чыннан да ахмак, шыр тиле! Ничек алай булырга мөмкин? Халыклар дуслыгы шулкадәр күңелгә һәм тормышка сеңгән, аны бит күрмичә мөмкин түгел! Һәм без шулай яшибез дә.

**5 август, 1956.**

* * *

Күрәсең, мин тыныч кына яши алмамдыр инде. Иртә белән торуыма кичә нәрсәнедер дөрес эшләмәгәнмен, нәрсәдер күңелемне борчып торадыр кебек сизә башлыйм. Тагын нәрсәдер эшлисе калган, нәрсәнедер тиешенчә җиренә житкерә алмаганмын кебек хис итәм. Менә шул күп вакытны көн буена житә. Кайвакыт шундый хәл минем үземнең эшемә генә түгел, бөтен оешманың эшенә бәйләнгән булып чыга. Әгәр мин Министрлар Советының рәисе булсам, ул вакытта шулай бөтенесе өчен борчылырга урын да булыр иде. Мин бит никадәр борчылсам да барыбер бөтен республика эшен яхшыртып бетерә алмыйм.

Тыныч кына яшәү анысы безнең идеал түгел, ул мещаннар хыялы. Шулай да, язучы кеше үзенең тирә-ягында тормышның азмы-күпме көйле баруына, халыкның нормаль тормышта яшәвенә ышанса гына үзен канәгать хис итә ала. Шулай булмаганда язуы бик кыен. Менә бит нинди хәл: республиканың төньягында иген бөтенләй булмады. Көньягында берникадәр булган иде, хәзер дүрт айдан бирле яуган янгыр булган кадәресен дә черетеп бетерә. Колхозчыларнын тормышы рәтләнә, көйләнә дип торганда алар тагын шул 150-200 грамм белән калачаклар. Күреп тордык, алар бит ел буе эшләделәр! Ел буе төн йокыларын кызганмыйча кырда, урманда, болында булдылар. Иген булмаганга аларның гаебе юк бит. Шулай булуга карамастан, иген начар булды исә, монын авырлыгы иң беренче нәүбәттә авыл халкы өстенә төшә.

Кайчан без иген уңышын күккә ялвармыйча гына, үз көчебез белән генә хәл итә алырбыз икән?

Ай-һай, кайчан булыр икән ул хәл? Ләкин аңа ирешергә кирәк!!..

**28 октябрь, 1956.**

* * *

Күптән борчып йөргән бер кичерешемне языйм әле.

Мин быел правление рөхсәте белән өч ай чамасы вакыт читтә йөрдем. Яна әйберемне язмакчы идем дә, анарга әллә ни вакытым калмады. Бердән, Башкортстанда Муса Җәлил пароходында байтак вакыт уздык, Уфага да кереп чыктым. Аннан, картая төшкән тәнгә бераз ял да кирәк бит инде, Кәримә белән Сочига дәваланырга киттем. Үзем өчен түгел, Сочиның дымлы, бөркү һавасы миңа ошамый, Кәримә өчен диярлек бардым. Әйдә, дингез буйларын, Кавказ тауларын күрсен. Анын өчен яналык бит ул. Кайтышлый Мәскәүдә дә туктадык, анда да байтак нәрсәләр күрде, авыл хужалыгы күргәзмәсендә булды. Аңа кадәр бер ай чамасы Ютазы районында Иске Зирекле һ.б. авылларда да булдым, элек булып узган авылларда да йөргәләдем. Язучыга берсе дә артык түгел.

Ярый, шулай итеп өч айга якын йөреп кайттым. Азмы-күпме ял да иткәнмен инде. Кайтып төшсәм, миңа бик сәер генә карап куйгалыйлар, анлашылмастай гажәп сүзләр әйтәләр. Әйтерсең, мин югында монда ниндидер мин анламаслык гажәп нәрсәләр булган! (Язучы кеше кайвакыт иптәшләренең күз карашыннан да күп нәрсә анлый бит ул!)

Ниһаять, миңа әйттеләр. Мин югында партия оешмасының ябык жыелышы булган икән. Шунда шәхес культы турында доклад булган, анда мине бик каты "иләгәннәр".

Ярый, Союзда эшли башлаганнан бирле мин һәр мәсьәләгә мөмкин кадәр тыныч карарга өйрәндем, объектив фикер йөртергә, кызмаска, һәр мәсьәләне кызмыйча, дөрес хәл итәргә гадәтләнә башладым (Чөнки минем үзем белгән гаебем юк, гаебем бар икән, аны миңа ап-ачык итеп әйтергә тиешләр дип уйлыйм). Нәрсә булган? Дүрт-биш кеше чыгып мине бик каты тәнкыйть иткәннәр. Кайберсе мине бюрократ

дип атаган. 3-4 ай буена без аны монда бөтенләй күрмибез дип әйткән. Ихтимал, анысы дөрес тә булыр. Ләкин мин өч айга иҗат командировкасына киткәч, мине монда очрата алмаулары бик табигый. Бик гаҗәпләндергәне Кави Нәҗми чыгышы булды (Соныннан беркетмәне укыдым, өстәп иптәшләр дә әйттеләр).

Җыелышта булган иптәшләр әйттеләр: күрәсең, сезнең ике арагызда бик зур дошманлык булырга тиеш, Кавинең чыгышыннан шулай аңлашылды, диделәр. Менә шунысы бик гаҗәп: минем бит Кавигә бер нием дә юк! Мин аңа дошман түгел, минем аңа бер дошманлыгым да юк. Шунысы гаҗәп: нигә ул миңа дошман икән? Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Мәхмүт Максуд, хәтта Мирсәй Әмир, Фатыйх Кәрим һәм тагын кайбер татар язучылары әле мин авылда эшләгән вакытта ук, гомумән, әллә кайчан ук язучы, алай гына да түгел, танылган, зур язучы иделәр. Мин аларның әсәрләрен укып үскән кеше, алардан азмы-күпме өйрәнгән кеше. Кави Нәҗминең, 1932 елларда булса кирәк, хәтта миңа кайбер киңәшләр дә биргәне бар. Ул аны үзенең хатында да язган иде. Мин бер дә ялагайланмыйча ап-ачык әйтә алам: Кави Нәҗми татар совет әдәбиятының башлангыч чорында бөтен татар совет әдәбиятының үсешенә зур йогынты ясаган кеше, үзенең тоткан урыны, күрсәткән хезмәте булган кеше. Шунлыктан, 1954 елда Бөтенсоюз язучыларының II съездында мин беренче булып аңа речь белән чыгарга тәкъдим иттем.

Аннан соңгы чорда да мин яшь язучыларны тәрбия мәсьәләсендә, гомумән, барлык язучыларның әдәби осталыгын күтәрү мәсьәләсенә Кавине тартырга тырыштым. Кайбер җыелышларда "Син елга бер генә мәкалә белән чыксаң да бик яхшы булыр иде" дип әйткәләдем. Ләкин мәкалә яки киңәш урынына, ул миңа яшел гимнастерка кесәсеннән врачларның басым турындагы белешмәсен генә күрсәтә иде.

Ул элекке квартирасыннан яхшы квартирага күчте. Аның өстеннән самолетлар очып йөргәнне яратмыйча, тынычрак урынга күчәргә теләде. Анда да минем ярдәмем тиде. Союз рәисе һәм Верх. Совет депутаты буларак, мин өлкән кешебездән аны яхшырак квартирага күчерүне үтендем. Ул вакытта югары сфераларда минем сүзем ансат үтә иде, аны бер айдан ук иң яхшы квартирага күчерделәр.

Бервакыт, Татарстан Вер. Советның чираттагы сессиясе ачылыр алдыннан төнлә белән сәгать 1дә мине бер оешмага чакырып Сессияне ачарга тәкъдим иттеләр. (Без ул вакытта икебез дә лауреат идек). Бердән, речь сөйләүләрне җенем сөймәгәнгә, икенчедән язучылар арасыннан Кави миңа караганда, һичшиксез, авторитетлырак, һичшиксез дәрәҗәлерәк язучы булганга мин, күзем яхшы күрмәүне һ.б. сылтау итеп, сессияне ачуны Кавигә тапшыруларын үтендем. Чыннан да, төнлә сәгать 2дә аңа машина җибәреп алдырдылар, сөйлисе язуны бирделәр, икенче көнне сессияне ул ачты.

Әгәр Кави уйлаганча, мин үземне генә кайгырта торган кеше булсам, мин анда нигә үзем эләкмәс идем, нигә Кавине тәкъдим итәр идем икән?

Ул партия җыелышында мине "төрле республика җыелышларында чыгышлары аз",—дигән. Нигә мәгънәсезгә сөйләнеп йөрергә? Мин мәгънәле чыгышларны гына ятатам. Әгәр мин язучыларны кайгыртып чыкмаган булсам, 400 меңгә төшереп клуб та эшләнмәгән булыр иде. 400 мең сумлык дача да салынмаган булыр иде[2].

Әгәр Кави минем Верх.Совет депутаты булуымны ошатмый икән, мин анысына берни дә әйтә алмыйм. Чөнки анысын миннән сорап тормыйлар. Язучы буларак та мин Кавидән көнләшмим. Чөнки аның үз юлы бар, минем—үз юлым. Аның үз укучылары бардыр. Мин аның артыннан иярергә теләмим, әйдә, бара бирсен. Аның иҗат стиле, аның теле—минем өчен идеал түгел. Мин лирик язучы, ә ул—публицист. Мин татар әдәбиятының беркем дә уза алмаган классигы Галимҗан Ибраһимовтан гына өйрәнә алам.

Гомумән, мин әдәбиятта нинди дә интригаларны, кешенең, бигрәк тә язучының үзе югында гайбәтен сатуны яклый алмыйм. Минем иҗатым турында, яки үзем турында берәр нәрсә әйтәсең килә икән, туп-туры үземә әйт, үзем булган җыелышта әйт, коридорда гайбәт сатып йөрмә.

[2] Сүз язучылар Союзының Тукай клубына капиталь ремонт ясату һәм Аккош күлендә иҗат йортлары салдыру турында бара.

Өлкән язучыларның вак-төяк гайбәтләр белән шөгыльләнүен ишетү бик рәнҗетә торган нәрсә. Моннан соң андыйны ишетмәсәк бик тә яхшы булыр иде. Әйдә, шулай булсын дип ышаныйк!

**8 декабрь, 1956.**

* * *

Тагын бер гадәтем яисә холкымның бер шундый үзенчәлеге бар икән әле: әгәр берәр кеше минем идеалымдагыча ук булмаса, минем аңа күңелем суына. Дөресен әйткәндә, бик тиз суына. Нинди мисал китерергә кирәк икән? Менә мисаллар яисә үрнәкләр бик күп.

Минем сеңел тиешлеләрдән берсе, яхшы укытучы булырга тиешле кешеләрдән берсе, мәсәлән, үзенең эше, үзе белергә тиешле нәрсәләр белән кызыксынмый. Минем менә шуңа җенем чыга! Әйе, мин аңа инде бүтәнчә карый башлыйм.

Менә бүген мин безнең әдәбиятыбызның тарихында беренче тапкыр чыккан "Татар шигыренең антологиясе"н алып кайттым. Бик зур шатлык бит инде бу! Аның бит моңарчы безнең тарихыбызда булганы юк. Менә мин кайткач ук бу авылдан килгән әдәбият укытучы сеңелемә шушы китапның төрле урыннарыннан үрнәкләр укый башладым. Дәрдемәнд, Гыйффәт туташ, Думави, Емельянов... Минем сеңелем болар турында да, аларның шигырьләрен дә элек укый алмаган. Димәк, ул алар белән кызыксынырга тиеш иде бит! Ә ул чәй эчүен дәвам иттерде, артык кызыксынмады. "Безгә аларны укытмадылар!"—дип утыра. Укытмасалар, менә хәзер укырга була бит инде!



*Гомәр Бәширов Арчада үзенең 80 яшьлегенә багышланган юбилей кичәсендә укучылар арасында. 7 январь, 1981 ел.*

Димәк, ул программада һәм тагы шундый кәгазьләрдә ниләр язылган булса, шуларны балалар белән үтә дә, башкаларында, ягъни программага кермәгәннәрендә, аның эше юк. Нигә? Чөнки дәреслекләргә, программаларга кермәгәннәр турында аннан сорамыйлар бит!..

Нинди аяныч! Нинди ярлы, нинди чикле бу кешеләр! Шунысы бик кызганыч, алар бит үзләре моны белмиләр. Димәк, моннан соң да алар шундый бик чикле, бик тар, йомык кеше булып калачаклар. Алардан тәрбияләнгән бала ничек киң карашлы, ничек киң колачлы була алсын?!

**30 декабрь, 1956.**

* * *

Бүген миңа шактый ук авыр кичерешләр уздырырга туры килде. Нилектән?

Баштан ук башлыйм инде. Быел яз көне Кави үлде. Мин рәис вакытта бу инде алтынчы үлем иде. Кави минем турыда шактый ук вакыт начар уйда булса да, минем күңелемдә аңа карата нахак рәвештә рәнҗетелүдән башка берни дә булмады. Мин аның минем хакта ялгыш уйда булуының сәбәпләрен белгәч үк аны күңелемнән гафу иттем. Соңгы вакытта ул моны үзе дә аңлады. Иң соңгы көрәшүебездә без инде аның белән якын дуслар булып аерылышкан идек. Кави үлде. Тормышының, иҗатының иң парлак вакытында үлеп китте. Әдәбиятка күп әсәрләр биргән, татар совет әдәбиятының үсешенә кулыннан килгәннең берсен дә кызганмыйча, һәммәсен дә биргән күпкырлы язучы иде. Ул хәзерге буын язучыларны Шәриф Камаллар, Һади Такташлар белән бәйләүче өлкән язучыбыз иде.

Ул җәрәхәт азмы-күпме яра белән тартыла гына башлаган иде, Мәскәүгә декадага киттек. Бик дулкынланып бардык. Чөнки беренче декада иде, чөнки без зур әдәбиятның, зур әдәби мирасның вәкилләре булып бара идек. Без ул әдәби мирасны саклый беләбезме, шундый зур мирасның лаеклы варислары булып бара алабызмы?

Менә бардык. Беренче көннәре яхшы гына узды кебек. Мәскәү безне яхшы каршы алды, алкышлады, тәбрик итте.

Әмма икенче көненнән үк фаҗига башланды.

Союзлар йортының Октябрь залында татар шигыре кичәсе бара иде. Башта бүтән шагыйрьләр чыкты. Алардан соң Бари Рәхмәт чыкты. "Әби белән бабушка"сын укыды. Аннары "Бабай белән дедушка"сын, тагын берничә кечкенә шигырен укыды. Мәскәүнең яшьләре, укымышлысы Бари агайны гөрелдәтеп кул чабып, соклангыч бер алкыш белән каршы алдылар. Монда Бари абзый гына түгел, без барыбыз да дулкынландык, безгә кыен да, рәхәт тә иде. Менә бер чыкты, ике чыкты, өч чыкты. Ниһаять, үкереп торган залның комсыз теләген берникадәр канәгатьләндергәннән соң урынына барып утырды. Ләкин барып утыруына ничектер инә башлады, башы бер якка авыша башлады. Президиумда утыручылар аны идәнгә егылып төшкәнче бик кыенлык белән генә тотып калдылар. Сәхнә артына алып чыгып салганнан соң галстугын-фәләнен чишеп җибәрдек, вак-төяктән бушаттык. Бари агай ике мәртәбә авыр итеп сулады да, ничектер кинәт тынып калды. Мин инде "бу бераз гына булса да сулыш ала башлады" дип уйлап, яулыгымны суга чылаттым да аның маңгаена, йөрәгенә куйдым. Ләкин ана карап ул җанланмады, ничектер бик хәвефле рәвештә тынып калды. Врач килде, күзләрен ачып карады. Күзенең "кешеләре" хәрәкәтләнми, катып калган иде. Врач "бу үлгән" дип әйтеп салды. Ләкин минем картның үлүенә ышанасым килми иде. Ачуым һәм ничектер җенем кузгалып "Син врачмы? Нигә алай дип әйтәсең?" дип сорадым. Яшь кенә бер ханыммы яисә кызмы "Әйе, мин врач, мин башкача әйтә алмыйм, карт үлгән!"—диде.

Мин рәис булган вакытта җиденче язучы минем үз кулымда үлде.

Нишләргә? Залда шау-гөр килеп концерт бара, кул чабалар, көләләр, гүлиләр. Ә монда, сәхнә артында иң карт язучыларыбыздан берсе үлеп ята.

Бераздан ук хөкүмәт комиссиясе оешты, икенче көнне цинк табутка салып үз аягы белән килгән карт язучыны самолет белән Казанга озаттык.

Бүген борчыган нәрсә әле аннан да башкарак иде.

"Өлкә"гә барып үзебезнең иптәшкә, җитәкче иптәшкә керсәм, анда Г. Г.[3] утыра... Юк, аннан түгел, декададан ук башларга кирәк.

"Туй үпкәсез булмый" ди татар. Бик дөрес икән ул. Декадада миңа бик күп кеше үпкәләде. Дөресен генә әйткәндә, күбесе урынсызга үпкәләде. Орденның кечерәген биргән өчен дә, банкетларның зурысына яисә кечкенәсенә билет житмәгән өчен дә—барысы өчен дә миңа үпкәләделәр. Ихтимал, минем дә гаебем булгандыр, мине кайбер иптәшләргә үзенең хезмәтенә, әдәбиятта тоткан урынына лаек орден яисә исем алу өчен тиешенчә сугышып житкермәгәнмендер. Мәсәлән, мин Риза Ишморатка дәрәҗәлерәк орден бирүне кирәк табып, аны беренче исемлеккә керткән идем. Ул "Хезмәт Кызыл Байрагы" алырга тиеш иде, шулай ук Әхмәт Фәйзи дә. Ә аларга тегендә, югарырак урында башкачарак караганнар, минем фикер белән исәпләшмәгәннәр. Ә мин исә үзем биргән исемлектәгечә булуына ышанып, соңыннан аны тикшермәгәнмен, үз фикерем өчен ахырына кадәр көрәшмәгәнмен...

Ярый, барып кердем, тегенди-мондый йомышларымны үтәдем, шуннан соң Г. Г. әйтә: "Менә мин как-раз Г. Бәширов өстеннән жалоба белән килдем",—ди. Шуннан сөйли башлады: "Гомәр Бәширов минем дошманым. Мин хәтта ул кергән бәдрәфкә дә кермәячәкмен".

Кешеләрнең күзе шар булды. Ничек инде ул, әллә кайчаннан дус кешеләр, ничек болай кинәт дошман булып китте?

Менә шуннан китте инде: "Ул мине батырырга йөри, ул татар балалар әдәбиятын бөтенләй юкка чыгарды, фәлән дә фәсмәтән".

Йә, Аллаһ, нигә мин Гариф Гобәйгә дошман булыйм икән? Нинди сәбәп? Аның

[3] Гариф Гобәй, язучы.

минем юлыма аркылы төшкәне, минем йә анамны, йә атамны үтергәне юк. Нигә дошман булыйм? Минә шул турыда бәхәсләшеп әллә бер, әллә ике сәгать вакыт узды.

Монда төп хикмәт, күрәсең, шунда: Гариф Гобәй үзен хәзерге татар балалар әдәбиятының классигы итеп таный, ягъни аның бер кимчелеге дә юк, ул һичшиксез, һичбәхәссез классик. Аны тәнкыйть итәргә ярамый, ул хәзер тәнкыйтьтән өстен тора. Ә мин аны тәнкыйть иткәнмен дә, ул аны, ягъни Г. Г.не бөтенләй бетерү, эштән чыгару дип аңлый. Аннары шунысы бик гаҗәп: бөтен татар балалар әдәбиятын тәнкыйть итүне ул үзен тәнкыйть итү дип кабул итә.

**29 июнь, 1957.**

* * *

Кенәр кешесеннән бик тә гыйбрәтле һәм шул ук вакытта кызык сүз ишеттем әле.

Быел Габдулла Тукай исеме элекке Кызыл Юл[4] районына бирелде бит. Моны Әтнә районының кешеләре бер дә ошатмаганнар. Имеш, ничек инде ул болай? Тукайның туган ягы, хәтта туган авылы безнең районда бит. Шунысы яхшы, дөресен әйткәндә, хәтта бик тапкыр да җавап биргәннәр.

Элекке "Кызыл Юл", хәзерге Тукай районыннан Әтнә районына берәү кунакка барган. Шунда Әтнә кешеләре моннан үзләренең ризасызлыкларын белдергәннәр. Тукай бездә туган, аның исеме безгә бирелергә тиеш иде, дигәннәр. Кызыл Юл районыннан барган кеше әйткән: Тукай сездә туган тууын да, сез бит аны бала чагында Казанга алып барып, "Кемгә бала кирәк, асрамага бала бирәбез",—дип Казанда калдырып кайткансыз. Ә безнең район кешеләре аны Казаннан кайткач үз балалары кебек тәрбияләп үстергәннәр,—дигән. Шуның белән Әтнә районы кешеләренең авызы томаланган.

**12 декабрь, 1957.**

* * *

Күңел бик нечкәрә башлады минем. Берәр моңлы җыр ишеттемме, кызганыч хәл сөйләделәрме, яисә, мәсәлән, берәр тантаналы вакыйга буламы минем күздән яшь килә башлый. "Кәккүк"не, "Гөлҗамал"ны, "Зиләйлүк"не минем күптән үк инде җыламыйча тыңлый алганым юк. Кайвакыт бик авыр, читтән тыш авыр була. Күңел сыкрый, хәтта гасабилек тәмам югары ноктасына менеп җитеп башым авырта башлый. Әгәр үз иркемдә генә яшәсәм, ихтимал, мин аны җиңәр дә идем, әмма хәзер кыенрак булыр инде.

Хыялым бик матур, киләчәгемә, иҗатымның тагын да үсәчәгенә ышанычым бик зур иде. Язучыларның IV съездыннан соң тыныч кына союз эшеннән төшеп калып, барлык көчемне иҗат эшенә бирмәкче идем. Әлеге яңа башлаган әсәремне язып бетерергә җыена идем. Авылга китәрмен дә халык арасында яшәрмен, шунда язармын дигән идем. Планнарым эшләнеп беткән кебек иде инде. Һич көтмәгәндә, эшләр менә болайга борылып китте.

Хәзер нишләргә инде? Язучылыкны ничек дәвам иттерергә?

Билгеле, иҗат эшен туктату турында бер генә түгел, хәтта ярты гына сүз дә булырга мөмкин түгел. Ул минем өчен үлем белән бер булыр иде.

Хәзер хикмәт вакытны оештыра белүдә. Ничек итеп оештырырга? Барлык көчне, барлык белемне һәм сәләтне шул әсәрне тәмамлауга ташларга кирәк. Ул минем барыбер төп максатым булып калырга тиеш.

Бәлки бик иртә ятып, бик иртә торырга кирәктер? Бәлки башкачадыр. Ничек кенә булмасын, бу теләкне, һичшиксез, тормышка ашырырга кирәк.

**15 декабрь, 1957.**

* * *

Шулай итеп, туганкай, менә 1958 елга да чыктык инде.

Хәтеремдә: 1940нче елда мин шушы көндәлекнең беренче китабында бераз монсуланып "Яшен җиткәч кырыкка, к... китә шырыкка" дигәндәй бер нәрсә

[4] Ул елларда Кушлавыч авылы Әтнә районына,ә Яңа Кырлай авылы Кызыл Юл,( Габдулла Тукай) районына кергән.

язган идем. Ул чакта мина 40тан узгач инде картая башлыйсың, анда инде әлләни эшләп булмас кебек тоелган иде. Хәзер менә мина 57 яшь тула, әмма үземне карт итеп хис итмим ләбаса!

Кырык яшемдә үземне бәлки мин тагын да яшьрәк хис иткәнмен, әмма мин хәзер дә карт кеше түгел, юк!

Аннан соң хәтер начарлана бара. Язучы өчен монысы бик куркыныч әйбер. Чөнки язучыга бик күп нәрсәне хәтерләргә кирәк, бөтен бер романны аерым каһарманнары, төрле тормыш мажаралары белән һәммәсен дә истә тотарга кирәк. Менә шул нәрсәдә аксамасам ярый инде. Юкса бит бер нәрсә дә яза алмаска мөмкин. Язучы өчен бу фаҗига. Минем түрә булып яшәвем кемгә кирәк? Чөнки түрә булып кем дә утыра ала, ә язучы ул башка нәрсә. Теләсә кем язучы була алмый. Аның өчен, һәркем белгәнчә, талант кирәк! Талант! Ә талант дип әйткән нәрсә ул сирәк очрый. Миндә ул нәрсә бар. Һичшиксез! Әгәр мөмкинлек булса, ягъни вакыт булса, мин тагын күп нәрсәләр яза алган булыр идем әле.

**1нче гыйнвар, 1958ел.**

* * *

Йә, Гомәр! Янасаланың Бәшир абзый малае!

Иртәгә бит бик зур вакыйга булачак, сине СССРның иң югары кинәшмәсенә чын вәкаләтле депутат итеп сайлаячаклар. Син шул вакыйганың бөеклеге, чиктән тыш бер вакыйга булуы турында уйлыйсыңмы, әллә, моннан элек сайланган булганлыктан, ул турыда уйламыйсыңдамы? Юк, уйлыйм мин, бик уйлыйм. Менә шушы арада гына сигез районнан йөреп кайттым. Сигез район үзәгендә, бер совхозда, МТСта, өч мәктәптә булдым. Мине һәркайсында илнең зур кешесе итеп, язучы итеп каршыладылар. Ләкин мин яшь кеше, башы уңышлардан әйләнә торган кеше түгел бит инде. Башым муенымда нык утыра, мине андыйлар гына чыгырымнан чыгара алмаячак. Сайлыйлар икән, мине Гомәр Бәширов булган өчен генә сайламаячаклар, бәлки татар совет әдәбиятының, димәк, шулай булгач бик күп милләтле совет әдәбиятының вәкиле итеп сайлаячаклар. Шулай булгач, син Гомәр туган, бер дә кәперенмә. Сине Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим... өчен дә сайлаячаклар, ә Гомәр Бәширов булган өчен генә түгел. Шулай итеп шул, синең әлләни мактанырлык, бигрәк тә кәперенерлек бер нәрсәң дә юк. Синнән бик югары торган Галиәсгар Камал, Һади Такташ та ул дәрәҗәгә ирешмәгән. Г. Камал "Кызыл Татарстан"да игъланнар бүлегендә эшләгән, Һади Такташ "Азат хатын"ның иң гади әдәби хезмәткәре генә булган. Муса да, хәтта хәзер бөтен дөньяга шаулаган Муса Җәлил дә шәһәр советы депутатыннан югары күтәрелә алмаган. Ә синең дәрәҗәң әнә кайларга таба китте! Билгеле, әгәр ул иптәшләр, әдәбиятыбызның ул бөек кешеләре исән булган булсалар, синең урынында алар булырга тиеш иделәр. Г. Ибраһимовны әйткән дә юк. Ул, ихтимал, хәзер СССР Фәннәр Академиясенең член корреспонденты, хәтта академигы да булган булыр иде.

**15 март, 1958.**

* * *

Әле генә Фатих Хөснидән кайттым. Мәрфугасы өйдә юк иде, кечкенә бүлмәсендә икәү генә утырдык. Шул бүлмәнең бер стенасында хуҗаның әллә кайчан төшкән бер рәсеме бар. Арткы планда ниндидер куе болытлар, шул фонда Фатих үзе бераз гына түбәнрәк карап, нәрсәләр турындадыр хыялланып утыра. Яшь чагы әле, чәчләренә дә чал кермәгән... Мин аны үземнең якташым итеп яратам. Чөнки ул чыннан да минем якташым. Янил урманын чыгуга—аның авылы. Без аның белән бала чактан ук бер туфракта үсеп, малай чакта тышка чыкканда бер үк йолдызларны күреп үскәнбез.

Әмма мин аны якташ булган өчен генә түгел, бәлки зур язучы, талантлы художник булуы өчен, авылча беркатлы булуы өчен яратам. Гәрчә беркатлы дип әйтүем үзе беркатлы. Итәрсең беркатлы крестьян агайны! Ул шундый хәйләкәр, шундый катлаулы, шундый зирәк! Ф. Хөсни дә шулай. Крестьян агайның иң нечкә хәйләләренә, иң төгәл исәп-хисапларына кадәр анда һәммәсе дә бар.

Безнең өчен Ф. Х.нең башка ягы кадерле—ул зур талантлы кеше. Әгәр тел ягыннан

тикшерә китсәң, ул, ихтимал, безнең соңгы елларда телебезне баетучылардан иң көчлесеңер.

Әле моннан 5-6 ел гына элек аның теле гомумән әйбәт тел, шома һәм бай тел генә иде. Менә бу соңгы әсәрендә ул телне чын художникларча эшкә җигә башлады. Хәзер аның теле гомумән бай, гомумән матур, гомумән шома тел генә түгел, бәлки төп геройларның холкын, фигылен ача торган тирән эчтәлекле, үзенчәлекле телгә әверелде. Ул телнең бөек көчен, аның гаҗәеп мөмкинлекләрен тирән итеп аңлый башлады, алай гына да түгел, образлар теле аша аның монарчы бүтәннәр әйтеп бирә алмаган соклангыч матурлыкларын ача башлады. Фатихның шушы үсеше өчен мин бик шат. Аның теле белән язылган әсәр соңгы вакытта бездә юк иде әле. Хәерле юл сиңа, Фатих якташ!

**11 апрель, 1958.**

* * *

Ниһаять, бүген Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Ниһаять дим, чөнки бу бик күптән көтелгән зур, биниһая зур вакыйга! Советлар Союзындагы һәрбер халыкның үзенең зур кешесе бар. Ул кешеләр халыкларның хәзерге үсешләрен, хәзерге тәрәккыятләрен хәзерләгәннәр. Әгәр алар булмаган булса, ихтимал, без бу дәрәҗәгә житмәгән дә булыр идек. Шунлыктан боларның әһәмияте безнең хәзергебез өчен генә түгел, киләчәгебез өчен дә бик зур. Чөнки без бит, дөресен генә әйткәндә, шулар башлаган баскычны дәвам итәбез.

Халык бик күп иде, халыктан да бигрәк чәчәкләр күп иде. Чәчәкләр, белсәгез, тормыш һәм бәхет билгеләре.

Менә безнең алдыбызда шактый ук биек пьедесталда Габдулла үзе басып тора. Бәлки ул нәкъ элекке Габдулла төсле үк түгелдер, ихтимал, ул ошап ук житмәгәндер. Ләкин хәзерге буын аны безнең халкыбызның сөекле шагыйре итеп кабул итте. Аңа бик озак кул чаптылар. Китапмы, дәфтәрме тотып тора. Үзе йөргән урамнарда басып тора. Бәлки ул үз халкының киләчәген, аның башкаласы булган Казанны мондый дип күз алдына китермәгәндер. Әмма яңа буын аны менә шулай итеп төзеде. Әгәр Габдулланың бөтен тормышын һәм иҗатын күз алдына китерсәң, аңларсың, ул халыкка, барыннан да бигрәк үзенең татар халкына яхшы тормыш, бәхетле тормыш теләгән, аның бөтен иҗаты әнә шул бөек максат белән илһамланган.

Тукайлар күп булмый бит ул. Менә шул бер булганы шәһәрнең уртасында күз алдына килеп басты. Инде көтик: татар халкының тагын бер Тукае килеп чыкмасмы икән?!

**9 август, 1958.**

* * *

Бүген минем кызымны үзенә алып китәргә теләүче кеше[5] килде. Ни дип әйтәсең, карап торуга чибәр генә бер яшь кеше. Сөйләвенә караганда, тормыш кыенлыкларын да аз күрмәгән булса кирәк. Кимсенеп тә яшәгән, үзенең ипиен вакытында бик кыенлык белән тапкан. Сугыш елларында черегән, өшегән бәрәңге дә ашап үскән. Аннан соңгы гомере дә шикәр белән май эчендә генә узмаган. Гомумән, азмы-күпме дөнья күргән кеше дип әйтергә була. Бу яклары аның файдасына сөйли. Тәскә-биткә дә ярыйсы гына.

Ләкин... Ләкин дип әйткән бер сүз бар бит әле. Ләкин кем ул? Аның рухи байлыгы нинди, холкы-фигыле ничек, тормышка карашы ничек? Ул ягын, борынгыча әйткәндә, алла үзе генә белә. Хәер, әгәр алла чыннан да булган дип гөман иткәндә, алла үзе дә белә алмаган булыр иде. Чөнки дөньяда аның бәндәләре шулкадәр күп, хәтта алла да барлык кешеләрнең дә холкын-фигылен белеп бетерә алмаган булыр иде. Әлеге шул борынгылар сүзе кала: хәерле булсын инде.

**14 февраль, 1959.**

* * *

Ике шагыйрьнең шактый ук уңышлы чыккан эпиграммалары искә төште. Әйдә, теркәлеп калсын әле. Бәлки соңыннан ул кайбер нәрсәләрне аңлатыр[6]

---

[5] Ул вакытта авыл укытучысы, соңыннан галим һәм язучы Мөхәммәт Мәһдиев.
[6] Эпиграммалар Батыев Салих Гыйлемхан улына багышланганнар.

*Үйныйязмыш безнең белән усал уен,*
*Килә дә гел Батый, бутый Идел буен.*

(С.Баттал)

Икенчесе:
*Күрә идем элек аны әти кебек,*
*Хәзер инде күрәм аны Батый кебек.*

(Ә.Исхак)

**2 сентябрь, 1959.**

Тагын бер елдан мина 60 яшь тула. Менә шуна борчылам. 60 яшь булганга түгел, 60 ел эчендә мин халкыма нәрсә бирә алдым? Менә нәрсәдә хикмәт!



*Гомәр Бәширов һәм композитор Сара Садыйкова иҗатларына багышланган "Җидегән чишмә" кичәсендә. Түбән Кама. 14 апрель, 1984 ел.*

Бик озак уйлыйм, бик озак! Әле болай уйлап карыйм, әле тегеләй. Ләкин соныннан берсе дә ярамый, бөтенесен янадан башларга кирәк була. Бәлки иҗат газабы шулдыр инде ул? Бер эпизодны бирү өчен аның кырыкмаса кырык вариантын эшләргә, уйларга кирәк.

Кайбер кешеләр 1 ел эчендә роман язып чыгалар. Бәлки алар бик талантлыдыр? Мин алай ук талантлы түгелмен? Ихтимал.

Әгәр дә мин шушы уйлаган әсәремне язып бетермичә үлем китсәм, бу хәл бик үкенечле булачак. Бик, бик! Мин халыкка нәрсәдер биреп бетермәгән булам бит! Алай бурычлы булып калырга минем хакым юк. Чөнки минем артымда бик талантлы язучылар унлап, егермеләп чират тормыйлар.

Бу әсәремне язып бетермәсәм, мина үлгәннән соң терелеп янадан монда кайтырга туры киләчәк. Уйла син моны, уйла!

**19 сентябрь, 1959ел.**

* * *

Бүген Фатих Хөсни үзенен "Литературная газета"га язган мәкаләсен кереп укыды. Бер колагым белән аны тыңлап, икенчесе белән дөньяны тыңлап тордым, чагыштырдым. Элек татар язучылары азмы-күпме русча белгәннәрдер инде. Әмма болай бөтен дөньяга чыгарлык мәкалә яза алмаган булырлар иде. Бу бик притимив чагыштыру инде. Шулай да монда уйланырлык бик күп нәрсә бар. Без бик нык үстек. Без хәзер рус әдәбиятына тиешле өлеш кертә алабыз.

Икенче ягы да бар. Әйе, ул ягы да бар. Татар әдәбиятына килү юллары кыенлаша бара. Нәрсәдер, татар мәктәпләрендә кинлек житми, бөтендөнья әдәбияты күзлегеннән чыгып балаларны өйрәтү житми. Укытучылар бик чикле кешеләр. Тормышны гына түгел, әдәбият алдында торган бурычларны гына түгел, бәлки гомумән эстетик тәрбияне тар аңлыйлар. Шунлыктан балалар әдәбиятны гына түгел, гомумән сәнгатьне бик тар, ачу китергеч дәрәҗәдә кысан аңлыйлар. Сәнгать нәрсә ул дигән сорауга балалар мәктәптән җавап алып чыкмыйлар. Бик аяныч хәл. Моны төзәтергә кирәк.

**24 октябрь, 1959.**

*Дәвамы киләсе саннарда*

# АК КҮҢЕЛ ҺӘММӘБЕЗГӘ КИРӘК

"Өйгә кайтасы килә. Минем—Сежене, Рифкатьнең—Рәҗәпне, Рамилнең—Карадуганны... күрәсе килә".

Язучы, Арча ягының Сеже авылы егете Вакыйф Нуриевнең "Әбиемә—әфлисун" исемле искиткеч повестеннан шушы юлларны укыгач, иseme китапка керүе хакында "Карадуганны күрәсе килгән Рамил"нең үзенә әйткән идем, әллә ни кызыксыну белдермәде. Ләкин бүгенге җәмгыятьнең китапка, китап сүзенә мөнәсәбәтен шактый тулы чагылдыра торган бу күренеш мине гаҗәпләндермәде, үзенә ияртмәде, киресенчә, "Әбиемә—әфлисун" әсәрен кабат укып карарга этәрде. Һәм, менә куаныч, аны кабат һәм кабат та укып була, ялыктырмый, укыган саен син үзеңне әсәр каһарманнары арасында тоя барасың, андагы якты күңелле "яшьтәшләрең" белән аралашудан күз алларың яктыргандай хис итәсең икән. Әле алай гынамы, үзеңнең дә шул матур уенга катнашасың, хәзер кибетләрдә өелеп тора, шунлыктан күзне һич кызыктырмый торган әфлисуннарны күп итеп сатып аласың һәм повесть каһарманына бүләк итәсең килә башлый. Сөендерсен иде авыру әбисен! Шуңа үзе дә куанып иде. Кемне дә булса шатландыра алу шәп бит инде, кеше гомерендә, нигәдер, сирәк була торган бәхет. Уникe яшьлек үсмер Вакыйф (әсәр каһарманы) та әнә шундый сирәк бәхеткә иядер, чөнки ул әлеге җыйнак кына истәлек-повесте белән никадәр укучысын сөендергән бит. Әйе-әйе, ул һаман да үсмер хәлендәдер, аның укучылары да, ничә дистә ел яшәүләренә карамастан, һаман яшьтәшләредер. Балачагыннан, яшьлегеннән киткәннәр әллә кайчангы вакыйгаларны болай тәэсирле итеп сөйли дә, күңелләре аша үткәреп укый да алмаслар, мөгаен.




Әмма сөенечләрнең дә төрлесе була икән шул әле. Сөенүчеләрне күреп, елата торганнары! Әнә "мич башында, әти үлгәч акча бирәләр икән дип, сәдакага сөенешеп калган" биш бичара сабый. Шуларның берсе—повесть каһарманының булачак әтисе. Биш баланың әнисе инде бүген—оныгы Вакыйфка 12 яшь чакта—"тугызынчы дистәнең яртысын сүтеп килүче" авыру әби. Малай "Яшь ленинчы" редакциясе бүләк иткән юллама белән "Орленок" пионерлагерына килеп, беренче тапкыр ашханәгә кергәч тә табынга куелган әфлисуннарга игътибар итә һәм өендә, урын өстендә ятып калган әбисен күз алдына китерә. Шуннан соңгы һәр вакыйга, лагерьдагы һәр кеше, кайта-кайта сөйләнгән һәр истәлек, китеп тә өлгермәстән малайларча пакъ сагыну белән сагынылган туган як шушы икегә—әбигә һәм малайның үз авызыннан өзеп аңа алып кайтачак әфлисуннарга мөнәсәбәттә ачыла. Нәкъ чын тормыштагыча: аны аңлаучылар, булышырга теләүчеләр дә, аңламаучы тупас җаннар, авыру әбигә дип җыеп тотылган әфлисуннарны урлап ашаучы әрсез алабайлар да бар монда. Хәер, кешеләр һәркайда да күптөрле. "Әбекәйнең әфлисун ашыйсы көннәре бар икән бит әле" дип, кайтышлый Мәскәү урамында шул татлы җимешкә чират торганда да булачак әдипнең хәтеренә шул төрлелек уелып калган. Әнә малайның "В деревне бабушка больная. Зинһар өчен, один апельсин. Пажалысты" дип ялваруын колакларына да элмичә, аның алдына баскан ике каратут мужик сатучы белән пышын-пышын сөйләшәләр дә, көньякның кызыктыргыч җимешен әрҗәсе белән алып китәләр. Чөнки әфлисун Мәскәүнең дә үзендә сирәк сатыла, бүгенгесе дә партия съезды ачылу хөрмәтенә генә чыккан. Ә "каратут"ларга,

*Жиденче палата: повестьлар, хикәяләр / Вакыйф Нуриев.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.*

базарда биш бәягә сату өчен, аны җай кылгәндә күбрәк эләктереп калырга кирәк, ниндидер узгынчы малайның авыру әбисендә аларның гаме юк. Чират азагындагы бер түтинең "Ну хоть мальчику дайте один апельсин" дип кычкыруы аларның аңына барып та житми. Хәер, ул елларда каратут "кардәш"ләрнең Казан базарларындагы кыланышлары да шуннан ким түгел иде.

Ләкин Вакыйфның күңелләргә нур өстәүче бу әсәрендә, шөкер, "караларга" бик-бик аз урын бирелгән. Балачагыннан якты хатирәләр саклаган әдип кенә укучы күңелен яктырта торган әсәр яза аладыр, ә Вакыйф дусның хатирәләре дә чиста-пакъ, язган кыйссасы да җаннарны сафландырырлык. Лагерьда малай белән бергәләп ял иткән Урал кызы Ләйләне генә күрегез сез! Аның садәлеге, күңел сафлыгы балачак истәлекләрендәге уңнарча "кара"ларның каралыгын күмеп китәрлек. Җитмәсә, малайның әбисенә алып кайтачак әфлисунын да поездда шушы кыз бүләк итә. "Итекләремне киеп ятканда, Ләйлә тагын пәйда булмасынмы! Карыйм—кулында әфлисун.

—Әфлисун!..

—Ал моны.—Әбиеңә—күчтәнәч.—Ләйлә үзе дә шул әфлисун кебек балкый, яна иде.

Мин сүзсез, телсез калдым". Әсәрдән ул күренешне уку әле бүген дә күпләрне "сүзсез, телсез" калдырадыр, мөгаен. Мең рәхмәт әтисе урыс, әнисе татар булган Урал кызына да, Сеженең укытучы Нәкыя улына да! Повестьны укыгач, ул елларда "Яшь ленинчы" газетасында эшләгән безгә таныш Әнвәр Хуҗиәхмәтовка, Венера, Рәисә, Саимә апаларга, Нургали Булатовка һәм башка каһарманнарга да бүтәнчәрәк карый башлыйсың.

Әлеге әсәр Вакыйф Нуриевның узган ел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Җиденче палата" исемле мәҗмугасын ачып җибәрә. Мондагы өч повестьны автор бик мәгънәле исем белән берләштергән: "Җаннарны чайкыйсы бар..." Җаннарыбызны чайкау зарурлыгын әдәбиятта Вакыйф беренче булып күтәрми, әдип-шагыйрьләребез ул хакта гел искәртеп килгән, тик моны ничек эшләргә икән соң? Тукаебыз да бит "тәңгә мунча, җанга—юк" дип офтанган. Әмма чарасына керешкән—әмәлен табар. Әйтик, нәфис әдәбият китаплары уку да шундый әмәлләрнең берсе була аладыр. Ул китапны Вакыйф кебек әдәпле әдипләр язса, әлбәттә.

Китаптагы повестьларның икенчесе "Карга карагы" дип исемләнгән. Сурәтләнгән вакыйгалары бөтенләй үзгә булса да, эчтәлеге, укучы аңында сынландырырга теләгән фикере беренче әсәрдәгегә шактый охшаш: бер якта—ихласлылык һәм гаделлек, икенче якта—кара йөрәклелек. Үсмер егет күңеле аша сөзелеп, сәләтле каләм белән сурәтләнгәнгә, болар һәммәсе укучы тарафыннан аңлап, якын кабул ителә. Беркадәр Гайдарчарак мажара да бар бу әсәрдә. Пионер Вакыйфның Аркадий Гайдарны укып үсүе һәм язуда азмы-күпме аның йогынтысына бирелүе гаҗәпмени? Өтермәс малае Булатны да "җинаятьчеләр турындагы китапларны су урынына эчеп, үскәч тикшерүче, юрист, һичьюгы милиционер булам дип хыялга чумган" итеп сурәтли бит. Менә Булатка "хыял"ын эшкә җигәргә җай да чыгып тора: Хәтәр кушаматлы авылдашы Тимерхан төрмәдән качкан, ди, әнә. Әгәр авылына кайтса? Бу уй шомландыра да, кызыксындыра да малайны! Байтактан участковый Наил тирәсендә бөтерелә ич ул. Бәлки әле җинаятьчене эләктерергә ярдәм дә итә алыр? Авыл тирәсендә малайлар белми торган, алар аягы җитмәгән урын юк бит, кая яшеренсә дә күрәчәкләр. Ятим Тимерханны элегрәк күрше карчыгының ике тавыгын урлап суюда да гаепләп сөйләгәннәр иде. Аннары ул авылдан китеп барды, Мәскәү тирәсенә барып урнашкан, диделәр. Бер-ике елдан авылдашларына "Кеше үтереп өтермәгә эләккән икән" дигән хәбәр килеп иреште. Инде менә каядыр качкан.

—Кая качсын?! Өтермәдән Өтермәскә кайтыр инде ул,—ди Гыйзелбанат әби.

Абау, бәлки ул төннәрнең берсендә Булат йоклаган келәт ишеген шакыр? Ә бит Тимерхан-ристанның Булаттан җиде төн уртасында җиде ишекне ачтырырга хакы бар". Чөнки ул 4-5 яшьлек чагындагы малайны язгы пычракка батыптуңып үлүдән коткарып калган иде.

Мавыктыргыч мажаралары байтак булса да, бу вакыйгаларга нидер җитми бит әле. Әһә, автор аны тиз таба—Булатны Күкчә кызы Гөлия белән "таныштыра", һәм әсәр шунда ук җылынып китә. И ул үсмерчак мәхәббәтенең Вакыйфлар чорына туры килгән, күңелләрдә аклык кына калдыра торган садәлеге. Шушылай язарга, истәлек өчен язып калдырырга кирәк аны, бер укылмаса, бер укылыр әле. Югыйсә, хәзерге чор үсмерләренең унөч-ундүрт яшьтә әти-әни булулары,

әле житмәсә шуларның "ялгышлыктан" туган балаларын теләсә-кая ташлап калдырулары хакындагы хәбәрләр белән матбугат тулды, алар заман әдәбиятына да үтеп керде. Тотнаклылык, пакьлек-әдәплелек үрнәге генә каядыр югала бара. Бүген безгә андый үрнәк кирәкми дә бугай: булганнарын да төрлечә пычрату жаен карыйбыз, андыйлар "җенебезне чыгара". Әнә Тимерхан, егет һәм егетлек үрнәге буласы жан, кеше дә үтермәгән, хәтта күрше тавыгын да ул суймаган, төрмәгә бер гаепсез эләккән. Гаепсезлеге бер расланыр, хаталарын танып, аклар-лар, дип көткән-көткән дә, гаделсезлек-кә җаны кыйналып, төрмәдән качкан. Аның сөйләгәннәре—Булат өчен үзе бер олы сабак, андый сабакны мәктәп тә бирә алмый. Болай булгач, Булаттан милиционер чыкмый инде. "Ристан"ны жәлли, Наил абый, әйдә, тимик аңа!—дип тора бит, шундый малай милиционер йә тикшерүче була диме? Димәк, Тимерхан абыйсы аны тагын бер баткактан коткарды. Участковый Наил абыйсы, акыллы, хәлне анлый торган кеше, Тимерханның бер гаепсезлеген белә торып, ана кабат төрмәгә озатачак, чөнки закон шулай таләп итә. Авылдашын яладан аралау, аның иреккә хокукын саклау өчен генә берни кыла алмаячак ул, егетне ялгыш япкансыз, дип, коллегаларына тел ача да алмаячак, нинди гаделлек ди әле монда. Бер Наил генә шундыймы, әнә кайдадыр тикшерүчеләр һәм хөкем ияләре, бер зур түрәнең малае үтерелгәч, үтерүчене тиз арада тотарга дип өстән бирелгән әмерне тайпылышсыз "үтәп", кул астына беренче эләккән яклаучысыз Тимерханны җинел генә тотып ябалар. Кешелексез гамәле өчен берсе дә үкенү белдермәячәк, Алладан да, гаепсездән "гаепле" каршында да ярлыкау сорамаячак—мондый хәлнең булганы юк. Аны гаделсезлектән, күрәләтә ялгыш хөкем карарыннан аралау өчен бер президент та, депутат та кыл кыймылдатмаячак—андый миһербанлыкны да беркем хәтерләми. Чөнки берсенең дә үз баласы түгел. Шулай итеп, Гайдарчарак башланган маҗаралы кыйссаның ахыры классикка бөтенләй капма-каршы юнәлеш ала, үзебезчә, үзебезнең Рәшит Бәшәрчә, Вакыйф Нуриевча гамьле, барабаннарсыз тәмамлана. Чын тормыштагыча диярлек бу. Төрмәдән качкан Тимерханның—мәктәп тәмамлаганда ук көрәшеп батыр калган нечкә хисле ятим егетнең—качкан хәлендә тау башыннан үз авылы Сабан туен күзәтүе—менә ул милләтнең, күп кенә милләт улларының авыр язмышы. Шуларның берсе булган Тимерхан сөйли:

"Көрәш!.. Татарча көрәш!.. Синче!

Йөрәгем кысып куйды. Эчемдәге ялкыным ургылып тышка бәреп чыкты. Мин—ут эчендә. Нишлим? Каршымда—имән. Мин аңа чытырдатып ябышам, төбе-тамыры белән күтәреп алмакчы булам. Үзем елыйм. Мин—"зэк", Сабантуй көнне, мәйданга керә алмыйча, авылымның тау башында елап утырам".

Нәкъ шул минутларда кайсыдыр ерак-ерак илнең мәшһүр спортчы Татарстан командасы өчен миллион сумнарга туп чөядер, мөгаен.

Повестьларның өченчесе—китапка да исем биргән "Жиденче палата" әсәре хакында, ул "Казан утлары"нда басылып чыгу белән үк , байтак уңай фикер әйтелде, аңа бик урынлы "алкышлар"ның әле дә тынып житкәне юк. Автор, үз гаиләсенә килгән шәхси бәхетсезлектән "этелеп китеп", реаль жирлекле, бик зур социаль яңгырашлы әсәр иҗат итә алган. Һич көтелмәгән урында машина казасына эләккән Ардуан әсәрдәге баш каһарман ролен повесть барышында әкрен-әкрен бүтәннәргә бирә. Чөнки монда, 12нче бүлниснең җиденче палатасында, сизгер әдип күзәтүенчә, тагын да бәхетсезрәкләр, моңсу кыйсса үзегенә куелып сурәтләнергә, күрәсезме бу балагызны, кешеләр, дип кычкырырга бигрәк тә лаеклылар бар. Биш караваттагы биш малайда—рухи дөньябызның биш кыйтгасы язмышы. Шушы бүлнистә генә дә авыру җәмгыятьнең бөтен чире чагыла. Автор ясалма төстә бергә тупламаган, ул очраклы гына аларның өстенә килеп чыккан. Димәк бу чирләр—һәркайда. Кеше белән кеше, ир белән хатын, ата белән улы, кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрендәге чиялә төйнәлгән төеннәр—менәниләр повестьны дулкынланып, борчылып, аерыла алмыйча укырлык итә.

Отыры миһербансызлана барган яшәешебез авыру яисә имгәнгән балалар, аларның якыннары аша тагын да җетерәк ачыла икән шул. Монда "ачылган" шәфкатьсезлек күренешләренен кайберләренә ышанып бетәсе дә килми, аңлап та булмый. Карагыз сез Гадел белән аның әнисе Гажилә язмышын. Гажиләне, баласы белән бергә, каенанасы, ягъни, Гаделнең әбисе, үзенең һәм улының дүрт бүлмәле фатирына прописка кертмәгән, һәм алар хәзер чит кешеләр янына сыенырга мәҗбүр.

Үз онытына, нәселе дәвамчысына куанмау гына түгел, аны бөтенләй танымау өчен нинди "әби" булырга кирәк ул? Ә Гажилә белән Гаделнең, фатир өчен түләүдән тыш, ашыйсы, киенәсе дә бар бит әле, һәммәсенә акча кирәк. Гажиләнең исә рәтле эш урыны да юк: элек эшләгән "пароховой"дан цехы-ние белән кыскартканнар, малае имгәнгәннән бирле базардагы "хезмәтенә" дә чыга алмый. "Ярый әле авылда әнекәш бар, азык-төлек белән ул булыша",—дип кенә йөргәндә, көтелмәгән үлем (әй, бик үк көтелмәгән дә түгел шул) аны да алып китә, ике кешелек мескен гаилә бер ярдәмчесез кала. Дөньяның бер өлеше хәрамнан һәм исәпсез байлыктан котырганда, хәләлдән дә мәхрүм Гажилә һәм аның улы кебекләрнең михнәтле язмышы бигрәк тә кызганыч булып күренә. Житмәсә, машина таптап больницада яткан авыр көннәрендә генә булса да, Гаделнең әтисе дә килеп чыкмый, чөнки аларның очрашуын "әби" теләми. Ә малай ничек көтә аны. Һәр килгән ир-аттан әтисен "эзли". Әнә беркөн, сабыры төкәнеп, жаны кыйналуга түзәр әмәле калмагач, автор әйтмешли, һәммәсен "утлы табага бастырды". "Аягым, аягым. Авырта. Үләм,—дип кычкырулары йөрәккә кадалды. Табибларны чакырдык. Алар нишләтеп карамадылар ул аякны. Бушаттылар, тарттырдылар. Тагын бушатып, тагын тарттырдылар. Аптырагач, укол кадамакчы булдылар. Гадел кадаттырмады, теше-тырнагы белән каршы торды.

Ак халатлы абыйлар, апалар!

Юкка мәшәкатьләнәсез бит сез. Авыртмый аның аягы. Чәрдәкләнгән булса да, сынык булса да авыртмый. Күңеле сынык аның. Күңеле әрнегәнгә түзә алмыйча елый ул. Күңелен сындырганнарга нәфрәтен белдерә".

Жиденче палатада язучы каләме озаклап тукталырлык, безнең "кемлегебезне" ачып күрсәтергә ярдәм итәрлек икенче авыру—Нияз атлы малай. Монысын Гадел хәлендә дип булмый, әти-әнисе, малайга игътибарсызрак булсалар да, тигезләр, йортсыз-жирсез дә түгелләр. Әмма Ходай (һәм повесть авторы!) бу баланы бүтән төрле сынаулар алдына куйган: аңа китап ярату, шигырьләр язгалау, башкалар өчен көенә белү, бүтәннәр күрмәгәнне күрү, матурлыкны тою сәләте биргән. Ә без, мокытлар галәме, андыйларны аңлыйбыз диме? Әнә беркөн, "чыгыгыз әле, чыгыгыз тизрәк, бернәрсә күрсәтәм?" дип, койма буйларында кар да эреп бетмәгән вакытта, яна шытып килүче яшь үлән күрсәтергә алып чыгуы да малайга тискәре ягы белән кайтты. Армиядән калу өчен генә больницага кереп яткан хөрәсән егетләр үзләрен Нияздан алданган кебек хис итәләр һәм, хәзер без сина күрсәтәбез ул үләнне, дип, умырткасы зыянланган малайны, ике кул белән башыннан кысып, өскә күтәрәләр. Яна тишелеп чыккан, әле теләсә кем күрә дә алмаган апрель үләнендә дә дөнья яме, киләчәккә бер өмет күрүче бер гаепсез хыялый малайга мондый ук жәзаны тапса да шул кансыз фашист кына таба алыр иде. Төнге аулак палатада Нияз белән бергә булган Ардуанга да эләгә. Ана хәтта "йолдыз күрсәтү" белән яныйлар. Бирedә нинди чир белән ятуы да билгесез Утлы күз (кызга бу исемне Ардуанның әтисе куша) коточкыч "тамаша"дан татлы ләззәт кичерә. Ә Нияз беркемне алдамаган, үлән чынлап та шыткан булган. "Яшә, яшел ямь!

Ә син, Нияз, безне гафу ит. Без бит берни күрмибез. Сукырлар без. Дөресрәге, күзле бүкәннәр без". Менә шулай, күзле бүкәннәр булуыбыз, кирәк чакта сөенә йә көенә белмәвебез, бәгырьсезлегебез өчен Ниязлардан кичерү сорап тәмамлана бу әсәр. Автор хаклы: жаннарыбызны ай-һай тырышып чайкыйсы-сафландырасы бар икән шул.

Вакыйф Нуриевнең әлеге китапка кергән һәм балалар тормышыннан алып язылган кыска-кыска хикәяләре дә тагын күп кенә Ниязлар, Ләйләләр белән таныштыра, исемнәре генә бүтән. "Матуркай"дагы, "Киек Каз Юлы"нда, "Ачуланма инде, Илһам!.." һәм башка хикәяләрендәге каһарманнарны да бик кирәкле, әмма сирәгәеп, тансыкка әверелә барган бик матур сыйфат—садәлек, саф күңеллелек берләштерә. "Соңгы йөреш" хикәясендә исә балаларның шундый ук якты күңелле остазлары сурәтләнә. Китапның өчтән бер өлешен алып торучы юмористик хикәяләр дә балалар матбугатында чарланган каләм, алар дөньясын әйбәт белүче һәм аңлаучы әдип ап-ачык күренә. Шул ук вакытта бер "кимчелек"не—сәләте була торып, Вакыйф Нуриевнең әдәби әсәрләрне азрак язуын—әйтеп үтәсе килә. Укуын укыр идек әле, язу—китап танныйбыз ич, шөкер. Һәркайсыбызның ак күңелле буласы килә ләбаса.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# З

**ЗАКИРОВ** Рифкат Хәйдәр улы (16.6.1938, Актаныш р-ны Усы ав.— 22.6.2004, Казан), шагыйрь. Минзәлә авыл хуҗалыгы уч-щесын тәмамлый. Гремячинск шәһәрендә (Пермь өлкәсе) шахтёр булып эшли. 1980 еллар ахырында Казанга кайта. "Сабантуй" газетасында бераз эшләп ала, аннары бары тик иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Беренче шигырьләре "Беренче карлыгачлар" (1968), "Юл башы" (1972) исемле күмәк җыентыкларда басыла. "Шахтёр моңы" (1983), "Ай сөярмен, ел сөярмен" (1987), "Йөрәк уты" (1993), «Җан җылысы» (2006) исемле шигырь китаплары авторы. З.ның геройларына ихласлык, кешелекне борчыган проблемаларга битараф булмау хас.

Әд.: Гаташ Р. Авыл улы, шахтёр, шагыйрь // Казан утлары. 1998. №6.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗАРЕЦКИЙ** Марк Давидович (24.1.1937, Киев—9.3.2003, Казань), шагыйрь, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Хабаровск ш.дә Пед. ин-т тәмамлаганнан соң (1959) Казанда яши. 1964—92 елларда Татар. китап нәшриятында матур әдәбият бүлегенең өлкән мөхәррире булып эшли. Шигырьләре 1955 елда басыла башлый. Аларга заманны фәлсәфи яктан анларга омтылу, афористик стиль хас. «Сүз» («Речь», 1987), «Дәрт» («Азарт», 1991) исемдәге поэтик җыентыклар авторы. Рус теленә Дәрдемәнд, Г.Тукай, Һ.Такташ, С.Хәким, Н.Дәүли, Ә.Маликов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин шигырьләрен тәрҗемә итте.

Әдәб.: Хаиров А. Весна на Заречной улице // Казань. 2003. №3; Черняева Е. Учитель // шунда ук..

**ЗАРИПОВ** Изаил Харис улы (27.2.1927, хәзерге Сарман р-ны Зур Нөркәй ав. — 18.12.1999, Әлмәт шәһ.), журналист, язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Рус телендә иҗат итте. Казан ун-тын тәмамлый (1968). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 елдан "Татбурнефть" тресты бораулау бригадаларында эшли. 1954-57 дә "Знамя труда" (Әлмәт шәһ.) газетасында бүлек мөдире, 1957-60та "Комсомолец Татарии" газетасы үзхәбәрчесе. 1963-68 елларда Лениногорск телевидениесе студиясендә иҗтимагыйсәяси тапшырулар хәбәрчесе, соңыннан өлкән мөхәррир вазыйфаларын башкара. 1968-75 тә Лениногорск һәм Әлмәт шәһәрләрендәге ТАССР МС телевидение һәм радиотапшырулар к-тында өлкән мөхәррир. 1977-80 Әлмәт торба з-дының хезмәтне оештыру бюросы начальнигы һәм "Союзнефтепереработка" Бөтенсоюз оешмасы норматив-тикшеренүләр станциясенең хезмәтне фәнни оештыру группасы җитәкчесе. 1950 еллар башында республика матбугатында һәм күмәк җыентыкларда язмалары басыла башлый. З.ның очерк һәм хикәяләре нефть чыга торган урыннарны үзләштерү, шул өлкәдә эшләгән алдынгыларның хезмәт уңышлары турында. Татарстан нефтьчеләренә багышланган "Буровики" («Бораулаучылар», 1957), "Коллективное творчество" ("Күмәк уңыш», 1961), "Мастер" ("Остакуллар", 1975), "Девятый вал" ("Тугызынчы вал", 1982), "О тех, с кем прожита жизнь" ("Гомердәш дуслар", 1997), "Слово о елховцах" ("Елхов нефтьчеләре", 2000) китаплары укучыларга яхшы билгеле.

Әд.: Гордеев С. О нефтяниках с любовью // Нефтяник Татарстана. 2001. 25 апр.; Фәхретдинов Ә. Нефтьчеләр елъязмачысы // Хәзинә. 1997. 28 март.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗАРИПОВ** Марсель Харис улы (23.10.1931, хәзерге Сарман р-ны Янурыс ав. туа), язучы, журналист, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981, 1987). Рус телендә иҗат итә. Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1956-58 елларда "Әлмәтнефть" берләшмәсендә электрик булып эшли, бер үк вакытта "Знамя труда" газетасы белән дә хезмәттәшлек итә. 1962-66 да "Советская Татария", 1966-91 дә "Советская Россия" газеталарында үзхәбәрче, 1992-98 дә "Татар-информ" информация агентлыгы хезмәткәре. З. ның хикәя һәм повестьлары "Чужой медовой месяц" ("Ятлар туе", 1968) һәм "Ордер на квартиру" ("Үзеңнеке — үзәктә», 1976) исемле җыентыкларына кертелгән. З.ның язмалары күбесенчә әдәби очерклар жанрында язылган, аның геройлары — нефтяниклар, нефтехимиклар, авыл хезмәтчәннәре. "Мы из Казани, с Волги" ("И кадерле туган як", Г.Ахунов белән берлектә, М., 1971), "Девятая высота" («Тугызынчы биеклек», 1973), "Вершины" ("Үрләр", 1981), "Звёздный час Нижнекамска" ("Мәңгелек шәһәр", 1981; Г.Тукай исем.

Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.

ТР Дәүләт премиясе, 1987), "Выгодный оборот" ("Отышлы вариант", 1986), "Чёрное сокровище" ("Алтын хәзинә", т. 1-2, М., 1998), "Бремя престола" ("Тәхет йөге", 2002) җыентыклары авторы. Рус теленә Ә.Еникинең "Әйтелмәгән васыять" ("Завещание", 1966), Г.Ахуновның "Артышлы тау буенда" ("За горой Артыш", 1973), В.Нуруллинның "Аккан су юлын табар" ("С ношей гору не обходят", 1982) повестьларын, Н.Фәттахның "Ител суы ака торур" ("Итиль- река течёт", 1978) романын тәрҗемә итте. Умартачылыкка караган "Сок из росы небесной" ("Баллы оҗмах", 1995), "Мёд на все случаи жизни" ("Балның файдасы", 1996), "Год на пасеке" ("Умартачы календаре", 2001) китапларының төзүче-авторы.

Әд.: Давыдов В. В семье российской, братской // Лит. газета. 1971. 20 авг.; Махмутов А. Где пел Сайдаш, писал Такташ // Лит. газета. 1972. 13 дек. ; Нуруллин И. Един в двух лицах // Советская Татария. 1987. 17 апр. ; Мостафин Р. Түбән Каманың бәхетле язмышы // Казан утлары. 1982. №3.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ЗАРИФУЛЛИН** Фирдәвес Захибулла улы (2.1.1962, Яшел Үзән р-ны Күгеш ав. туа), язучы, журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1990). Казанның төрле оешмаларында электрогазосварщик, Кемерово өлкәсе Прокопьевск шәһәрендә шахтада, Татарстан КПСС өлкә комитеты нәшриятында китап басучы булып эшли. 1989 дан "Татарстан" ДТРК әдәби редактор, 1994 дән "Мирас" ж-лында баш мөхәррир урынбасары. З. татар халкының рухи яңарышына, яшь буынны тәрбияләүдә әхлак проблемаларына багышланган "Татлы җәй" (2001), "Кайту" (2002), "Мин көтәрмен сине" (2003), "Пар дулкын" (2004) исемле проза җыентыклары авторы.

**ЗАҺИДУЛЛИНА** Дания Фатих кызы (1.10.1964, Мөслим р-ны Әмәкәй а.), әдәбият галиме, филол. фән. докт. (2001), проф. (2002). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, гыйльми сәркатибы (2008), татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы каф. мөдире (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1986), 1989 елдан шунда эшли. Хезмәтләре татар әдәбияты теория һәм тарихына, татар әдәбиятын урта мәктәптә укыту методикасына карый.

Хезм.: Әдәбият кануннары һәм заман. К., 2000; Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003; Дөнья сурәте үзгәрү. XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. К., 2006; Яна дулкында. К., 2006.

**ЗӘБИРИ** (Зәбиров) Хәбибрахман Габделвәли улы (псевд. Чистапули) (1881, бүтән мәгълүматлардан 1880, Казан губернасы Чистай өязе Зирекле а. - 14.1.1942, Казан), язучы, педагог. 1901 елга кадәр мәдрәсәдә укый, аннары Чистайда укытучылык итә. 1905 елдан аның актив катнашында Чаллы пристанендә ачылган мәктәптә укыта. Соныннан "Хөсәения" (Оренбург ш.) мәдрәсәсендә укыта. 1908 елдан Казанда, "Тәрбия" ж-налының фактик мөхәррире. 1908-16 елларда "Сабах" нәшриятендә, 1916-21 елларда И.Н.Харитонов типографиясендә, 1921-29 төрле дәүләт нәшриятләрендә эшли. Мәгърифәтчел идеяләр б-н сугарылган "Гыйлем вә җәһәл, яхуд Нури әфәнде илә Мөхәммәтҗан карт" исемле хикәясе, 10 якын юмористик мәзәге, "Төшенү, яки Указ баласе" исемле комедиясе ("Сәйяр" труппасы тарафыннан 1907 елда куела), 1906 елда "Әлгасрелҗәдид" ж-лында басылып чыга. 1914 елда "Ил" г-тасында Г.Тукай турындагы "Габдулла әфәнденең Уфадан Петербургка баруы" мәкаләсе басыла. З. - беренче татар "Мәктәп балаларына юлдаш, яки Рәсемле әлифба" (1907) китабы, башлангыч мәктәп өчен язылган физика, этика, тарих дәреслекләре авторы. Нахакка репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Әдәб.: Шәһидуллин Ш. Заман календаре. К., 1915; Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана. К., 1973; Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. К., 2001; Хәтер китабы. К., 2002. Т.3.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ЗӘЙДУЛЛА** (Зәйдуллин) Ркаил Рафаил улы (23.1.1962, Чуваш АССРның Комсомольск р-ны Чичкап авылында туа), шагыйрь, прозаик, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1984). 1985-87 елларда "Яшь ленинчы", 1987-89 да "Татарстан яшьләре" газеталарында эшли. 1989 дан "Идел" ж-лында редактор. 1970 еллар ахырында матбугатта басыла башлый. "Кояшлы күзләр" (1984), "Күрәзә" (1988; М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы премиясе, 1990), "Урыс кышын озату" (1993) дип исемләнгән шигъри җыентыклар авторы. Шигырьләре гражданлык хисе белән сугарылган, публицистик яңгырашлы, эмоциональлек хас. Проза әсәрләре "Ил" (2000) җыентыгына тупланган. "Саташкан сандугач" (Татар акад. т-ры 2001 дә сәхнәләштерде) пьесасында автор хәзерге тормыш каршылыклары аша чын хакыйкать һәм ялганга корылган кыйммәтләрне күрсәтә.

Әсәр.: Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар. К., 2005.

Әд.: Вәлиев М. Учагың сүрелмиме? // Учагың сүнмәсен. К., 1988; Гыйльманов Г. Күрәзә // Заман сүз сорый. К., 1991; Зөлкарнәев Ф. Р.Зәйдулла иҗаты // Чакма чакмый ут чыкмый. К., 1991; Закир М. Йомшак агачны корт баса // Казан утлары. 2002. N1.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӘЙНАШЕВА** Гөлшат Хисам кызы (13.1.1928, хәзерге Тукай р-ны Иске Теләнче ав. – 1.4.2005, Казан), шагыйрә, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988). Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1949). 1949-65 (бүленеп) елларда ТАССР МС каршындагы радиокомитетта әдәби-драма, сонрак музыкаль тапшырулар мөхәррире. 1952-63тә Татарстан китап нәшриятында редактор, 1973-83 тә кадрлар буенча инспектор вазыйфаларын башкара. 1950 еллар ахырында матбугатта һәм коллектив җыентыкларда беренче язмалары басыла. "Тынларсынмы җырларымны" исемле беренче шигырь җыентыгы 1958 елда дөнья күрә. "Замандашыма" (1967), "Җырлап яшик!" (1971), "Гөлләр иле" (1977) җыентыкларына тупланган шигырьләре мәхәббәт, туган якның матурлыгы, аның кешеләренең күңел байлыгы турында. Композиторлар М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Р.Яхин, С.Садыйкова, З.Гыйбадуллин, Б.Гайсин белән берлектә иҗат иткән җырлары "Илле җыр" (1988; Г.Тукай исем. ТССР дәүләт премиясе, 1991) җыентыгын тәшкил итә. "Гөлсем Сөләйманова" (1957), "Сара Садыйкова" (1987) очерклары З.ның замандашлары – татар музыка сәнгатенең күренекле вәкилләре тормышыннан алып язылган. З. пьесалар авторы да. Аның әсәрләре буенча Татар драма һәм комедия т-рында "Гайфи бабай, өйлән давай!" (1996), «Җаным җәл түгел сиңа» (1997), Минзәлә татар драма т-ры сәхнәсендә «Бәхет кошым" (1964), «Кем гүзәл?» (1970), «Комиссия килгәч» (1976), «Яшел сумка» (1982), "Язмышлар һәм ялгышлар" (2000), "Әкият" татар курчак т-рында «И, кызык Шүрәле» (2000) спектакльләре куелды; З. сценарие буенча "Татарстан – Яңа гасыр" телевидениесе тарафыннан «Тузган торактан күчкәндә» (2004) телефильмы төшерелде. 2006да Казанда З.ның музее ачылды.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 2006.

Әд.: Гаташ Р. Моңнар бәйрәме //Казан утлары. 1998. №1; Нәҗми Н. Илле шатлык // Шәһри Казан. 1991. 12 апр.; Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова Д. Мең кыллы күңел // Мәйдан. 2002. N5.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӘКИ Шәмсетдин** (псевд., чын исеме һәм фамилиясе Гобәйдуллин Шәмсетдин Ярмөхәммәт угылы) (Шәмсетдин Суфи) (1821, бүтән мәгълүматларга караганда 1822 яки 1825 ел, Оренбург губ., Башкорт кантоны Эзәк-Ишмәт а., хәзерге Башкорстан Республикасы Куюргазы районы – 1825 октябрь, Таганрог ш.), суфи-шагыйрь. Псевдонимы туган авылы исеменнән алынган. Чыгышы б-н мулла гаиләсеннән. 4 яшендә сукырая. Башлангыч белемне туган авылында ала, соңыннан Күрше авыл мәдрәсәләрендә укый. 23 яшендә Казанга килә, Күл буе мәдрәсәсендә 7 ел белем ала. Белемле, сәләтле кеше була; Коръәнне, хәдисләрне, мөселман фикхе буенча хезмәтләрне, шәрекъ әдәбиятының күпчелек әсәрләрен яттан белә; матур җырлый торган була. Укыган елларда ук яшь шәкертләрне укытуда катнаша. 30 яшендә туган авылында мәдрәсә ачылгач укытырга кайта. 3 елдан соң авыл аксакаллары б-н низакка керү аркасында бер төркем шәкертләр б-н Уфа губерниясе Эстәрлебаш а. күчеп китәргә мәҗбүр була һәм гомеренең соңгы көненә кадәр шунда укыта. Шәкертләре арасында М.Акмулла, Г.Чокрый һ.б. шагыйрьләр була. З. Мәккәгә барганда юлда вафат була.

Шигъри мирасының төп өлешен газәл, мәдхия, робагый, фәрд һ.б. жанрларында язылган лирик әсәрләр тәшкил итә (46 шигыре татар телендә, 6 – гарәп, 1 – фарсы телендә). Шагыйрь иҗаты дини-суфи идеяләр, тормыш мәгънәсе турында уйланулар б-н сугарылган. Аның шигърияте өндә югары әхлак идеаллары раслана, суфыйларча яшәү рәвеше мактала. З. урта гасыр һәм төрки-татар поэзиясе традицияләрен дәвам итте. Аның лирикасына эмоциональлек, фикер һәм хисне туплый белү сәләте, ритмиканың аныклыгы һәм аһәңлеге хас. Җәмгыятьтә хөкем сөргән гаделсезлек, реаль тормышны кабул итмәү аның лирик героенда үзенең эчке дөньясында мистик рәвештә кереп бикләнү теләге тудыра. Аның "Булгай, булмагай", "Өйрәнмәк кирәк", "Бу үлем бәңа дошман түгел" һ.б. шигырьләренә тормыш хакында тирән фәлсәфи уйланулар, теленә тапкырлык һәм үткенлек хас. "Йә, Иляһи, бер нәзар кылгыл...", "Акыздым канлы яшем..." шигырьләре Аллаһка мистик мәхәббәт б-н сугарылган. З. нең чәчмә әсәрләре исламның төрле күрсәтмәләренә багышланган, Коръәннең аерым урыннарына комментарийлардан торалар. Аның танылган гарәп телендә язылган "Әр-рисаләт әл-фәридә" кульязма китабы суфичылык мәсьәләләренә багышланган. З.нең аерым шигырьләре 1982 дә басылган "XIX йөз татар әдәбияты ядкәрләре" җыентыгына кергән; 2002 дә Ә.Каргалый шигырьләре б-н бергә "Мөнәҗәтләр. Хикәятләр" китабында урын алган. Аның тормышы һәм иҗаты Р.Фәхретдин, З.Мөхәммәт-Рәхими, М.Х.Гайнуллин, Х.Й.Миннегулов, М.В.Гайнетдинов һ.б. тарафыннан өйрәнелде. Р.Фәхретдин З. иҗатын Мәгарри һәм Физули иҗатлары б-н чагыштыра торган булган.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Шарипова З.Я. Пером и словом. Уфа, 1993; Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1907. 2 том, 13 җөзья; Миннегулов Х., Садретдинев Ш. XIX йөз татар әдәбияты ядкәрләре. К., 1982.

*Х.Й.Миннегулов.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Габделмәннан Рахманколый (1858—1908)

ТУУЫНА—150, ҮЛЕМЕНӘ 100 ЕЛ

Халкыбыз тарихында, аның рухи тормышында тирән эз калдырган нәселләр бар: Габдессәламнәр (үзе һәм оныгы Әбелмәних Каргалый), Мәржани, Әмирхан, Рәмиев, Бигиев, Сәлимжанов, Юзиевлар h. б. Мондыйлар арасында Рахманколый нәселе дә мөхтәрәм урынны били. Солтан (Әхмәдсолтан) Рахманколый (1888—1916)—XX йөз башы татар, Казан мәдәни тормышынын үзәгендә кайнаган зат: жырчы, әдип, тәржемәче, сүзлек-дәреслекләр авторы... Ул Тукайлар белән бергә кичә-концертлар оештыра, Ф. Әмирхан, М. Вахитов, Г. Камаллар белән аралаша. Кызганыч, тууына быел 120 ел тулган бу талантлы шәхес 28 яшендә үк үлеп китә. Анын әсәрләре, сүзлекләре, тәржемә әсәрләре кат-кат нәшер ителгән. Хикәяләренең соңгы басмасы, М. Мәһдиев тарафыннан әзерләнеп, 1979 елда дөнья күрде. Бу китапта төзүченен бай эчтәлекле кереш мәкаләсе дә бар. Татарның яраткан жырчысы, композитор, Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы Мәрьям Рахманкулова (1901—1990) исеме өстәмә аңлатуларга мохтаж түгел. Бу күренекле шәхесләрнең әтисе һәм кайбер башка билгеле затларнын нәсел башы—мәгърифәтче, әдип, педагог, тәржемәче Габделмәннан Әхмәтжан улы Рахманколый. Ул 1858 елда хәзерге Әтнә районы Мәңгәр авылында туа. Кечкенәдән ятим кала. Хәзерге Саба районы Олы Шыңар авылында асрамага алынган бала сыйфатында төрле кыенлыклар күреп үсә. Әүвәл Кышкар мәдрәсәсендә, аннан Казандагы «Укытучылар мәктәбе»ндә («Учительская школа»да) белем ала. Аны тәмамлагач, 14 ел буе Шыңарда балалар укыта. И. Гаспралы үрнәгендә педагогик процесста яңа ысул-алымнар куллана. Арифметика, рус теле, география кебек дөньяви фәннәрне укытуга да зур игътибар бирә. Ата-аналар, шәкертләр арасында ул зур абруй казана. Шыңарда эшләү елларында Габделмәннан мөгаллим Арпаяз авылының Мәстүрә исемле кызына өйләнеп, гаилә корып жибәрә. Беренче балалары Әхмәдсолтан да Шыңарда туа.

90нчы елларда Г. Рахманколый гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Әүвәл конторщик булып эшли. Бераздан «Бертуган Кәримевләр» басмаханәсендә—мөдир («управляющий»). Анын тырышлыгы белән гарәпчә басма хәрефләр камилләштерелә—«яңа кегельләре» булдырыла. Улы Каюмнын да шушы басмаханәдә эшләве мәгълүм. Гомумән, Г. Рахманколый балаларын белемле, тәрбияле, һөнәрле итүгә зур игътибар бирә. Мәсәлән, улы Солтан Казандагы реаль училищедә укый.

К. Насыйри, Р. Фәхреддин, Ф. Халиди кебек, Г. Рахманколыйнын да бөтен эшчәнлеге халыкны аңлы, белемле, тәрбияле итүгә юнәлтелгән. Ул мәктәп-мәдрәсәләр өчен берничә дәреслек-әсбап әзерли. Аларның түбәндәгеләре Казан дәүләт университетынын Гыйльми китапханәсендә бар: «Тәнбиһе сыйбиян» («Сабыйларны искәртү», 1898. Яңа укый башлаган балалар өчен); «Мөгаллим: Ысуле саутия белән тәгълим итү өчен» (1897,1898, 1906); «Ачкыч: Уку китабы» (1906); «Хөсне хатт (матур язу.—Х. М.) мөгаллиме» (Ике кисәктә, 1913, 1917) h. б. Бу төр китапларда мөһим тәрбияви, дидактик фикерләр бар. Авторның К. Ушинский, Л. Толстой, Әхмәд Мидхәд карашларына да теләктәшлеге сизелеп тора. Үзенен дәреслек-әсбапларында Г. Рахманколый әдәби текстлар да урнаштыра. Алар арасында төзүченең балалар өчен язган үз әсәрләре дә бар. Шунысы кызыклы: 1980 елда Н. Исәнбәт, Г. Рәхим, Р. Кукушкин әзерләвендә «Татар балалар поэзиясе антологиясе» басылып чыкты. Анда «Балалар шагыйрьләре» бүлеге Г. Рахманколыйнын «Яз» шигыре белән ачыла.

XIX йөз ахырында XX гасыр башларында татар дөньясында А. Пушкин, Л. Толстой белән кызыксыну гаять көчәя. Аларның аерым әсәрләре татарчага да күчерелә. Бу изге эшкә Г. Рахманколый да билгеле бер өлеш кертә. 1901 елда ул рус шагыйренең «Балыкчы һәм балык» турындагы әкиятен тәржемә итеп бастыра. Анын уку китапларында да Пушкинның аерым шигырьләре («Кышкы кич», «Кышкы юл», «Евгений Онегин»нан өзек h. б.) урын алган.

Мәшһүр нәселнең нигезчесе Габделмәннан Рахманколый 1908 елда 50 яшендә Казанда вафат була, «Яңа бистә» зыяратына жирләнә.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

# КОМИССАР ӘДИП УРАМЫ

Мең яшьлек Казанда ике меңгә якын урам бар. Шәһәргә килгән мосафирлар мәрхәмәтлерәк күренгән инсаннарны туктатып теге яки бу урамны эзләп йөрер. Урам исемнәрен кайтарып сораганда татар язмышы ишетелеп ала сыман.



Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, К. Тинчурин, М. Җәлил, Г. Кутуй кебек тагын йөзләрчә күренекле шәхесләребез Уфадан, Тамбов, Сембер, Пенза, Оренбург, Саратовлардан килеп мәркәзебез тарихында мактаулы урам булып калганнар.

Шамил Усманов Казанга бик урау юллар аша килә. Пенза, Әстерхан, Сембер һәм Сызрань шәһәрләрен үтеп белем ала, һөнәр ияле эшче була. 1917 елгы революция язмышы аны III Интернационал легионы һәм татбригада комиссары, Үзәк Мөселман хәрби коллегиясенең политбүлек башлыгы, Татарстанның ревком секретаре итә; Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтында политбүлек начальнигы дәрәҗәсендә Идел һәм Урал буйларында сыный; Төркестан фронты каһарман итеп үстерә.

Хәйрулла мөгаллим улы Шамил Усманов бик теләсә әтисе янында—“Хөсәения” мәдрәсәсендә генә дә эшләп кала алыр иде. Ләкин, кечкенәдән язучы булырга теләгән кеше көрәшле юлны сайлый, фронт аның иҗат бүлмәсенә әверелә, хикәяләрен сугыш тынып торган араларда яза.

Бары тик 1927 елда, хәрби хезмәттән отставкага чыккач кына, Ш. Усманов җин сызганып иҗат эшенә тотына.

“Легион юлы” дилогиясе белән “Памирдан радио” повестьлары бүгенге укучыларга яхшы таныш. Кызыл карага манып язылган күпчелек хикәяләре генә язучының сайланма әсәрләре рәвешендә кала бирә.

“Легион юлы” повесте (1923-1935) буенча менә дигән фильм төшереп булыр иде. Гражданнар сугышы чоры тамашачы өчен һәрчак тансык тема.

Кызылармеецлар белән ак казаклар арасында туктаусыз бәрелеш, кан коюь, мөлкәт бүлү бара. Вакытлыча җиңү яулаган станицаларда байраклар гел алышынып тора. Җентекләбрәк укысаң, автор үзе дә кайсы якка басарга белми кебек. Ш. Усманов сюжет бөтенлегенә килгән “Легион юлы” повестен икегә бүлә. “Кызыл байрак астында” дигән өлешендә аклар җиңүе тантана итә. “...Бик кызу сугыштан соң Самара һәм Сызрань шәһәрләре... өстендә бөек Россиянең өч төсле (!) милли байрагы җилферди... Меңләгән кешенең шатлыклы йөрәк талпынуы белән атылып чыккан көчле “ура” тавышы... Советлар тарафыннан зур йортлары алынган качакларның шатлык елаулары иде... Большевиклар тарафыннан таланган, җимерелгән станицалар тергезеләчәкләр... Чыгып баручы соңгы кызылармеец белән матросның аркасын күреп, шатлыгыннан чукынып алган обыватель акларны ачык йөз белән каршы алды...”—дигән юллар белән төгәлләнә ул бүлек.

“Легион юлы”ның икенче кисәге—“Тургай далалары” исә, киресенчә, Кызыл Армия сафларына җәлеп ителгән мужиклар отрядының хәрби мәктәп үткән ак казакларны җиңүе белән романтик рухта тәмамлана. “Пролетариат шәһәре үзен коткаручы Кызыл Армияне сагынып, шатланып каршы алды”,—дигән юллар белән бетә әлеге дилогия.

Коммунизм төзүчеләрнең “Легион юлы”н укыганда баррикаданың кайсы ягына

басып рухи көч биреп торуын күз алдына китерүе һич кыен түгел. Ә бүгенге укучы кайсы якта? Бүген дилогиянең кайсы бүлеген алга куярга? Дөнья базарына ияреп, иҗтимагый стройның полюсларын алмаштырсак та мөлкәтлеләр һәм мөлкәтсезләр арасындагы антогонизм югалмады лабаса?!.

"Памирдан радио" (1925) повестендагы кызыл комиссар Җаббар да Октябрь революциясе казанышлары белән бик санлашмый. Ул әле Төркестан сугышында, әле Парижда, әле Алжирда, әле басмачылар ягында, әле кызыллар арасында. Әйтерсең лә ана кайда һәм кемне яклап сугышса да барыбер, тик батырлыгын күрсәтерлек мөмкинлек кенә тусын... Повесть сугыш күренешләре тезмәсеннән тора. Аерылгысыз, тоташтан укытырлык сихри көчкә ия ул. Җаббар мажараларының уйдырмага гына корылмыйча, чынбарлыкка бик якын итеп сурәтләнүенә карамастан "Памирдан радио" фантастик повесть дип бирелә.

Шамил Усмановча фантастиканы күрәзәлек дип тә аңлап була. Әйтик, ул Советлар илендә байраклар алышынасын алдан ук сизенгән. Татарстанда телевидение 1959 елның 7 ноябрендә генә эшли башлый, ә Ш. Усманов инде бу турыда утыз ел алдан ук хыяллана. Ул Казан радиостанциясен булдыручыларның берсе—беренче дикторы да хәтта. 1925 елда язылган әлеге повестьта Җаббарны урынсызга гаепләп ачылган суд процессы экраннан күрсәтелеп бара... Ә прокурор бүлмәсендәге пневмопочтадан түгәрәк капкачлы савыт белән бер язу килеп төшә... Илле ел узгач, Татарстан газета-журналлар нәшриятында (бүгенге "Идел-Пресс" бинасы) нәкъ менә шундый пневмопочталар эшли иде. Редакцияләр белән типография корпусы арасында кулъязмалар һәм корректураларны җил тизлеге белән илтеп житкерә иде ул.

70нче еллар уртасына чаклы прозаик һәм драматург Шамил Усманов иҗатына карата шактый игътибар булган. Гази Кашшаф, Флүн Мусин, Миләүшә Маннуровалар аның турында иҗат портретлары тудырган. Ә Альберт Яхин үзенең кандидатлык диссертациясен тулысынча Ш. Усманов иҗатына багышлаган. Ул автореферат 1964 елда яклана. Һәм һич очраклы хәл түгелдер—нәкъ шушы елдан башлап Казанның элеккеге "5нче-Союз" урамы Шамил Усманов исеменә үзгәртелә. Иң мөһиме,—язучы хыялланган телестудия дә шушы урамда.

30 нчы елларда Казанның Үзәк паркындагы Туганнар каберлегенә күмелгән шәхесләрнең язмышы уртак фаҗигале. Инквизиция, дөресрәге НКВДиция сызган шик сызыгын бик күп талантлар исән килеш үтеп чыга алмаган. Исемнәре дә югалган. "Легион юлы" һәм "Памирдан радио" повестьлары белән Шамил Усманов та үз-үзенә хөкем карары чыгарган.

Шөкер, Н. С. Хрущев Совнархозга председатель итеп куелгач, 1957-1964 елларда исемнәре булса да әйләнеп кайтты. Олы шәхесләребезнең иҗатын урам исемнәре белән бәяләү традициясе әле бүген дә дәвам итә. "Өрәңгеле", "Аркылы-торкылы", "Тракторлы", "Чокырлы" урамнарына алмашка атаклы фамилияләр килә.

Тыкрыкларга революция элгән калай исемнәрнең кайберләрен бүгенге демократия җыеп алса да Шамил Усманов урамы исән калды. Чөнки аның иҗатында матур әдәбият кануннарына килештермичә, бернинди ретушьлаусыз тасвирланган тарихи чынбарлык ята.

**Камил КӘРИМОВ**

# СӘХНӘГӘ ҖАН КЕРТТЕ

## ДРАМАТУРГ Х. ВАХИТНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, 20дән артык пьеса, күпләгән скетч, дүрт опера либбреттосы, балалар өчен әсәрләр, публицистик һәм тәнкыйди мәкаләләр авторы, күренекле драматург Хәй Вахит турында үз вакытында матбугатта байтак язылган. 60-70 елларда театр сәхнәләрендә әсәрләре гөрләп барган Х. Вахит иҗаты, аның фикерләре бүгенге көндә дә актуаль, заманча яңгырый. Аның әсәрләрендә мәңгелек темалар һәм мәсьәләләр күтәрелә, аларда бөтен гуманистик әдәбиятка аваздаш булган сыйфатлар бар. Урыс халкының бөек язучысы А. П. Чехов сүзләре белән әйтсәк: "Үлемсезлеккә дәгъва иткән һәр әсәрдә андый билгеләрнең булуы зарур".



Х. Вахит драмаларының геройларына югары әхлак принциплары, рухи чисталык һәм намуслылык хас. Авторның идея-эстетик карашлары, аның рухи дөньясы кешеләрдә һәм шул нисбәттән җәмгыятьтә дә рухи культура, әхлакый чисталык табуга юнәлдерелгән. Әлеге сыйфатларны гәүдәләндереп, автор үз әсәрләрендә яна тип уңай герой тудыра. Бу герой әлеге сыйфатларны чагылдырып кына калмый, алар өчен актив көрәшә; җәмгыятьтә "файда" принцибына таянып кына яшәүчеләргә протест та белдерә, үз-үзен тотышы белән тирә-юньдәге кешеләргә әхлакый тәрбия дә бирә.

Шул елларда әдәбият дөньясында уңай герой тирәсендә барган бәхәстә Х. Вахит еллар буе сурәтләнгән идеаль геройдан баш тарта һәм үз позициясен түбәндәгечә белдерә: "Уңай герой—автор кулындагы көчле корал ул. Автор уңай герой аркылы үзенең исбат итәргә теләгән фикерләрен исбат итә, аның аша тормышның җиңел баручы тойгыларын үткәрә, аның күзләре белән киләчәккә карый, аның сүзләре белән тамашачыны алга өнди. Ләкин бу әле һәр уңай герой сөттән ак, судан пакъ булырга тиеш дигән сүз түгел. Алай булса ул гомумән кеше булмас иде." *("Соц. Татарстан, 1961 ел, 11 ноябрь)*

Чыннан да, 1950 еллар ахырында сәхнәне бер-берсенә охшаган, кичерешсез, эчке хәрәкәте, драматизмы булмаган, баштан азакка кадәр үзгәрмәс геройлар басып ала. Х. Вахит исә үз әсәрләрендә кешене кеше итеп сурәтләргә омтыла. Ул: "кешенең ялгышларга да, начар сыйфатларга да, кимчелекләргә дә хакы бар",—ди. Нәкъ менә шундый тормышчан, җанлы, "җир кешесен" Х. Вахит үзенең пьесаларына герой итеп сайлый да. Аның каһарманы һәрвакыт гаделлеккә омтыла, эзләнә, үз принциплары өчен өзлексез көрәш алып бара. Автор героеның эчке дөньясындагы көрәшне тирә-юньгә, тышкы тормышка чыгарып, җәмгыять кануннары шартларында сурәтли һәм шул рәвешле геройлары йөз тоткан әхлакый кануннарын төрле хәлләргә куеп сыный.

Х. Вахит геройлары кысынкы заманнарда да бәргәләнеп, чәбәләнеп, ирекле намуслары кушканча яшәү өчен көрәшәләр: Тәлгать ("Беренче мәхәббәт), Шәүкәт ("Җырым табар сине"), Нияз ("Соңгы хат"), Марат ("Туй алдыннан) һәм башкалар—әнә шундыйлардан. Заманның һәртөрле догмалары, иске тәртипләре аларны рәнҗетә, аларның күнел дөньясын изә, рухын битәрли. Мондый халәт, мондый геройлар бүген дә сәхнәгә менәргә лаек. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры репертуарында "Талак, талак..." (режиссеры Ф. Бикчәнтәев), К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында "Туй алдыннан" (режиссеры Р. Заһидуллин) бүгенге көндә дә зур уңыш белән бара торган спектакльләр.

Автор тудырган геройлар үзләренең төрле һөнәр иясе булуы, төрле социаль баскычта торуы, яшьләре белән генә түгел, тормышка карашлары, фикерләүләре, тирә-юнь мохиткә һәм иҗтимагый тормышка алып килгән фәлсәфәләре, идеаллары, омтылган максатлары белән дә үзгә.

Х. Вахитнең үз геройлары турында түбәндәге сүзләре бар : "Уйлап карасаң, безнең

замандашларыбыз—гажәеп кешеләр. Аларның эшләгән эшләре, атлаган юллары, үз-үзләрен тотышлары, характерлары синен күнелендә тирән эз калдыралар. Аларга сокланып туя алмассын. Менә шулар арасында күнелемә ин якын булганнарын сайлап алып сәхнәгә күтәрергә уйладым. Чөнки мин аларны яраттым. Тормыштагы ин якын кешенне ничек онытылып яратырга мөмкин булса, шулай яраттым. Шунлыктан да бөтен тырышуым асылда бер нәрсәгә кайтып калды: хыялда туган шул образларны үзем яраткан кебек тамашачылардан да яраттыра алсам икән. Бу минем бердәнбер теләгем иде." (Вахит Х. Истәлекләр *(1960 ел. гыйнвар)// ТФА Г. Ибрагимов ис. ТӘСИ нен гыйльми мирасханәсе, ф.103, тасв.1.)*

Драматургнын беренче зур уңышы булган "Беренче мәхәббәт" (1961) әсәренә игътибарны юнәлтик.

"Беренче мәхәббәт" драмасы язылу татар әдәбияты тормышына хәрәкәт, җанлылык алып килсә, татар театрына тамашачыны кайтару өчен бер зур вакыйгага әверелә. Шул вакытта Х. Вахит кин җәмәгатьчелеккә чын драматург булып таныла. Мавыктыргыч сюжет, эчке драматизм, романтик рух драманы менләгән тамашачы өчен карап туймаслык сәхнә әсәре итеп таныта. Шул ук елны Татар дәүләт академия театры аны сәхнәләштерә. Тамашачылар һәм тәнкыйтчеләр спектакльне хуплап каршы алалар.

"Беренче мәхәббәт"—тормышчан вакыйга-күренешләрдә мәхәббәткә, хезмәткә мөнәсәбәт, яшәү мәгънәсе, бәхет төшенчәсе кебек проблемаларны күтәрә торган һәм житди каршылыкка нигезләнгән драма. Андагы һәрбер образ турында озаклап сүз алып барырга мөмкин. Алар кызыклы эчтәлекле, төрле конфликтлы мәсьәләләр күтәреп әсәрнең драматизмын, лирик аһәнен, тормышчанлыгын арттыралар. Хезмәт белән үскән Тәлгатьнең холык- фигыле яшь буынга үрнәк алырлык итеп сурәтләнә. Ул—сабыр, тырыш, хезмәт ярата, үз сүзендә тора белә, анын эше сүзләре һәм фикерләре белән тәнгәл, ул уйлаганын әйтә, ә әйткәнен эшли. Анын дөньяга үз карашы, үз мөнәсәбәте, тайпылмас әхлак прициплары бар. Табигый акылы, рухи чисталыгы Тәлгатьне бөтен геройлардан өстен куя. "Һәркем намусы кушканны эшләргә тиеш",—ди ул. Тәлгать өчен намус—"күнел уставы". Бу сүзләр әсәрдә сурәтләнгән һәр герой, һәр персонаж өчен янгырый кебек. Чөнки аларнын үткәндәге ялгышлары да, бүгенге проблемалары да нәкъ менә намус кушканча эшләмәүдән, әхлак кануннарын бозудан килә.

Әсәр башында үк Тәлгатьнең дикъкатен музыка җәлеп итә һәм сихри моң дөньясына алып китә. Рәхилә уйнаган скрипка моңнары, гүзәл музыка тудырган хисләр, Рәхиләнең матурлыгы Тәлгатьне әсир итә. Рәхилә образы да әсәр өчен генә түгел, гомумән татар драматургиясендә яна бер ачыш була. Күренекле галим, әдәбият белгече Азат Әхмәдуллин үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: "Автор бу кызнын үзен табигый тотышына нык игътибар биргән. Шаян һәм тапкыр, баштарак тормышка артык җинел караган, ләкин акрынлап җилбәзәклектән котылу юлына баскан тәҗрибәсез яшь кыз образлары сериясеннән бу—беренче уңышлы башлангыч, сәнгатьчә яна бер ачыш булды. *(Әхмәдуллин А. Г. Драматургнын усү юлы // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш.—Казан, 1980.)* Чыннан да, Рәхилә образы үсеш-үзгәрештә бирелә. Әсәр башында ул скрипка чиертеп, какао эчеп утыра торган, тормышка җинел караган "әтисе кызы" булса, ахыргы монологта мөстәкыйль фикерли, эш йөртә торган, үз язмышын үзе хәл итәргә әзер, житлеккән шәхес булып өлгерә.

"Сонгы хат" (1966) әсәренең төп геройлары Нияз, Зөфәр, Зөһрә исә—бәхетле булуны һәрберсе төрлечә анлый һәм уңышка ирешү юлларын һәркем үзенчә сайлый. Нияз өчен бәхеткә, уңышка ирешү—яраткан эшендә бөтен көченне куеп, фидакарь хезмәт итү булса, Зөфәр өчен ул төрле хәйләләр белән "җылы урын", "дәрәҗәле эш" алу, үз максаты өчен барлык мөмкинлекләрне файдалану. Нияз образына тирән психологик кичерешләр, тормыш юлынын ин башында сайлаган табиб хезмәтенә тугъры калу, шул фидакарь максат өчен күп нәрсәләрне корбан итү хас. Ул—әдипнең яратып тудырган образларынын берсе.

"Туй алдыннан (1969) драмасында Марат образы тискәре булырга тиеш кебек. Тик пьеса эчтәлегеннән күренгәнчә, драматург үз каһарманынын гөнаһсызлыгын, әхлакый чисталыгын, күнел сафлыгын күрсәтә. Укучынын игътибарын анын дәрәҗәсенә түгел, ә фикерләренә, күнел дөньясына юнәлдерә.

Х. Вахит Марат образын махсус рәвештә авыр тормыш хәлләренә куеп сыный. Марат һәрвакыт йә дусты, йә яраткан кызы мәнфәгатьләрен кайгырта. Ул биш ел элек дусты Рафаэльне яклап калып төрмәгә утырмаса, яраткан кызы Адиләне

күреп элекке хисләрен янадан белдерә башламаса, төрмәдә бергә утырган Наил исемле малайны хулиганнардан якламаса—беренче чиратта, үз намусы, вөҗданы алдында гаепле булачак. Ә Марат өчен аннан да авыррак җәза юк. Ә Рафаэль үзе турында болай ди: "Син мине гомерлек газапка салдың. Биш ел төрмәдә утыруга караганда күп мәртәбәрәк авыррак бу. Хәзер мин хөкем алдында да синең алдыңда да, гаепле. Иң авыры, бу гаепне берничек тә юып булмый". *(Х. Вахит. Яшьлек юллары. Казан, 1978.)*

Автор эзлекле рәвештә Рафаэльне Марат белән чагыштырып килә. Беренчесе матди байлыкны, яхшы эшне, уңышлы карьераны, фатирлы, машиналы булуны бәхет дип санаса, икенчесе өчен иң кыйммәтлесе—үз-үзенә ихтирамны бетермәү, намуска тугры булып калу, йөрәгең кушканны эшләү. Болардан күренгәнчә, Х. Вахитка көрәшче, үз принципларын яклаучы, алар өчен көрәшүче герой якын.

Х. Вахит торгынлык заманнарында да яшьләрне тәрбияләп, төзәтергә омтыла. Чынлыкта заманны алай гына төзәтү мөмкин түгел иде шул. Әмма "вульгар социологизм" тәнкыйте язучылардан шуны таләп итә. Тормышчан иҗатлы булуына карамастан, Хәй Вахит тә әлеге киртәләрне читләтеп үтә алмый. Заман таләпләре аны да мәгълүм кысалар эчендә тота. Әмма шундый шартларда да ул янача, җанлы, кызыклы әсәрләр иҗат итә.

Х. Вахит драматургиясе тулаем шәхес иреген яклау идеаллары белән сугарылган. Аның асылында—демократик карашлар, гуманизм , әхлаклылык. Шуңа күрә аның иҗаты, җәмгыятьнең рухи кыйммәтләрен саклый, үстерә. Авторның пьесалары Рәсәйнең күп театрлары репертуарына кертелгән. Татар драматургиясендә һәм татар театры тормышында борылыш ясавы, әсәрләренең халык хәтерендә калуы Х. Вахит пьесаларының чын кыйммәтен билгели, аларны озын гомерле итә.

**Гүзәл ГАБДУЛЛИНА**

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*
## *Ак җилкән*

Илдус
Хуҗин

### ЯҢА РОБИНЗОННАР

"...Өч дус Фәритнең бүлмәсендә утыралар.

—Дусларым, Алсу югалды,—диде Фәрит.

—Кайда югалды, ничек?

—Былтыр җәй иптәшләре белән теплоходта круизга киткән иде ул. Сингапурда теплоход дүрт көн торган. Шәһәргә чыккан жиреннән Алсу әйләнеп кайтмаган. Соныннан аны илчелек аша да, төрле оешмалар аркылы да эзләтеп карадылар, ләкин бернинди нәтиҗәсе булмады.

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты.

—Егетләр! — диде бераздан Фәрит.—Мин Алсуны эзләмәкче булам. Миңа юлдаш һәм ярдәмче була алыр идегезме?

—Ничек? Син акылыңдамы?—дип дуслары Фәритне сораулар белән күмделәр.

—Без анда туристлар төркемендә барачакбыз. Алсуның әтисе бу проектны матди яктан тәэмин итәчәк..."

Бу мажаралы хикәянең бүлек исемнәрен алдан ук әйтеп куйыйк әле: "Яңа дуслар", "Алсуны эзләп", "Юлбарыслар эзеннән", "Ерткыч оясы", "Виктория!", "Өйгә кайтабыз!"

## Дифгат Сирай
(1933 – 1985)

### Ватан төсе

Туган җиремнең суларын
Таныйм зәңгәр төсләреннән.
Көлә-көлә җилләр чаба
Зәңгәр дулкын өсләреннән.
Колач җәеп йөзгәнем бар,
Ләззәтләнеп, иркәләнеп...
...Зәңгәр дарья булып җирдән
Ватан үзе чыккан бәреп.

Туган җирем болыннарын
Таныйм яшькелт төсләреннән.
Көлә-көлә җилләр чаба
Яшькелт дулкын өсләреннән.
Йөгереп килеп чумганым бар,
Тирбәлгәнем шунда ятып...
...Яшькелт келәм булып җирдән
Ватан үзе чыккан калкып.

Туган җирем басуларын
Таныйм саргылт төсләреннән.
Көлә-көлә җилләр чаба
Саргылт дулкын өсләреннән.
Ера-ера йөргәнем бар,
Шау-шуына булып гашыйк...
...Саргылт ташкын булып җирдән
Ватан үзе чыккан ташып.

Туган җирем урманнарын
Таныйм куксел төсләреннән.
Көлә-көлә җилләр чаба
Куксел дулкын өсләреннән.
Җыр таратып узганым бар,
Аланнарын иңләп-буйлап...
...Куксел океан булып җирдән
Ватан үзе чыккан шаулап.

Туган җирем болытларын
Таныйм аксыл төсләреннән.
Көлә-көлә җилләр чаба
Аксыл дулкын өсләреннән.
Нурлар эзләп менгәнем бар
Баш әйләнер биеклеккә...
...Аксыл киңлек булып җирдән
Ватан үзе ашкан күккә.

Төсләр, төсләр!..
Ватанымның
Мәңге уңмас һичбер төсе;
Күңелләрдә балкый алар,
Бергә кушылып бөтенесе.

### Җил җыры

«Кошларны уятам сызгырып,
Гөлләрне иркәләп уятам.
Елгалар өстеннән узганда
Шау-шулар кузгатам, кузгатам.
Күкләрне уятам сызгырып,
Болытны төрткәләп уятам.
Урманнар өстеннән узганда
Шау-шулар кузгатам, кузгатам...»
Мине дә, ияртче, җилкәем,
Дөньяны бергәләп уятыйк.
Бергәләп уятып, кешеләр
Күңелендә моң-җырлар кузгатыйк...

## Нигә соң?

Болытлар агыла.
Нигә соң
Түгел мин шул болыт, шул болыт?
Тәрәзәң каршына төшеп мин,
Утырыр идем ак тау булып.

Яңгырлар шыбырдый.
Нигә соң
Түгел мин шул яңгыр, шул яңгыр?
Тәрәзәң каршына төшеп мин,
Яңгыратыр идем гел дәртле җыр.

Яшеннәр ялтырый.
Нигә соң
Түгел мин шул яшен, шул яшен?
Тәрәзәң каршына төшеп мин,
Чытырдар идем әй көн вә төн...

## Ишетәсе килә

«Исемең ничек, улым,
Ник дәшмисең!
Йоттыңмы әллә ялгыш телеңне?» —
Күршедәге карт-корылар шулай
Йөдәтәләр иде гел мине...
«Исемең ничек, энем?» —
Укытучым
Шул сорауны бирде бастырып.
Бит очында янып тора кебек
Шул чаклардан калган алсулык...
«Исемең ничек, егет?» —
Күз кыстылар
Кыз-кыркыннар соңыннан,
сүз катып.
Юри генә шаярттылар микән,
Сорадылар микән яратып?!.
«Исемең ничек, иптәш?» —
Шулай диеп
Сорашалар кат-кат хәзер дә.
Рәсми итеп ләкин сорашалар,
Шунысы тия килеп бәгырьгә.
Шуңа, ахры, ешрак сагынамдыр
Үткәннәрдә калган көннәрне.
Ишетәсе килә: "Исемең ничек,
Улым,
энем,
егет?" — дигәнне.

Фрунзе
Фазулай

# КҮРЕНЕКЛЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕМӘ

## Татар халкы

*(кереш)*

***Бердәм, бердер татар халкы—мөселманы, чукынганы,***
***Нинди исем аңар такма, юктыр аның «ычкынганы»!***
***Җәберләнеп тукмалса да яман язмыш тукмагыннан,***
***Чыга алган олы юлга кысрыкланган сукмагыннан!***

***Кайларга ул таралмасын, зар—моң аша ни булса да,***
***Кыйбла якка тоткан юлын, кайчак җаны буылса да!***
***Буылса да явызлардан, тыеп язмыш «аксаклыгын»,***
***Саклый алган буыннардан буыннарга аң сафлыгын!***

***Татарлар ул сабыр халык, сабырлыкның—төбе алтын,***
***Тагын күпме җыяр байлык, "булмасмы соң инде артык"!?***

**Абдуллин Рубин**
музыкант

**Рубин ич ул «якут ташы», композитор, органист та,**
**Консерватория ректоры, профессор, ул артист та.**
**Йөртәдер лә йөрәгендә ике туган халкы канын,**
**Насыйп иткән илебездә туганнары югалтканын!**

**Акчурин Ренат**
хирург

**Ренат туган, зур хирург,—йөрәкләрне тазартучы,**
**Таза тәннән таза аң-рух теләк белән төз атучы!**
**Аның изге кулларыннан күпме йөрәк яшәү көткән,**
**Күпме өмет кылларыннан бәхет үреп яшәр иткән!**

**Алишина Ханисә**
тел белгече

**Ханисә ханымның исеме—мөлаем дигән мәгънәдә,**
**Төмәндә ул тел белгече—түгел соң нидән сәхнәдә!**
**Күңеле Себер якларында, халкы белән бер кайгыда:**
**«Телсез калса татар анда, ниләр күрердер тайгада?"**

**Бәйрәмова Фәүзия**
язучы

Фәүзия ханым заманында сөйләп яхшы, яманын да,
«Менгәләгән яңакларга», түзгән ялган-яманына да.
Кайсы дус та куя «сыртын», татар телен яклаучыга,
Азатлык та ярты-морты, юк «яулыкны» аклаучы да!

**Вәлиев Разил**
язучы

Разил туган ул язучы, директор да, депутат та,
Әллә беркем юк узучы, барадырмы дөлдел атта!
Бар тормышы тезелгәнме хакыйкатьне аңлап кына,
Чын дәүләткә бер юл диме сабырлыктан атлап кына!

**Гайнетдин Равил**
дин белгече

Баруди күк, Равил туган,—белем алган Бохарада,
Дингә караш йомшагандай әллә булган шул арада.
Мәскәү җамигъ мәчетенең хәзер ул имам-хатибы,
Ходай кушып күрсәткәнме изге юл галәм тәртибе!

**Гәрәев Мәхмүт**
хәрби теоретик

Мәхмүт иптәш хәрбиләрчә, тәртипледер һәр нәрсәдә,
Үз илем дип яшидер лә, заманыбыз үзгәрсә дә
Гади татар эшче улы—«үсеп» җиткән генералга,
Хәрби юлда тугрылыгы илткәндерме гел, гел алга?!

**Исхаков Дамир**
этнограф

Дамир туган, ул этнограф, тарих фәннәр докторы да,
Күп—ди, язма мирасыбыз, өйрәнелми тик бары да.
Татар халкын бутәләп тә тырышалар кимсетергә,
Катнаш никах чүпли читкә, үзебезгә ди ни әйтергә!?

**Миңнуллин Роберт**
шагыйрь

Роберт туган алга чыга, шигърияттә—бар яктан да,
Күп яза ул балаларга, көрәшкән ди, «Сабан туйда»,
Аннан килеп батырларча, булып китә «урынбасар»,
Кемнәр генә халкыбызга адашмаслык юлын ачар?

**Фәйзуллин Равил**
шагыйрь

Равил туган—«язгы кояш», шагыйрь кеше исемендә,
Булган кояш булганда яшь, туры килгән җисеменә!
Бүген дә әле ул биектә, төшеп бармый ич «баешка»,
«Казан утлары»н биетә, үрелгәндә кич кояшка!

**Фәтхетдинев Салават**
җырчы

Салават ул мактау җыры, җырчы тора мактаулардан,
Моң-җыр—күңеле яңгырашы, ансы Урал—ак таулардан!
Салават ул килгән җиргә, нурлы күпер аша күктән,
Улы итеп көткәнгәдер, моңлы Илһам-"ата" күптән!

## 2009 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

(МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1430–1431 ҺИҖРИ ЕЛЛАР)

**7 январь (чәршәмбе)**— Гашура бәйрәме. Сөнниләр тарафыннан Аллаһы Тәгалә Үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шиитләр тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы имам Хөсәенне (626—680) җәзалап үтерү көнне мөбәрәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тотканнар.

**13 январь (сишәмбе)**—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн. (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**27 январь (сишәмбе)**—Сәфәр ае башланган көн.

**21 февраль (сишәмбе)**—Һиҗрәт кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

**8 март (якшәмбе)**—Мәүлид кичәсе. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам туган көн (570 елда). Бу көнне мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә, тантаналы гыйбадәт кылулар булып уза.

**9 март (дүшәмбе)**—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**25 июнь (пәнҗешәмбе)**—Рәҗәб аенын беренче җомгасына каршы кич — Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**26 июнь (җомга)**—Мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**19 июль (якшәмбе)**—Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**20 июль (дүшәмбе)** —Мигъраҗ бәйрәме.

**23 июль (пәнҗешәмбе)**—Дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбан ае башлану көне.

**5 август (чәршәмбе)**—Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**21 август (җомга)**—Изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**10 сентябрь (пәнҗешәмбе)**—Фәтех Мәккә көне.

**15 сентябрь (сишәмбе)**—Кадер кичәсе. Бу төн—язмыш хәл ителә торган төн, көчкодрәт төне. Ураза ае тәмамланыр алдыннан булучы башка төннәрдә, йокламыйча, Аллаһы Тәгаләдән ярлыкауны теләп-ялварып, намаз укып чыгалар. Кадер төнендә Коръәннең төп нөсхәсе, Аллаһы Тәгаләнең тәхете өстеннән алынып, Җәбраил фәрештә тарафыннан күкнең җиргә иң якын катына күчерелә һәм, шуннан торып, аның эчтәлеге 22 ел буена Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелеп тора.

**20 сентябрь (якшәмбе)**—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**15 октябрь (пәнҗешәмбе)**—Хәтер көне. Каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны, якыннарыбызны, туганнарыбызны искә алу көне.

**26 ноябрь (пәнҗешәмбе)**—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**27 ноябрь (җомга)**—Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Бу ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**28, 29, 30 декабрь (шимбә, якшәмбе, дүшәмбе)**—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**17 декабрь (пәнҗешәмбе)**—1431 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**26 декабрь (шимбә)**—Гашура көне.

Төзүче мөхәррир
**Хаҗи Абдулла ДУБИН.** Казань.

Әхмәт
Рәшит

#ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

## Тар җиргә—тана башы

...Шулай итеп без әти сугышка кадәр салырга гына өлгергән зур, иркен йорттан инде искереп беткән бәләкәй генә бер өйгә күчеп килдек. Сеңелем Фәүзия дә (ул әни шифаханәдә чагында өч ай чамасы Норлатта бабайның энеләрендә яшәгән иде) туган авылга кайтты. Абыйның дүрт баласы арасына без дә килеп кысылдык. Моңарчы да бик үк тату тормаган абый белән җиңәчи арасында әледән әле тавыш чыга, бер генә гаебебез булмаса да, ахыр чиктә бөтенесенә сеңел белән мин сәбәпче булып чыгабыз—әлеге дә баягы шул борынгы халык әйтемендәгечә: "Үксез бозау асрасаң, авызың-борының бал булыр, үксез бала асрасаң, авызың-борының кан булыр". Югыйсә бер генә сылтау да бирмәскә тырышабыз. Ә иң әшәке сүзләр әйтешеп кычкырышырга берәр сәбәп барыбер табыла. Ул гына да түгел, болай да кызу канлы абый, чалбарыннан каешын суырып алып, җиңәчине кыйный башлый. Малайлары кычкырып елаша, өйдә сүгенү авазлары. Мин сеңелем белән бу җирәнгеч тамашаны карыйбыз да, күзләр зур булып ачыла: шулай да яшәп була микәнни?! Безгә бу коточкыч күренешләр гайре табигый, кыргый кешеләр арасында гына була торган хәл булып күренә. Чөнки без моңа күнекмәгән, чөнки без башка шартларда үскәнбез—без бердәм, тату гаиләдән. Бөтенесе елый, ә без аптырап карап кына торабыз. Юк, безне юк кына гаеп табып гел-гел кыерсыткан җиңәчине кыйнаганы өчен абыйга хәерхаһ булып, шулай кирәк аңа, дип сөенешеп тормыйбыз. Безгә дә кыен. Тик нишлик соң—аның бу кыргый гамәлләрен гаепләп күз яшьләребез генә чыкмый. Чынлап уйлап карасаң, җиңәчи үзе үк гаепле: йә морҗаны ачмыйча өйгә төтен тутырган, йә без бөртекләп җыйган, духовкага киптерергә куйган башакларны алмыйча учакны тергезеп җибәргән, йә салган ипие чиле-пешле булып чыккан, йә өйдәге хәлләрне күрше хатыннарына кереп сөйләгән... Хәер, низаг өчен сәбәп табылмыймыни?

Ул, абый сугыш кырыннан әйләнеп кайткач, бер көн дә колхоз эшендә эшләмәде. Анын өчен ул заманнарда мәҗбүри булган хезмәт көне минимумын без—балалар тутыра идек.

Абый исә көне-төне бил бөкте: колхозның яшелчә бригадиры булды, урман полосалары утыртты, фермадагы терлекләрне карады. Мин аның бервакытта да тик торганын күрмәдем. Һөнәрләре дә күп иде аның, кулы да теләсә кайсы эшкә ята—кыскасы, тормыш дигән бу чыгымчылаучы арбаны икәүләп тигез тартсалар, икесе дә бер теләк-омтылыш белән яшәсәләр, иллә әйбәт булыр иде дә бит! Ләкин... ләкин шул менә!

Җиңәчи һәрвакыт диярлек йөкле: берсе имидән аерылырга өлгерми, икенчесе туа. Сабыйлар коелып кына тора: Рәшидә, Рокия, Суфия, Давыт, Гөлсем, Шәмсун... Әле арада үле туганнары яки тугач үлгәннәре дә бар. Хөкүмәт хуплый иде инде ул эшләрне: орден-медален дә бирә, акчасын да кызганмый—халык саны гына артсын. Хатын-кызларны юмалар өчен әллә нинди җиңеллекләр уйлап чыгарды бит хәйләкәр Сталин бабаң. Хәер, ул елларда бала табып үстерүне бер авырлыкка да санамадылар.

*Дәвамы. Башы журналның 8–10 саннарында.*

Өлкәннәре үсә торды, алар туасы энекәшләре һәм сеңелкәшләре өчен тормышның беренче сабакларын өйрәтүче булды. Ана кечерәйгән кием бәләкәйләренә ярады. Өстәвенә балигъ булганчы азмы-күпме акча да түләп торалар иде. Яңа Чәчкапта өчме-дүртме хатын хәтта Герой-ана дәрәҗәсенә иреште.

Минем эчне иң пошырганы—бу өйдә бер дә татулыкның булмавы, көн саен булмаса да, бик еш кабатланып торган гауга-талаш, сугыш-кыйнаш... Сеңелем Фәүзия белән икәү генә калган чакта, ул: "Башларымны алып качар идем, барыр, куыш табар жирем генә юк",—дип өзгәләнә, аһ-зарларын әйтеп, мина сыенып елый торган иде. Аны бу мәхшәрдән коткару уе нәкъ менә шул авыр мизгелләрдә тугандыр да. Мине әрләгәннәре, кыйнаганнары, төрле әшәке сүз әйтеп кимсеткәннәре, әллә нинди кушаматлар такканнары бер хәл—анысына түзәр идем. Ә менә сеңелемне кыерсыткан чакларында, аның белән бергә минем йөрәгем дә елый, сызлана иде. Ике бөртек ятим идек бит без бу дөньяда. Аның да, минем дә икешәр-өчәр көн тамагыбызга бер тәгам ризык капмаган вакытлар булды. Әйтәсе генә ансат—кешеләр күзенә нәрсәдер өмет итеп мөлдерәп карауның нәрсә икәнен үз башыннан кичкәннәр генә белә.

Тормыш никадәр генә аяныч булмасын, ныклап аякка басарга, кемнәр тарафыннандыр тапталып изелмәскә, кеше рәтле кеше булырга кирәк иде. Шуңа күрә тырышып укыдым да мин.

Укытучыларым арасында төрлесе бар иде инде: югары белемлеләре дә, читтән торып укып йөрүчеләре дә, урта, хәтта жидееллыкны гына тәмамлаганнары да. Алда искә алып үткән, Кайбычтан килгән Галия апа, мәсәлән, жидееллыкны гына бетергән. Шулай да ул мине хәреф танырга, саннарны кушарга, алырга, тапкырларга, бүләргә өйрәтте—шуңа күрә мин аңа гомер буе рәхмәтле булдым. Инде иҗатым тәкъдир ителеп, язучы булып житешкәч, ул яшәгән авылда чыгыш ясагач, каләмдәшләремнең кадерле вакытын алып булса да, аның өен эзләп таптым, калын гына китабымны бүләк иттем. Картайган иде инде ул, ләкин элекке шәкертенең игътибарына бик сөенде—аяклары сызлау сәбәпле әдәби кичәгә килә алмаганы өчен кат-кат гафу үтенде.

Икенче класста безне укыткан Сафия апа Хафизова буйга житеп килә торган улы белән генә яши, кырыс, утызынчы еллар коммунистлары кебек һәркемгә таләпчән, кайчагында укучыларының яңагына чалтыратып жибәрүдән дә тайчанмый торган бер дорфа һәм надан хатын иде. Аның рус теле дәресләрендә "еф ышкуле", "еф калхузе" дип укырга өйрәтүләрен без хәзер дә көлеп искә төшерәбез. Бер заман ул ни өчендер мине дә парта арасыннан колагымнан тартып чыгарды. Колак арты чиләнеп чыккан иде. Абый, шуны күргәч, мәктәпкә барып каты гына тавыш та куптарды.

Шул бердәнбер улын да ул, кырыс кысаларда тотып, коммунистларча тәрбияләргә тырышты. Ул Равил абыйның исә авыл кызлары да, егетләр дә чит итәләр, арага кертмәскә карыйлар иде. Сәбәбе: ул сөннәткә утыртылмаган иде. Үзенең акылы життеме, әллә берәрсе киңәш иттеме, авылга бабачы килгәч, 16-17 яшьләрдә микән, ниһаять, сөннәтле булды. Шуннан соң инде аны кыерсытмадылар—уеннарга катнаштыра, араларына ала торган булдылар.

Язмыш шаяруы дими, ни дисең—кайда, ничек танышканнардыр—ул Тархан урта мәктәбендә минем белән бер класста укыган, минем күзне кыздырып йөргән Мәгъсумә исемле кызга өйләнде. Соныннан гына белдем, Сафия апа килененә дә юньле көн күрсәтмәгән икән.

Мәктәп директоры Сабир абый Садыйков та каты куллы кеше иде. Бала-чага, бигрәк тә малай халкы, утыртып куйган бүкән кебек тик кенә утыра аламыни дәрестә?! Йә күчерергә ниятләп күршесенең дәфтәренә күз сала, йә алгы партадагы кызның чәч толымын тарта, йә тагын берәр нәрсә... Укытучы исә чыгырыннан чыга—тәртип бозучыны кара такта янына бастыра. Башын иеп тормасын өчен ияген утын пүләне белән терәтеп куя. Ә гаепле малай исә тозәлергә уйламый да—чырайларын әллә ничек жыергалап кемнедер үчекли, кемгәдер күз кыса. Ә парта артыннан аңа карап торучылар пырхылдап көлеп жибәрә. Берәр ялагаерак исә, кул күтәреп: "Апа, ул безне үчекли" дип әләкли. Дәреснең яме бетә. Ул "хулиган" малайны жилтерәтеп, директор кабинетына алып кереп китә. Сабир абыенның инде тәжрибәсе бар: акылга шәплап утырта—жилкә тамырына гына кундыра. Ата-анана

да зарлана алмыйсың: үзең гаепле.

Бәлки бу ямьсез күренешләр турында сөйләп тә тормаскадыр, алдынгы совет мәктәбенең яманатын сатмаскадыр? Ләкин нишлисең, А.Твардовский әйтмешли, "так это было на земле". Кыйныйлар иде безнең мәктәптә, кешелегенне саклап кимсетүдән бер мыскал да тайчанмыйлар иде. Директор үзе шулай булгач, аңа иярүчеләр, аннан үрнәк алучылар табылмыймыни?!

Әлбәттә, безнең мәктәп тормышы мондый күнелсезлекләрдән генә тормый, без яшәешнең асыл мәгънәсенә төшенергә, юк кына нәрсәләрдән дә ямь табарга, шактый кырыс тормышыбызны кызыклы итәргә, алдагы көнгә өметле күз белән карарга тырыша идек. Юк, без укытучыларыбызның нервысында уйнап, шуннан кызык табарга омтылмый идек. Нигездә һәммәбез "4"ле һәм "5"легә генә укырга хыяллана—нәтиҗә исә һәркайсыбызның табигый сәләтенә, педагогларның үз дәресләрен мавыктыргыч итеп оештыра алуына бәйләнгән иде.

Минем өчен иң якын укытучылар, мөгаен, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барган Рәхилә апа (ул вакытта фамилиясе дә Әлмөхәммәтова әле) һәм аның ире, биология укытучысы Абдулла абый Буриев булгандыр. Язмышлар уртаклыгымы (алар да ятим үскән!), әллә мин алар алып барган фәннәрдән аеруча тырышып укыгангамы, яраталар, үз итәләр иде алар мине. Авыл клубында берәр спектакль куеламы—сәхнә түрендә ирле-хатынлы алар. Сайлау компаниясе башланса, ул замандагыча әйтсәк, "коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларын" яклап, йорттан йортка йөреп агитация алып барырлар иде. Урып-җыю чорында авыл зыялыларын колхозга булышырга дип кырга яки ындырга чыгарга өндәп йөрүчеләр дә алар булды. Алар гомер буе минем шактый катлаулы язмышыма теләктәшләр, хәерхаһлар иде. Рәхилә апа минем шигырьләрне беренче булып укыды. Беренче бәяне дә ул әйтте. Кулъязма журналлар чыгарып, безнең беренче тәҗрибәләребезне бергә туплады. Безнең дим, күплек санда әйтәм—әдәбият белән мавыгучылар байтак иде безнең арада. Тутай авылыннан йөреп укучы Ленар Җамалетдинов (ул хәзер филология фәннәре докторы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, татар халык иҗаты буенча дистәләгән китап нәшер иткән галим) шигырьләр яза; ике яшьлек чагыннан ук минем белән кулга кул тотынышып йөргән Тәүфикъ Җиһаншин, соңыннан Социалистик Хезмәт Герое, мин яшүсмер чакта исә безнең авылда клуб мөдире булып эшләгән Рәүф Әһлиуллинның энесе Рифгать, Тәүгелде авылыннан Илгиз Ибраһимов, тагын, тагын әллә кемнәр хикәяләр, әкиятләр, шаян такмаклар чыгара иделәр. Авылны күпме генә "гыйбадлар" дип үртәсәләр дә, чын талантлар нәкъ менә аннан чыга. Әгәр тиешенчә укырга мөмкинлекләре булып, тирес-торыстан арынып, Көнбатыш Европаның яки Россиянең атаклы шәхесләре кебек башка, нормаль, мәдәни даирәдә үссәләрме?! Һи-и-и! Татарның потенциаль мөмкинлекләрен белмисез әле сез!

Безнең бөтен класс малайларын үзенә караткан тагын бер укытучыбыз бар иде. Гаепләрлеге юк: кайчагында укучылар да үз укытучыларына гашыйк булалар. Елена Никифоровна Мәхмүтова безне немец теленнән укытты. Яшь, чибәр чуваш кызы иде ул—авыл егетләре дә аңа күз кыздырып йөрделәр бугай. Ләкин... ул авылдагы тәртип өчен җаваплы участок милиционерының хәләл җефете иде шул—кагылып кына кара! Менә шул Елена Никифоровна берзаман безгә русча шигырьләр язарга тәкъдим итте.

—Хаталарын үзем төзәтермен, хафаланмагыз... Русча да бер журнал чыгарып карыйк әле,—диде.

Андый эштән мин читтә каламмы соң?! Барлы-юклы русчам белән (ул вакытта инде русча китапларга да теш үтә башлаган иде) яздым мин шигырьне. Әллә аның игътибарын җәлеп итәргә теләп, әллә башкаларны тагын да уздырырга уйлап, немец телендә дә дүртьюллык сырларга булдым. Эчтәлеге үтә гади иде аның: "Балалар чана шуалар, урамда шундый күнелле..." Тирән белемле психолог булган икән ул: немец теле дәресләрен без көтеп ала идек. Билгеләребез дә башка фәннәрдән алган бәһаләргә караганда өстенрәк иде.

Рус теленнән безне Буа кызы Мария Егоровна Будилина укытты. Минем рус телен башкаларга караганда әйбәтрәк белүем (әйтәм бит, авылдагы татарча китапларның латин хәрефендә басылганнары да укылып беткәч, бер-бер артлы русчаларын актара идем инде), аның үзе белән дә шактый иркен сөйләшә-

анлаша алуым ошый торган булгандыр. Хәтта ул мине параллель "А" классына алып кереп, шигырьләр сөйләттерә, сораулар бирә, минем җавапларымнан бик канәгать булып кала иде. Минем русча чагыштырмача яхшы белүем китаплардан гына да булмагандыр ул. Әле укырга кергәнче, район шифаханәсендә озак кына ятып, операциядән соң терелә башлагач, ике аймы, өч аймы Буа малайлары белән (күбрәк рус малайлары иде) сөйләшеп, уйнап йөргәндә үк күп нәрсә хәтергә сеңеп калгандыр. Алгарак китеп булса да, әйтим: университетка кергәч, безнен группа студентларына укытучыбыз В.Б.Бородатов диктант яздырган иде. Башкаларның билгеләре "2"ле дә, "3"ле булса, бер минеке генә "4"ле бәясе белән тамгаланган иде. Юк, мин моны мактаныр өчен дә, үземне өстен куяр өчен дә әйтмим—фәкать ничек-ничек булганын гына кәгазьгә терким.

Мария Егоровна, күрәсен, комсомол яшендә генә булгандыр. Җыелышларны без бергәләп үткәрә идек. Ике ел дәвамында безнен комсомол оешмасы үсте, җитди сәяси көчкә әйләнде.

Математик Сөембикә апа Шиһапова, физик һәм бер үк вакытта физкультура укытучысы Сәлим абый Латыйпов, өченче-дүртенче классларда безне укыткан Гыймран абый турында да бик күп җылы сүзләр сөйли алыр идем мин. Алар минем шәхесем формалашуга хәлиткеч өлеш керткән олуг шәхесләр булдылар.

Ләкин җидееллык мәктәпне тәмамлау белән генә олы хыялыма—үз көнемне үзем күреп алга таба да уку бәхетенә тиз генә ирешә алмадым. Әллә нәрсә генә килеп чыкты шунда. Чыгарылышка багышланган җыелышта, мине җидееллыкны Мактау кәгазе белән тәмамлады, дип игълан иткәннәр иде. Мин укытучым Рәхилә апа киңәше буенча документларымны Казан педагогия училищесына җибәрдем һәм район мәгариф бүлегеннән әлеге тылсымлы кәгазьне көтеп йөри башладым. Көн артыннан көн үтә дә үтә, директорыбыз С.Садыйковка да, уку-укыту бүлеге Т. Садуровка да мөрәҗәгать итеп карыйм. Алар:

—Борчылма, килер, килер,—диләр. Инде менә училищедан дә хат кисәге килеп төште. "Яки Мактау кәгазегезне җибәрегез, яки кабул итү имтиханнарына килегез",—диелгән иде анда. Мин мәктәп җитәкчеләрен тыкырдата башлагач, шул ачыкланды: минем алгебра буенча язма эшемдә мәсьәләләр дөрес чишелмәгән икән дә, минем имтиханым тартып-сузып "дүртле" белән генә бәяләнергә тиеш икән. Менә сиңа мә! Озакка сузмый, документларымны кире җибәрделәр. Аз булса да стипендия алырмын дип хыялланып йөргәндә шулай итеп ярык тагарак янында утырып калдым. Елым әрәм үтмәсен дип Буадагы Мулланур Вахитов исемендәге мәктәпкә мөрәҗәгать итеп карадым. Анда ниндидер бер апа: "Үскәнем, өч параллель класс та шыплап тутырылган бит, бөтенесендә утыздан артык бала. Колхозда эшләп тор быелга—киләсе елдан укый башларсын..."—диде. Бу юату минем язмышка артык усал хөкем иде шул.

Авыл җирендә һәр кеше исәптә. Мине дә тынычта калдырмадылар. Урак өсте бит. Күршебез Хәкимҗан абый Тимергалиевнең үзйөрешле комбайнына салам төшерүче итеп билгеләделәр. Анысы әлләни авыр эш түгел инде түгелен. Иртә таңнан караңгы төшкәнче булуы гына арыта. Хәер, анысына түзәр идең. Комбайн урган сабаклар чуала да барабанга кермичә җанга тия. Хәкимҗан абый аптырагач, кулыма нык кына таяк тоттырып, тыгылган башакларны шуның белән төрткәләп җибәрергә куша. Кайчагында комбайн туктап та кала. Ачкычларның кайсы номер икәнен чамалап, тиз генә китереп бирергә кирәк—Хәкимҗан абый, аты-юлы белән сүгенергә яратса да, миңа алай каты бәрелми, җайлап кына төшендерә. Комбайнда эшләгәннәргә хезмәт көне зур итеп языла. Тик ул барыбер минем исемгә исәпләнми—җинәчинең минимумын тутырасы бар бит. Мин инде укуымны дәвам итүдән тәмам өметемне өзгән, киләчәк тормышымны мөгаен машиналар, тракторлар, комбайннар белән бәйләргә туры килер дип фикер йөртә башлаган идем—язмышыма инде бөтенләй күнгән идем.

Ләкин бөтен уйларны үзгәртеп августның утызында көчле яңгыр явып үтте. Табигать биргән бу ял, бу тәнәфестән файдаланып, Рәхилә апаларга киттем. Алар, минем шушы хәлләргә борчылып, үзләренчә план корганнар булып чыкты.

—Ерагын ерак инде. Тарханда минем абыем мәктәп директоры. Газиз абыең Әлмөхәммәтов, үзе дә ятим үскәч, аңлар ул сине. Елыңны әрәм итмим дисәң, бар шунда. Фатирына үзебез түләп торырбыз. Газиз абыең аз-маз тамагыңны да

кайгыртыр,—диде Рәхилә апа. Ике уйлап торыр чак түгел иде. Әлбәттә, барам.

Әле анысы гынамы—ул көнне шул Олы Тархан дигән ерак җиргә укырга барырга малайчак дустым Тәүфикъны да күндердем. Абыйга ялынып торасы түгел иде—ул бу мөмкинлеккә шатланды гына. Аның мине, һичшиксез укытасы, кеше итәсе килә иде. Үзенең минем белән бергә укыган малае Кадим уку мәсьәләсенә бөтенләй битараф карый, билгеләре дә "өчле" дә "дүртле" тирәсендә генә, андый омтылышы да әлләни юк иде бугай—ул авылда калуны кулайрак санады.

Иртәгәсен абый безне Буага кадәр озатып, Тархан ягына баручы бер "бензовоз"га утыртып җибәрде. Шофер Борындык станциясенә кадәр генә бара икән—безгә, әллә ничә авыл аркылы үтеп, ул вакыттагы район үзәге Олы Тарханга кадәр җәяүләп тәпиләргә туры килде. Озын юл бит—авылдан алтмыш чакрым чамасы. Ул көнне без барып җитә алмадык. Бидәнге дигән авылдан ерак түгел кырда салам эскертенә чумып, шунда йокладык. Тарханга без икенче көнне төш вакытларына гына барып җиттек. Директор Газиз абый безне бик җылы каршылады. Мәктәп ишегалдындагы өйләренә алып кереп, алдыбызга катык һәм икмәк китереп куйды.

—Ач йөрмәгез, ашыйсыгыз килсә, монда гына килегез,—диде. Кемнедер кайларгадыр җибәреп, фатир мәсьәләсен белеште. Кичкә таба без мәктәптән ерак түгел яшәгән Сәхия апа Чумариналарда урнаштык. Бу 1954 елның 1 сентябре иде.

## Сталинга хат

...Эч серләремне сөйләрдәй дусларым бик күп иде дә минем. Иң-иң якыннары инде теге дөнья тарафларында. Кайсы бу якты дөньяда пенсия яшенә кадәр дә яши алмады. Әле ул гынамы?! Әле иллегә, хәтта кырыкка да җитмичә үлеп киткәннәре булды. Менә авылдаш дустым Тәүфикъ... Кем уйлаган бит аңа шул каһәр суккан рак зәхмәте килеп ябышыр дип! Яшьрәк чакта аның кызы минем олы малайга кияүгә чыгар да, кодалар булып гомер кичерербез дип хыялланган идек. Булмады... Әллә нинди буталчык бу дөнья—нишләптер без дигәнчә генә бармый. Аның кызы да бик бәхетлеләрдән түгел, минем малай да...

Ә тузанлы юллардан яланаяк үткәндә, тезгәчә җиткән пычракларны ерып йөргәндә, тишек бишмәтләрдән суык җилләр үтеп тәнкәгә тигәндә, без башкача идек, без сафрак идек, без иманлырак идек. Әйттем бит әле генә: хәзер күрше күршегә керми, туган туган белән кунакка йөрешми. Әле менә бүген исән калган сирәк-мирәк дуслар белән дә ярым рәсми телдә сөйләшәбез. "Исәнме-саумы?" "Ярый инде шунда, түзәрлек"—шул бер-ике сүз алышабыз да, төрлебез төрле якка китеп барабыз. Ә ми катламнарына сыенып яткан уйлар кем тарафыннан да ишетелмәгән килеш каядыр яшеренеп посканнар, инде онытылырга хөкем ителгәннәр. Кешеләр ялгызлыктан интегә. Бу заманның иң хәтәр чире—юк, рак та түгел, СПИД та түгел, башкасы да түгел, ә ялгызлык...

Фатир хуҗасының иске паласын ябынып идәндә бер-беребезгә сыенып ятканда, яшерми-нитми эч серләребезне бүлешкәндә, без Тәүфикъ белән бәхетлерәк, һәрхәлдә бүгенгеләрдән күпкә, бик күпкә бәхетлерәк идек. Иң яраткан хатынына да сөйләми торган сүзләр була. Ирләрне чын-чынлап бары ирләр генә аңлый. Аңлый һәм... бик күбесе ул серләрне үзенеке кебек кадерләп саклый да.

Тәүфикъның матди хәле минекенә караганда әйбәтрәк иде. Әнисе белән инде егермедән узган апасына бердәнбер, күз өстендәге каш кебек кадерле кеше. Күпмедер дәрәҗәдә иркәләнебрәк үссә дә, адәм затына кирәкле матур сыйфатларын җуймаган эчкерсез дус иде. Ул соңгы сыныгын да минем белән бүлеште. Икебез бер үк кызга гашыйк булгач та, араларны бозмады, гади генә: "Кыз үзе хәл итсен..."—диде. Безнең дуслык гомер буена сузылды. Мин үзем нихәтле яхшылык эшли алганмындыр—белмим, әмма ул минем тормышымда хәтәр чаклар булганда, иң ышанычлы терәк иде.

Олы Тарханның беренче мәктәбендә без фәкать бер ел гына укыдык. Аннан Тәүфикъ Юдинодагы тимер юлчылар училищесына керде, мин исә укуымны Буаның М. Вахитов исемендәге урта мәктәбендә дәвам иттем.

Олы Тархан—күптәнге, тарихи авыл, галимнәрнең әллә никадәр фәнни хезмәтләрендә телгә алынган археология истәлеге. Безне башта күп кенә укучыларның

фамилияләре гаҗәпләндергән иде: Ышна, Элмә, Управляющий, Чумарин, Чукмаров, Урамбашев, Камбеев... Сөйләшләре дә безнең яктагыга ошамаган. Ишегалдындагы әтәчне күреп, аны "әтәч" дип әйткән идек, фатир хуҗасының кызы Сания апа: "Оятсызлар, нинди әшәке сүз сөйләп утырасыз..." дип орышырга тотынды. Әһә, "Әтәч" дигән бу йорт кошы "Кучат" дип атала икән... Тора-бара күнектек тагын—үзебез дә мишәрчә сүзләр кыстырып сөйләшә башладык.

Биредә яңа дуслар таптык. Мәктәпнең шахмат буенча чемпионы Хәмзә Минкин безне бу гаҗәеп мавыктыргыч уен серләренә өйрәтте. Бидәнге авылыннан килеп укучы Мингәрәй Шаммасов минем кебек үк шигырь белән җенләнә икән—шуңа да аның белән серләребез бик тиз килеште. (Озак еллар хатлар алышып тордык. Хәзер Лениногорскида яши. Врач.) Илдар Әхмәдиев исә Сталин, Жданов, Тукай, Жамбул рәсемнәрен коеп кына куя иде. Бар иде анда да талантлар!

Бер минут тынгы белмәс рус теле һәм әдәбияты укытучысы Роза апа безгә тәнәфес вакытында да файдалы шөгыль таба—мандолинада уйнап йә биетә, йә вальс әйләндерә иде.

Әкрам Камбеев абый исә безне техник түгәрәккә җыеп, йә планерлар ясарга, йә автоматтан атарга өйрәтә. Химия дигән фән шактый катлаулы бит инде югыйсә—укытучыбыз Хәмдия апа Камаева шул кадәр мавыктыргыч итеп сөйли, шундый тәҗрибәләр ясый—дәреснең узганы да сизелми кала иде. Атаклы химия профессоры Гыйлем Камайның бертуган сеңлесе дә икән әле житмәсә. 1952 елда Г.Камайга Сталин премиясе бирелгәч, Хәмдия ападан да бигрәк без шатландык. Янәсе, менә нинди кешенең сеңлесендә укыйбыз без!

Татар теле һәм әдәбиятын безгә Азат абый укытты. Ул—атаклы җырчылар Генрих белән Руслан Дәминовларның әтисе. Һәрвакыт үзе дә, хатыны да Олы Тархандагы мәдәни тормышның үзәгендә кайнады. Җырладылар да алар, биеделәр дә, музыка коралларында да уйнадылар. Өстәвенә Азат абый шактый оста рәссам да икән әле. Тарханда укыган чордан ничәмә-ничә еллар үткәч, мин язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында директор булып эшләгәндә, бүлмәмә йөз чалымнары таныш бер абзый килеп керде. Кара, кара, исән икән бит әле Дәминов абый! Майлы буяу белән Тукай әнисенең рәсемен ясаган. Мин инде бу өлкәдә белгеч түгел—шуңа күрә профессиональ рәссамнарга күрсәтергә киңәш кенә итә алдым.

Һәр шәхес үзенчә кызыклы, һәр язмыш кайсы ягы беләндер үзенә тартып тора. Без үзара "Кутузов" дип кушамат таккан тарихчы Михаил Илларионович та (чын фамилиясе онытылган да инде), класс житәкчебез Зәйнәп апа һәм аның бертуган сеңлесе старостабыз Сария Рәхмәтуллина да, егетләрнең күзләрен яндырып йөргән чибәр-чибәр кызларыбыз Мәгъсүмә Чумарина, Зөһрә Измайлова, Бидәнгедән килеп укучы, кемнәр өчендер гомерлеккә "Катюша" булып калган Кәүсәрия (Мингәрәй Шаммасов таккан иде аңа бу романтик исемне), һәрвакыт кырыс Шамилә... тагын, тагын әллә кемнәр... Кайберләре менә онытылган—ярты гасырдан артык вакыт үткән бит инде. Кайберләре якты дөнья белән дә байтактан хушлашканнар...

Әйбәт, тату яши идек без. Юк кына нәрсәдән дә кызык табып көлешә, шаярыша идек. Комсомол җыелышларында бер-беребезгә вак-төяк гаеп ташласак та, үпкәләшми, ачуланышмый идек. Роза апаның мандолина чиерткәненә дәртләнеп коридорда танцевать иткәндәй була идек, һәртөрле түгәрәкләргә йөри идек. Мин инде, алда әйткәнемчә, классташларымны "Безнең Чаян" дигән кулъязма журнал чыгарырга күндерә алдым—ул әллә нинди маҗаралардан соң, ничәмә-ничә еллар үткәч, минем кулга янәдән килеп керде.

Кызык иде, онытылмаслык иде ул мәктәп еллары. Тик ярлылык, ятимлек үзен барыбер гел-гел искә төшереп торды. Киемнәрнең туксан ямаулы булуы, директорыбыз Газиз абый, фатир хуҗаларыбыз Сәвия әби белән Сания апа, жан дустым Тәуфикъ булышкаласа да (алардан да гел-гел өмет итеп булмый!), туктаусыз ашыйсы килү күңелне төшерә, рухны рәнҗетә, кешелектән чыгара иде. Шунысына сөенәм, интексәм-интектем, әмма бөтенләй түбәнлеккә төшеп, бүтәннәр әйберенә тимәдем—урлашмадым.

Кышкы каникулга кайткач кына, шул бәрәңгегә генә булса да аз-маз тамак туя, аннан абый ат белән күпмедер бәрәңге, күпмедер он, һәм әниләре Тәуфикъка җибәргән азык-төлекне төяп, безне Тарханга илтеп куйгач, ачлыктан интеккәннәр азмы-күпме онытыла да, яшисе килә башлый иде.

Бер кышкы салкын көндә шул Тарханыбызга барганыбызны хәтерлим. Ат арык, кабыргалары беленеп тора, ике адым атлый да туктый, чыбыркы булып чыбыркыга да исе китми. Житмәсә, кайдандыр бүре дигән нәрсә килеп чыкты (ул елларда байтак иде бит алар!). Без кычкырабыз, кулларны болгыйбыз. Ә ул, берни булмагандай, бераз утырып тора да, без кузгалгач, тагын арттан иярә. Иллалла, мен бәла белән шулай Кыят дигән урыс авылына килеп життек. Урысларның ниндидер бәйрәме (Раштуа дип атала бугай) икән. Берничә йортта "отказ" ишеткәч, ниһаять бер абзый идәннәрендә кунып чыгарга кертергә килеште. Юньле йокы эләкмәде инде, караңгылы-яктылы кузгалырга булдык. Хужалар үзләре лакандагы су белән юыналар икән. Ә анда—какырык та төкерек. Абый сәерсенеп карап торды да:

—Кырга чыккач кар белән юынырбыз әле!—дип тиз генә киенергә кушты.

Ул алып килгән бәрәңге белән он барыбер озакка житмәде. Тагын мөлдерәп Сәхия апалар һәм Тәүфикъ (аның запасы күбрәк иде шул!) күзенә карарга калды. Аптыраган Сания апа (ул район уполминзагында хисапчы булып эшли иде—әйе, заманында андый контора да бар иде):

—Әллә, наный, Сталинга язып карыйсыңмы,—дип куйды. Ярдәм итсә, ул гына ярдәм итәр...

Беткән баш беткән, дип сырладым мин ул хатны. Сталин бөтенесен белә, ул һичшиксез татарчаны да аңлыйдыр, дип ихлас күнелдән ышанабыз бит ул заманнарда. Хатның башына "Это письмо на татарском языке" дип куйдым да, бөек юлбашчыны данлап байтак кына сырлаганнан соң, үземнең зарларымны, гозерләремне тезәргә керештем. Аны еламыйча укырга мөмкин түгел иде һәрхәлдә. Мин юләр малай башыннан хәтта: "Сталин да еламый калмас" дигән тиле уй да йөгереп үтте ул мизгелләрдә.

Гажәп, жавап озак көттермәде. Дәрес вакытында мине "Укытучылар бүлмәсе"нә чакырып алдылар да, бер конверт (нишләптер ул ачылган иде инде!) тоттырдылар. Кош теле хәтле генә кәгазьдә: "Ваше письмо, поступившее через Особый сектор ЦК ВКП(б), Президиумом Верховного Совета ТАССР, для проверки и принятия соответствующих мер, направлено в исполком Больше-Тарханского районного Совета депутатов трудящихся" дип язылган иде. Икенче көнне мине райисполком рәисе Акмал Һадиевич Башаров чакыртып алды. Ул инде минем кем булуым, авылда 25 сутый бакчам һәм атамнан калган зур йортым барлыгы турында кирәкле мәгълүматларны жыйган—мине кырыс чырай белән каршылады:

—Иптәш Сталинны борчырга ничек башың житте синең?! Нәрсә житми соң сина?

Мин курка-курка итегемнең тишек булуын, өс-башымның ертык икәнлеген, инде ничәнче көн ашамаганымны аңлатырга тырыштым, кирәксә-кирәкмәсә дә:

—Костюмым да юк... дип кыстырдым.

—Минем малай да костюм кими әле,—диде райисполком башлыгы.—Менә дигән йортың бар икән бит, сенлең белән синең өлешкә бәрәңге бакчасы да утырталар. Сезне карап үстерергә әтиеннең абыйсы алынган икән, ул кайгыртырга тиеш...

Шулай итеп бу түрә бүлмәсеннән мин яшьләремә буылып чыгып киттем.

Сталинга язган ул хатның жиле абыйга да тигән булып чыкты. Атна да үтмәгәндер, ул бәрәнге, он, яшелчә-мазар төяп Тарханга килеп житте. Теш арасыннан гына:

—Ул кадәр Сталинның үзенә үк жаловаться итмәсәң,—дип, канәгатьсезлеген белдереп тә куйды.

Тамак ягы азмы-күпме рәтләнсә дә, яз житкәч башка мәсьәләләр туды: итек инде тәмам эштән чыккан, юеш чакта киярга хәтта гап-гади галош-мазар кебек нәрсә дә юк иде. Имтиханнарга мин, кешеләрдән, бигрәк тә классташ кызлардан ояла-ояла (ни дисәң дә егет кисәге бит!) яланаяк барып йөрдем.

Тарханда укуымның иң зур сөенече шул булды: район газетасында минем "Жиңүне алдан әзерлә" исемле шигырем һәм татарча да, русча да мәкаләләрем басылды. Бу—минем фамилиянең матбугатта иң беренче күренүе һәм чынлыкта аннан соңгы житди ижатымның чишмә башы да иде. Ә минем үземә исә бары 16 яшь кенә тулып үткән иде.

## Туган як җылысы кирәк шул...

Олы Тархан дигән ул якларга барып чыгу. Товар поезды тоткаларына ябышып, зәмһәрир суыкларда жилфердәп кайтулар...

Булды инде, бөтенесе булды. Ул поездларның кондукторлары, кисәктән генә әллә кайдан пәйда булып, безне—"куяннарны"—куып төшерәләр иде. Аннан... тәпилә шпаллар буйлап. Бервакыт безне Октябрь бәйрәме алдыннан, ярты юлны үткәч, төшереп калдырдылар. Әле ярый, ниндидер күпер янында бер мәрхәмәтле абый очрап, землянкасына алып кереп йоклатты. Әй, андагы борчалардан интеккәнебез!..

Анның каравы Буага күчкәч, бераз җиңеләйде инде. Тугызынчыны, унынчыны Буаның шул атаклы Вахитов исемендәге урта мәктәптә укыдым бит мин. Узган ел "Класслар тулды бит инде, киләсе елга килерсең" дип мине борган кешене башка күрмәдем—кем булгандыр ул?! Тәуфикъ урта белем алуга тәмам кул селтәп, Юдинодагы тимер юлчылар училищесына китеп барды. Мин укуымны монда дәвам итәргә булдым...

Ә мин... мин Олы Тархан район газетасында басылган шигырем һәм мәкаләләрем өчен гонорар алмаган идем. Әмма күпмедер түләргә тиешлекләрен белә идем. Тәвәккәлләп киттем товар поездына эләгеп. Кондуктор күреп алды да, куа гына бит. Вагоннар түбәсендә куышып йөрибез. Такта төягән вагоннар—ике вагон арасы әлләни зур түгел—берсеннән икенчесенә сикерәсе генә. Әлбәттә ялгышып төшеп китүең дә бар. Аннан, беттең дигән сүз! Теге абзый ардымы, әллә егылып төшәрмен дип курыктымы—мине эзәрлекләүдән туктады. Ул арада мин төшәсе станциягә килеп җиткән идек. Аннан Тарханга 17—18 чакрым. Ким дигәндә өч сәгатьлек юл. Җәйге матур көн иде—элдерәм генә. Гонорарымны сыкранып кына бирделәр: редакторларын, бухгалтерларын көтә-көтә әллә никадәр вакыт үтте. Мин 25-30 тәнкә булыр дисәм, кулыма 10 тәнкә тоттырдылар да—вәссәлам. Шуннан сораша-сораша Тәтешкә бара торган юлга чыктым—ә пристаньга кадәр 40 чакрымлап атлыйсы. Минем Казанга нәкъ менә пароходка утырып барасы килә. Янәсе, билет бәясе дә арзандыр, дөнья күреп тә барырмын. Арып-талып төн уртасында пристаньга килеп җиткәч, исләрем-акылларым китте: акчам арзанлы балигъ булмаганнар билеты алырга да җитми икән. Әле ярый, бер абзый пароходка качып керү җаен өйрәтте. Керүен кердем, әмма, ярты юлны үткәч, барыбер контролерлар эләктереп алды үземне. Ун тәнкәмнән күпмесенәдер җир җиләге алып ашаган идем—калганын соңгы тиененә хәтле билет тикшерүчеләр сыпырып алдылар.

*Ә ул көнне Идел моңсу иде,*
*Ике күзем тоташ дымсу иде,*
*Утлар йота-йота акчам юкка,*
*Утырдым да ап-ак пароходка,*
*Бәхет эзләп чыктым ерак юлга—*
*Балаларга ничек тарымыйсың?!*
*Билетсыз да көе ак бәхеткә*
*Ак пароход алып барырмы соң?*

Шулай, килеп төштек Усия дигән җиргә. Рәхилә апа: "Ухтомский дигән урамга 1 нче трамвай бара", дигән иде. Вокзалга барып җиткәч, Абдулла абыеңны эзләп табарсың дип адресын биргән иде. Югыйсә, янәшәдә генә булган икән үзе. Кешеләрдән сорарга кыенсынам. Киткәнмен шунда урамнар буйлап. Кайларда гына булып бетмәгәнмен. Хәзер шул адашып йөргән юлларымны хәтеремнән кичерәм дә, гаҗәпләр калам. Ярты шәһәрне җәяүләп үткәнмендер. Ниндидер могҗиза белән кабат шул Ухтомский урамына килеп чыкканмын. Абдулла абый торган фатирны тапкач, анның институттан кайтканын көтә-көтә утырган җиремдә йоклап та киткәнмен.

Аннан Абдулла абый да (ул читтән торып педагогия институтында укый, җәйге имтиханнарын бирергә килгән иде) кайтты. Ак күмәч белән чәй эчертте. Ике көн буе ач йөргән миңа шунда ук хәл кереп китте.

Сонрак басылган "Казан" дигән поэмада мин аны болай сурәтләгән идем.

*Хәтерлим беренче мәртәбә,*
*Эчемнән укып бар белгәнне,*
*Ашкынып калага килгәнне,*
*Балакны сызганып тезгәчә,*
*Казансу буенда йөргәнне.*

*Сай идең, сай идең ул чакта,*
*Кемнәрдер хәтере шикелле,*
*Мин дә бит дүрт диеп йөргәнмен*
*Икегә тапкырлап икене,*
*Бәясен көтмичә һичкемнең.*

*Ә ярда, биектә Кремль—*
*Манара артында манара;*
*Җилкенде тынгысыз хыялың—*
*Инде дә күр барын, йә кара—*
*Әнә ич алдыңда—башкала.*

*И сабый, и авыл малае—*
*Урысча дәшәрлек юк сүзең.*
*Кемнәндер сорарга кыймыйча*
*Адашып йөрдем мин көнозын...*
*Эсседә... ач килеш... бер үзем...*

Иртәсен мин еллар буе хыялланган шул Бауман урамын, Матбугат йортын эзләп таптым. Киндерә белән бәйләгән галошымны лаштыр-лоштыр өстерәп, кулыма шигырьләр дәфтәремне тотып, килгәч тә иң беренче каккан ишегем “Чаян” журналы редакциясенеке булып чыкты. Миңа гаҗәпләнеп тә караганнардыр инде, әмма анысын сиздермәделәр. Түрдә утырган, нәкъ журналның тышындагы чаян сурәтен хәтерләткән зур күзлекле, йомры гәүдәле Г. Хәбиб дигән абый, мине нигәдер зурга санап, үзе янында утырган кешеләрне санап чыкты:

—Менә бусы Галимҗан абыең Насыйров булыр, бусы—Фазыл Басыйров дигән хезмәткәребез, бусы кызык-кызык карикатуралар ясаучы Петр Новичков. Ә менә диванда утырган абыең—атаклы драматург Гамир Насрый безгә материал алып килгән. Сине кем диеп белик инде?..

Мин кыска гына үзем турында сөйләдем. Казанга килүемнең максатларын әйттем, шигырь дәфтәрләремне карап чыгуларын үтендем.

—Берәр җиргә эшкә урнашасы иде,—дидем.

Абыйлар, минем хәлне аңлап, уйлана калдылар. Бәләкәй генә буйлы, чандыр, житү чәчле авыл малаен кем генә эшкә алыр икән,—дип икеләнүләре дә булгандыр бәлки.

Чыннан да, редакциядәге абыйлар ничек кенә баш ватсалар да, мине бер җиргә дә урнаштыра алмадылар. Аның каруы озакка сузмый минем “Ясалма кеше” дигән шигырем “Чаян”да басылып чыкты. 16 яшьлек малай өчен моннан да зуррак сөенеч булуы мөмкин түгел иде.

*Мин ялан аяклы бер ятим*
*Ул чакта зур шатлык татыдым...*
*Һәм менә илле ел йөгәнлим*
*Шул Пегас аталган атымны*
*Бозмыйча балачак антымны!*

Бу юлы мин бәхетемә күрә Вахитов исемендәге мәктәпнен директорына очрадым. Зарларымны сөйләп бирдем. Гөлсем Галләмовна үзе дә ятим үскән, өстәвенә энеләрен дә тәрбияләгән тәҗрибәле педагог булып чыкты. Ул кадәресен инде мин сонрак, бу мәктәптә укый башлагач кына белдем. Дөньяда бер язылмаган канун

бар: ятим кеше ятим кешене бервакытта да төртеп екмый, соңгы сыныгын булса да бүлешә. Гөлсем апа мине шунда ук интернатка урнаштырды. Бераздан, укытучылар, хезмәт хаклары алган көннәрдә, күпмедер акча җыеп мина бирә торган булдылар. Өстемә "лыжный" дигән костюм-чалбар, аякларыма кун итек алып бирделәр—мин ярыйсы гына кыяфәткә кердем. Минем мәктәп тормышында актив катнашуымны белгәч, класста комсорг итеп сайладылар. Тугызынчыдамы, унынчыдамы, хәтта ВЛКСМның район конференциясенә делегат итеп тә җибәрделәр...

Хәзер кайбер имансызлар шул үткәннәргә тибеп, бөтенесеннән уздырып, без үзебез язган тарихны сүгәләр, элекке юлбашчыларын мыскыллыйлар—ахмаклыкның чиге-чамасы юк. Минемчә, нишлисең, булганы—булган инде. Ялгышмы ул, түгелме—мин барыбер үткәнемнән баш тарта алмыйм. Шул комсомол мине иҗтимагый яктан актив булып үсәргә, яхшыдан яманны аерырга өйрәтте. Әйе, без җыелышларыбызда К. Маркс һәм Ф. Энгельсның "Коммунистлар партиясе манифесты", В. И. Ленинның "Материализм һәм эмпириокритицизм", И. В. Сталинның "Ленинизм нигезләре", "СССРда социализмның экономик проблемалары", "Тел белеме мәсьәләләре" дигән хезмәтләре буенча докладлар ясый, фикер алышулар уздыра торган идек. Мәктәп программаларында каралмаса да, ул безнең күбебезгә соңрак, инде югары уку йортларында (ә безнең чыгарылышның житмешләп проценты өлгергәнлек аттестаты алуның беренче өч елында ук институтларга керде) укыганда, политэкономия һәм философия кебек катлаулы фәннәрне әйбәт үзләштерергә ярдәм итте. М. Вахитов исемендәге урта мәктәптә таләпләр каты, педагоглар югары әзерлекле, матур традицияләр инде ныклап урнашкан иде... Республика күләмендә атаклы мәктәп иде ул...

Буада укыган чагында мин ул кадәр ачлыктан, мохтаҗлыктан интекмәдем шикелле. Интернатта Поля түтәй көн саен мәктәпнең үз участогында үскән бәрәңгене пешерә, төеп тә, кабыгы белән дә... Авылдан миңа атнасына бер икмәк биреп җибәрәләр, икмәк салмаган чак булса, абый ун тәнкә (сеңелем белән икебезгә 56 сум пособие түлиләр иде бит!) акча бирә иде. Анысы әйбәтрәк тә әле, чөнки ул заманнарда бер буханканың бәясе—3 сум 50 тиен чамасы. Аннан газетадан гонорар дигән нәрсә акмаса да, аз-азлап тама тора. Сабакташларым да кайчакларда булышкалый. Кыскасы, бик иркен булмаса да, чагыштырмача ярыйсы гына яшәргә мөмкин иде. Олы Тарханда чагында авырлыгым 32 килограмм, буем 1 метр да 37 сантиметр булса, унынчыда укыганда инде авырлык 45 килограммга, ә буй 1 метр 49 сантиметрга җитте. Хәрби комиссариат комиссиясе мине аэроклубка кабул кылу мәсьәләсен хәл иткәндә:

—Укып бетергәнче тагын 1 сантиметрга үсәрсең әле, калган күрсәткечләрең яхшы, нормада,—диделәр...

Аэроклубта да укып йөрдем бит әле...

Егермеләп малай идек. Соңыннан беребез генә—үтә үҗәт Харис Сөнгатуллин гына авиация училищесына үтте. Аны тәмамлагач та, шул якын араларга оча торган По-2 дан уза алмады. Мин малай чактан фанер кисәгеннән шундый самолетлар ясап, өстәл җәймәләрен парашют итеп очыртып юләрләнеп йөрсәм дә, ул һөнәрне сайлыйсы итмәдем. Аннан перспектива да бик күренеп тормый иде. Җитмәсә, мәктәбебезнең беллерүләр тактасына Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә чакырып, типографиядә басылган беллерү дә китереп элделәр. Анда шагыйрьләрдән Ә. Юныс, С. Шакир, тагын кемнәрнеңдер шул бүлектә укулары турында әйтелгән иде. Бу игълан бөтен зиһеннәрне чуалтып, бар планнарны әйләндерде дә куйды. Шигырь язып җенләнеп йөр дә, ничек инде шундый мөмкинлекне кулдан ычкындырасың?! Җитмәсә, В. И. Ленин үзе укыган бит әле анда. Без, параллель класста укучы дустым Ленар Җамалетдинов белән гаризаларны шунда, фәкать шунда гына тапшырырга булдык.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## «Казан утлары» архивыннан



*Язучылар берлеге китапханәсендә (Бауман ур., 19). Уңнан сулга—Атилла Расих, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Хәсән Туфан, Геннадий Паушкин. 1979 ел.*



*Даими авторыбыз— филология фәннәре докторы, профессор Фирдәвес Гарипова. 2005 ел.*



*Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен укытучылар арасында. Саба районы, Икшермә авылы. 70 нче еллар.*



*Татарстан радиосы ветераннары. 1977 ел.*



*"Казан утлары" журналының редколлегия утырышыннан соң. 1998 ел.*



# "РУХИ ТОРМЫШЫБЫЗ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ"

"Казан утлары"ның меңенче саны чыгу уңаеннан "Сүнмәс утлар балкышы" дигән китабыбыз нәшер ителүгә (2006 ел, декабрь) ике ел тулды. Бу вакыт эчендә китап Татарстан һәм Россиянең барлык төбәкләренә дә диярлек барып иреште, Төркия, Англия, Америка кебек илләргә дә юл тапты. Аның турында матбугатта бик матур фикерләр әйтелде.

**Айдар Хәлим, язучы:**
—Бу капиталь хезмәт милләтебезнең мең еллык мәдәни тарихын инде тагын бер тапкыр черемәс фикер гранитында расланган рухи капиталыбызга әверелде.

Кыска гына вакыт эчендә редакциянең үз көчләре белән генә чыгарылган мондый энциклопедик басма-фолиант Казанны саклаганда шәһит киткән бабаларыбызга һәйкәл ул.

**Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы, профессор:**
—Китапларның төрлесен күргән, "Казан утлары"ын да бит күптәннән укып барган кеше буларак, бу басманы мин, йә, ни майтардылар икән дигәндәй, скептик рәвештәрәк кулга алдым һәм... исләрем-акылларым китте. Чын мәгънәсендә бер хәзинә бу...

Журналның гына түгел, ә гомумән татар рухи тормышының, милли яшәешенең бер өлешмәсе, чыганагы, энциклопедиясе, хрестоматиясе кебек тә ул.

**Рәис Даутов, тәрҗемәче, әдәбият белгече:**
—Үткәндәге мәдәни-иҗтимагый тормышыбызның куанычлы һәм аянычлы этапларын язма әдәби материаллар мисалында объектив рәвештә яктырткан уникаль китап-антология... Тарихи әһәмияткә ия зур бер яңалык, казаныш.

**Ркаил Зәйдулла, язучы:**
—Укучылар кулына инде "Татар энциклопедиясе", "Татар тарихы" дигән олуг хезмәтләрнең кайбер томнары килеп иреште. Һичшиксез, "Сүнмәс утлар балкышы" дип аталган китап та киштәбездә шулар янәшәсендә урын алырлык.

**Рафаэль Мостафин, әдәбият белгече, тәнкыйтьче:**
—Татар әдәбиятының бу үзенчәлекле антологиясен укыганда тулы бер дәверне яшәп чыккан кебек буласың, еш кына катлаулы һәм авыр, кайчакта исә фаҗигале дә булган вакыт сулышын тоясың.

**Адлер Тимергалин, язучы:**
—Уртакул американ төрмә бинасына тартым "хрущоба"ның кысан фатир-мәгарәсендә, һава җитмәгәндә тәрәзә ачкалап утырам. Теземдә кызыл мәрмәрдәй саллы том—үзе бер китапханәгә бәрабәр "Сүнмәс утлар балкышы". Мин бу утларның саллы җылысын тезләрем белән дә, күңелем белән дә тоям...

Әгәр дә мәгәр бер мәлне мине адәм заты яшәми торган утрауга озатасы булып, үзем белән ун китап алырга рөхсәт итсәләр, шуларның берсе һичшиксез "Сүнмәс утлар балкышы" булыр иде. Алай-болай ерак йолдызара сәяхәткә чыгып китсәм дә үзем белән алыр идем мин аны...

*Китап редакциядә бар әле.*
**Адресыбыз:** Казан, Декабристлар ур., 2. "Казан утлары". 10нчы кат.
**Белешү өчен телефоннар:** 292-38-60, 292-36-49.

# 2008 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2008 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында №5

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Яңа елда гамьле уйлар. №1

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVI КОРЫЛТАЕН КАРШЫЛАП**

Соңгы өч елда... (М. Маликова, Г. Морат, Л. Лерон, Р. Рахман, Ю. Сафиуллин чыгышлары). №4

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVI КОРЫЛТАЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ**

Ибраһимов И. Уебызда—милләт язмышы. *(Татарстан язучылар берлегенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турында хисап доклады).* №9

Вәли-Барҗылы М. Тәнкыйтьне кем ярата? *(Әдәби тәнкыйть).* №9

Газизова Л. Заман сулышы. *(Рус әдәбияты һәм тәрҗемә).* №9

Закирҗанов Ә. Сәхнә әдәбиятыбыз. *(Драматургия).* №9

Корбан Р. Заман яңа герой сорый. *(Балалар әдәбияты).* №9

Мансуров З. Шигърият урталыкны өнәми. *(Поэзия).* №9

Миңнуллин Т. Безне олы сынаулар көтә. *(Татарстан язучыларының XVI корылтаен ачканда әйтелгән кереш сүз.)* №9

Фәйзуллин Р. Бердәм булсак—югалмабыз. №9

"Казан утлары" журналы турында. №9

Хәлим А. Ватан хакы. *(Публицистика).* №9

Хөснияр З. Булган, бар һәм булачак. *(Проза).* №9

Татарстан Язучыларының XVI корылтае резолюциясе. №9

**Бөтендөнья татар конгрессы IV корылтае материаллары №2**

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әмирхан М. Үрбәт ханәкә гыйшкы. *Роман.* №№4-7

Әхмәтгалиева А. Өзелгән гөл. Хикәя. №3

Бәйрәмова Г. Теләк. *Хикәя.* №4

Вәли Р. Канатлы татар. *Роман.* №№2-4

Габделхакова Р. Нишләттегез Гөлкәйне? *Повесть.* №1

Габделхакова Р. Китмә!!! *Хикәя.* №4

Галиева Ф. Тозак. *Хикәя.* №1

Гаффар Ә. Коелы өй. *Хикәя.* №1

Гаффар Ә. Кәфенгә кесә текмиләр. *Хикәя.* №12.

Зәйнуллин З. Кави Нәҗми дигән язучы... *Роман.* №№7, 8

Иксанова И. Җиткән кыз. *Хикәя.* №12

Кадыйров Р. Сугыш. *Документаль повестьтан өзек.* №10

Кәбиров М. Елмаю. *Хикәя.* №2

Мәснәвиева Ф. Ачы алма. *Хикәя.* №2

Мулланурова Р. Өрәңге өрәге. *Хикәя.* №10

Мөхәммәдиев Р. Кош булып очар идем... *Роман.* №№11, 12

Низами Р. Төнге яңгыр. *Хикәя.* №5

Нуриев В. Кара бишмәт. *Хикәя.* №9

Салихҗан И. Нурлыһөдәнең якты көннәре. *Хикәя.* №6

Сафин Р. Атландым атның биленә. Чик сакчысы язмалары. №10

Сафиуллин Ә. Сынаулар аша. *Повесть.* №9

Фәизов Р. Ат карагы. *Хикәя.* №11

Хәлим А. Хунвейбин. *Роман-эпопея.* №№5-9

Хәсәнов Ә. Әнис алмалар. *Повесть.* №3

Хуҗин М. Ипи. Колын. Без. *Хикәя.* №5

## ШИГЪРИЯТ

Арсланова Р. "Моңнар бүләк итәм"... *Шигырьләр.* №12

Әхмәтҗанова С. Әбелхәят тамчысы... *Шигырьләр.* №6

Әюп. Х. Яңа шигырьләр. №6

Баян Ә. Ак күңелле, серле дөньядан. *Шигырьләр.* №9

Булатова К. Дөнья тулы, юкса, умырзая... *Шигырьләр.* №3

Бәдигый Х. Мәйдан. *Шигырьләр.* №6

Габдерәхим Ф. Антка тугры калсам... *Шигырьләр.* №1

Гадел Ә. Тормыш дигән япан кырда... *Шигырьләр.* №10

Галиев М. Миндә бара күк һәм җир тартышы. *Шигырьләр.* №1

Галиев Ш. Халкым, син моңнан яралган. *Шигырьләр.* №2

Галиев Ш. Мәңгелек утны да мизгел кабыза. *Шигырьләр.* №11

Гарифуллина Р. Кем көчлерәк? *Поэма-баллада.* №7

Гәрәева С. Аккош канатыдай ак болыт... *Шигырьләр.* №11

Гыйззәтуллина Ф. Юл—озын, өметләр—урау... *Шигырьләр.* №10

Гыйләҗев И. Ил-көн каршында. *Шигырьләр.* №2

Гыйльфан Ф. Аккоштай кагынып... *Шигырьләр.* №10

Җәлил М. Дуска. *Шигырь.* №9

Зәйдулла Р. Иске моң—галиҗәнап... *Шигырьләр.* №10

Зәкуанов Р. Чатыртауга менәм... *Шигырьләр.* №3

Идиятуллин Р. Бәгырьләрне өзә бүз тургай... *Шигырьләр.* №7

Иксанова И. Кичер, хәят... *Шигырьләр.* №8

Киньябулатов И. Гомер. *Шигырьләр.* №7

Маннапов Ш. Гомер үрендә уйланулар. *Шигырьләр.* №1

Мансуров З. Табу дәрте ерак алып китә... *Шигырьләр.*№4

Миңнуллин Р. Сандугачлар туа гына... *Шигырьләр.* №8

Мингалим Р. Янмый калган шигырь эзләп... *Шигырьләр.* №8

Мирза М. Адәм баласына. *Бишьюллыклар.* №1

Морат Г. Юл тамгасы—йолдыз язуыннан... *Шигырьләр.* №3

Мөдәррисова Х. Күңелемә яуган карлар. *Шигырьләр.* №4

Мөхәммәтшин Г. Агымсуга башын игән тал мин. *Робагыйлар.* №12

Нәзиров М. Кош юлыннан китеп барам. *Шигырьләр.* №4

Низами Р. Җанда—июнь... *Шигырьләр.* №6

Рәхим Г. Сәгать тавышы—гомер агышы. *Шигырьләр.* №12

Сәгыйдуллина Л. Мизгелләр йолдызлыгында. *Шигырьләр.* №5

Ситдыйкова Ә. Мәңгелек ямь эзләп. *Шигырьләр.* №3

Суфиянов А. Киеренке кылы күңелнең... *Шигырьләр.* №5

Фатыйхов В. Сират күперендә. *Шигырьләр.* №1

Шәмсетдинов Г. Күңел кыллары чыңлый... *Шигырьләр.* №12

Шәрипов Р. Соңгы сәлам. *Өч монолог.* №5

Шәрифуллина Э. Үз җиремнең җиләге мин. *Кыска шигырьләр.* №9

Якупова С. Саф тамчылар. *Шигырьләр.* №6

Янсуар Л. Җәйрәп ята гомер—алдыбызда... *Шигырьләр* №8

Яруллин Ф. Төрле еллар—төрле җырлар. *Шигырьләр.* №2

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Лерон Л. Кичерәлсәң, кичер... *Ике пәрдәле мелодрама.* №8

Миңнуллин Т. Дивана. *Ике пәрдәле драма.* №11

Салихов Д. Таш сандык. *Ике пәрдәле сатирик комедия.* №10

Сафиуллин Ю. Акмулла. №9

## ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин М. Су язып, май чыкмый. №6

Әхмәтҗан М. Тормыш мизгелләре. №2

Бәйрәмова Ф. Себер иленә сәяхәт. №№8–10

Вафин Т. Мәкруһлар. №11, 12

Закир Л. Казан шәһәренең исемен ни өчен үзгәртмәгәннәр? Мәхәббәт, коммунизм һәм тәмәке. №2

Фәтхерахманов Р. Милләт темасына этюдлар. №4

Хәрәкәттә—бәрәкәт. *("Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның "Идел-Пресс" басмаханәсе генераль директоры Ислам Әхмәтҗанов белән әңгәмәсе).* №4

Һәр нәрсәнең иясе бар... *(Шагыйрь Разил Вәлиевнең рәссам Әхсән Фәтхетдинов белән әңгәмәсе.)* №7

Ф. Яруллин турында замандашлары. №2

Юныс Р. Карабыбыз батып барганда... №12

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әхмәдулла Ш. "Әмир иле"нә сәяхәт. №6

Баттал Ф. Безне беләләрме? №11

Вәлиев М. Намуслы кешеләр. №1

Галиуллин Т. Тарих сабаклары. №5

Заһидуллина Д. Ил йөрәгенә яза ул. №7

Кәбиров М. Ул да берәү генә... №8

Минһаҗева Л. Шигъриятебездә Истанбул образы. №11

Мөхәммәтшин З. Чит илләрдә татар әдәбияты. №6

Низами Р. Аучы. Шагыйрь. Гуманист. №7

Хәмидуллин Л. Тәрҗемәне онытмыйк. №10

Хәсәнова Ф. Шигърияттә Сәйдәш яши. №4

Шәехов М. Латыйфи романнары. №11

### ФӘН

Бакиров М. "Идегәй" дастанына яңа караш. №8

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №№2-11

Миңнегулов Х. Таҗеддин Ялчыгол. №10

Тимергалин А. Миллият сүзлеге. №2, 3

Фәтхи Ф. Замана мәгърифәтчесе иде. №8

Хуҗин Ф. Күпкырлы галим. №5

### ТАРИХ

Гаффарова Ф. Садри Максуди Арсал. №7

Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды? №4

Мостафин Р. Хәсән Туфан һәм Гаяз Исхакый. Бер кызыклы гөман турында. №6

Солтанбәков Б. Татарлар һәм Игнатьев. №12.

### ӘДӘБИ МИРАС

Анак Ш. Күзгә сары яфраклар. Медитацияләр. №11

Миңнегулов Х. "Нәһҗел-фәрадис" (1358) турында. №11

### СӘНГАТЬ

Газиев И. Татар җыры—йөз ел элек. №10

Җәмитов К. Кайттым герман җиреннән... *Скульптор язмалары.* №№5-7

Монасыйпов Ш. Тәрәзәгә язмыш чирткәндә. №5

Ризванов Г. Күңеленә сандугач оялаган. №8

Хәрефләр, тарихлар терелә... *(Н. Нәккаш белән Р. Ягъфәров әңгәмәсе).* №6

Ягъфәрәв Р. Татар халкының тамаша сәнгате. №4

### ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ. УЛЬЯНОВ (СЕМБЕР) ӨЛКӘСЕ

Иделбикә. Яшә, Казан! *Шигырьләр.* №9

Марат А. Каенсарда. *Шигырьләр.* №9

Хисмәт Р. Шагыйрьгә. *Шигырьләр.* №9

Шәфигуллин Р. Язасы иде былбыл бәетен. *Шигырьләр.* №9

### ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ

Ширмән Х. Кул язганны колак ишетсен. №5

### ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Райнер Мария Рильке. Шагыйрь үзе турында. *Шигырьләр.* №7

Шагыйрьҗан Л. Шигърият галәмендәге дәрвиш. №7

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ШИГЪРИЯТЕННӘН**

Кырымтатар шагыйрьләре шигырьләре. Бәкер Чабан-задә, Чәләби Җиһан, Әмди Гәрәйбәй, Әшраф Шәми-задә, Сәйтүмәр Әмин, Шәүкый Биктүрә, Леман Сөләйман. №2

**ХӘТЕР**

Алишина Х. "Без үзебез—Себер татары". №5

Бәширов Г. Күңел дәфтәре. №11,12

Гаитов М. Җырга багышланган гомер. №1

Госманов М. Затлылык. №3

Госманов М. Остаз кайгысы. №5

Гыйләҗев А. Гомернең бер елы. Көндәлек сәхифәләреннән. №№1-4

Ихсанова Л. Зөлфия хатлары. №9

Миңнуллин Р. Шагыйрь булулары җиңел түгел. *Бер хатирә.* №12

Мозаффаров Р. Сибгат Хәким архивы. №6

Рәшит Ә. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр.* №№8–12

Сөләйманов Б. Чал Иртышның үзе кебек. *Шигырьләр.* №5

Фәйзуллин Р. Хатларда да безнең язмыш. №8

Фәттах Н. Беренче шигырь күк балачак... *Истәлекләр.* №№10–12

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ

Юзиев А. Милли идеологиягә нигез салучы. №1

ГАБДЕЛМӘННАН РАХМАНКОЛЫЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Миңнегулов Х. №12

ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Мусин Ф. Милләт сагында. №2

ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Әхмәдуллин А. Идеология корбаны. №1

ШАМИЛ УСМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Кәримов К. Комиссар әдип урамы. №12

ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Сверигин Р. Фатих Хөсни феномены. №2

"ШУРА" ЖУРНАЛЫНА 100 ЕЛ

Госманов М. Тарихыбызның тутыкмас бер көзгесе. №1

"ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН"ГА—90

Кәримов К. Унөченче өмет. *(М. Сәфәров белән әңгәмә.)* №3

ВЕРА МИНКИНАГА 90 ЯШЬ

Редакция котлавы. №9

"КЫЗЫЛ ТАҢ"ГА—90

Юлаев К. Мәҗит Гафури иҗатындагы мөһим баскыч. №3

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Мостафин Р. Әдәбиятыбызның иҗат баганасы. №1

ГАБДУЛЛА ГАЛИЕВКӘ 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

ГӨЛЧӘЧӘК ГАЛИЕВАГА 80 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Язучының яшен сорамыйлар. №3

МИРФАТИХ ЗӘКИЕВКӘ 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №8

САИМӘ ИБРАҺИМОВАГА 80 ЯШЬ

Язучы. Тәрҗемәче. Журналист. №3

ФУАТ МАНСУРОВКА 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВКА 80 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Ил агасы Әлмәндәр. №10

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВКӘ 80 ЯШЬ

Юзиев Н. Балаларга шатлык өләшүче. №11

ХӘЙ ВАХИТНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Габдуллина Г. Сәхнәгә җан кертте. №12

ГОСМАН ГОМӘРГӘ 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

МАРС ШАБАЕВНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Кәримов К. Үҗәт мөхәррир. №7

ХУҖИӘХМӘТ МӘХМҮТОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРОВКА 70 ЯШЬ

Галиуллин Т. Рух бөеклеге. №2

ДИАС ВӘЛИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Фәлсәфи рухлы әдип. №7

КАНӘФИ НӘФЫЙКОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №11

МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №7

РАБИТ БАТУЛЛАГА 70 ЯШЬ

Хатыйпов Ф. Тынгысыз җан. №3

РАВИЛ ШӘРӘФИГӘ 70 ЯШЬ

Низами Р. №4

РИФКАТЬ ЗАКИРОВКА 70 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Үз моңын тапкан шагыйрь №6

РИНАТ ТАҖЕТДИНОВКА 70 ЯШЬ

Шакирҗан Л. Бер сөйләшү—бер гомер. №1

ЭРОТ ЗАРИПОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №7

ШАҺИНУР МОСТАФИНГА 60 ЯШЬ

Шәрәфиев Р. Күңелендә күпме җылылык бар. №2

ФӘҮЗИЯ СОЛТАНГА 50 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. "Салмак кына еллар шулай узып бара..." №9

ХӘБИР ИБРАҺИМГА 50 ЯШЬ

Редакция котлавы. №11

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Әхмәтҗан Р. Мәхәббәт иле. №10

Вәлиулла И. Илче. №2

Йосыпова Н. Балачакка сәяхәт. №10

Фәйзуллин Р. Гамьле шагыйрь бакчасы. №3

Шәрәфиев Р. Ак күңел һәммәбезгә кирәк. №12

Шәрифуллина Э. Энҗе бөртекләрен тезгән ул. №4

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Галиева Ф. Эшмәкәр әби. Тормышның кыйммәте нидә? №6

Гариф Н. Гыйбрәтле хикәятләр. №3

Гәрәева Ф. Кәче Барый. №5

Фәизов Р. Забастовка. Юлбашчы башы. Тере Ленинны күрдек! №2

Хәмидуллин Н. Кабер казучылар. №6

**ЮМОР-САТИРА**

Миңнуллин Р. Дусларым, дус ишләрем... №3

Нәҗмиев Т. Шундый-шундый хәлләр. №6

Фәтхи А. Уймакка сыйган уйлар. №6

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Аланлы Л. Без эзләгән Бәхет. *Шигырьләр.* №11

Бикмуллина А. Бәхет ул ишек шакымый. *Шигырьләр.* №9

Вәлиева Л. Безнең серне саклар күкләр. *Шигырьләр.* №10

Гобәева Р. Югалмабыз. *Шигырьләр.* №11

Мөхәммәтшин Р. Өмет—иң якты уй. *Шигырьләр.* №9

Сәлах Р. Туган туфрак җылысы. *Шигырьләр.* №6

Фәтхетдинова Л. Булыр. *Шигырьләр.* №4

Якупова Л. Яшенле төндә. *Шигырьләр.* №3

Һадиева Э. Һәм мәңгелек тәмегадилектә... *Шигырьләр.* №4

**УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ**

Фазулай Ф. Күренекле милләттәшләремә. №12

**БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ**

Камил Сәгъдәтшин. №1

Гөлфия Исхакова. №3

Рафаэль Хәкимов. №3

Гөлзадә Бәйрәмова. №4

Марс Хафизов. №4

Равил Сабиров. №5

Әхәт Хәбибуллин. №7

Алмаз Хәмзин. №10

Искәндәр Гыйләҗев. №10

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Гомәр Г. Тукай—мулдакә. №11

**ГАМӘЛ**

Тимергалин А. Сүнмәс ут янында уйда без. №1

**ХИКМӘТЛЕ ҖӨМЛӘЛӘР**

Фәтхетдинов З. №5

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Кашаев А. Сагышларны җилләр тарата. *Шигырьләр.* №9

**ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ**

Мостафин Р. Мирсәй Әмир гаепләме? №10

**ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН**

Сирай Д. Ватан төсе. *Шигырьләр.* №12

**БЕЗНЕҢ КҮРГӘЗМӘ**

Скульптор А. Абдрәшитов эшләре:

Айрат Арсланов. №4

Таҗи Гыйззәт. №6

Мөхәммәт Мәһдиев. №6

Туфан Миңнуллин. №8

Шәүкәт Биктимеров. №8

Мансур Хәсәнов. №11

Рафаэль Мостафин. №11

**АК ҖИЛКӘН**

Габдулкаюмова Э. Сөюдә без тигез. *Шигырь.* №4

Закиров Х. Карамзин нәрсә дигән? *Хикәя.* №1

Сәйфуллин И. Шаян хикәяләр. №4

Юсупова Р. Тэтчер маҗаралары. №№1-6

**КЫЗЫКЛЫ ДӨНЬЯ**

Шакиров К. Курку. №7

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Зариф Бәширинең тууына 120 ел. №5

Заһидулла Яруллинның тууына 120 ел. №11

Фатих Сәйфи-Казанлының тууына 120 ел. №3

Рәшит Ваһаповның тууына 100 ел. №5

Бәян Гыйззәтнең тууына 90 ел. №7

Мөнир Мазуновның тууына 90 ел. №4

Нәҗип Мадьяровның тууына 80 ел. №3

Нур Гыйззәтуллинның тууына 80 ел. №6

Шамил Бикчуринның тууына 80 ел. №1

Ямаш Игәнәйнең тууына 70 ел. №1

"Татар энциклопедиясе" битләреннән. №№1-12

Бер сорауга—бер җавап. №№1, 2, 8

Укучы сүзе. №№2, 6, 11

Хат. №№1, 4

Хушлашу сүзе. №№4, 6, 11

"Гаилә елы уңаеннан". №№5, 6, 8-12

"Казан утлары" архивыннан. №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

Яңа китаплар. №№1-12

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

## ИЗГЕ ЯДКӘРЛӘРЕБЕЗНЕ КАДЕРЛӘРГӘ ӨЙРӘНИК

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ БЕЛДЕРҮЕ

Быелның изге Рамазан ае төгәлләнгән көннәрдә рухи тормышы бөек, җисми тормышы фаҗигале булган, даһи шагыйребез Габдулла Тукайның шәхси язмыш дәфтәренә тагын бер кара сәхифә язылды—аның Казандагы төп торагы—"Болгар" кунакханәсе юкка чыгарылды. Киң җәмәгатьчелек, бигрәк тә язучыларыбыз, соңгы берничә дистә еллар дәвамында әледән-әле, бу бина төзекләндерелеп, аның кадерле Тукаебыз яшәгән бүлмәсендә шагыйрьнең мемориаль музее оештырылырга тиеш, дигән тәкъдим ясап килде. Әмма бу тәкъдимнәр тормышка ашырылмый калды.

Ни аяныч, Тукай тормышының фаҗигале мизгелләре инде өченче гасыр дәвам итә. Дөньяга Тукайны бүләк иткән XIX гасыр шагыйребезнең ятимлеге һәм фаҗигале балачагы гасыры да булды, XX гасыр 27 яшьлек даһиның гомерен өзде, инде килеп, XXI гасыр аның җылы оясын туздырып ташлады...

Бөек Тукаебыз яшәгән йортның юкка чыгуын шагыйрь иҗатына гашыйк миллионнарча әдәбият сөючеләр дә, күпләгән җәмәгать оешмалары да олы фаҗига булара кабул итте. Тукай варислары булган язучыларыбыз бу фаҗигане аеруча авыр кичерә.

Әле 26 сентябрь көнне генә без Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышында бөек Тукаебызның тууына 125 ел тулу уңаеннан төзеләчәк хөкүмәт планына теркәү өчен 32 тәкъдим кабул иттек. Аның 7 нче бүлегендә: "2010 елга Г. Тукай яшәгән "Болгар" кунакханәсен төзекләндерергә һәм анда музей оештырырга",—дип язылган иде.

Кызганыч ки, изге теләгебез тормышка ашмас хыял гына булып калды. Башкалабызда татар халкының күренекле шәхесләре белән бәйле биналар юкка чыгарылган өчен, шул исәптән, күптән түгел генә мәдәниятебездән тартып алынган, бик күп каләм әһелләренең бишеге булган Матбугат йорты өчен тетрәнеп йөргән көннәрдә Тукайга да кизәнергә өлгерделәр.

Без барыбыз да республикабыз һәм Казан шәһәре җитәкчелегенә, мәдәният һәм архитектура оешмаларына, газит-журнал, радио һәм телевидение редакцияләренә, бигрәк тә Татарстан Язучылар берлегенә өзлексез шалтыратып торган замандашларыбыз әйткән, җәмәгать оешмаларының рәсми мөрәҗәгатьләрендә чагылган тирән борчылу хисләре белән тулысынча килешәбез. Алар барысы да бу гамәлне кылган кешеләрнең исемнәрен җәмәгатьчелеккә белдерүне, бу эшне рәсми рәвештә гаепләп чыгуны таләп итә. Болай эшләү киләчәктә халкыбызның изге мәдәни ядкәрләрен күз карасыдай саклау өчен зур бер сабак булыр иде.

Безне бүген, "Болгар" кунакханәсеннән бушаган бу изге урын киләчәктә ничек файдаланылыр икән, дигән сорау да борчый. Тарихи Печән базары, Тукай үз гомеренең соңгы көннәрен кичергән "Амур" кунакханәсе һәм шагыйрь күп тапкырлар чыгыш ясаган "Шәрекъ клубы" биналары, каршында бөек Салих Сәйдәшев басып торган милли уку йортыбыз—гуманитар-педагогика университеты, атаклы Г. Камал театры янәшәсендәге, Тукайның үз һәйкәле һәм музееннан ерак булмаган бу кишәрлек һичшиксез бөек шагыйрь исеме һәм милли мәдәниятебез белән тыгыз бәйләнештә файдаланылырга тиеш. Матбугатта, бу урында "Болгар" кунакханәсе бинасы нәкъ элеккеге кыяфәтендә торгызылачак, дигән хәбәр күренеп киткән иде. Әйе, бинаның тышкы кыяфәтен, бигрәк тә Тукай яшәгән 40 нчы бүлмәне тулысынча кабатлаган яңа бина төзелү бүгенге фаҗигане өлешчә генә булса да җиңеләйтер иде. Бүгенге көндә бу җир кишәрлеге "Татнефть" карамагында, диләр. Әгәр шулай булса, без мәдәниятебезгә һәрчак хәерхаһ булган "Татнефть" ачык акционерлар җәмгыятенең югарыда әйтелгән тәкъдимне тормышка ашыруына ышанып калабыз.

## ИСЛАМ ФАКТОРЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге Россия делегациясе Согуд Гарәбстанына визит ясады. Делегация «Ислам конференциясе оешмасы» (ИКО) каршында эшләүче «Россия-Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең

дүртенче утырышында катнашты. Мәгълүм булганча, Россия белән Ислам илләре арасында мөнәсәбәтләр урнаштыруда Татарстан күпмедер дәрәҗәдә күпер ролен үти. Казанның элеккеге мэры Камил Исхаков, мәсәлән, Россиянең ИКОдагы даими вәкиле итеп билгеләнде. Ә Минтимер Шәймиев «Россия-Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең рәистәше.

Әлеге форум 2006 елда Россия һәм ислам дәүләтләре арасында тормыш эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә дә хезмәттәшлекне үстерү өчен киңәшләшү органы буларак оештырылган иде. Алдагы утырышлар Мәскәү, Казан, Истанбулда үтте. Минтимер Шәймиев житәкләгән быелгы делегация составында РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиленең беренче урынбасары Владимир Зорин, ТР Президентының халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе Тимур Акулов, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Госман хәзрәт Исхакый, Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин һ. б.лар бар иде.

—Соңгы елларда ислам дәүләтләре белән Россия элемтәсе даими үсештә. Моңа Россиянең Ислам дәүләтләре оешмасы конференциясендә күзәтүче статусында катнашуы да этәргеч бирде. Ике арадагы бәйләнешләрнең ныгуына Татарстан Республикасы, Казан шәһәре ныклы нигез булып тора. Ислам фәннәр академиясенең башкалабызда узган чираттагы утырышы, Ислам Үсеш банкы үсешенә багышланган Халыкара инвестиция конференциясе, «Алтын мөнбәр» кинофестивале моңа дәлил булып тора,—диде Минтимер Шәймиев.

Аның фикеренчә, «Россия—Ислам дөньясы» утырышының иң мөһим максатларының берсе—диннәр арасындагы каршылыкны киметү. М. Шәймиев дин тоту 80 ел дәвамында рәсми рәвештә тыелып килүдән соң, Россия территориясендә исламның нинди шартларда янаруы хакында сөйләде. «Без диннең мәңгелек булуына, аның кешеләр күңелендә саклануына инандык»,—дип билгеләп үтте ул. Республика Илбашы түбәндәге саннарны мисалга китерде: үзгәртеп кору елларына чаклы Татарстан территориясендә 23 мәчет эшләсә, хәзер аларның саны 1200 дән артып китә. Мәчетләрнең саны күпләп арту имамнар житмәү проблемасын китереп чыгарды. Бу эштә Төркия, Согуд Гарәбстаны һәм башка мөселман илләренең уку йортлары ярдәмгә килде.

Минтимер Шәймиев форумда шулай ук якындагы айларда көчәеп баручы дөнья кризисы «финанс» категориясеннән «икътисади»га күчәргә мөмкин, дигән шиген белдерде. «Бу очракта бөтен көчебезне тупларга кирәк булачак, һәм монда ислам дәүләтләренең уртак тырышлыклары хәлиткеч булырга мөмкин»,—диде ул.

Минтимер Шәймиев шулай ук Ислам Үсеш банкы рәисе Әхмәд Мөхәммәд Али белән очрашты. Татарстан Республикасы Президенты катнашында Ислам Үсеш банкы һәм Россия ислам мәгарифе, мәдәнияте һәм фәненә ярдәм күрсәтү фонды арасында үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү турындагы меморандум имзаланды.

### «АЛТЫН МӨНБӘР» ЖИҢҮЧЕЛӘРЕ

Халыкара "Алтын Мөнбәр" мөселман киносы фестиваленең дәрәҗәсе һәм абруе елдан-ел арта бара, быел фестивальнең ачылу һәм ябылу тантаналарына кунаклар аеруча күп килгән иде.

22 октябрьдә "Пирамида" мәдәни-күңел ачу үзәгенә җәелгән кызыл келәмнән Россия кинойолдызлары Ирина Мирошниченко, Александр Митта, Наталья Бондарчук, Анастасия Заворотнюк, Жанна Эппле, 12 яшеннән кинода уйный башлаган, безгә "Королева Марго" һ. б. фильмнар аша яхшы таныш атаклы француз актрисасы Изабель Аджани һ. б. үтте.

Ниһаять, "Алтын Мөнбәр"нең жиңүчеләре дә мәгълүм булды. Ислам динен пропагандалауга керткән өлеше өчен, "Ислам дөньясы" телекомпаниясе директоры, фестивальнең генераль директоры Зауди Мамиргов атаклы Ислам мәгърифәтчесе Муса Бигиев турындагы "И раскололся месяц" (режиссеры Батыр Баишев) фильмына махсус приз һәм акчалата бүләк тапшырды.

Ә халыкара "Тюрксой" оешмасы үзенең "Төрки халыкларның кинематографиясенә керткән өлеш өчен" махсус призын һәм акчалата бүләкне уйгыр халкының катлаулы язмышын гәүдәләндергән "На натянутом канате" (режиссеры Петр Лом, Канада-Норвегия) фильмына бирде. Болар икесе дә документаль фильмнар иде.

"Иң яхшы документаль фильм" номинациясендә бүләккә Австралиядән "Запрещенная ложь" (режиссеры Анна Броиновски) ия булды. Бу фильмга шулай ук Россия кино белгечләре һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясе дә үзенең махсус призын ирештерде. "Лицом к лицу" (Нидерланды-Франция) фильмының режиссеры Жерар Максимин документаль фильмнар арасында иң яхшы режиссер дип билгеләнде.

Кыска метражлы нәфис фильмнар арасыннан Яңа Зеландиядән "Кофе и Аллах" (режиссеры Сима Урале) фильмы иң яхшы дип табылды.

Тулы метражлы фильмнар арасыннан режиссер Нурания Жамалиның "Өч аяклы ат" (Айдар Хәлим әсәре буенча) нәфис фильмын төшерүчеләр төркеме (Эдуард Ситдыйков, Рәфкать Зыятдинов) иң яхшы оператор эше номинациясендә жиңүче булды.

"Джодха и Акбар" (режиссеры Ашутош Говарикер) фильмында баш рольне уйнаган, һиндстанның иң яхшы өч ир-ат актерларыннан берсе Ритик Рошан "Иң яхшы ир-ат роле" номинациясендә җиңү яулады.

Ә менә Иранның "Ми" для мамы" (режиссеры Рәсүл Муллагалипур) фильмында төп рольне уйнаган Гөлшифтех Фәраханинең "Иң яхшы хатын-кыз роле" номинациясендә беренчелеккә чыгуы гаҗәп тоелмады. Гөлшифтех бу бүләккә бер мәртәбә лаек булган иде инде.

Бөекбританиянең "Почти взрослая" (режиссеры Юзоф Али Хан) фильмының сценарие авторы Рона Мунро иң яхшы сценарий авторы дип табылды.

Иранның "Каждая ночь одиночества" фильмының режиссеры Рәсүл Садр Амелйп иң яхшы режиссер булып танылды.

Гран-прины, ягъни иң зур дәрәҗәдәге бүләкне быел ""Ми" для мамы" һәм "Джодха и Акбар" фильмнары бүлеште.

"Гран—прины кемгә бирү җәһәтеннән бәхәсләр күп булды, әмма 8 кешедән торган жюри бертавыштан шушы фильмнарның исемен атады",—диде жюри рәисе. Кыргызстанның халык артисты, СССРның Дәүләт бүләге иясе Болотбәк Шәмшиевнең үзен дә кино сәнгатенә керткән тинсез хезмәте өчен алтын статуэтка белән бүләкләделәр. Американың "Такси на темную сторону" (режиссеры Алекс Гибни) документаль картинасы "Кино сәнгатендәге гуманизм өчен" Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең махсус бүләгенә лаек булды.

Ә менә француз актрисасы Изабель Аджанинның фестивальгә һәм Татарстанга биргән бәясе һәркемнең күңеленә хуш килгәндер.

"Мин Казанга килгәндә Азия һәм Европа Көнчыгыш һәм Көнбатыш кисешкән ноктага баруымны белми килдем. Монда төрле милләтләр, конфессияләр дус-тату яшәвен күреп, мин сезнең республикагызны бөтен дөнья өчен тынычлык үрнәге буларак кабул иттем. Ә бу—иң мөһиме. Шуның өчен мин Казанны тынычлык өчен Нобель бүләгенә тәкъдим итәр идем", -диде актриса.

### ТАРИХИ ВАКЫЙГА

17 октябрь көнне борынгы Сембер каласы Ульянда тарихи вакыйга—бөек шагыйребез Кол Галигә һәйкәл ачылды. Татарстаннан читтә мәшһүр шәхесләребезгә һәйкәлләр бик сирәк торгызыла (Санк-Петербургта, Уральскида—Тукай, Оренбургта—Җәлил). Бу яктан ульянлылар күркәм үрнәк күрсәттеләр. Өстәп шунысын да әйтергә кирәк: шул көнне һәйкәл янында ук Татар мәдәнияте Үзәге дә ачылды. Үзәк 1958 елны салынган "Октябрь" кинотеатрының янартылган бинасында урнашкан.

Кол Гали һәйкәлен ачу—бөтеншәһәр бәйрәменә әверелде. Тантананы ачуда өлкә һәм шәһәр житәкчеләре катнашты. Ульян өлкәсе губернаторы Сергей Морозов һәйкәлне ачканда "бу һәйкәлне ачу зур тарихи мәгънәгә ия",—диде. Тантанага Россиянең татарлар яши торган төбәкләреннән—Уфа, Ижау, Чебоксар, Пенза һәм башка шәһәрләрдән вәкилләр күп килгән иде. Казаннан Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ренат Закиров житәкчелегендәге зур делегация катнашты. Һәйкәл ачу тантанасында бүтән ораторлар белән рәттән шагыйрьләр Равил Фәйзуллин һәм Мөхәммәт Мирза да чыгыш ясады. Һәйкәлне төзүдә һәм татар мәдәнияте Үзәген торгызудагы чыгымнарны Сембер Татар эшкуарлары күтәргән, меңләгән халык вәкилләре хәләл акчасын биргән, Татарстан тарафы да саллы өлеш керткән. Шул ук көнне өлкә администрациясенең Зур залында Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының күчмә утырышы үтте. Бу утырыш милли мәгарифне үстерү мәсьәләләренә багышланган иде. Кинәшмә-утырышта өлкә мәгариф системасында эшләүче җаваплы хезмәткәрләр, шулай ук Татарстан мәгарифенең житәкче вәкилләре катнашты. Кинәшмәне Ренат Закиров алып барды.

### БЕЗ—ЭНЦИКЛОПЕДИЯЛЕ ХАЛЫК

22 октябрьдә Татарстан Фәннәр академиясенең зур залында Татар энциклопедиясенең татарча 1 нче томы чыгу уңаеннан тәкъдир итү тантанасы үткәрелде. Анда галимнәр, мәдәният әһелләре, педагоглар, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Фәннәр академиясе президенты Ә. Мәзһәров үз чыгышында әлеге басманың дөнья күрүе республикабызның рухи тормышында зур вакыйга буларак кабул ителүе турында искәртте. Бу чыннан да шулай, чөнки Россия халыклары тарихында менә шундый универсаль энциклопедик томнар беренче мәртәбә басыла.

Татар энциклопедиясе институты директоры урынбасары, басманың җаваплы мөхәррире Г. Сабиржанов тантанада катнашучыларны 1 нче томның кыскача эчтәлеге белән таныштырды. Бу басмада җәмгысе 4 меңгә якын мәкалә, шул исәптән А һәм В хәрефенә кадәрге 1600дән артык персонаж, 1200 иллюстрация урын алган. Энциклопедик басма 6 томнан торачак. Рус телендә аның 3 томы чыкты инде, ә 4 нче томын әзерләү төгәлләнү алдында.

Тәкъдим итү тантанасында академик М. Госманов, Татарстанның халык шагыйре, ТФРның шәрәфле академигы Р. Фәйзуллин, Татарстанның халык шагыйре Р. Харис, мәдәният министры урынбасары Г. Нигъмәтуллина h. б.лар чыгыш ясады.

Аннары ТФА президенты Ә. Мазһаров, энциклопедик басмаларны югары сыйфатлы итеп бастыру эшен оештырганы өчен, "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексы генераль директоры И. Әхмәтҗановка академиянең Рәхмәт хатын тапшырды, 6 томлы энциклопедияне үзебез исән чакта чыгарып, аларны шушы залда тәкъдим итәргә язсын, дигән теләк белдерде.

*P.S. Энциклопедия томнарын Казанның Пушкин урамында (56 йорт) урнашкан Татар энциклопедиясе институтында һәм шулай ук институт янәшәсендәге (опера һәм балет театры каршында) китап кибетеннән сатып алырга мөмкин.*

### ТАТАР КИНОСЫ ҮСЕШ АЛАЧАК

Октябрь аенда Казанда татарстан кинематографистлары берлегенең IX съезды булды. Анда Татарстан кинематографиясенең үсеш мәсьәләсе күтәрелде. Шул уңайдан берлекнең рәисе Юрий Гвоздьның хисап чыгышы тыңланды.

Съездда мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты. Ул соңгы өч елда фильмнар төшерүне финанслауның өч мәртәбә артуын хәбәр итте. Әйтик, быел бу юнәлешкә 34 миллион сум бүлеп бирелгән. Кино төшерү тармагының киләчәге өметле, дип белдерде министр. Кыска метражлы фильмнар һәм сериаллар төшерү мөмкинлеге дә бар икән. Бу юнәлештә Рабит Батулла сценарие буенча фильм, Зөлфәт Хәким әсәрләре буенча сериал һәм Габдулла Тукайның 125 еллыгы уңаеннан фильм төшерергә заказ бирелгән.

Зилә Вәлиева Татарстан кино төшерү процессын активлаштыру уңаеннан "Алтын мөнбәр" халыкара мөселман кино фестиваленең йогынтысы зурлыгын аеруча ассызыклап үтте. Яшь кинематографистларның төрле илләрнең кино осталары белән очрашуы республикада фильм төшерү дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итәчәк, дип белдерде министр.

Съезд барышында җанлы фикер алышулар булды. "Татаркино" директоры Владимир Батраков, кинооператор Николай Морозов, режиссер Эдмас Үтәгәнов һәм башкалар берлек эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәрен керттеләр.

Татарстан Президентына мөрәҗәгатьтә съездда катнашучылар милли кинематография үсешенә юнәлдерелгән эшчәнлекләренә ышаныч һәм "Татарфильм" киностудиясен оештыруының якын арада гамәлгә ашачагына ышаныч белдерделәр. Шулай ук иҗади берлекнең бу максатлар өчен тәҗрибә, белем һәм осталыкларын кызганмауларын җиткерделәр.

Съездда ТР Кинематографистлары берлеге рәисе итеп Илдар Матуров сайланды. Шулай ук РФ Кинематографистлар берлегенең декабрьдәге съездына делегатлар тәгаенләнде. Съездда РФ Кинематографистлар берлегенең рәисе урынбасары Владимир Макеранец та катнашты.

### КОМСОМОЛ—БЕЗНЕҢ ТАРИХ

29 октябрьдә ВЛКСМның оешуына 90 ел тулды. Шул уңайдан Милли музейда "Яшьлегем минем—комсомол" дигән күргәзмә ачылды. Ул әлеге яшьләр оешмасы тарихына багышланган.

Күргәзмәдә комсомолның тарихы гражданнар сугышыннан башлана һәм XX гасырның сугыш конфликтлары белән тәмамлана. Шул чорның плакатлары, комсомол билеты, спецназ киеме аларның кыюлыкларын һәм батырлыкларын күрсәтеп тора. Мәгълүм булганча, тыныч вакытларда комсомоллар студентлар төзү отрядларына һәм яшьләр бригадаларына берләшкән. Күргәзмәдә тарихның бу сәхифәләре дә чагылган.

Күргәзмәне ачканда, комсомолның юбилеена багышланган китапны тәкъдим итү дә булды. "Летопись комсомола" китабын "Хәтер китабы" нәшриятендә икътисад фәннәре докторлары И. Рахманкулов, Ш. Агеев, тарих фәннәре докторы А. Иванов, комсомол ветераннары Г. Башкиров, Ю. Бехтерев, И. Милмөхәммәтов һ. б. редакцияләп чыгарган. Мәҗмугада 1917 елның апреленнән алып 2008 елның октябренә кадәр комсомол тарихының иң мөһим сәхифәләре чагыла.

### КӨРӘШЧЕ ӘДИП

Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Нурихан Фәттах гомере буе телебезнең сафлыгы, мәдәниятебезнең яшәеше, чын, асыл тарихыбызны халкыбызга кайтару өчен көрәшеп яшәде, шуңа күрә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында әдипнең 80 еллыгы уңаеннан уздырылган кичә дә "Мин көрәшергә булдым..." дип исемләнгән иде.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева кичәдә ясаган чыгышында язучы Нурихан Фәттахның тарихи роман жанрын үстерү белән бергә, рус, чит ил язучылары әсәрләрен тәрҗемә итүгә дә зур игътибар биргәнен әйтте.

—Нурихан Фәттах—70 нче елларда тарихи роман жанрына яңа импульс биргән әдип,—диде КДУ профессоры И. Гыйләҗев.—Өстәвенә, ул әдәби әсәр аша үзе яшәгән чорның сулышын чагылдырды. Билгеле булганча, 70 нче елларда татарда милли үзаң уяна башлый, татар кешесе тарихын, мәдәниятен барларга омтыла. Нурихан ага әнә шул үзгәрешне тарихи романнары аша күрсәтә алды.

Язучы Р. Батулла Н. Фәттахның бе-

ренче романнары белән үк әдип исемен яулавы турында әйтте. Аның балаларына ана телендә тәрбия биргән, татар булып яшәргә өйрәткән зирәк язучыларның берсе икәнлеген искәртте.

—Нурихан ага мәҗлесләрдә, җыелышларда күренмәде дияргә була,—диде шагыйрь Р. Миннуллин.—Ул танылырга омтылмыйча, тыныч кына үз эшен эшләде. Ә танылу аны әдип үзе исән чакта ук эзләп тапты.

Шагыйрь Р. Вәлиев язучы Н. Фәттахның татарның үзе кебек унган, белемле, зыялы чын язучы булуын әйтте. Татарстан китап нәшрияте директоры Д. Шакиров исә тиздән әдипнең "Аклан" романының китап булып дөнья күрәчәге турында ирештерде.

Кичәдә шагыйрьләр Р. Зәйдулла һәм Г. Морат, Н.Фәттах рухына багышлап язылган шигырьләрен укыдылар. Тамашачылар шулай ук әдипнең әсәрләре буенча Г. Камал театрында куелган "Сармат кызы Сәринә", "Кол Гали", К. Тинчурин театрында сәхнәләштерелгән "Әтил суы ака торур" спектакльләреннән өзекләр карады, җырчылар З. Сәхабиева, Р. Миндияр, Салават, "Фәридә-Алсу" дуэты башкаруында җырлар тыңлады.

## 90 ЯШЬТӘ ДӘ СӘХНӘДӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында әле мона хәтле бер генә артистның да 90 яшендә сәхнәгә чыгып уйнаганы булмаган. Үзенең октябрь аенда узган иҗат кичәсендә Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Вера Минкина Т. Миннуллинның «Гөргөри кияүләре»ндә 389 нчы мәртәбә Палый ролен башкарды. Вера апа Минкинаны тамашачы электән үк яратып каршылый иде. Бу юлы ул сәхнәгә чыгуга аягүрә басып алкышладылар. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова артистка Президент Указы нигезендә «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды.

Мәшһүр җырчы Илһам Шакиров заманында «Зәңгәр шәл» спектаклендә Вера апа Минкина белән бергә уйнаган. Әнә шул чакта башкарган «Бик ерakta идек без» дигән җырын ул яраткан артистына бүләк итте. Юбилярны тәбрикләргә Чистай районыннан якташлары да килгән иде. Камаллылар В. Минкинага ихластан, зур хөрмәт белән аның иңнәренә ап-ак оренбур шәле салдылар. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Ренат Тажетдинов аны «мәшһүр артист» дип атады. Тамашачы ул көнне танылган артистыбызга багышланган язмалардан тупланган китапны да күрә алды. Кичәне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова алып барды.

## АФӘРИН, МАЭСТРО!

С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында Россия, Татарстан һәм Казакъстанның халык артисты, ТР Дәүләт симфоник оркестры сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры, Россиянең Зур театры дирижеры Фуат Мансуровның 80 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы кичә булып үтте. Юбилей концертында "Виват, маэстро!" фестиваленә старт бирелде.

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Россия Зур театры йолдызларының катнашуы кичәгә аеруча тантаналылык өстәде. Тәбрикләү сүзендә М. Шәймиев Ф. Мансуровның кинкырлы шәхесенә олы бәя бирде. "Әгәр бүген республикабызда шундый оркестр һәм классик музыканы аңлый торган тамашачы бар икән, моның өчен Сезгә ихлас рәхмәт!"—диде Президент, юбилярның Татарстан дәүләт симфоник оркестрының башкару осталыгын камилләштерүгә куйган фидакарь хезмәтен югары бәяләп. Республика җитәкчесе кайчандыр "Огонек" журналыннан укылган хатирәләре белән дә уртаклашты. Мәкаләдә альпинизм буенча спорт остасы, 7 телдә иркен сөйләшүче, математика өлкәсендә бик өметле яшь талант Ф. Мансуровның үзен музыкага багышлавы турында бәян ителгән булган. Президент М. Шәймиев мәшһүр дирижерга республиканың иң югары бүләген—"Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен" орденын тапшырды.

Кичәдә юбилярны ТР Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Р. Кәлимуллин, Казан дәүләт консерваториясе ректоры Р. Абдуллин, Евразия альпинизм федерациясе рәисе Э. Мысловский да тәбрикләде. ТР дәүләт симфоник оркестры, Россиянең Зур театры йолдызлары чыгышы концертның асыл бизәгенә әверелде.

## СӘНГАТЬ БӘЙРӘМЕНӘ ӘВЕРЕЛГӘН КИЧӘ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Татарстанның халык шагыйре Роберт Миннуллинга 60 яшь тулу уңаеннан "Яшь бара бит, егетләр!.." дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

Тамашачылар хәтерлиләрдер, Р. Миннуллин үзенең иҗат кичәләрен монарчы да әледән-әле оештырып торды, һәм шигърият сөючеләр театрга бу юлы да гап-гади юбилей чарасына гына түгел, ә чын сәнгать бәйрәменә өметләнеп килгәндер. Чыннан да, рәсми дата уңаеннан әзерләнгән кичә үзенең асылы белән шигырь, җыр, сәнгать бәйрәменә әверелде. Бу табигыйдер дә, чөнки шагыйрьнең иҗаты күпкырлы: ул балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә бердәй

дәрәҗәдә унышлы эшли. Халык аны бик күп популяр җырлар авторы, шулай ук публицистика остасы буларак та яхшы белә. Ул үзенең әдәби эшчәнлеген иҗтимагый вазыйфалар белән тыгыз бәйләп алып бара, депутат буларак, парламентыбызда инде байтак еллар җаваплы постларда эшләп килә.

Әдәби-музыкаль кичәдә бәйрәмдарны Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, шулай ук Әзербәйҗан, Башкортстан, Мари Иле, Удмуртиядән килгән вәкилләр, республикабызның төрле оешмалары котлады. Шагыйрьнең композиторлар белән берлектә язылган җырларын Фәридә Кудашева, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Зөһрә Сәхабиева, Римма Ибраһимова, Идрис Газиев, Салават Фәтхетдинов, Айдар Галимов, Резеда Галимова, Рәсим Низамов, Айдар Габдинов, Илнар Сәйфиев һ. б.лар башкарды. Юбилярның шигырьләрен тамашачыларга Айрат Арсланов, шулай ук башкалабызның мәктәп укучылары, иҗат үзәкләренә йөрүче балалар ирештерде. Юбилей кичәсендә Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге оркестр, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең бию төркеме, башка иҗат коллективлары катнашты.

### ӘДИПНЕ ОЛЫЛАУ

10 октябрь көнне Казан дәүләт университетының актлар залында күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, язучы Тәлгат Нәби улы Галиуллинның 70 яшьлеге тантаналы рәвештә билгеләп үтелде. Бәйрәмне татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы профессор Искәндәр Гыйләҗев ачып җибәрде. Аннан соң КДУ проректоры Данис Нургалиев сүз алып, Т. Галиуллинга "Казан университетының атказанган профессоры" дипломын тапшырды. Юбилей кичәсендә галим-язучының гыйльми һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында зур абруйлы байтак шәхесләр чыгыш ясады: Татарстан фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров, Мәгариф һәм фән министры Наил Вәлиев, ТР Дәүләт советы депутаты, академик Индус Таһиров, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, ТГПУ ректоры Рәдиф Җамалетдинов, ТФАның вице-президенты Рүзәл Юсупов, Чаллы педагогия институты ректоры Фәйрүзә Мостафина, Алабуга педагогия институты ректоры Айдар Калимуллин...

Алар барсы да Тәлгат Галиуллинның Алабугада озак еллар ректор, Казан университетында декан, кафедра мөдире булып эшләгән чорларда фидакарь хезмәт куюын, Республиканың мәгариф һәм фән алгарышына зур өлеш кертүен билгеләп уздылар.

Туфан Миңнуллин Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлау хатын тапшырды һәм үз исеменнән кайнар котлады.

Әдипнең юбилей тантаналары шулай ук аның туган ягы Норлат төбәгендә дә зурлап уздырылды. Башта туган авылы Кычыткан-лыда, аннан шәһәр үзәгендә. Норлат муниципаль район башлыгы Наил Шәрәпов ачып җибәргән бу кичәдә Казан һәм Чаллы әдипләреннән—Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Айдар Хәлим, Газинур Морат һ. б. катнашты. Якташлары аны шәһәрнең мактаулы гражданы итеп кабул иттеләр һәм истәлек медале тапшырдылар.

***


Татарстан Республикасы дәүләтен һәм мәдәниятен үстерү өлкәсендәге зур казанышлары, нәтиҗәле әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен шагыйрь, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарының комиссиясе рәисе **МИҢНУЛЛИН Роберт Мөгаллим** улы "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* **Кышкы манзара**.

*Дүртенче биттә:* язучы **Рәмзия Габделхакова**.

**Ниһаять!**




Татар энциклопедиясенең
ана телебездә чыккан I томы

*Китап турында мәгълүмат шушы сандагы*
*"Без—энциклопедияле халык" дигән хәбәрдә бирелгән (189 бит).*



Рәмзия Габделхакова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)